ISSN 0206–4189 12+
Индекс 73210

# Казан утлары

7.2014



# БУ САНДА:

**Гүзәл СӘГЫЙТОВА:**




*Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы спектакленең премьера афишасы. 1939 ел.*

«Көтмәгәндә Литинский, торып: «Татар операсы булачак, аны Нәҗип Җиһанов язачак, ә либретто авторы — Әхмәт Фәйзи», — дип әйтеп салды һәм, миңа иелеп: «Язам дип әйт», — дип пышылдады. Мин көтелмәгән бу яңалыктан дулкынланып, куркып кына: «Әйе, опера булачак», — дип җавап бирдем», — дип искә ала Җиһанов...»

163

## КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ

**Рөстәм ЗАРИПОВ «Милициянең йөз кызыллыгы»**



«...Ике пләмәш юрист булырга җыена минем, укырга кергкән өчен дә буш итмәдек, сессия барышындагы имтихан-зачётлар өчен дә кыркыштыра торалар. Димәк, яңа пешкән хокук сакчыларының беренче адымы, остазларының шәхси үрнәгенә ияреп, белем эстәгәндә тоткан чыгымнарны кайтару икән, аклап булмаса да, аңлап була торгандыр?.. Ә башланган эш — беткән эш. Әйткән ди бит бер прокурор, безнең хезмәт хакы ташка үлчим, әле ярый отпускнойлар зур, дип...»

97

КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Әмиржан МОТАЛЛАПОВ. Гамь. *Роман.* ........ 3
Газинур МОРАТ. Әкиятне башлыйк янабаштан... *Шигырьләр.* ........ 26
Зиннур ХӨСНИЯР. Гарасат. *Роман.* ........ 31
Фәйрүзә МӨСЛИМОВА. Мизгелләр елларга биргесез. *Шигырьләр.* ........ 92
Чыңгыз МУСИН. Шигырьләр бит җирдә языла. *Шигырьләр.* ........ 140

КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ

Рөстәм ЗАРИПОВ. Милициянең йөз кызыллыгы. ........ 97

ТАРИХ

Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ. Беренче Бөтендөнья сугышында Алманиядә мөселман әсирләре. ........ 146

ФИКЕР

Флёра ХАННАНОВА. Чорлар үзгә – мәсьәләләр уртак. ........ 152

ХӘТЕР

Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ. Шуның белән шул... Вокзалдан язам. *Мемуарлар.* ........ 159

СӘНГАТЬ

Гүзәл СӘГЫЙТОВА. «Качкын». *(Татар опера сәнгатенә нигез салынуга 75 ел).* ........ 163

ДИН ҺӘМ ТОРМЫШ

Рабит БАТУЛЛА. Мәгънә. *(Коръәндәге могҗизалар).* ........ 166

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. *Сәхифәне Рәйсә МУСАБӘКОВА алып бара.* ........ 173

ШАЯН СӘХИФӘ

Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ........ 176

АК ҖИЛКӘН

Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА. *Шигырьләр.* ........ 179
Алсу НУРГАТИНА. Сынаулар. *Повесть.* ........ 182

«Казан утлары» архивыннан. *Сәхифәне Равил ФӘЙЗУЛЛИН алып бара.* ........ 144
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ........ 188

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
ачык акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст.1618).*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.5).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.06.2014, график буенча 30.06.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1769. Тираж 3300.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел



Әмирҗан
Моталлапов

# ГАМЬ[1]

РОМАН

## Беренче кисәк

Сугыш тәмамланганда Рәсим унҗиде яшьлек егет иде. Атасы Сафаны фронтка озаткач, алар, сеңлесе Хамия белән, анасының төп терәге булып калдылар. Рәсим кечкенәдән колхоз эшенә катнашты. Исәя төшкән саен хезмәтнең саллырагын тапшыра тордылар. Күрше Тимәк авылындагы җидееллык мәктәпне тәмамлагач, район үзәгендәге урта мәктәптә укый башлаган иде Рәсим. Ананың берьялгызына тормыш йөген тарту авырая төшкәч, тугызынчыны укып чыгу белән, мәктәпне ташларга уйлады.

— Хаталанасың, улым, укып бетерергә кирәк иде, бер генә ел калды бит, — диде Фәния, улының нияте белән килешәсе килмичә.

— Сиңа авыр. Сугыш беткәч, уку җае чыгар. Ана кадәр колхозда эшли торам, — диде егет, карарыннан чигенергә теләмичә.

— Хәзер берәүгә дә җиңел түгел. Түзәр идек әле... Калган эшкә кар ява, укудан бөтенләй читләшмәсәң ярый ла, — дип ана үзенекен тукыды.

— Әнкәй, кайгырма. Мина, бәлки, укыган чаклысы да житкәндер. Хамияне укытырбыз. Аннан хикмәт чыкмасмы әле.

— Чыгуын чыгар... Тик кыз бала — кеше кешесе. Канатлы кош кебек. Вакыты життеме — оядан оча да чыгып китә, — диде ана, Хамиянең төп йортта вакытлы гына икәнлегенә ишарәләп.

— Сугыш бетәр, әткәй кайтыр... Ике уйлап тормастан укырга китәрмен. Бәлки, техникумга керермен, — диде Рәсим, анасын юатырга теләп.

— Хәерле булсын... Үзенә нәрсә кирәген аңларлык яшьтә инде син. Яңадан, җилкәң кызмый башлап, үкенергә калмасын. Искә төшәр — соң булыр, — диде Фәния, үзалдына сөйләнгәндәй, тыныч кына.

— Үкенмәм, әнкәй. Сугыш беткәч, михнәт чигү онытылыр әле. Теләге булганнар, шәт, үз юлларын табар. Мин дә төшеп калмам.

[1] Журнал варианты

Әмиржан МОТАЛЛАПОВ (1934) — *прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк иясе. «Яшьлегем кайтавазы», «Бал сатучы Төлке», «Абыну», «Шобага» һ.б. китаплар авторы. Актанышта яши.*

— Амин! Шулай була гына күрсен... Икегезне дә укытасым килә минем. Авылда калып, ат койрыгына карап, гомер уткәрмәссең бит. Сәләтең бар. Укырга тиеш син, шуны онытма, — диде ана, соңгы сүзен әйтеп.

Рәсимдә гәп куерту исәбе юк иде.

— Онытмам, әнкәй, — дип, анасы белән килешкәнлеген генә белдерде.

Мәктәпне ташлыйм дигәч, әнкәсе ачуланыр, чарага куймыйча чәкәләшер дип уйлаган иде Рәсим. Аның болай тиз ризалашуына гаҗәпләнебрәк тә куйды.

...Фәния укуга үзе дә хирыс иде. Тормыш авырлыгы аркасында гына җиде сыйныфтан ары китә алмады. Яшәү рәвеше рәтләнер дә укуны дәвам итү мөмкинлеге килеп чыгар дигән өметтән аерыла алмыйча, байтак еллар яшәде Фәния. Ике баласы тугач та ышанычы кимемәгән иде хәтта.

Берәр шәһәр егетенә кияүгә чыгып, ияреп китәргә иде, дип тә хыялланды ул яшь чагында. Анда яшәсә, әшли-әшли уку мөмкинлеге дә чыгар иде, дип уйланды. Зур булмаган Аланбаш авылында колачлы хыяллар белән яшәгән, укырга сәләтле, дәрәҗә яратучы кыз барлыгын белүче шәһәр егетләре генә күренмәде. Сафадан башка берәү дә хатынлыкка алырга тәкъдим ясап сүз катмады... Бер-бер артлы өч бала туды. Тик соңгысының гына гомере кыска булды. Фин сугышы кабынып китәр алдыннан гына биш яшьлек кызларын җирләделәр. Кызамыктан вафат булды сабыйкай. Мондый кайгы бер аларга гына килмәде, шул ук елны авылдан алты баланы җир куенына салдылар...

Сафа теше үтмәстәй планнар корып яшәмәде. Буй җиткергәч, шәһәргә юл тотты. Кайткач өйләнде. Колхозга керделәр. Үзе дә күмәк хуҗалык эшенә чумды. Авылда яшәп, шушында эшләүдән башка чара барлыгын уйлап баш ватмады. Күндәмлеге, гаделлеге өчен аны авылдашлары ихтирам итте. Фин сугышыннан исән-сау урап кайткач, Сафаны икенче бригадага җитәкче итеп сайладылар. Герман сугышына шушы хезмәтеннән китеп барды.

Фронтта да риясыз сугышты Сафа. Канкойгыч бәрелешләрдә күп тапкырлар катнашты, ике тапкыр яраланып, госпитальдә дәваланды. Җәрәхәте артык катлаулы булмаганлыктан, аны кабат фронтка озаттылар. Күптән түгел генә хаты килеп төште. Ул анда:

«Белоруссияне азат итү сугышлары бара. Дошманны озакламый сәүит җиреннән куып чыгарабыз. Тәмам дөмеккәннәрен генә күреп булса иде инде...» — дип язган иде.

Кара төннең кай мәлендә күзен ачса да, Фәния Ходайдан иренә исәнлек бирүне теләп ялвара. Авылдан киткән ирләрнең яртысына «үлде» хәбәре алынды инде. Бөтенесе дә кырылып бетәргә димәгән, кемгәдер кайту фарыздыр бит?!.

***

1942 нче ел башында Аланбаш авылы бер гаиләгә ишәйде. Гаилә зур түгел-түгелен: ана һәм кыз. Сугыш башлангач, Украина якларыннан җибәрелгәннәр. Ульян, Самара, Нижгар өлкәләре аша узып, никтер ул тирәләрдә төпләнмичә, Татарстанга килеп чыкканнар. Сугыш барган җирләрдән күченеп килгән берничә гаилә авылда болай да яши иде инде. Алары хәзер үз кешеләр кебек, халык белән уралышып яшиләр, өлкәннәре колхозда эшли.

Яңа килүче гаиләне дә тарсынмый кабул итте авыл. Эшче көчкә кыргынлык кичергән вакытта бер кешегә артуны да хәтәр зур казанышка санадылар. Әле алар икәү бит, кызы да кул арасына керерлек.

Яңа гаиләне Рәсимнәр күршесендәге ялгыз карчыкка урнаштырдылар. Хатын Софья, ә кыз Оксана атлы иде. Татарчага охшатып, аларның исемнәрен якын кабул иттеләр.

— Суфия дученка, родыгызда татарчуклар юк идеме? — дип ин әүвәл фатир хуҗасы Рәсилә түти кызыксынды.

— Каян беләсен? Бәлки, булгандыр да. Нәсел тамырынын очына кем чыгып беткән? — дип җавап кайтарды Софья. Урысча әйтте. Рәсилә түти шулай да төшенде. Марҗа халкы белән аралаша алуына сөенеп тә куйды әле. «Бед өйдәшем белән урыччa рәхәтләнеп сүләшәбед», — дип күрше хатыннар алдында мактанып та алды.

Өлкәннәр Софьяны «Суфия сеңлем», яшьрәкләр «Суфия апа» дип атап йөрттеләр, кызга «Үксинә» исеме беректе.

Унөч яшьлек Оксана шук һәм тере кыз иде. Әнисенә ияреп колхоз эшенә йөрде. Мәктәптән кайткач, кышкы салкыннарда авыл хатыннары белән басуга кар тотарга, салам эскерте төпләрен көрәргә чыкты.

Авылга килүенә биш-алты ай узуга, Оксана татарча рәхәтләнеп аралаша башлады. Алтынчы сыйныфны украинча тәмамлап килгән кыз, Рәсимнен сеңлесе Хамия белән бер партада утырып, җиденче сыйныфта татарча укый башлады. Тимәк мәктәбенә көн саен барып-кайтып йөрделәр.

Кызны беренче тапкыр күрү белән Рәсим үзе дә аңламаслык халәт кичерде. Телдән әйтү түгел, уйларга оялырлык хисләр биләп алды йөрәген. Бу тойгы анын тынычлыгын югалтты. Оксананы очратканда гына түгел, анын турында уйлый башласа да йөрәге ашкынып тибәргә керешә, хисләреннән үзе оялып, йөзе кызыллыкка күмелә.

Тәүге мәхәббәтнен йөрәк тилертерлек сихерләү көченә ия икәнлеге турында китаплардан укыганы да, өлкәннәр авызыннан ишеткәне дә бар. Нәкъ шундый халәт кичерә Рәсим. Димәк, анын йөрәгендә дә беренче мәхәббәт ялкыны дөрли башлаган!

Мәхәббәтнен көче бу тиклем буладыр дип Рәсимнен уена да кергәне юк иде. Сихерләдеме сон әллә бу украин кызы аны? Тынгылыгын алды, йокысын качырды, тамактан яздырды, уйга батырды — күз алдында үзгәрде егет.

Ана йөрәге улындагы үзгәрешләрне сиземләде. Башта, укуын ташлавына үкенәме әллә, дигән фикердә иде, тора-бара, яшьлек кичерешләре үз башыннан да үткәнгә, улынын йөрәгенә сөю дигән садә хис кереп оялавын төшенде ул. Бу тилерүдән берәүнен дә котыла алмавын беләнлектән, Фәния улынын сагышка бату сәбәбен сорап вакланмады. Кирәк тапса, үзе чишелер, дип уйлады.

Нигә төпченсен инде?! Тәүге мәхәббәт кемнәргә килмәгән дә кемнәрдән үтмәгән?! «Бу «чир» ничек килеп кагылса, шулай китеп барыр да», — дип фикер йөртсә дә, Рәсимнен кем өчен янып-көеп йөрүен беләсе килде ананын. «Үзенә тин микән? Юк-барга төшкән эт гыйшкы төсле генә түгелме? Башын арзанлатып йөрмәсен тагын», — дигән икеләнүләрен ачыклыйсы килә иде Фәниянен. Рәсимнен күзе күршедә яшәгән украин кызы Оксанага төшәр, дигән уй Фәниянен башына барып җитми иде әле...

***

...Фәния гаиләдә бердәнбер кыз иде. Иркә үсте. Кием-салымга мохтаҗлык кичермәде. Бөтү йөрттеләр. Төскә-биткә, буй-сынга да төшеп калганнардан түгел иде. Зәңгәр күзле, соргылт чәчле, нәзек билле, зифа буйлы кыз егетләр күнелендә беренче караштан ук урын алырга лаек иде.

Вакыт үтә торды, әле дә булса сөелүнен тәмен ихлас татымаган чибәр кыз гомер баскычларыннан күтәрелә бирде. Егерме биш яшен каршыларга торганда, ата-анасы бер-бер артлы үлеп китте. Өйдә берьялгызы торып калды Фәния. «Ихата-кураны туздырып, авылдан башны алып олагыргамы әллә?» — дигән фикер дә еш килде анын башына. Тик тәвәккәллеге җитмәде.

Егерменче-утызынчы еллар тирәсендә авылдан-авылга йөреп киез итек басучылар, кием-салым тегүчеләр, калай җиһаз ясаучылар еш күренәләр иде. Көннәрнең берендә Аланбашка аталы-уллы тегүчеләр килеп чыкты. Алар Фәнияләрдән ерак түгел генә яшәүче карт белән карчыкка урнаштылар. Шуларда торып, авыл халкына кием текteләр.

Тегүчеләр озакламый китәләр икән, дигән хәбәр ишетелгәч, Фәния осталар янына керде. Күп еллардан бирле сандыкта яткан, атасы ерак ярминкәдән сатып алып кайткан затлы сукнодан пинжәк тектереп каласы килде кызның. Китәргә ашыксалар да, Фәниянең соравын кире какмады осталар. Тегеп бирергә ышандырдылар.

Яшь тегүченең күзен дә алмыйча томырылып каравына оялып, тегү үлчәмен алганда үзен ничек тотарга белмичә аптырап бетте Фәния. Өлкән тегүче: «Булды», — диюгә, чыгып таю ягын карады...

Кара тиргә баткан иде ул. Өенә кереп, көч-хәл белән чишенде дә, әллә нинди авыр эш башкаргандай ару тоеп, озын сәкегә утырды. Нишләп мондый хәлгә тарыды соң әле ул? Мондый хикмәтнең гомерендә булганы юк иде бит! Оялуданмы? Бәлтерәп төшәр яше түгел ләбаса!

Сәбәбе бар икән! Тегүче егет бер караштан анын күнеленә кереп оялады. Менә кайчан икән анын дуамалланыр чагы! Мәхәббәт дигән өттергеч хис биләп алды анын йөрәген. Унҗиде-унсигез яшьлек кызлар да егет турында уйланып болай тилермәс. Нишләп әле үзен кулга алалмый соң ул? Сазаган кыз югыйсә!

Каяндыр килгән, кемлеген белмәгән егеткә бер күрүдә карап капланыр вакыты күптән артта калган. Фәниянең йөрәк белән түгел, акыл белән пар сайлар вакыты. Кинәт кабынган хисләр томанында югалып калу үкенеч белән тәмамланырга да мөмкин бит...

Шуны аңлый торып та, Фәния акылы белән идарә итү куәсен югалтты. Күршеләрдә теге егетне күреп чыкканнан бирле сихерләнгән бәндә кыяфәтендә йөри ул. Үзен кая куярга урын тапмый...

Төн саташып, уяулы-йокылы узды. Ул гадәттәгедән озын тоелды. Иртән түнгән баш белән торды. Баш, җилгә эленгән буш тубал шикелле, туктаусыз гөжли. Кичәге хисләр дә томан аша күренгән шәүлә шикелле генә. Яшь тегүченең көйдергеч карашы да йөрәккә кадамый төсле.

Көн барыбер егет турындагы уйлар белән кайнашып узды. Алардан арынырга вакыт та табылмады. Култык астына төенчек кыстырып, өйләгә чаклы егет үзе килеп керде. Типчелгән пиджәкне кызга кидереп карарга диюе икән.

— Иртәгә үк әзер итәм. Үзгәртәсе урыннары килеп чыкмасын, шуна кидертеп карарга кердем, — дип егет Фәниянең иненә пинжәк өлгесен салды.

Егет кулы кагылу белән кыз ихтыяр көчен югалтты, тез буыннары хәлсезләнде, гәүдәсе чайкалып, авып китүдән чак-чак тыелып тора башлады. Иелгән башын күтәрмәде. Тимгелләнеп кызарган йөзен егеткә күрсәтәсе килмәде.

— Хәтәр килешле чыгачак. Сезнең зифа гәүдәгә ятып кына торачак, — диде тегүче, Фәния өстендәге киемне сыпыргалап.

— Кешелеккә киярлек булса иде инде, — диде кыз, ишетелер-ишетелмәс кенә.

— Ничек кенә әле! Авыл кызлары көнләшерлек булачак.

— Исемең Фәния бит әле? — диде егет, кинәт кенә.

— Әйе.

— Минеке — Фаяз. Исемнәрне әйтеп сөйләшик. Бер чоргылардыр бит без.

— Мин олырактыр, — диде Фәния, кул селтәп.

— Ничә яшь?

— Күп инде, күп...

— Чамасы бардыр бит? Минем сыман утызда түгелдерсең әле?

— Алай ук юк.

— Тормышланмадыгыз? Шулаймы?

— Әйе.

— Утызга җитеп, мин дә өйләнергә җитешә алмадым.

— Әй лә! — диде Фәния, егет әйткәнгә битарафлык күрсәткәндәй. — Күп сайлагандырсың... — Үзе исә кызыксыну белән егеткә күтәрелеп карады. Кем белә, бәлки аның бәхете шушы тегүче егет кулындадыр?! — Мир арасында йөрүчеләрне кем белеп бетергән? Өйдә хатыннары була торып та егетләнеп йөрүчеләр бардыр, — диде Фәния, Фаязның тел төбен тартып карау исәбе белән.

— Өйдә хатын калдырып, айлар, еллар буена сукбайлыкта йөреп булмый. Өйләнсәм, мин һичшиксез, утраклыкка күчәм. Чит өй идәнендә, как сәкедә йоклау мина да рәхәт түгел, — диде егет, авыллар гизеп йөрүнең читенлеген төшендерәсе килеп.

— Нишлисең, икенең берсе инде... — «Йә акча эшлисең, йә кул кушырып өйдә утырасың», — дигән мәгънә аңлатып әйтүе иде кызның.

— Шулай инде, — дип егет аның белән килеште.

Бер сәгать тирәсе гәпләштеләр. Бер-берсе белән күпмедер танышып өлгерделәр. Фаяз бирегә кергәнче үк кызның ялгыз яшәве турында өй хуҗаларыннан ишеткән иде инде.

— Берьялгызың тормыш куу җиңелдән түгелдер, — дип әйтеп куйды Фаяз, кызның өйләнешүгә карата булган фикерен чамалау өчен.

— Юньле егетләр карамый, әшәкеләре белән бәйләнәсе килми, — дип, кызлар тарафыннан еш кабатлана торган сүзләр белән җавап бирде Фәния.

— Шушы чибәрлегең белән ялгыз яшәвенә аптырыйм мин. Сәбәп үзеңдә дә бардыр, мөгаен. Ризалаш кына, сиңа бүген тотып өйләнергә әзер мин.

— Кызларга авыл саен әйтелә торган сүзеңме бу? — дип көлемсерәде Фәния.

— Һич юк. Андый сүз белән шаярырга ярамый. Күпме сайласам да синнән артыкны таба алмам, дип уйладым. Син мина ошыйсың...

— Кай арада кабынып өлгерде соң әле андый хис?

— Сине беренче тапкыр күрү белән дөрләде. Өй хуҗалары да сине мактадылар. Әгәр килешәбез икән, өйләнешү мәсьәләсен озакка сузу ниятем юк.

Фәния җавап кайтарырга ашыкмады. Каяндыр кемдер килер дә йөрәген яулар, дигән хис аны беркайчан да ташламады. Хыялының чынга ашуына икеләнсә дә, ул мәлнең килерен көтте... Шул көн тудымы әллә? Хыялда көткән егет әллә шушымы?..

— Нигә эндәшмисең? — дигән сорау белән егет аны уйларыннан бүлдерде.

— Нәрсә әйтим? Бер сөйләшүдә хәл итә торган мәсьәлә түгел бит. Бераз уйларга кирәк...

— Уйлый тор, сөйләшербез. — Фаяз, алып кергән төенчеген күтәреп, чыгып китте.

...Кечке аяк юлы басылгач, Фәниянең ишеген шакыдылар...

— Кем бар?

— Мин!..

Кеlә күтәрелде, Фаяз эчкә узды. Бу төнне Фаяз Фәния кочагында үткәрде...

Тегүчеләр бер атнадан икенче авылга күченделәр. Киткәндә егет Фәнияне кисәтте:

— Безнен эш артык озакка сузылмас, тиздән китәрбез. Кайткач, бераз әзерләнми булмас, шулай да озакка сузмабыз. Ай эчендә сине килеп алырмын. Әзер тор. Тоткарлык килеп чыкса, хат аша хәбәр салырмын, — дип ныклап торып ышандырды.

Инанды Фәния. Ул үзен Фаяз хатыны итеп тоя иде инде. Тегүченең тасма теленнән коелган тәмле сүзләргә йөрәк тиз эреде. Үзе белән идарә итә алмаслык хәлгә төште Фәния. Беренче төнне үк кызлык намусына хыянәт итте. Фаязлар авылдан киткәнче ир белән хатын булып яшәделәр...

Фәния егеткә жаны-тәне белән ышана иде. Күңеленә мәкер ташы төйнәп, барган бер авылында кызлар алдап йөри торган залим бәндә дип уена да кертә алмый. Елдамлыгы бар-барын, тик дуамал бәндәгә тартмаган...

Егерме көн чамасы вакыт узгач, Фаяз килеп чыкты. Туп-туры Фәния янына кагылды. Күптән киткәннәрдер, дип исәпләп йөри иде Фәния, житешә алмаганнар икән.

— Кием тектерүче күбәеп китте. Тегесе дә, монысы да үтенеп сорый, тынламыйча булмады, — дип аңлатты тоткарлану сәбәбен. Иртәгә юлга кузгалачакларын, китәр алдыннан Фәнияне күрү, теге чакта әйткән сүзләренең хаклыгын раслау өчен йөрүен әйтте.

— Килеп алуыңны көтәм. Бу хәлдә мин бүтән кемгә кирәк, — диде Фәния, бәйләнышның тирәнгә китүен искәртеп.

— Син кемгә дә кирәк. Әртисләр чибәрлеге бит синдә. Кайсы гына егет кызыкмас!

— Хатын кешегә сикереп төшмәсләр.

— Кыз син! Бәби китермәс борын хатыннар арасына керәләрмени?

— Анысына да озак түгел...

— Әллә әзерләнәсең дә?

— Шөкер, әлегә юк. Корсак күтәреп, иргә бармаска иде инде.

— Дөрес уйлыйсың...

Фаязның иненнән тау төшкәндәй булды. Чәй эчәргә дә теләмичә, китәргә ашыкты. Юлга җыеныргa кирәклеге белән аңлатты кабалану сәбәбен. Кагылуының төп максаты Фәниянең авырга узу-узмавын белешү иде. Ярый, эш катлаулыга китмәгән. Өйләнмичә кала алмас иде югыйсә. Ә хәзер аяк-кул чишүле аның...

Егет Фәния яныннан канәгатьләнү тойгысы белән чыгып китте. Бүтән аяк басмас ул бу тупсага. Ятим-җилпе кыз белән азалануга атасының риза-бәхиллеге юк. Аның ихтыярына каршы бара алмый бит инде ул. Фәния көтәр-көтәр дә Фаяз дигән егетнең дөньяда барлыгын онытыр. Икенчене табар...

Айлар узып, Фаяздан бернинди хәбәр килмәгәч, Фәния төп башына утырып калганлыгын чамалады. Болай да кимсенгән күңелгә тагын хәсрәт өстәлде. Өмете чәрдәкләнде, ир-атка карата ышанычы кимеде... Бер күрүдә нишләп капланды соң Фаязга? Сихерләдеме әллә?

Авыр, бик авыр иде Фәниягә. Көннәр, айлар үтте. Акрын узгандай тоелса да, вакыт дигән галиҗәнап үз адымы белән бара торды, йөрәк яраларын ямый бирде. Фәния үз язмышы белән ризалашып яшәвен дәвам итте. Ул хәзер теләсә нинди иргә хатынлыкка барырга риза инде...

Күмәк хуҗалыклар оештыру турында мәш килеп йөргән көннәрнең берсендә авылга Сафа исемле егет кайтып төште. Тулы ятим иде ул. Атасы ягыннан чыбык очы саналган түтәсенә тукталды. Шунда яши башлады.

Авылга аяк басуының икенче көнендә үк Сафа Фәниягә кагылды. Бераз

кызмача иде. Кыюлык өчен, тел «ачкычы» урынына «чеметкән» иде егет. Иркен сөйләште ул. Кызның тормыш-көнкүреше белән ныклап кызыксынды. Үзенең сукбайлыкта узган тормышы белән дә таныштырды.

— Ил гиздем, бәхет тапмадым. «Кая барсаң да кара сакалың үзеңнән калмый», дип, минем кебекләр әйткән. Вакыт үтә, яшь бара, әмма бәхеткә юлыгып булмый. Кайда йөри торгандыр ул? — диде Сафа, йодрыгы белән өстәл өстен җинелчә төеп.

— Һәркемнең бәхете үзе белән. «Агыйделнең аръягында — бер энәгә бер сыер», дигәнгә алданып йөрисе юк, — диде Фәния, егеткә акыл биргәндәй.

— Мин юк җирдә рәхәт яшиләрдер кебек тоелды. Шундый урынны юлладым. Хәзер аңладым: бәлтерәп йөрисе калмаган.

— Авылда төплән.

— Сыеныр урын юк шул... Бәлки, икәү союз төзербез?..

— Нинди союз?

— Бергәләшү... Син дә ялгыз, мин дә ялгыз, син дә ятим, мин дә ятим — кушылыйк, бер булмаса!

— Чыннан да, без игезәк язмыш кешеләре икәнбез ләбаса! Синең тәкъдимең хакында уйлашырга ярый торгандыр, — диде Фәния, кыюлана төшеп.

— Уйлап вакыт үткәрәсе юк. Авыл советына барабыз да язылышабыз.

— Хәзер үкмени? — диде Фәния, көлемсери төшеп. Сафа шаярта дип уйлады ул.

— Хәзер барабыз.

— Иртәгә чаклы көтик булмаса. Төн чыкканчы акылың үзгәрүе бар.

— Үзгәрмәс. Мин синең ризалыгыңны алырга өметләнеп килдем.

— Уйларга вакыт бир, Сафа. Әлегә төпле фикерем юк.

— Уйлан, тик сузма.

— Тырышырмын...

...Сузмадылар. Бер атна дигәндә Сафа Фәния янына күчеп килде. Шулай итеп, авыл бер гаиләгә артты...

***

Рәсим юл буе уйланып кайтты, әмма төпле карарга килә алмады.

Колхозда калу иде аның исәбе. Авылда эшләсә, гаиләгә ярдәмем күбрәк тияр, дип исәпләде. Тәкмәк мәктәбе директоры Саттаров абыйсы ана укытучылык хезмәтен йөкләмәкче.

— Әйбәт укыдың, сәләтең бар, синнән бер дигән укытучы чыгачак, — диде директор, сугышка алынган математика укытучысы урынына килергә димләп.

Егет көтелмәгән тәкъдимнән аптырап калды. Укытучы булырмын дип күз алдына китергәне, язмышымны мәктәп белән бәйләрмен, дип уйлаганы юк иде аның.

— Минем белем белән генә ул фәнне тартып булырмы соң? — дип икеләнеп сорады Рәсим, директор тәкъдименә каршы бүтәнчә җавап таба алмыйча.

— Булдырырыңа ышанганга күрә дә сине чакырттым. Мөгаллимлек хезмәтенә күңелең ятуы кирәк. Алынып кара, охшап китсә, җәйгә чыккач педучилищега экстерн тәртибендә имтихан тапшырып, документ алырсың, тулы хокуклы укытучы булып китәрсең. Ары таба да уку теләгең туа икән, институтка ухталып карарга була, — дип үгетләде егетне директор.

Рәсим колхозда эшләү нияте белән укуын ташлавы турында әйтмәде. Гаиләне алып бару авырлыгына сылтады. Мәктәпкә урнашуына әнкәсе, әлбәттә, каршы килмәячәк. Акчалы хезмәт бит, граммнар белән исәп-хисап

ясала торган арзанлы хезмәт көне түгел. Укытудан гаилә өчен ярдәм күбрәк киләчәк, билгеле.

— Сезнен тәкъдимгә нәкъ бу мәлдә генә кырт җавап бирергә мин әзер түгел. Әнкәй белән сөйләшеп карыйм әле, ул нәрсә әйтер? Ризалык бирә икән — мин каршы түгел, — диде Рәсим, соңгы фикерен белдереп.

Ике-өч көн эчендә төпле фикергә килергә килештеләр. Озакка сузарга ярамый, укулар башланырга санаулы көннәр калып бара. Рәсим ризалык белдермәсә, икенче укытучы юллау өчен вакыт кысылып килә...

Рәсим өйгә кайтып, авызын ачарга өлгергәнче, ана телгә килде:

— Синдә нинди йомышлары калган? — дип кызыксынды, улы бусагадан атлап керүгә үк.

— Директор эш тәкъдим итә.

— Кем итеп?

— Укытучы...

Рәсим шаярта дип уйлап, ана әйтергә сүз таба алмыйча торды.

— Чын әйтәсенме? — диде улының җавабын кабат ишетәсе килеп.

— Әйе. Тик синең белән киңәшмичә торып, ризалык бирәсе итмәдем.

— Ышаныч белдерәләр икән, бар гына, улым, — диде Фәния, нindидер горурлык белән.

— Син ничек әйтсәң, шулай булыр, әнкәй...

Бу сүзләр ананы янә куандырды. Улының үзен санга сугып шулай диюенә эреп төште ул.

— Минем бер каршылыгым юк, улым...

Мәктәпкә урнашудан баш тарту турында уена да кертми Рәсим.

Тимәккә йөреп эшли башласа, ул көн саен Оксананы күрәчәк...

Август түгәрәкләнеп килә. Тиздән — сентябрь башы. Уку ае саналса да, ул балаларны колхозда эшләтеп узачак. Елдагыча, һәр бала үз авылында хезмәт куячак. Аланбаш балаларына җитәкчелек һәм күзәтчелек итүне Рәсимгә йөкләячәкләр. Егет көн саен укучылар белән булыр, көн саен Оксананы күрер...

...Рәсим урамга чыкты. Кояш офык өстенә утырган — менә-менә баерга тора. Бүген караңгы төшәрен оныткандай, авыл көтүе һаман күренми. Көтү, гадәттә, иртә кайтучан. Ялан-кыр бүре белән тулы. Караңгыга каршы кайсыдыр бер мал төп көтүдән аерылса, аның исән калырына өмет итү кыен. Атка да, сыерга да ташлана хәзер бүреләр. Сарык-кәҗә турында әйтеп торасы да юк. Аларны көтүдән эләктерә башладылар. Ач бүреләрдән чыбыркы яки таяк белән генә саклану әмәле калмагач, көтүчеләргә мылтык тоттырдылар. Аның файдасы күренде. Бүре атып екканнары юк көтүчеләрнең, шулай да шарт-шорт атыштырып, бүреләр йөрәгенә курку салдылар.

Рәсим урап килгәндә кичке салкын һава авылга кереп килүче мал тавышлары белән тулган иде. Көтү каршыларга чыккан бала-чага чыр-чуы да өстәлгәч, урамга ныклап җан керде, авыл шау-шу белән тулды.

— Малларны япкач, бала яшерешле уйнарга чыгабыз. Уенны алачык янынннан башлыйбыз, — дип, кычкырыша-кычкырыша, малайлар һәм кызлар бер-берләрен кич чыгарга чакыралар иде.

Күптән генәме Рәсим дә шушы уенны башлап оештыручыларның берсе иде. Урта мәктәптә укый башлагач кына бизенде. Күңел эрелеге көчәюдән түгел, үсә төшү билгесе иде бу. Сугышка кадәр урам буйлап ташлама сугуда, бала яшерешле уеннарында өлкәннәр дә катнаша иде. Хәзер зурлардан уен кайгысы китте. Аларны ачлыктан җан саклау хәсрәте басты...

— Рәсим, кичке уенга чыгасыңмы?..

Кинәт ишетелгән тавыштан сискәнеп китте егет. Таныш тавышны мизгел арасында абайлап, каушый калды. Ана сорау бирүче кыз — Оксана иде. Рәсим бер мизгелгә аптырап торды. Бу сорауны башка берәү биргән булса: «Юк!» — дип кырт кисәр иде. Әмма аннан җавап көтүче зат алсу йөзле, зәңгәр күзле, аны хисләргә батырган кыз Оксана иде...

— Картайгансың, дип, уенга кертмәсләр мине, — дигән булды, өздереп җавап бирмичә.

— Сүләп торган буласың тагын! — диде кыз, авыл карчыклары әйткәнчә итеп. — Уенга йөрүчеләрнең күбесе синең чордагылар.

— Син чыгасыңмы соң?

— А как же! Мин чыкмый калсам, дөньяның чите кителә, — диде кыз, кет-кет көлеп. Аның көлүе дә ягымлы, елмайганда йөзе тагын да чибәрләнә төшә.

— Сиңа иптәшкә чыгам, алайса.

— Көтәм, чык...

«Көтәм», — ди бит, Рәсим ничек баш тарта алсын инде?!

...Уенда катнашу уе түгел, Оксана янәшәсендә буласы килү теләге урамга тартты Рәсимне.

«Бала яшерү» уены авыл буйлап йөгермәле. Бер төркем каядыр кача, икенче төркем шуны эзли. Яшеренү өчен урынны тиз генә эзләп таба алмаслык итеп сайларга тырышалар. Каралты-кура тирәләре, чокыр-чакыр аралары да калмый. Яшеренгәннәрне эзләү тапканчыга кадәр дәвам итә. Табучылар аннары үзләре кача... Шулай итеп, уен алмаш-тилмәш эзләүгә көйләнгән. Качучыларны эзләп таба алмыйча өйләргә таралышу очраклары да булыштыра...

Рәсим Оксана тирәсендә кайнашты. Алар бер төркемдә иде. Башта каршы яклар качтылар, аларны тапкач, Рәсимнәр яшеренде. Яшелчә бакчасы астындагы куаклы тирән чокырга сыенды алар төркеме. Төнлә түгел, көндез дә юллап тапмалы түгел бу урын. Рәсим Оксана янәшәсенә чүмәште. Бераздан Оксана:

— Суытты, салкын бәрә башлады, — дип зарланып алды. Рәсим пинҗәген салып, кызның иңенә япты. Янәшә утырсак, җылырак булыр дигәндәй, кызны үз янынарак тартты. Ярдан шуып төшеп китүдән курыккандай, «ой» дип аваз салып, кыз Рәсимнең муеныннан кочаклап алды. Аңлы рәвештә килеп чыктымы, очраклымы — бу чаклысын уйлап тормады егет, Оксананы кысып кочаклады. Кыз тавыш-тынсыз ана елышты... Иреннәр иренгә тиде...

...Ике яшь җилкенчәк, шушы тирән яр эчендә, гомерләрендә беренче тапкыр үбешү тәмен татыды. Шушы көннән алар йөрәгендә Мәхәббәт дигән олы хис тудырган ялкын дөрләп яна башлады...

***

Рәсимнең Тимәк мәктәбенә эшкә урнашу хәбәре авыл өйләренә яшен тизлегендә таралып өлгерде. Балалары шунда йөреп укыган ата-аналар бу хәбәрне шатланып кабул итте. Бер борчулары кимегәндәй булды. Рәсим Тимәккә балалар белән бергә барыр, бергә кайтыр, аларга күз-колак булыр, дип сөенделәр.

Тимәк мәктәбенә балалар дүрт авылдан йөреп укый. Малайларның юлда үзара низагка кергән чаклары булгалый. Бер авыл белән икенче авыл малайлары арасында тәпәләшү очраклары да юк түгел. Рәсим янәшәсендә балалар «әтәчләнергә» батырчылык итмәсләр, дигән өмет бар ата-ана күңелендә.

Атасыз калган малайларның күпчелеге тезгеннән ычкынды, аналарын тыңламый башлады. Укытучыларны саңга сугулары да чамалыга әйләнеп бара. Тәртипсезлек кылучылар, нигездә, ярты ятим үскән малайлар. Ир-ат

тарафыннан ярдәм булмыйча торып, аларны тәртә арасына кертү җинел түгел, билгеле.

Балалары Тимәккә йөреп укучыларның аналары өчен хәвефләнергә икенче сәбәп тә бар иде. Соңгы вакытта: «Якын-тирә урманнарда сугыштан качучылар яшеренеп ята икән. Юлбасарлык кылалар, мал-туарга кыргынлык салалар, кешеләрне талыйлар», — дигән сүзләр куера төште. Качкыннарны күрүче дә, алар зыян салган бәндәләрне очратучы да юк әлегә. Ә сүзләр күперә, телдән-телгә күчеп, авылларга тарала.

Авыл халкының шиген арттырырдай сәбәпләр чыгып кына тора. Базардан яки район үзәгеннән йөреп кайтучылар чираттагы шомлы хәбәрне ирештерә. Янәсе, качкыннар фәлән авылдан бер хатынны көчләп, икенче бер төбәктә көтүдән кайтмый калган сыерны суйганнар. Кайдадыр кибет басканнар, амбарга төшкәннәр...

Курку көчәя бара. Хәзер көтүне гадәттәгедән иртә алып кайталар. Төнгелеккә яланга чыгарылган ферма малларын берничә кеше каравыллый. Кулына шакылдаткыч тотып, урам буйлап таңга кадәр төнче йөри. Мондый кизүлек өй чиратыннан оештырыла. Халык аларны «ночной»лар дип атый.

Кичтән ут алучы сирәгәйде. Лампа кабызганда да, яктылык тышка төшмәсен өчен, өй эчендә бар булган әйбер белән тәрәзәне ныклап томалыйлар. Лампасы яки керосины булмаганнарның кышкы төннәрдә болай да ут яктысы күргәне юк.

Рәсим Тимәккә балалар белән бергә йөри. Аның бу гамәлен мәктәп директоры Фаяз да хуплады. Балаларның хәрәкәтен күз алдында тотуың хәерле. Заманасы хәвефле, юлда алар белән ни булмас, диде.

Барганда да, кайтканда да Рәсим янәшәсендә Оксана атлый. Гәпләшә-гәпләшә шулай йөрү алар өчен гадәтигә әйләнде. Татар егете белән украин кызы арасындагы бәйләнешнең көннән-көн тирәнгә китүен күреп-белеп торалар. Берәү дә яманлау, гаепләү ягында түгел. Мәхәббәт дигән бөек һәм кайнар хис шулар яшендә кабына да инде. Яшьлек сукмагын үткәннәр гыйшык утының көйдерү көчен, талымсызлыгын яхшы белә. Аларның гайбәтен сату яшьлекне мыскыл итү булыр иде. Уналты яшьлек егет белән ундүрт яшьлек кыз мәхәббәт дигән хиснең мәгънәсен аңлау дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр инде...

Бүген, педсовет үткәрелгәнлектән, Рәсим кайтырга соңга калып чыкты. Октябрь аеның сүрән матурлыгы хөкем сөргән көн кичкә ныклап авышып килә. Ай бетеп килүгә карамастан, кар бөртегенең күренгәне юк әле. Көннәр болай сузылса, каз өмәләренең соңга калуы да ихтимал. Башка еллардагыча, ноябрь башларында үткәреп булмастыр.

— Рәсим!

Кинәт ишетелгән тавыштан Рәсим каушап калды. Тирә-якка күз салды, әмма берәүне дә шәйләмәде. «Янәшәдә кем булсын инде! Авыл ягыннан ишетелгәндер», — дип уйлап, егет юлын дәвам итте.

— Энем Рәсим!..

Тавыш якыннан килә. Рәсим карашын урман полосасы ягына текәде. Шәрәләнеп калган сәрви куагы арасында күренер-күренмәс торган кеше шәүләсен чамалады. Эндәшүче, үз янына якынаерга ишарәләп, кул изи иде. Бер мизгелгә шөлләү тойгысы кичерсә дә, куркудан тиз арынды. Таныш түгел кеше ана үз исеме белән эндәшер идемени? Якынайды Рәсим. Аның каршында сакал-мыек баскан, сәләмә киемле ир-ат басып тора иде.

— Танымыйсыңмы әллә? Мин — Хаҗи абзыең булам...

— Көч-хәл белән таныдым, Хаҗи абый, бөтенләй икенче кешегә әйләнгәнсең, — диде егет, көлемсери төшеп.

— Танымассың да! Урман карачкысына әйләндем бит, кача-поса гына йөримен.

— Сине яраланып госпитальдә яткан, озакламыйча фронтка җибәрәчәкләрен әйтеп хат язган, дип сөйлиләр иде. Каян килеп чыктың соң әле?

— Хак әйткәннәр... Минем фронтка китеп барышым.

— Ничек? Фронтка юл шушыннанмыни? — дип шаяртткандай итте Рәсим.

— Госпитальдә ятканда мина сеңлем Сәлимә Гашия җиңгәннең ир-атлар белән уйнашлык кылуы турында хат язган иде. Чын хәлне үзем күреп-белеп китү өчен кайтуым иде.

— Очына чыга алдыңмы?

— Завхуз Сафетдин белән ятканда өстенә кайтып кердем. Иштем мәгәр икесен дә. Сынмаган сөякләре аз калгандыр, — диде Хаҗи, үз гамәленә канәгатьлек белдереп.

— Эш зурга китмәгәе.

— Китмәс. «Тын-тавыш чыгара калсагыз, зираттан урын эзли торыгыз», — дип кисәттем мин аларны. Арт яклары чөйле бит, читләргә сиздерергә шөлләрләр... Энем, сина соравым шул: Сафа абзыйдан калган искерәк жылы кием алып килсәң иде. Төнгә каршы юлга чыгам. Үзен беләсен, салкынлык үзәккә үтмәле бит хәзер, — диде Хаҗи төп йомышын җиткереп.

— Мондый гына йомышны үтәргә булыр. Озакламыйча килеп җитәрмен, — дип Рәсим авылга таба атлады...

Тиз әйләнде егет. Күлмәк-ыштан янына шарф, бияләй әләктерергә дә онытмаган.

— Рәхмәт, энем. Исән калсам, кайткач бәхилләшербез, Алла боерса... Мине тегеләр күрде дә син генә. Очрашу хакында берәүгә дә сөйләмә инде. — Хаҗи, Рәсим китергән киемнәрне солдат капчыгына салып аркасына асты да, полоса буйлап әрәмәлеккә таба китеп барды...

***

Гашия Аланбашка сугыш башланыр алдыннан килен булып төште. Хаҗи белән бер ай элек танышканнар иде. Хаҗи армия хезмәтен үтәгәч, буш өйгә кайтып керде. Үзе юкта ата-анасы бер-бер артлы гүр иясе булды. Үзеннән өлкән ике апасы башка авыл егетләренә кияүгә чыгып, үз тормышларын корганнар иде. Ялгызлыктан гаҗизләнгән егет күңеленә хуш килгән беренче кызны күрү белән өйләнергә карар кылды. Гашияне очратты да күрү белән гашыйк булды. Озакка сузмыйча, тәкъдим ясады. Кыз ялындырып, көязләнеп тормады, ризалык бирде. Май башларында никахлашып, бергә яши башладылар.

Килен булып төшү белән Гашияне яшелчә бакчасына эшкә билгеләделәр. Бакчада эшче кулның иң кирәк чагы иде.

— Хәлебезнең хөртилеген сизенеп, безнең авылга килен булып төшкәнсеңдер син, — дип шаярттылар бакчачы хатыннар, Гашия эшкә керешүнең беренче көнендә үк.

Сугыш елларында да яшелчә бакчасын ташландык урынга әйләндермәде аланбашлылар. Аны тагын да киңәйтә төштеләр. Чөгендер, кәбестә, шалкан, кишер, бәрәнгеише яшелчәләрнең мәйданнары зурайды. Колхозчыларның хезмәт көненә бүлеп бирә башладылар аларны. Икмәкне кырып-себереп алып киткән елларны халык яшелчә белән җан саклады. Ярый әле бәрәңгедән кала башкасын дәүләткә мәҗбүриләп тапшыртмыйлар иде.

Бакчада әйбәт кенә эшләп йөргән җиреннән Гашияне амбар алдына күчерделәр. Хуҗалык мөдире Сафетдиннең «тырышлыгы» аркасында килеп чыкты бу үзгәреш.

— Гашия яшь, куәтле чагы. Амбар алдында капчыклар белән эш итү өчен шундый хатын-кыз кирәк, — дип бригадирның колак итен «ашый» торгач, Гашияне Сафетдин карамагына тапшырдылар. Колхоз җитәкчесе Хәлимә дә бу тәкъдимгә каршы килмәде.

Сафетдиннең Гашияне амбар янына эшкә алуының төп сәбәбе — хатынны үз тирәсенә якынайтырга теләүдән иде. Астыртын гына гыйшык тотышалар алар. Халык күзенә чалынмаска тырышалар, шулай да күпләр хикмәтнең асылын сизенә. Авыз тутырып гайбәт сатучы гына юк. Тол хатыннар арасында мәхәббәт уены уйнаучылар күбәеп китте, бозыклык гадәти күренешкә әйләнде. Шуна күрә тол хатыннарның ирләр белән мавыгуына шаккаткыч вакыйга итеп карамыйлар иде инде...

***

Хаҗи Самара госпиталендә дәваланды. Терелгәч, ялга кайтарып җибәрмәсләр микән дигән өметтә тора иде. Бу теләге тормышка ашмады. Яралары төзәлгән һәр солдатны фронтка озата тордылар. Хаҗи да элек үзе сугышкан частька барып кушылырга тиеш иде.

Сенлесеннән хат алганнан соң авылга кайтып килү теләге көчәйгән иде. Сиздермәстән генә пәйда булып, хатынын этлек өстендә тотып, аның арт сабагын укыту нияте аны туган якка әйди иде. Бәреп үтерердәй булып ачуы кабарды аның. Ул чит-ят җирләрдә кан коеп йөрсен, ә хатын сугыш сөреме күрмәгән җыбытый ирләр белән өегеп ятсын инде! Икәвен үтерсәң дә фарыз буладыр...

Баштарак шулай уйлап йөрсә дә, тора-бара кан кызуы басыла төште. Соңгы чиккә барып җитүне урынсызга санады. Икесен берьюлы кул кычытуы басылганчы дөмбәсләп алса, шул җиткән, дигән карашка килде.

Госпитальдән чыгар алдыннан, ниндидер мәслихәт сәбәп уйлап табып, авылга кайтып килү турында баш ватып ятты Хаҗи. Урап килү өчен өч көн вакыт җитә ана. Каян алырга ул өч көнне? Частька өч көнгә сонарып барып керсә, әлбәттә, үзенә эләгәчәк, дезертирлыкта гаепләп, трибуналга бирүләре дә ихтимал. Дәвалаучы табиб белән сөйләшеп карарга мы? Татар кешесе бит, аның хәлен анламый калмас.

Шул өмет белән ул табиб бүлмәсенә керде һәм үз хәлен анлатты. Өч көн алдан чыгарып, частька китү вакытын өч көнгә кичектереп язуын сорады.

— Син фаҗига чыгарып, үзенне дә, мине дә бәлагә тарытмакчы буласынмы? — диде табиб, Хаҗины тынлагач.

— Кәнтәй өчен бәла-казага юлыгу планы корганым юк. Тырнак белән дә чиртмим. Үз авылына куып җибәрәм дә өй ишеген кадаклап китәм. Исән калып, кайту бәхетенә ирешсәм, үзем торырмын. Шәһит китсәм, ике апаның берсе өйгә хуҗа булыр, — диде Хаҗи.

— Соравынны үтәрмен мин, тик бер шарт куям: авылга кайткач, кеше күзенә күренмәскә тырыш. Әләк-чәләк аркасында тикшеренә башлаулары ихтимал. Ул чагында икебезгә дә рәхмәт әйтмәсләр.

— Анлыйм.

— Анласаң шул — бүген кич үк сыпырт...

Бәхете бар икән. Юлда җай чыгып кына торды ана. Татарстаннан килгән атлы юлаучыны очратты. Аның белән төне буе кайттылар. Атлы үз авылында туктап калгач, Хаҗи утыз чакрымны җәяү атлады. Тәүлек тулганда ул авылы урамына аяк басты. Корбанын көтеп поскан ерткыч җәнлек шикелле, карангы төшкәнче куаклар арасында яшеренеп ятты. Авылны урап чыгып, күрше-күлән, дус-иш белән күрешәсе килсә дә, бу теләген авызлыкларга мәҗбүр булды.

Табиб әйткән хак сүзләрне күрәләтә аяк астына салып таптый алмады Хажи. Сизгерлекне бер генә минутка да югалтырга ярамый иде ана.

Ихатага ындыр артлап керде. Аяк очларына гына басып, мәче саклыгы белән атлап, тәрәзә янына килде. Өй эченә колак салды. Сизгерлек житәрлек иде Хажида. Өй эчендә шыпырт кына барган әңгәмәнең аерым сүзләрен эләктереп алды ул. Аның хатыны кайсыдыр бер ир белән гәп кора, хәтәр кәнтәйләнеп сөйләшәләр.

Хажиның исәбе тәрәзә төбе саклап вакыт үткәрүдә түгел иде. Ана өй эченә үтәргә кирәк. Ишекләрне ничек ачу турында ана өйрәтәсе юк. Үзе көйләгән келәләр бит. Тавыш чыгармыйча, шыпырт кына ачты ул ишекләрне. Өй ишеге бикләнмәгән булып чыкты.

Немецлардан кулга төшерелгән кесә фонаре белән яктыртып, Хажи сәке янына килде. Шәрә гәүдәсен яшерү өчен, хатын ямаулы юрган астына чумды, чәрелдәп кычкырырга тотынды: «Бур бар! Талыйлар!..» Ир торып утырды, калтыранган кулларын көч-хәл белән тынлатып, киенергә керешә. Хажи аны бер карауда таныды. Чатанлыгы аркасында фронтка алынмаган Сафетдин иде ул.

Хажи хатын өстеннән юрганны тартып төшерде дә кулындагы сыек тал чыбыгы белән шәрә гәүдәне сыдырырга керешә. Хатынны кызганыпмы, ирлеген күрсәтәсе килепме, Сафетдин арага кермәкче булып кыланган иде, солдат каешының саллы аелы чигәсенә эләккәч, идәнгә бөгелеп төште.

Кулы кинәнгәнче, алмаш-тилмәш ярды Гашия белән Сафетдинне Хажи. Жан тәслим кылуларыннан шикләнеп, ахыры чиктә туктыйсы итте, шөлләп куйды. Ахыры яман бетүе бик ихтимал бит. Үзенә авырлык киләчәк...

— Әгәр өегүегезне туктатмыйсыз икән, жаныгызны алачакмын. — Хатынына төбәп әйтте: — Син, себерке, ишекне тыштан калаклап, иртәгә үк авылыңа ычкын. Монда эзең суынсын. Чыраеңны күрәсем килми. Исән калсам, миңа юньле хатын табылмый калмас... Мине аңладыңмы? — дип, жавап та көтмичә, өйдән чыкты да, кызу-кызу атлап, төнге караңгылыкка кереп югалды...

Иртәгәсен, ярым үлек хәлендәге Сафетдинне капка төпләреннән күреп алып, өенә кертеп салдылар. Көзге салкын жирдә ятып, тәмам өшегән, сүз әйтә алмаслык дәрәжәгә килеп, авызы күшеккән иде. Нинди хикмәткә таруын аңлатырга рәте юклыгын чамалап, сорау белән аны тинтерәтергә уйламадылар. Хикмәтнең асылы барыбер ачылачагына икеләнмәделәр. Кечкенә авылда яшереп калырлык серләр булганы юк ләбаса!

...Ни гажәп, аякка баскач та ачылып китмәде Сафетдин. Кызыксынып сораштыручылар белән сөйләшеп торырга да теләмәде. Кыйналуын яшермәде, чөнки аның билгеләре әйтмәсәң дә ярылып тора иде.

— Капка төбенә кайтып житкәч, арттан килеп суктылар. Һушымны югалтканмын, кемнәр икәнен белә алмадым, — дигәнне әйтүдән башка кулай жавап бирмәде ул. Районнан килгән тикшерүчегә дә шулай диде. Алар да чын гаепләне тапмады. Хажиның, жир ярыгыннан чыккандай кинәт пәйда булып, төн уртасында Сафетдинне тукмап юкка чыгарып берәү дә күз алдына китерә алмады.

Сафетдиннең икеле-микеле сүзләре авылда төрле гайбәт таралуга сәбәп булды. «Төнлә амбар басарга килүчеләр кыйнаган икән», — дигән сүзләр куерып алды. Качкыннарга эләккән, дигән фикерләр дә әйтелде. Гашиянең авылдан кинәт китеп баруы да төрле уйдырмалар куеруга юл калдырды. Гайбәт таратырга маһир хатыннар: «Амбар алдында икесен берьюлы ишкәннәр. Төнгә чаклы буш келәттә өегеп яткан булганнар», — дигән хәбәргә канат кую белән, ул яшен

тизлегендә таралып өлгерде. Аланбашта гына тукталып калмады, күрше-тирә авылларга да барып житте...

...Чынбарлыкны авылда өч кенә кеше белде. Шуларның берсе — Рәсим иде. Ул Хажи сөйләгәннәрдән аңышты...

***

Сафетдин белән Гашия мәрәкәсе хакында төрлечә гоманлап алдылар да бераздан тынып калдылар. Чынбарлыкны белмәгәнлектән, гайбәтнең гомере кыска булды.

Сафетдин күзгә күренеп имгәнгән. Таякка асылынып, көч-хәл белән йөри. «Бер килгәнгә килә — гариплеге өстенә гариплек», — дип аны кызганучылар да байтак иде. «Саранлыгы өчен Ходай Тәгаләдән җибәрелгән каза бу», — дип юраучылар да табылды.

Тар күңеллелек бар, әлбәттә, Сафетдиндә. Амбар алдында эшләүче хатыннарның кесә төпләрен какмыйча торып, аларны өйләренә җибәрми. Ул күрмәгәндә ашап туенсалар гына инде. Үзләре тамак ялгау белән мени?!. Өйдә ач балалар көтеп утыра бит аларны. Сабыйларның күңелен ничек күрергә соң?.. Моны төшенми завхоз. Үз баласы булмаган кеше башкалар хәлен ничек аңласын инде? Шундый миһербансызлыгы өчен өнәми аны авыл халкы. Күпләрнең Сафетдин йөгенә кермәвенең сәбәбе дә шуннандыр, мөгаен...

Эшләрлек рәте калмавын чамалап, хуҗалык мөдирлегеннән баш тартты Сафетдин. Аның гаризасын идарә утырышында тикшереп, соравын канәгатьләндерергә дигән карарга килделәр.

Амбарларга хуҗа булырдай кеше урынына Фәнияне кулай таптылар. Авылда белемле кешеләрнең берсе, исәп-хисап ягына башы эшли, гаделлеге бар, дип фикер йөрттеләр. Фәния үзе генә икеләнде: «Тарта алырмынмы соң?» — дип әйтеп карады. «Хәзер аерым тармаклар гына түгел, заманасы авыр. Авырлыктан барыбыз да кача башласак, эшләргә кем калыр соң?» — дип мәсьәләне кабыргасы белән куйдылар.

— Ирләр сугыштан кайтканчы эшләп торырмын, алайса, — дип ризалык бирде Фәния ахыр чиктә.

Аланбашта житәкчелек тулысынча диярлек хатын-кыз кулына күчте. Идарә әгъзалары арасында сугыштан бер кулын өздереп кайткан хисапчы Салихтан башка бер ир заты калмады.

***

Софья да башкалар белән бергә колхоз эшенә керешге. Урак урганы гына булмаган аның. Авылда туып-үскән хатын-кыз буларак, игенчелек һәм терлекчелек хезмәтенең нечкәлекләрен бик яхшы белә. Җәйге айларда болында печән чапты, чүмәлә өйде. Болын эше тәмамлангач, ашлык сугуда катнашты.

Кышкы айларда авыл хатын-кызларының төп хезмәте кар тотудан, салам эскерте төпләрен көрәүдән, бәләкәй чана белән басуга тирес чыгарудан гыйбарәт. Софья да шушы эшләргә тартылды. Гашия авылдан киткәч, бригадир Талига аны яшелчә бригадасына күчерде.

Хатыннар Софьяны тиз арада үз иттеләр. Исемен дә татарчага җайлаштырып, «Сафия» дип йөрттеләр. Белгән чаклы санаулы урыс сүзләренә татарныкын кушып дәшә башлагач, Софья хезмәттәшләренә:

— Сез мина татарча гына эндәшегез. Мин аңларга тырышырмын. Тора-бара әллә сөйләшеп тә китәрмен, — диде. Шуннан соң хатыннар Софьяга татар телендә генә сүз каттылар. Украин хатыны да акрынлап татарча пупалый башлады.

— Сезнен тел катлаулы. Гел аралашканда өйрәнмәслек түгел шулай да, — диештерде башта еш кына.

— Ныклап торып өйрәнәсен әле син. Хәзер үк анлаша башладык бит. Әнә, кызын Үксинә татар кызларыннан аерылгысыз. Сиптерә генә татарчаны, — дип рухландыралар хатынны.

— Яшь тал тиз бөгелә. Ә мин карт өрәнге белән бер, бөгү өчен көч тә, вакыт та кирәк, — ди Софья жавабында.

— Бөтенләйгә үзебездә калырсын. Сөйләшергә дә өйрәнерсен, безнечә яшәргә дә, — диләр хатыннар, мөмкин булса, анын бүген үк кайтып китәргә атлыгып торуын белүгә карамастан.

— Калыр идем дә, сездә кыш салкын. Чыдый алмам, — дип шаяртып жавап бирә Софья.

— Кызын калса, нишләрсен?..

Оксана белән Рәсимнен чат беркешеп йөрүеннән чыгып әйтәләр, билгеле.

— Ул гомер буе барыбер мина бәйләнеп ятмас бит. Кызлар — туган оясыннан чыгып китү өчен яратылган. Тәкъдир кая ташлый — алар шунда. Ата-ана ихтыярында түгел, — ди хатын, кызынын язмышы анын кулында түгеллеген анлатып.

Хәлбуки, эченнән икенче төрле уйлады. Бер бөртегеннән аерылып, ничек яшәсен сон ул? «Сонгы сулышыма кадәр кызым янымда булсын иде», — дип адым саен Ходайга ялвара. Шушы теләге кабул булсын өчен чукынып та алмакчы иде, дин тотмасалар да, үзләрен мөселман кавеменнән дип атап йөрткән хатын-кызлар алдында христианча табынуны унайсыз санады.

— Алла нәрсә чыгарын кем белгән? Вакыт күрсәтер. Ул чорга кадәр яшисе бар, — дип фикерен йомгаклап куйды, бераз тын торгач.

Кызы белән Рәсим арасындагы мөнәсәбәтнен көннән-көн куера, тирәнәя баруын белә ана. Яшь йөрәктә кабынган сөю хисен киртәләрдәй әмәл юклыгын да чамалый... Вакыт үтәр, алар китеп барырлар. Яна танышлар барлыкка килер. Оксана берсеннән-берсе елгыр, чибәр егетләрне очратыр, дуслашыр. Йөрәгендә янә мәхәббәт уты дөрли башлар. Биредәгесе күптән күргән татлы төш сыман гына булып хәтердә калыр... Ана әлегә шулай уйлый...

Ундүрт яшьтә кабынган мәхәббәтнен гомерлек түгеллегенә инанып житмәгәнгә, ана шундый фикердә тора. Кызынын бүгенге хисләрен вакытлыча мавыгуга гына саный. Еллар узу белән әһәмиятсез бер истәлеккә генә әйләнеп калырына инана.

Биредә калу!.. Софьянын башына мондый уйнын юри генә дә килгәне юк. Бу хакта уйланырга да теләми. Кызынын азалануы гына тирәнгә китмәсен. Рәсимне гомерлек юлдаш итеп сайлый гына күрмәсен. Ил икенче, тел икенче, жир икенче. Читлек кошы халәтендә гомер кичерергә калыр балага... Юк, юк! Ул кызынын үз ихтыяры белән язмыш колына әверелүен теләми... Ярый, Оксана балалыктан чыкмаган, еракка карап корылган планнар белән яшәми торган чагы. Шулай да әлләни килеп чыгуы ихтимал... Тфү-тфү... Үзен сакла!..

Софья кызы белән басымлап бер сөйләшү ниятенә керде. Хатыннар белән бүген ярым шаяргандай сөйләшү аны тирән уйга батырды...

***

Рәсим белән Оксана мәктәптән бүген дә житәкләшеп кайттылар. Софья аларны авыл башында каршылады.

— Әни, нәрсә булды? — дип гажәпсенеп сорады кыз, анын Рәсим белән бергә кайтуын күрү өчен килүен чамаласа да.

— Амбар алдына килгән идем. Сезне күрдем дә, бергә кайтырбыз дип көтеп алдым, — дигән булды ана, очраклы күрешү икәнлекне искәртергә теләп.

— Көтүең әйбәт булган, Софья түти. Әйдәгез, бергә-бергә кайтабыз, — диде Рәсим. Оксананың йөзендәге ризасызлык билгесен юкка чыгарырга теләп. Софьяның аларны каршылау сәбәбен Рәсим белә иде инде. Ана белән кыз арасында җитди сөйләшү булган. Анның әчтәлеген Оксана Рәсимгә түкми-чәчми җиткерде. «Кирәгеннән артык мавыгып китеп, йөрәгенә тирән яра алырлык булма», — дип вәгазь укыган ана. «Без хәзер сабый түгел. Мәхәббәтебез җитди безнең. Беркайчан да, нинди генә сәбәпләр килеп чыкса да ташлашмаячакбыз», — дип үзенекен тукыган кыз. «Хәзер генә шулай тоела ул. Кайтып киткәч, бу хисләрдән гел арынырсың, кайдадыр Рәсим атлы егет барлыгын да онытырсың. Беренче мавыгу кемдә дә була, кемнеке дә онытыла», — дигән Софья, үз башыннан кичкән хисләргә нигезләнеп. «Безнең мәхәббәт син аңлаганча, син күргәнчә түгел. Үлгәч тә онытылыр микән әле?!» — дип Оксана сүзен бирмичә, үз фикерендә калган...

Сүзсез килеш озак атлый алмадылар. Кичә өзелеп калган фикерен дәвам иткәндәй, ана телгә килде:

— Бераз гына да аеры тора алмыйсыз икән. Башка укучылар әллә кайчан кайтты. Ә син, Рәсимнең эше бетүен көтеп, кагаеп басып тордыңмы? — диде ул, кисәткәнне һич аңлый торган түгел икәнсен дигәндәй, баш селкеп.

— Әни, ул хакта бүтән сүз куертмыйк инде. Сөйләштек, аңлаштык түгелме соң?

— Сөйләштек, тик син һаман аңламагансың сыман.

Кыз башкача сүз катмады. Рәсимнәр турына кайтып җиткәннәр иде инде алар. Үзләренең торган өйләре дә рәттән генә. Керә-килешкә сорау бирде кыз:

— Минем адымны болай тикшереп йөреп, ни кылмак буласың соң син, әни?

— Артык оятсызланып китүегездән куркам. Синең яшьтәге кызлар арасында бала табучылар азмыни? Ялгыз килеш татар баласы карап үстерергә язмасын, дим.

— Әни, хафаланма, безгә ул хакта уйларга иртә әле.

— Сез нәрсә хакында гына уйлыйсыз соң?

— Киләчәк хакында.

— Сез уйлаган киләчәк нинди рәк инде?

— Бик матур... Сугыш бетәр, ил тынычланыр. Тормыш рәтләнер. Барыбыз да рәхәт яши башларбыз. Самолетларда очарбыз, поездларда йөрербез.Теләгән җиргә барырбыз, кайтырбыз...

— Барып-кайтып йөрерсез йөрүен. Кайда утракланырсыз соң?

— Бу хакта уйлап бетермәдек әле.

— Монда калмакчы түгелдер бит?

— Кем белә? Вакыт күрсәтер, — диде Оксана, зурларча җавап биреп.

— Шулай да тыйнак бул, кызым. Хисләренне яшерә бел. Эчендәге тышында булмасын Беркатлы кызларга егетләр ышанмыйлар, акыллы кызларны кулай күрәләр... Шуны аңла: пешек сагызы шикелле чат берекмә. Үзенне тыйнак тотсаң гына дәрәҗәң булыр, ихтирам итәрләр, — дип, ана әңгәмәгә нокта куйды.

Җиткерәсе фикерләре калды-калуын. Анынчы Рәсимнең анасы Фәния белән гәпләшүне кирәк санады. Ике ана, һичшиксез, уртак фикергә килми калмаслар. Фәния дә уйланмыйча гына йөрми торгандыр. Балалар арасындагы мөгамәләне ул да белә бит...

***

Жирне көзгә кырпак япкан көннәрдә: «Якын-тирә урманнарда качкыннар күренештерә икән», — дигән хәбәр тагын куерып алды. Сүз таралуга нинди вакыйга сәбәпче булгандыр, кышкы айларда качкыннарның бу якларда яши алмаячаклары һәркемгә мәгълүм, югыйсә. Зәмһәрир салкыннарда бил тинелтә сырынтыны ярып, агачлар арасыннан ничек йөрсеннәр дә, каян нәрсә табып тамак туйдырсыннар? Кеше аяк басмаган урыннарда эз калдыру — качак өчен үз-үзен тоттыру белән бер бит. Күреп кенә алсыннар, сугыш афәтләрен кичерүдән бәгырьләре ташка әйләнгән, бер-берләрен сатуны тиенгә санамаган бәндәләр хәбәрне кирәкле урынга шундук ирештерәчәк.

Эт өрә торыр, бүре йөри торыр, дигәндәй, качкыннар турындагы сүзләр чыгып-чыгып торса да, халык урманга да барды, басуга да чыкты. Дөнья кирәге йөртте кешеләрне. Ачлык-ялангачлык изүе качкыннардан шөлләүдән яманрак иде...

Беркөнне эштән кайтып килгәндә, урам башында Рәсим белән Оксананы Фәния каршылады.

Әнисенең аны көтеп тору галәте булмаганлыктан, Рәсим хәвефкә төште.

— Әнкәй, әллә берәр хәл бармы? — дип кабаланып сорады.

— Белмим инде, улым... Ниндидер бер офицер йөри. Сине авыл советына чакырып ике тапкыр килделәр. Шул хәрби сората, ди.

— Шикләнерлек нәрсә булырга тиеш түгел. Борчылма, әнкәй, — дип егет анасын тынычландырырга тырышты.

Фәниянең йөрәге үз урынында түгел инде. Заман өркетеп бетерде бәндәне, куян хәленә төшерде. Рәсимнең хәрби яныннан чыгуын Фәния белән Оксана ут йотардай булып көтеп алдылар. Ярый әле озак тоткарланмады.

— Нигә чакырткан? — Бу икесе берьюлы биргән сорау иде.

— Ике авыл арасында йөргәндә чит-ят бәндәләрне күрү-күрмәвем турында кызыксынды. Качкыннар турында сөйләнәләр бит. Мондый сүзләр органнарга да барып ирешкәндер, күрәсең, — дип җавап кайтарды Рәсим.

— Алай гына булса ярый, — дип, аны көтеп торучылар җиңел сулап, тынычланып калдылар...

Рәсим ишектән килеп керүгә, өстәл артында утырган капитан урыныннан күтәрелде, күптәнге танышын очраткандай елмаеп, күн итекләрен шыгырдатып, кул биреп исәнләште.

— Энем, син Нәбиев буласыңмы әле? — Белмәгәннән сорамады, билгеле. Нәселенең төбе-тамыры белән кызыксынган иде инде.

— Әйе, Нәбиев булам, — дип җавап кайтарды Рәсим.

Алар арасында сүз куера башлаганчы ук бүлмәдәгеләр чыгып беттеләр. Икәүдән-икәү калгач, Рәсим шомлана төште. Җитди мәсьәлә буенча сүз барачагын чамалады. Әткәсе турында ниндидер хәбәр ирештермәкчеме? Түгелдер. Андый яңалыкны әйтү өчен Рәсимнең Тимәктән кайтуын көтеп утырмас иде бу капитан...

— Сафа улы бит, әйеме?

— Шуныкы.

— Атаң, мәрхүм, шәп кеше иде...

Рәсимнең йөрәге жу итеп китте. Димәк, аның әтисе вафат... Һәлак булган?..

— Кайчан? — диде ул, агарына төшеп.

— Ничек «кайчан»?

— Әткәй кайчан мәрхүмгә әйләнгән?

— Ник? Ул исәнмени?

— Кичә генә хатын алган идек бит...

— Гафу ит. Икенче кеше белән бутаганмын, — диде капитан, хәтер калдырырлык сүз ычкындырмаган гөнаһсыз җан төсле кыланып. Рәсим эндәшмәде.

Мона кадәр күрешеп сөйләшкәне булмаса да, бу хәрби хакында кайбер хикмәтле сүзләр ишеткәне бар иде. Район үзәгендә укыганда очрашты ул бу бәндә белән. Өлкән лейтенант погоны таккан иде ул чакта. Үзеннән алда гайбәте йөрде. Хатын-кыз аеруча өнәми иде үзен. «Безнең ирләр фронтта кан коя, ә бу хәшәрәт ике айга бер тапкыр кайта да килә, кайта да килә. Сугыш беткәч: «Мин батырларча сугыштым», дип күкрәк төеп мактанып йөрер әле», — дип зарланалар иде өлкән лейтенант Алтаф турында.

Үзенә карата әйтелгән сүзләрне ишетмәдеме, әллә ачуларын юри кабартасы килдеме, өр-яңа парад формасы киеп кайтып төшә иде. Аның билендәге киң каешында пистолет кобурасы, тезенә тикле асылынган тар каешта кынасына тыгылган бизәкле саплы хәнҗәр булыр иде. Шушы килештән, ялтырап торган итекләрен тешкә тиярдәй шыгырдатып, үзәк урамны көнгә берничә тапкыр урар иде...

Рәсим офицерның тагын бер сәер гадәте турында ишетеп белә: кыш айларында кайтканда, тимер юл станциясенә җигүле атта бары тик хатын-кызларга гына илттерә икән ул. «Ярты юлда кунасы бит, Алтаф ялгыз йокларга курка», — дип гайбәтлиләр иде.

... Алтаф өстәл артыннан урын алды. Рәсимгә үзенә якын бүкәннән урын күрсәтте. Егет утыргач, әйтте:

— Энекәш, бер деликатный вапрусны ачыклыйсы бар. Шуның өчен чакырту иде сине.

— Минем ярдәм тияр микән соң? — диде Рәсим, җилкәләрен сикертеп.

— Бәлки, тияр... Беләсең, авыр чорда яшибез. Сугыш бара, берәүләр кан коя, ә икенчеләр качып йөри. Дезертирларны әйтүем...

«Хаҗи абзый артыннан иснәнеп йөрүеме әллә?» — дигән шик йөгереп үтте Рәсимнең башыннан. Түгел икән. Аерым кеше турында дәлиле барлыгы сизелми. Шулай да кемнәндер, нәрсәдәндер шөбһәләнеп йөрүе ачык...

— Син, энем, Тимәккә көн саен барып-кайтып йөрисең. Кырга охотага да чыгыштырасын икән... Юлда шикле бәндәләр күренгәне юкмы? — диде Алтаф, егетнең күзенә сөзеп карап.

— Ю-у-у-к! — диде Рәсим, сузып.

— Аяк эзләре дә күзенә чалынмадымы?

— Бер дә күренгәне булмады.

— Алай икән... Энем, шулай килешик: шикле затларга юлыгасың икән, мина хәбәр итү ягын кара. Мин булмаганда, военкомның үзенә җиткер. Түлке берәү дә сизенмәсен. Бүгенге сөйләшүне дә сер итеп сакла, — диде капитан, Рәсимне кисәтеп...

Рәсим Алтаф Хаҗиевнең ни өчен ике айга бер тапкыр ялт итеп кайтып төшүенең сәбәбен аңлый төшкән сыман. Тышкы кыланмышы белән кайберәүләр Алтафны дуамалга санасалар да, эчке яктан серләр сөременә төрелгән бәндә икән ләбаса! Холык-фигыленә төшенеп бетәрдәй затка тартмаган ул бу килештән. Бер төрле сөйли, икенче төрле гамәл кыла кебек...

Өч көн үтүгә, Иркәш авылыннан бер ирне кулына богау салып алып киттеләр, дигән хәбәр ишетелде. Бер тәүлек элек кенә кайткан булган. Мунча керергә генә өлгерә алган. Аны «аулауда» капитан Хаҗиевнең кулы уйнавын чамалады Рәсим. Кайтуы, сораштырып, иснәнеп йөрүе юкка булмаган икән...

***

Эштән арып-талып кайтуга карамастан, авыл халкының байтагы фронт хәбәрләрен ишетү өчен, кызыл почмакка җыйнала. Кайбер көннәрне бүлмәгә сыярлык булмый. Тәрәзәләрне ачып, радионы тышкы яктан тыңларга мәҗбүр булалар сонарыбрак килгәннәр.

Бу арада ишетелгән хәбәрләр буенча, җиңү көннәренең Каф тавы артында түгеллеген чамалый халык. Украина җирләрен азат итү өчен каты бәрелешләр бара. Бу төбәктә тиз арада дошманның эзе дә калмаячак, дип яза газитләр. Софья шул хәбәрне ишетүгә үк, шатлыгын кызы белән уртаклашты:

— Кызым, бирергә яшисе көннәребез санаулы гына калып бара, — диде ул, басудан талчыгып кайтып, тамак ялгарга утырган Оксанага.

— Нишләп алай? — дип сорады кыз, аны-моны аңышмыйча.

— Безнең җир тиздән азат ителеп бетәчәк...

Сөенергә дә, көенергә дә әзер түгел иде Оксана. Ана баласының хәлен сизенде, әмма белмәмешкә салышты. Юату сүзләре әйтүдән дә тыелды. Гәп агышын икенче эзгә кертеп җибәрү өчен җай тапмыйча, үзе дә бер мәлгә аптырап торды...

Шулчак урам ишеген шакыдылар. «Кем бар?» — диюгә, ирләр тавышы килде. Рәсимнеке. Оксана, урыныннан сикереп торып, өй ишеген ачты, Рәсимнең муенына асылынды.

— Кайчан кайттың, Рәсим?

— Әле генә. Бер стакан чәй эчтем дә караңгы төшкәнче сезгә кагылыйм, дип керүем.

— Имтиханнарыңны биреп бетердеңме? — дип төпченде кыз.

— Барысын да түгел. Тагын ике атнадан килергә куштылар.

— Ул чакта диплом алып кайтасың, әйеме?

— Исәп шулайрак.

— Рәсим, бер тотынгач, ярты юлда калма, институтка кер, — дип, Софья яшьләр арасында куерган әңгәмәгә кушылды. — Синнән үрнәк алып, башкалар да белемгә омтылырлар. Тыныч тормышка күчкәч, белемлеләр кайда да кирәк булачак.

Егет авыз ачканчы, Оксана сүзне икенчегә борды:

— Без озакламыйча китәбез, — диде ул, Рәсим өчен мөһим яңалык җиткереп.

— Ничек? — Рәсим сораулы карашын хәбәр ирештерүче Оксанага түгел, Софьяга төбәде.

— Гомерлеккә килмәдек бит, озакламый китәрбез инде, — дип ана кызының сүзен раслады.

—Сугыш туктамый торыпмы?

— Без яшәгән урын азат ителде инде. Озакламый туган җиребез тулысынча чистарып калыр. Кайтып, ныклап торып оя кору хәстәренә керергә кирәк булачак...

Рәсимнең йөзе җитдиләнде, уйчанлык чаткылары йөгерде. Дмитриенколарның гомерлеккә килмәвен, иртәме-соңмы китәчәкләрен белеп йөрсә дә, ул көн тиз килеп җитәр төсле түгел иде. Мәхәббәт хисләре белән тулы йөрәк нинди авыр заманада да көннәр санын тоймый икән...

Өй эчен сүрән караңгылык биләп алды. Өстәл өстендә кукраеп утырган сукыр лампа яктысы үз тирәсеннән китми. Ул да менә сүнәм дигәндәй, кечкенә утлы телен як-якка болгап утыра. Җәелеп утыруны урынсыз санап, Рәсим чыгып китүне кулай күрде. Хәерле төн теләп, өйдәгеләр белән саубуллашты.

Оксана аны озата чыкты. Тышкы баскычта егетнең муенына сарылды, Рәсим аны кысып кочаклады...

Өйгә кергәч, Оксана сәке түренә өелгән урын-җир өстеннән мендәр тартып алды да шуна капланып еларга кереште. Кызының әреп төшү сәбәбен аңласа да, ана сорау бирде:

— Ни булды, кызым?

— Булмады, — диде кыз, күз яшьләренә тыгылып.

— Булмаган өчен үксемиләр бит.

— Үксемичә! Аерылышабыз бит... Без әллә бүтән мәңгегә күрешә алмабыз... — дип Оксана тагын да ярсый төште.

— И-и, җүләр! Сезнең барысы да алда. Кырык күрешеп, кырык сөйләшерсез, — диде ана, әйткәннәренә үзе үк ышанып җитмәсә дә...

Оксана тынычлана төште. Башкача сүз катышмадылар. Җәйге төн кыскарып килә, иртән иртүк икесенә дә эшкә кузгаласы...

***

Авыл кешесе өчен фронт сызыгыннан хат алудан да киеренке тойгы юктыр. Фәниягә бүген хат китереп тоттырдылар. Ире Сафадан иде.

Бер айга якын хәбәре килми торды. Эчендәгесен сиздермәсә дә, төрлечә юрап, ныклап торып хафалана башлаган иде Фәния. «Үлде хәбәре китереп кенә тоттырмагайлары», — дип хәвефләнеп, утлы кузга баскандай, курка-өркә генә йөрде...

Җәһәт-җәһәт кенә ачты да хатны укырга кереште Фәния. Яраланган икән аның ире. Бер госпитальдән икенчесенә күчереп йөртүләре аркасында, адрес ачыкланмыйча торып, хат яза алмаган. Өй эчендәгеләргә, күрше-күләнгә кайнар сәламнәрен тезгәннән соң, түбәндәгеләрне хәбәр иткән:

«... Ходай Тәгалә тагын бер үлемнән алып калды. Өченче тапкыр яралануым югыйсә. Ә мин исән! Әйткәнем булмасын... Яшәргә иде бит әле. Тыныч тормышта тагын бер тапкыр рәхәтләнеп яшәп карыйсы килә...

Самара госпиталендә ятам. Снаряд кыйпылчыгы уң аякның тез капкачын чәрдәкләде. Кисү ихтималы барлыгын да әйткәннәр иде, шөкер, аңа барып җитмәделәр — бөгелмәсә дә, үз аягым белән калдым...

Кадерлем, озакламый күрешербез. Мине бөтенләйгә кайтарып җибәрәчәкләр.

Хәерсез үлем белән монда адым саен очрашмалы. Ул госпитальдә дә кешеләрне сагалап кына тора. Кичә авыр яраланган бер татар егетенә операция ясаганнар иде, аңына килә алмыйча бакыйлыкка күчте. Кукмара ягыннан иде. Безнең тирәне белә, күп йөргән. Тегүчеләр нәселеннән икән. «Сезнең якта яраткан кызым бар иде, ятим булганы өчен әткәй алдыртмады. Бай кызга өйләнгән идем, баладан үлде. Исән калсам, беренче яраткан кызымны юллаячакмын», — дип хыялланып ятты. Шунысы кызганыч: кызның исемен, кайсы авылдан икәнлеген сорамаганмын. Ә ир Фаяз атлы иде...»

Фәниянең тез буыннары калтырарга кереште. Беренче мәхәббәте, тегүче Фаяз хакында язган ләбаса аның ире. Менә язмыш! Кемнәр белән кемнәрне генә очраштырмый! Һәм нинди хәлләрдә генә...

Аерылышуга ничә еллар узуга карамастан, Фәния Фаязны йөрәгеннән чыгарып ташлый алмады. Күпмедер онытылган тоелса да, тәүге мәхәббәт күңелдән уелмый икән. Көндәлек мәшәкать, нәрсә беләндер мавыгу, кайгы-хәсрәт кебек кичерешләр генә аны артка чикереп тора да, барыбер, көтмәгәндә искә төшеп, бәгырьне телеп, йөрәкне җилкендереп ала...

«Фаяз... Фаяз... Мин бит сина барыбер ачу тотмыйм. Мәхәббәт көчен

таныткан беренче кешем буларак, сина бәхет кенә теләдем мин. Син бәхеткә барыбер кинәнә алмагансын...»

Фәния, шундый бер фикергә килеп, янә бер көрсенде дә Фаязга җәннәттә урын теләп, гадәти чынбарлыкка әйләнеп кайтты. Анын үзен яратучы, ихтирам итүче ире бар. Аннан туган балалары бар... Тиздән анын белән көрәшәчәк. Бергәләп, гөрләшеп яши башлаячаклар...

***

Эштән кайтышлый, вакыт соң булуга карамастан, Софья кызыл почмакка кагылды. Халык байтак җыйналган иде. Шылт иткән тавыш чыгармыйча, радио тапшырган фронт яналыкларын тынлыйлар. Софья килеп кергәндә, радио Икенче Балтик буе фронты гаскәрләре тарафыннан дошманнын «Пантера» дип аталган көчле оборона линиясе өзелүе хакында сөйли иде.

Икенче һәм Өченче Белоруссия фронтлары гаскәрләре азат иткән шәһәрләрнен, авылларнын исемнәре аталды. Днепр елгасы флотилиясе морякларынын батырлыклары турында мактау сүзләре әйтелде...

Софья Украина фронтына кагылышлы хәбәрнен янгыравын түземсезлек белән көтте. Ул хакта әллә сөйләмиләр микән, дип икеләнеп торганда, диктор: «Беренче Украина фронты гаскәрләре, һөҗүмгә күчеп, Львов юнәлешендә немецларнын көчле оборонасын өзделәр һәм сонгы өч көн эчендә илле километрга алга киттеләр», — дип хәбәр итте. Азат ителгән шәһәрләрнен исемнәре аталды, алты йөздән артык торак пунктнын кире кайтарылуы әйтелде.

— Безнен гаскәрләргә немецларнын кырык бишенче дивизия командиры генерал Энгель әсирлеккә төште, — дип сүзен тәгалләде диктор...

Софья башкасын тынлап тормады, китү ягын карады. Ул кайтып кергәндә Оксана өйдә иде. Сирәк-мирәк сүз алышып, мич төбендә телемләп киптерелгән каткан бәрәнгене ипи урынына чәйнәп, тәмләп кенә гөлҗимеш чәе чөмерделәр.

— Мин Хәлимә янына барып киләм, — дип кузгалды чәй яныннан Софья.

— Төнгә каршы нигә тагын? Иртәгә көн беткәнмени? — дип гаҗәпсенеп сорады кыз.

— Беткән. Иртәгә эшкә чыкмаска иде. Минем урынга башка кеше билгеләсен.

— Анын өчен рәис янына бару мәҗбүри түгел, бригадир белән дә килешергә була.

— Икенче йомышым да бар. Ашарга сорыйм.

— Бүтәннәргә бирмәгәндә, сина тәтер дисенме?

— Сонгы үтенечкә колак салыр, бәлки... Юлга кәтеркәй катырмый булмас. Поездда нәрсә ашарбыз?

— Китү вакыты килеп җиттемени?

— Тиздән...

Ана барысын да әйтергә теләмәде. Рәсим кайтып күренгәнче кузгалу исәбендә тора ул.

Күрешми калсалар, икесенә дә җинелрәк булыр дип уйлый иде ана...

...Казан юридик институтына 1944-1945 нче уку елына студентлар кабул итү буенча район газетасында белдерү басылган иде. Педагогия училищесын тәмамлап кайткан Рәсимгә мәктәп директоры Саттаров шушы институтка барып карарга кинәш итте. Читтән килүчеләр икмәк карточкалары белән тәэмин ителәләр, тулай торакта яшиләр, диелгән белдерүдә. Шушы якларын

искә алып, егет бәхетен сынап карамакчы булды. Укырга керә алганда, авызга көн саен ипи эләгәчәк. Стипендия дә түләнәчәк икән әле...

Институт каршында әзерлек курслары эшли икән. Документларны тапшырган вакытта кабул итү комиссиясендә утыручылар Рәсимгә шушы курсны узарга киңәш иттеләр.

— Сугышта катнашучыларга, авыллардан килүчеләргә институтка керүдә өстенлек бирелә. Сез бу төркемгә эләгәсез. Икенче ягы да бар: әгәр курсларны уңышлы үтәсез икән, имтихансыз кабул ителергә мөмкинсез, — диделәр ана.

Укырга булгач — укырга, дип, Рәсим җиң сызганып, курсларда белем алырга керешә. Уку программасы шактый катлаулы иде. Укулар урыс телендә алып барыла. Авылда туып-үскән татар малае өчен белгән кадәресен аңлаешлы итеп сөйләү җиңелдән түгел иде. Тырышты егет, курсны алдынгылар рәтендә тәмамлады. Институтка берсүзсез кабул ителде ул...

... Рәсим курсларда укып йөргәндә аналы-кызлы Дмитриенколар авылдан китеп барганнар иде инде...

***

Ерак юлдан кайтып, тамак ялгап алгач, Рәсимгә сеңлесе Хамия хат тоттырды. Күңеле сизенде егетнең. Конвертны ачмыйча кулында бөтергәләде дә өстәлгә куйды, иркәләгәндәй итеп, аны акрын гына сыпырыштырды. Тынлык сузыла төште. Хамия аны бозарга базмады. Хәер, аның уенда абыйсын юатырдай җылы сүзләр дә юк иде. Рәсим башын күтәреп тәрәзәгә карады. Ерактагы ниндидер ноктага текәлеп күпмедер торганнан соң:

— Кайчан? — дип сорады.

— Өченче көн киттеләр, — диде кыз, җавабында.

— Бераз көтә алмаганнар икән...

— Оксананың китәсе килмәгән иде, әнкәсе чарага куймады. Җае да шулайрак килеп чыкты. Салих абый бер айлык курска китте. Аны тимер юл станциясенә илтәсе аттан Софья түтинең дә каласы килмәде, — дип аңлатты Хамия булган хәлнең асылын.

Ачаргамы-юкмы, дип икеләнгәндәй, Рәсим хатны кулында кырыкка әйләндерде. Ачса, хатны укырга хәленнән килмәстәй тоелды аңа. Күңелен бушлык биләп алды. Сөрән салып, нидер кычкырасы, өзгәләнә-өзгәләнә җылыйсы килде егетнең. Тик тамак төбенә утырган коры төер, аваз чыгару түгел, сулыш алуны да тоткарлый иде...

— Абзыкай, үзеңне кулга ал, борчылмаска тырыш. Алар барыбер китәсе кешеләр иде бит... Вакытлы яшәүчеләр... Оксана киткәндә: «Тормыш бераз рәткә кердеме, мин монда киләчәкмен», — диде. Күрешерсез әле, — дип Хамия абыйсын тынычландырырга теләде.

— Шулаймы? — диде Рәсим, йөзенә бернинди чаткы чыгармыйча.

— Әйе. Хатында да әйтеп язгандыр әле...

Хамия, хатны тынычлап укысын дип, абыйсын ялгыз калдырып, өйдән чыгып китте. Рәсим конвертны ачты. Күңелгә якын таныш кульязма... Хат амбар кенәгәсе битенә язылган. Төсен югалтып, саргая төшкән бу кәгазь кисәге Рәсим өчен бар нәрсәдән кадерле иде. Анда язылганнарны бирелеп укырга керешә ул...

«Рәсим, йөрәгемнең яртысы синең янда калды. Аның барлыгын тоеп яшә, мине онытма. Ә мин сине бер минутка да истән чыгармам. Әни: «Яшь чактагы мәхәббәт килә дә, китә дә. Синнән дә үтәр», — ди. Кемгә ничектер, әмма минем мәхәббәтем сүнә-сүрелә торган түгел. Сине өзелеп яратам. Әгәр синең хисләрең

дә мина карата шундый көчкә ия икән, безнең мәхәббәт ни өчен килеп-китә торган мавыгу гына булырга тиеш?! Мин мона ышанмыйм...

Кадерлем, китәсе төндә сине төшемдә күрдем. Акбүз атка атлангансың да авыл башындагы Суганлы тауга менеп барасың. «Нигә мине ияртмисен?» — дип кычкырам сиңа. «Бераз көт, сине дә алам», — дип кул болгап китеп бардың.

Уяну белән, төшне әнигә сөйләгәнче, үзем юрадым. Мәртәбәле, абруйлы кеше булачаксың син. Хезмәтеңдә югары күтәреләчәксен... Иртәргә инандырдың бит, димәк, мин дә синнән калмаячакмын...

Рәсим, бәгърем, онытма мине. Кызганыч, киткәндә гашыйклар шикелле җылы аерылыша алмадык. Вәгъдә куешмадык. Өлгерербез, дип уйлыйм. Барып чыгармын әле. Бәлки, үзең дә килергә тәвәккәлләрсең...

Авылдан китү авыр булды миңа. Сине күрмичә юлга кузгалу бәгырьне телгәләде. Түзмәдем, җыладым. Әни төрлечә юатты, әмма аерылышу сагышларын үгет-нәсихәт белән генә бастырып буламыни?!

...Рәсимкәем, кайтып төпләнү белән хат җибәрермен. Минем хатны җавапсыз калдыра күрмә берүк. Синнән хат килми башласа, үзем белән ни булырын күз алдына китерә алмыйм. Саргаеп үләрмен мин... Ишетәсеңме?

Кызган, ярат син мине. Язмышлар чатында ялгызымны калдырма. Мин һәркайда, һәркайчан сиңа тугрыклы калырмын...

Сине өзелеп яратучы Оксана дип белерсең.

21 июль, 1944 нче ел.»

Хатны укып бетергәч, башын ике кулы белән кысып, Рәсим тирән уйга калды. Беренче күрешүдән үк дөрләп кабынган һәм ике яшь йөрәкне көяр дәрәҗәгә җиткереп яндырган иң самими, иң саф, иң гөнаһсыз тәүге мәхәббәт шушы көннән сүнә башлар сыман тоелды аңа.

Юк-юк... Мөмкин хәл түгел бу! Рәсим беркайчан да, нинди генә хәлләрдә дә сөйгәнен бүтәннәргә алыштырмас. Гомер буе тугрылыклы калыр ул Оксанага!

Оксананың: «Без озакламый китәбез», — дип еш кабатлаган көне килеп тә җиткән, узып та киткән. Рәсимнең сөйгәне хәзер туган җирендә инде. Бу минутларда, бәлки, ана хат язып утырадыр? Язсын гына. Егет хатның берсен дә җавапсыз калдырмас, хәбәр көттереп тилмертмәс...

Рәсим, уйга чумган халәтеннән бераз айный төшеп, урыныннан күтәрелде. Баш җилләтү өчен урам һавасы кирәк иде аңа. Акрын гына атлап, амбар ягына юнәлде. Әнисе аның кайтканын да белми бит әле. Институтка керү яңалыгын җиткереп, куандырасы килде Рәсимнең. Гел шомлы хәбәрләр генә көтеп яшәргә димәгән бит. Йөрәк бер җылы хәбәргә дә кинәнсен...

*Дәвамы киләсе саннарда*



Газинур
Морат

# ӘКИЯТНЕ БАШЛЫЙК ЯҢАБАШТАН...

## Китап сүзе

Хөкем итмә — хөкем ителмәссең, —
Күктән иңгән тәүге хәбәрдер.
Әлмисактан килгән Китап сүзен
Хәкарәтләү язык, хәрәмдер.

Угры түгел — тугры булу кирәк, —
Шулай кушкан Китап яшәргә.
Кассаплыкны кәсеп иткән өчен
Купкандыр бу Җирдә мәхшәр дә.

Кан коючы, җан кыючы булып,
Барымтага барма күршеңә.
Хәрәм белән түгел — хәләл белән
Яшәү индерелгән кешегә.

Яманлыкны ялган белән ямау —
Илгә килгән иң зур казадыр.
Илдә һаман канун ишәйгәндә,
Азгынлык та шулай азадыр.

Китап сүзе иңгәчтен дә, дөнья
Карыш юл да гүя үтмәгән.
Илдә һаман канун ишәйгәндә,
Илнең башы чыкмас фетнәдән.

Бер кануны меңгә әйләнгәндә,
Меңгә төрләнгәндә үзебез,
Сират күперен дә кичәрбез күк,
Тота алсак Китап сүзен без.

Газинур МОРАТ (1959) — *шагыйрь, публицист; «Түбә», «Җәяүле кошлар», «Тәнге әверелеш» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Республикасының М.Җәлил, Татарстан Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге бүләкләре иясе. Казанда яши.*

## Вәсвәсә

Тыйганыннан — тыел...
Хава да бит
Алма гына юкса ашаган.
Ата — улны, ана кызны белмәс
Заманалар шулай башланган.

## Памир–алай хатирәсе

*Рафаэль Ишморатка*

Ургыл сулар улавы да монда
Йөз кайтаваз булып тарала.
Тау белән тау, бәлки, очрашмыйдыр,
Без очраштык менә тауларда.

Аклыклары, ваклыклары белән
Бар дөньясы калды түбәндә.
Тау да безгә таба киләдер күк,
Күтәрелгән чакта түбәгә.

Һәр адымын упкын күзләп тора,
Ишетелә хәтта сулышы.
Тау менү ул — адәм баласының
Үз язмышы белән узышы.

Күккә якыная барган саен,
Ерагая Күкләр тагын да.
Мәңгелекнең мизгел икәнлеген
Әйтеп бирер Һира тавы да.

Жилләр, силләр кыссә юлыбызны,
Күкләр безне үзе бәхилләр.
Кырык яшьлек пәйгамбәргә, әнә,
Мәгарәдә ингән вәхи дә.

Күккә якыная барган саен,
Куя кебек тау да калкынып.
Баштан сыйпап үтә каурый болыт,
Тынга каба галәм салкыны.

Тауга карап тау булмабыз ансы,
Таусыз яшәве дә читен лә.
Без — кечүдә.
Өскә үрмәлибез.
Ә үзебез — упкын читендә.

Өскә үрмәлибез...
Өстебездән
Таш кантарлар оча түбәнгә.
Тау да безгә таба киләдер күк,
Күтәрелгән чакта түбәгә.

## Хайтарма

...Бар тарафны төн ялмады,
Кабат таңнар атармы?
Таң туганда жантимерләр
Илдән куды татарны.

Ни чараң бар — мең алтатар
Төбәлгәндә чигәнә?..
Чал чинарлар үксеп калды
Туган-үскән җирләрдә.

Таулар калды ыңгырашып,
Җил елады далада:
Дала күңле анада, дип,
Дала күңле балада.

Җил елады, давыллады,
Диңгез какты ярларга:
Ярабби, дип, үксезләрне
Ялалардан арала.

Бу җиһанда баскын гына
Сайлап ала ватанны...
Күз яшедәй коргаксыды
Бакчасарай фонтаны.

Парә-парә коргаксыды
Гөл-чәчкәләр багы да...
Ә кем һаман хөкем итә,
Гафу сорар чагында.

Һаман хөкем чыгаралар,
Хаклык бер көн дәшәрме?
«Кайту» дигән кино бара.
Илдән куу мәхшәре.

## Гөлнар ханым

Бар дөньясы, кыргый, диеп каргый,
Корсын, диеп, тизрәк аты гына.
Шул кавем соң ник кирәккән әле
Казан башлыгының хатынына?

Кара йөзләр каһкаһәләп көлә,
Зыян килгәндер, дип, акылына.
Ә Мәрҗани ни хаҗәт соң әле
Шундый көяз марҗа хатынына?

Хәзрәт, диеп зурлап дәшә ана,
Гел килешле хәтта татарчасы.
Каюм Насыйридан сабак ала,
Өйрәнгәне — төрек, татар, фарсы...

Танып аны, үзе ачыладыр
«Кырык бакча»ларның капкасы да...
— Хуш килдегез, — диеп каршылый ул
Фатих Кәриминең атасын да.

Дөнья белән ипле аңлаша ул,
Гарәбен дә белә, алманын да...
Үз телендә ләкин аңламыйлар,
Бу илне шул кыен аңлавы да.

Кара йөзләр һаман пошаманда,
Ни даулый ул, диләр, ни хакына?
Бу татар соң ник кирәккән әле
Изге анакайга тиң хатынга?

...Ә ул, әнә, җылы эзләп йөри
Казан ятимнәре кавеменә.

Кеше шулай кара дәверләрнен
Вөждан, намусына әверелә.

Ә ул, әнә, якты эзләп йөри
Илсез илдәшләре өммәтенә.
Ә хәзрәтләр дога багышлыйдыр
Ольга Сергеевна[1] хөрмәтенә.

Ярый әле илендә бер бикә
Анлый белә, диеп, үксез хәлен.
Ә ул һаман: «Хуш килдегез!» — диеп
Каршы алыр Казан үксезләрен...

## Шигырь әйтеп...

Җәмил атлы жилле бер жегет ул,
Үзе чапак, үзе чаядыр.
Ул һәрвакыт юлда. КамАЗында
Дөнья йөген илтә каядыр.

Ул һәрвакыт юлда.
Ә юл башы
Бер саладан анын, Сабадан.
Чакрымнары күптән ашкан инде
Айны урап кайтыр чамадан.

Тәкъдире шул: үз-үзенә кеше
Юллар кичә-кичә төшенә.
Ул да, әнә, Айдан хикмәт эзли,
Зөһрә кызны күреп төшендә.

Шөгыле шәп — шигырь ярата ул,
Шигырь белән көйли дөньясын.
Һәркем дә, ди, иртән шигырь әйтеп,
Догалы сүз әйтеп уянсын.

Догалы сүз белән дөнья көтсән,
Чынга ашар татлы төшләр дә.
Эшем кешеләре ишәйгәндә,
Эш кешесе, ди ул, өшәнә.

Эшлесеннән эшлексезе ишле, —
Дөнья, әнә, шулай бүленгән...
Ул Зөлфәтне безгә яттан сөйли,
Һәм Мәһдине белә күңелдән.

Яттан сөйли, — нәкъ шагыйрьчә итеп,
Күккә чөя-чөя бармагын, —
Рәшит Әхмәтжанны, Мөдәррисне...
Һәм... күрсенеп куя аннары.

[1] Ольга Сергеевна Лебедева (1854-?), әдәби тәхәллүсе — Гөлнар ханым; җәмәгать эшлеклесе, публицист, тәржемәче, Идел буе татарларының этнографиясенә, мәдәният тарихына багышланган хезмәтләр авторы.

Күнел сәфәрендә үз юлдашы
Язгандыр шул һәрбер юлчыга.
Ул һәрвакыт юлда.
Шигырь әйтеп,
Догалы сүз әйтеп юл чыга.

## Империя

Ялган белән яла бер тамырдан,
Бер камырдан бугай тарих та.
Җирдә җәбер-золым яшәгәндә,
Гел үзгәреп торыр харита.

## Өндә төшләнү

Уянасы килми бу йокыдан, —
Сине күрдем тагын төшемдә.
Синең хакта шигырь сөйли идем,
Чал башымны куеп түшенә.

Уяндым да уйга калып ятам,
Үзгәрәк шул өннең мазасы...
Түшкәйләрең кайнар түшәк иде,
Ә шигырьне... килми язасы.

## Әкиятне башлыйк яңабаштан

Әкиятне башлыйк яңабаштан.
Ак бүренең кайтсын әфсене,
Кабат тораташка әйләнмәсен
Ашинаның асыл нәселе.

Әкиятне башлыйк яңабаштан.
Ярылыплар китсен түмәре,
Карурманда беркем рәнҗетмәсен,
Гел иректә булсын Шүрәле.

Әкиятне башлыйк яңабаштан.
Хәләл ымсындырсын байларны,
Нигезендә Шомбай койма койсын,
Бүрек кисен алтын каймалы.

Әкиятне башлыйк яңабаштан.
Чур, чыкмасын Дию яктыга,
Аркадашлар чокыр казымасын
Туганыдай Турай батырга.

Әкиятне башлыйк яңабаштан.
Җен кайтарсын ана каргышын,
Пәри ярлыкасын үксезләрне,
Сак белән Сок кабат кавышсын.

Әкиятне башлыйк яңабаштан...



Зиннур
Хөснияр

# ГАРАСАТ

РОМАН

## Төш күрү

Борын-борын заманда бик зур, дәһшәтле патшалыкта бер сихерче булган. Беркөнне ул гадәти булмаган сыекча уйлап тапкан һәм аны әлеге патшалыктагы гади халык эчә торган суга тамызган, ди. Ошбу суны эчкән һәр кеше беравыктан сәерләнә, хәтта җүләрләнгән кебек, ди. Күпмедер вакыт узгач, әлеге судан авыз итә торгач, патшалыкның барча халкы акылдан язып беткән, ди.

Патша гаиләсе эчә торган суны исә махсус коедан алганнар, тылсымчы биек коймалар аша анда үтеп керә алмаган.

Менә, күп тә үтми, патшалыкта төрле сәер, гайре табигый хәлләр башланган, халык ыгы-зыгы килгән, буталыш, фетнәләр кабынган! Патша, тәртип салырга теләп, бер-бер артлы яңа әмерләр чыгарып караган, вәзир-яраннар аларны шундук халыкка ирештерә торган булган. Ләкин халык, патша акылдан язган дип уйлап, әлеге әмерләрдән көлгән генә. Патшаның акылдан язуы хакындагы хәбәр мәмләкәт буенча таралган, һәм халык: «Безгә җүләр, акылсыз патша кирәк түгел», — дип фетнәләр күтәрә икән. Хәлләр торган саен катлауланганнан-катлаулана барган, халык һаман патшаның «җүләр» әмерләренә буйсынырга теләми икән, ди. Чөнки алар хәзер патша сараендагылар таләп иткән тәртип белән яшәргә теләмиләр, әмерләрен дә акылсызга санийлар бит инде. Патша гаиләсе белән аның яраннары исә халыкның ни сәбәпле болай чуалуының сәбәбен аңламый, дөресрәге, өстәгеләр белән астагылар һич уртак тел таба алмый икән, ди. Патшаның хатыны зирәк була, ул патша янына килә дә әйтә: «Бәлки безгә дә алар эчкән суны эчә башларгадыр?» Башка чарасы калмаган патша бу фикер белән ризалаша һәм алар да халык эчкән, акылдан яздыра торган суны эчәргә карар кыла. Шулай итеп алар үзләре дә акылдан язганнар һәм патша теләсә нинди әмерләр чыгара башлаган. Ошбу указлар халыкка бик ошаган, алар тынычланып, ошбу канун-күрсәтмәләргә карусыз буйсына башлаганнар, ди. Шул рәвешле генә халык белән уртак тел табылган һәм әлеге патша бик озак еллар теләгәнчә идарә итә алган.

*Дәвамы. Башы 5, 6 саннарда.*

Вакытлар үтә торган. Акылдан язганнар патшалыгында тормыш үзенчә, боларның суын эчеп карамаган күрше патшалыкларда исә бөтенләй башкача дәвам итә икән. Еллар узгач, теге тылсымчының оныгы, бабасын да уздырып, бөтен Жир шарындагы суларны агулый торган сыекча уйлап тапкан һәм аны сулыкларга тамызып чыккан. Тора-бара Жир кешеләренең барысы да акылдан язып беткән. Тик шунысы бар: әлеге сыеклык кайбер кешеләргә тәэсир итә алмый икән, алар тулы акыллы булып яшиләр, ди. Болар калганнарга нинди су эчкәннәрен һәм кылган гамәлләренең дөрес түгел икәнлекләрен аңлатмакчы булып тырышалар икән. Тик аларның сүзләрен берәү дә чынга алмаган, ышанмаган, киресенчә, аларны җүләргә санаганнар, сез акылдан язгансыгыз дигәннәр, ди.

Жир шарындагы гавамның тереклеге әле дә булса шул көенчә дәвам итә икән, ди...

Ошбу риваятьне Байтамак халкы Камай авызыннан ишетте. Ә Камайның бу турыда кайдан укыганлыгын берәү дә төпченеп тормады, чөнки аның Мәскәүләрдә белем алып кайтканлыгы мәгълүм ләбаса.

Кайбер кеше ачуын, кайгы-хәсрәтен эченә җыючан, кемдер күңелендәгесен һәрвакыт тышка чыгарып тора, һичбер вакыт үзенә җыеп сакламый. Камай да шундыйлардан. Аның хәтта тиктомалдан гына: «Су эч!» — дип куюлары да, берәр кайгы-хәсрәтен сөйләп, бушанырга теләгән кешегә дә җавабы шул бер булыр: «Су эчеп куй син!» — дигән сүзтезмәдән артмый. Ләкин ул «Су эчеп куй! Хәлен җиңеләер!» — дип әйтеп бетерми, бары «Су эч! Су эчеп куй!» гына. Шуннан соң хәлең җиңеләерме, шуннан соң эчең бушармы, анысын инде син үзең белерсең! Хәер, Камай ошбу сүзне юкка гына әйтми, чөнки су эчеп куйганнан соң адәм баласы, чыннан да, җиңеләеп китә, җанына тынычлык иңә. Монысын исә һәр кеше үз халәтеннән чыгып белә.

Камайдан син суның һәм тимернең нинди молекулалардан торганлыгын сора, ул шунда ук җавап бирер, җавабы да уйдырма түгел, фәнни, ягъни ышандырырлык булыр. Африкадагы баунти кабиләләренең тарихы хакында мәгълүмат сора, җавапны шундук ишетерсең! Ләкин түфли башың нигә тишелгән кебек гадәти сорау бирергә уйласаң, җавап көтмә, Камай мондый сорауны ишетүгә, кыяфәте белән нәкъ сабый баланы хәтерләтеп, иңбашын гына җыерып куяр, яки әлеге сорауны бөтенләй ишетмәгәнгә салыныр. Озын Хәсәннең хатыны Фәһимә усалмы, юкмы кебек сорауларга да Камай җавап бирә алмас. Фәһимә Фәһимә инде, тагын нинди булсын ди ул! «Фәһимә», алар телендә «Пәймә», кушаматы «Фетнә-Петнә Пәймә». Шуннан башкасын Камайдан сорамагыз. Ул беркайчан да кеше турында гайбәт сөйли белми. Һәрвакыт үткен акыллы булган Камай гади тормышта бик гади, самими, беркатлы ихлас егет иде. Начарлык кылуның ни икәнлеген дә белми Камай. Хатын-кызга матур-матур сүзләр әйтеп, күңелләрен күтәрү — шулай ук Камайның гадәтенә кергән бер сыйфаты.

— Сине бүген төштә күрдем әле. Ап-ак күлмәк кигәнсең. Ирегез белән икегез каядыр кунакка барасыз. Икегез дә шат, көләсез, елмаясыз!

Ул бу сүзләрне әйткән хатынның нәкъ шул көнне ире ләх булып эчеп кайтып, өйдә уклау уйнап алган булса да, тегесе моңа чын күңеленнән сөенә, иренә булган ачуы да шундук онытылып, дөнья киң һәм матур булып күренә башлый.

— Яулыгың бигрәк матур, Фәлән апай. Малаең алып кайтып биргәндер инде!

Бу сүзләрне ишеткән апа кеше шәһәрдәге малаеның бүләккә яулык алып кайту түгел, хат та язмавын әйтеп тә тормый инде, хәтта телефоннан да шалтыратып хәл белгәне юк, элегрәк айга бер булса да кайтып күренә иде. Шәһәр кызы белән йөри башлагач, ул кайтулар да сирәгәйгән була. Шулай да Камайдан мондый

мактау ишеткән авылдаш апага рәхәт булып китә, ул авызын ерып елмая, ана рәхмәтләр укый. Анын бик тә, бик тә шул чагында, Камайның бераз гына булса да юлын бүлеп, вакытын алып, малаенын кечкенә вакытта эшләгән берәр шуклыгын сөйлисе килеп китә. Ләкин Камайның тынлап торырга вакыты юк, Камай ашыга. Тик кая ашыкканын үзеннән башка берәү дә белми. Ә теге апа, авызын ерган хәлдә, игелекле теләкләр теләп, анын артыннан бик озак карап, озатып кала. Әйе шул! Матур яулык кына түгел, әллә ниткән кыйммәтле-кыйммәтле бүләкләр алып кайтыр әле аның газиз улы! Бу фикер апа кешене тагын да канатландырып җибәрә. Бер дә ким түгел анын баласы кешенекеннән!..

«Безнең авыл кешеләре... тау башы урамнары Каспий буенда, югары урамнар Алтай якларында, яна урамнар Төньяк Кытай стенасы буйларында яшәгәннәр. Аларнын һәркайсы артыннан яраткан сихәтле чишмәләре дә ияреп кайткан. Әбелхәят чишмәсе Әллүкигә Урал таулары артыннан ук килгән. Искән җилгә утырып килгән. Болыт булып килгән Әбелхәят чишмәсе безнең авылга.»

Бу сүзләрне ул мәктәп балаларына сөйли, Камай абыйларынын күп белгәненә шикләнмәгән бала-чага авызын ачып тынлый һәм һәркайсы күнелennән генә шул мизгел эчендә, хыял канатларына утырып, Алтай тауларына барып кайта, Каспий дингезендә чумып чыга, Ерак Көнчыгышка ук барып житеп, боланнарга атланып йөрергә дә өлгерә. Аннан сон Камайнын түбәндәге такмагын куен дәфтәренә теркәп куя:

Килә давыл, китә авыл,
Барган юлы ни юлдыр?
Идел-Чулман үз йортыбыз,
Авыл китсә ни булыр?
Идел суы кага торыр,
Үз баласын ул да таныр!..
Тынсын давыл.Калсын авыл,
Шунда бөтен көчебез.
Су эчегез, су эчегез!
Олыгыз вә кечегез,
Этегез һәм бетегез!..

Камай сүзләренен, телдән телгә күчә-күчә, авыл буенча йөрүләре исә хак иде:

— Ачуыгыз килгәндә су эчегез!

— Бик каты тамагыгыз ачканда су эчегез!

— Ирегез авыр сүз әйткәндә, телегезне тешләп, су эчегез!

— Шук балагыз чәшке төшереп ватса, ачуланырга ашыкмагыз. Кул күтәрмәгез! Су эчегез! Үскәч, аңа дөнья үзе дә кул күтәрергә өлгерер әле!

— Хатыннарыннан кача-поса ужымга керергә ниятләнүчеләр! Су эчегез!

— Ирләренә хыянәт итәргә уйлап йөргән хатыннар су эчсен!

— Көнче күршеләр! Талашмагыз, су эчегез! Хөсетлегегез тиз басылыр һәм башкалар, һәм башкалар!

Күптән түгел «Диннәр һәм бүгенге дөньяви вәзгыять» дигән темага «Аурупа союзы»нын фәнни Үзәге уздырган бәйгедә Камай Жамалетдиновичнын доклады бүләкле урын алды. Элегрәк, Камайның «су фәлсәфәсенә»дә, кайбер сәер гадәтләренә дә көлебрәк караган кешеләр «аһ» итте! Аурупа бәйгесендә Камай призлы урын яулаган бит! Камай яулаган шул! Аларнын Байтамак Камае! Тигәнәк Камай!!!

Бу вакыйгадан сон алар Жәмил хәзрәт белән дуслашып киттеләр, кичләр буе утырып сөйләшәләр, бәхәсләшәләр дә...

Баштарак Камай Байтимерне өнәп бетермәде. Хәтта ул очучы булса да, космонавтлар әзерли торган төркемдә булганлыгын ишетеп белсә дә, сонрак, Байтамакта агрофирма төзеп, хәзер, халык әйтмешли, аларның «колхоз рәисе» булуына да карамастан! Камай яшьрәк чакта, дөресрәге, малай вакыттан күршесе Нурбикәгә гашыйк иде. Авылда шулай булгалый, малайларны: «Син анын кияве, фәлән-төгән!» — дип котырта башласаң, алар, чыннан да, күрше апасына гашыйк булып куеп, борынына чынлап торып хатын-кызның итәк җиле бәрелә башлаганчы, шул рәвешле хыялланып йөри торган була. Дөрес, яшь аермалары шактый булуга карамастан, буй үстергәч тә, Нурбикәгә булган тартылу хисе сүрелмәде егеттә. Нурбикә Байтимергә кияүгә чыккач исә, үзен кая куяр урын тапмый йөрде әле. Бер караганда менә шундый гади дә, гади дә түгел бер егет иде Жамали малае Камалетдин, «Тигәнәк» кушаматлы Камай...

Байтимер белән уртак кайгы дуслаштырды бугай Камайны. Байтимер аны үзенең кинәшчесе итеп алды. Элеккеге колхоз вакыты булса, әлбәттә, бу аптырарлык, шаккатмалы яналык булган булыр иде. Ләкин хәзер «Байтамак» агрофирмасында көн саен берәр вакыйга булып торганлыктан, хәтта Камайның элек Байтимер үзе йөргән чит ил машинасына күчеп утыруына да гаҗәпләнгән кеше булмады. Ләкин Камайга яшьтәше Саниянең күз кыздырып йөргәнлеген, Байтимер өчен Алтын Бәртәстәге Марфа маржаның җан атуын алар үзләре белми, ә бу турыда авыл кешеләре арасыннан кайберәүләр сизенә башлаган иде инде.

Байтимер Камайны һәм тагын бер егетне, тәҗрибә өйрәнеп кайтыгыз дип, Сингапурга җибәрергә уйлады. Югыйсә алар белән бергә үзе барып кайтса да начар булмас, кайгыларыннан бераз онытылып торыр, дөнья гизәр иде. Юк, Байтимер үзе бармады. Чөнки хакимият башлыклары төркемендә бер барып кайткан иде. Ләкин әлеге сәяхәт турында нигәдер берәү белән дә ачылып сөйләшмәде, урынбасары Борис Айсинның бик төпченеп: «Йә, нәрсә анда? Нинди инновацияләре белән шаккатыра Сингапур?» — дигән соравына каршы: «Җибәрермен. Әнә, Камай белән бергә барып, танышып кайтырсыз», — дип кенә куйды.

Бер атнадан юлга кузгаласы дигәндә, Камай Жамалетдинович әүвәл Сания кочагына түгел, ә Алтын Бәртәснең Марфа маржа кочагына барып керә язды!.. Әтисе Жамали агай, райүзәккә эш-мазар белән киткәндә умарталыкка күз-колак булырга дип Камайны калдыра торган иде. Каравылчы Хәммәткә ышаныч юк, эчү өянәге кузгалып китсә, бер чирек көмешкәгә бөтен умартаны сатып җибәрергә мөмкин. Аны каравылчы итеп тотмас та иде Жамали агай. Тик Хәммәтнең унай яклары күбрәк шул! Монарчы анын бер кашык балга да тигәне, кыек эшләр белән тотылганы да, сизелгәне дә юк. Иң әһәмиятлесе: ул монда каравыл тора башлагач, бал урларга килүче шәһәр этрәк-әләменең эзе суынды. Хәммәт усал һәм гадел каравылчы иде. Күрше Алтын Бәртәскә көмешкәгә барып киләсе булса, ул бүрегә охшаган алагаем зур гәүдәле бик усал этен бәйдән ычкындырып калдыра, өстәвенә, иренмичә, тир-якка бүре капкыннары тезеп чыга иде. Моны һәр кеше белә, шуңа күрә Хәммәтнең Алтын Бәртәстә йөргәнен күрсәләр дә, умарталыкка барырга җөрьәт итүче юк бу тирәдә. Кала тирәсеннән килеп чыгучы булса гына. Алар Хәммәтнең мондый гадәтләрен белмиләр. Кыскасы, Жамали карт райүзәккә чыгып китте, Камай, күз-колак булырга дип, умарталыкта калды. Эт бәйдә иде. Камай умарталыкка килүгә, беренче эш итеп, әүвәл этне бәйдән ычкындыра, бәйдә килеш тотарга кызгана ул аны. Ни дисәң дә, аләм акыллары булган бу этне стансадан ул табып алып кайтты бит. Алабай дигән исемне дә (бу кушаматны очраклы гына Байтимер авызыннан ишетте булса кирәк) үзе кушты. Һәм ни гаҗәп: эт, шулай диюгә, бик тиз ризалашкандай койрыгын болгады.

Агрофирмада эше күп булса да, әтисенең сүзләренә каршы килә алмады

Камай, шуна күрә, ул әйтүгә, умарталыкка килеп житте. Яшерен-батырын түгел: әтисеннән күреп, анда беркайчан да умартачы булу теләге уянмаса да, Камай бал кортлары дөньясын бик ярата, аларга карап соклана, һәм әлеге кечкенә генә кортларнын холык-фигыльләре, гадәтләре аны шаклар катыра иде. Кызыксынучан егет иде Камай, ана бал кортлары гына түгел, хәтта чебен-черкинен дә гамәлләре бер табышмак булып тоелып, ул аларны үз акылы белән ачарга, белергә тырыша иде. Бал кортларына килгәндә исә, Жәмил хәзрәт ана үзенен яшел китабынын бер битенә төртеп үк күрсәтте, менә укып бак, янәсе. Укыды Камай һәм жавап кайтармады, бу нисбәттән ул вакытта фикерен белдермәде, бары үз эченә генә йомылды. Коръәннен «Нәхел» сүрәсендә түбәндәге аятьләр бар иде: «Раббын бал кортларына вәхий кылды: «Ий, бал кортлары, тауларда, агачларда вә кешеләр тора торган унайлы урыннарда үзегезгә оялар ясагыз! Сонра һәр жимеш чәчәкләреннән бал ашагыз һәм жыегыз вә итагать итеп, мин әмер кылган юлга керегез!» — дип. Бал кортлары эчләреннән кешеләр өчен төрле төстәге балларны чыгарып бирәләр, ул балларнын тәме дә, шифасы да бар. Фикерли белгән кешеләргә бал кортларынын гамәлләрендә зур дәреслек вә гыйбрәт ятадыр. Кешеләр бал кортларына түгел, бал кортлары аларга дәрес бирер». Әйе, монысы хак, ләкин яналык түгел дип уйлаган булыр иде Камай башка чакта. Мәгълүм бит: бал кортлары балны үзләренә житәрлек микъдарда гына әзерләми, дистәләрчә тапкыр күбрәк жыя алар ширбәтне! Ни өченме? Кешеләр өчен!.. Чөнки Аллаһ тарафыннан аларга шундый эш йөкләнгән! Менә бит ул!... Бу хакта аятьләрдә ачыктан-ачык әйтелә ләбаса!..

Әйе, кемгәдер нәрсәнедер дәлилләү өчен ерак барасы түгел, анын өчен әтисенен умарта бакчасына килеп, бал кортларынын тормышын күзәтү дә житә. Аларнын тормышы хакында фәнни мәгълүматын булса, тагын да әйбәтрәк. Тик фән бал кортларынын холык-гамәлләрен төп-төгәл анлатып бирә аламы сон? Менә шунысы әһәмиятле иде Камай Жамалетдиновичка! Чөнки дөнья үзе генә түгел, анын һәр бөжәге могжиза белән чишелмәс табышмактан тора! Чишелмәс? Юк, Камай аларны чишәргә тиеш... Чишелмәгән табышмакны яратмый ул. Чөнки, бер караганда, тормыш-яшәеше белән дә, кайбер чакларда холкында, үз-үзен тотышында чагылып-чагылып алган сыйфатлары белән дә Камай үзе бер табышмак сыман. Ләкин ул барыбер гап-гади бер адәм баласы, ана дөньянын һәр ягы да чит-ят түгел, гәрчә кайбер сәер гадәтләре күзгә бәрелеп торса да... Яше утызга якынлашса да, өйләнү турында уйлау түгел, анын хәтта кызлар кулын тотып караганы да юк. Хатын-кыздан курка Камай. Нурбикәгә гашыйк булу малай чакта калган, ул бары тик бер самими балалык гамәле генә, сабыйлык, өлкәннәрне кабатларга тырышу гына. Әйе, монысы бал кортлары «табышмагыннан» да катлаулырак табышмак! Әлбәттә, Камай өчен түгел, авылдашлар, беренче чиратта, әтисе өчен, әмма әнисе өчен түгел. Әтисенә оныклар кирәклеге анлашыла. Камай берданбер малай бит. Тик ул оныклар нишләп әнисенә кирәк түгел икән сон? Ни өчен килен кирәк түгел икән әнисенә? Юкса улын өйләндерергә тырышучы беренче кеше ул булырга тиеш бит?!

Хәер, бал кортлары хакында уйлану барыбер рәхәтрәк... Хәтта һәр гамәлләре табышмакка охшаш булса да... Менә, мәсәлән, ун ай буена аларнын ояларында (кеп-кечкенә ояларда бит әле!) жыелган бал ни рәвешле бозылмыйча саклана ала? Димәк, аларнын «суыткычлары» бар, «жылыткычлары» ояда һәрвакыт 35 градусны саклап тотып тора!.

Тагын мисаллар кирәкме? Табигатьтә төрле бактерия-вируслар мыжгып торганлыгы мәгълүм. Менә шулар ояга үтеп кермәсен өчен ишек төбендә берничә сакчы корт кизү тора икән. Әгәр дә зуррак башка бөжәкләргә көчләре

житмәсә? Моның да җае бар: бал кортлары җилем кебек махсус сыекча бүлеп чыгара һәм ояга эләккән теге «дошман»ны шуның белән ябыштырып, катырып куя икән! Әлеге корт тизәге (прополис) белән алар оядагы тишек-тошыкларны да ямыйлар, ул җилдә, кояшта тагын да ныгый һәм менә дигән төзү-ремонт материалы буларак хезмәт итә.

Галимнәр раслаганча, әлеге сыекча эчендә бактерияләр үрчи алмый. Алар моны каян белгән соң? Төрле үле бөҗәкләр белән бергә ояга ияреп кергән бактерияләр аларның өйләрен кыска вакыт эчендә һәлак итәргә мөмкин икәнлеген кайдан белгән бу бал кортлары? Әллә алар тумыштан ук химиклармы? Әлбәттә, алар моны белми, гәүдәләре бер-ике сантиметрдан артмаган ошбу бөҗәкләр химияне дә «белми». Шулай булгач, ни дип уйларга кала соң инде? Андый чакларда Камай, күккә багып, үзенең фәлсәфи иреннәрен кыймылдатырга гадәтләнеп китте...

Камайның әлеге дөньяви булмаган фикерләрен Алабайның ярсып өргән тавышы бүлдерде. Шуның артыннан ук ачыргаланып кычкырган хатын-кыз тавышы ишетелде. Ул ашыгып өй артына чыкты һәм тагын да гаҗәбрәк күренешкә тап булды: аңа таба, йөгерә-атлый, хатын-кыз кыяфәтендәге шәп-шәрә бер нәрсә килә иде. Әле һаман берни аңламыйча тораташ кебек басып торган егетнең башыннан мизгел эчендә ошбу фикер чагылып узды: «Күбрәк хыялланган, шулай була ул: күзгә әллә нәрсәләр күренә башлый!» Тик, гонаһ шомлыгына каршы, әллә нәрсә түгел иде бу, күрше Алтын Бәртәснең Марфа марҗа бит, шәп-шәрә үзе. Чү, ник көлә соң ул? Әллә бик каты курыккан, әллә шулай ялангач булуы үзенә дә бик ошыймы? Камай, аны-моны абайлап өлгергәнче, Марфа аның кочагына ташланды. Баксаң, кызның күлмәген бәйдән ычкындырылган Алабай аерып төшергән икән! Хәзер Камай үзе каушады. Марфаның тыгыз имиләре аның күкрәк читлеген кысты, муенына килеп бәрелгән кайнар сулышы тәнен пешерде. «Әллә күлмәген генә түгел, башка эчке киемнәрен дә аерып ташлаган инде Алабай моның? — дип уйлап куйды әле һаман аптырап басып торган Камай. — Хәер, күлмәктән башка бүтән эчке киеме булмагандыр Марфаның. Алабай кызны барыбер шәп-шәрә калдыра алмас иде...» Ул, үз күлмәген салып, Марфага бирде. Үзенең шәрә булу оятыннан Марфа җир тишегенә кереп китәргә әзердер, — дип уйлады ул һәм аны юатырга теләп:

— Вәт, кызык! Мин сине бүген төштә күрдем! Шәп-шәрә килеш. Гүзәл фәрештә кебек идең, — дип куйды. Кыска ирләр күлмәге кызның түгәрәк ботларын каплап бетерә алмаган, ул хәзер тагын да матуррак, гүзәлрәк һәм серлерәк тоелды Камайга. Марфа, берничә төймәне төймәли алмады, аның мул күкрәкләре Камай күлмәге эченә генә сыешмады. Кыз бик тә унайсызланыр дип көткән иде, тик алай булып чыкмады, Марфа телен тешләп өзәргә өлгермәгән икән:

— Төштә гүзәл, ә хәзер алай түгелмени? — дигән булды, кыланчыкланып. «Вәт марҗа!» дип эченнән генә уйлап куйды Камай һәм, кызга кулын сузып, өйгә әйдәде.

Марфа ничек кенә тыныч булырга тырышса да, Камай электән белгән бу чая кыз барыбер эчтән калтырана, өй эченә кергәч, әлеге халәте тагын да ачыграк күзгә ташлана иде. Камай, мич буендагы имән кисмәктән салкын чишмә суы тутырып алып, аңа сузды:

— Су эч!

Марфа йотлыгып эчте һәм калган суны каршысында кызарып-бүртенеп басып торган егеткә сузды:

— Син дә су эч, Камью! Дәртең суыныр. Алайса өскә ташланырсың тагы...

Камай үзе дә су эчеп куйды. Бу рәвешле сүзсез-авызсыз катып тору килешми, унайсыз иде, шуна күрә Камай сүзне башка темага борырга теләп:

— Бал кортлары чакмагандыр бит? — дип сорап куйды.

— Мине корт чакмый, — диде кыз анын соравына каршы.

— Алар матурлыкны анламый торганнардыр шул!

— Анламасалар, чәчәктән чәчәккә кунып очмаслар иде.

— Синдәй чәчәккә кунмаганнар бит әле!

— Алар мине таный, — дип куйды кыз.

— Таный?

— Ыһы... Оныттынмыни? Мин дә умартачы кызы бит! Дядя Гена... Геннадий Медведьев. Алтын Бәртәс умартачысы.

Әлбәттә, Камай умартачы Гена дәдәйне дә, малай чакта ул ашаган балнын тәмен дә яхшы белә. Умартачынын балына караганда кызы, җиләк кебек кызы, бал иренле Марфасын белү дә житеп тора иде канә бу минутларда!.. Юкка гына кызарынмады, бүртенмәде, егет кайнап чыкты. Ул хәзер үзе Алабай булырга әзер иде. Нишлисен, умартачы Гена дәдәй анын әтисе белән дуслар иде, аралашалар иде. Тик менә Камай электән белгән чыра торыклы Марфушаны танырлык түгел, тәмам пешеп житкән, жиләк кебек кыз-хатын булып өлгергән.

— Син тагын су эчеп куй, Камью! — диде Марфуша һәм үзе карават читенә барып утырды. Камай тагын бер чүмеч су алып эчте. Суынды бугай. Дөресрәге, суынган шикелле булды.

— Баймурзин машинасы дип торам. Капка бикле булгач, киртә аша гына кермәкче идем. Теге җүнсез этегез...

— Монда Баймурзинны эзләп килденмени?

— Юк. Җиләккә дип. Бераз арырак кура җиләге күп. Кирилл атакай чирләп китте дә. Катя үтенгән иде.

— Әтиен ни хәлдә?

— Урын өстендә һаман.

— Теге бандитларны тапмадылар бугай?

— Аларны эзлисе юк, болай да билгеле бит кемнәр икәнлеге, — диде Марфа һәм сүзне икенчегә борды. — Мин гомер буе бал кортларына сокландым. Бала чакта алар мина бөтенләй чишелмәс табышмак кебек иде. Мин әти янында пасекада үстем бит.

— Табышмаклар хәзер чишелдеме инде?

— Юк, — диде Марфуша. — Этегез үземне чишендерде...

— Сез мәчеткә укырга йөри башлагансыз икән Катя белән.

— Катя ул мина ияреп кенә йөри инде шунда.

— Ә син кемгә ияреп?

— Үзем теләп!

— Нишләп үзен теләп чиркәүгә йөрмисен? Хәзер побыгыз да бар бит инде.

Марфа ирен читләре белән генә көлемсерәп куйды да шунын артыннан ук сорауга каршы сорау белән җавап бирде:

— Әйт әле, менә син рус кызына өйләнер идеңме?

— Белмим, — диде анын бу соравына каршы Камай кыюсыз гына. — Әлегә беркемгә дә өйләнеп караган юк.

— Ну шулай да... Әйт әле, Камью, рус кызына өйләнер идеңме син?

— Яратып та караган юк әле минем. Башымны катырма, Марфа!

— Ә беләсеңме, Камью?

— Белмим! — диде тегесе коры гына һәм шул мизгелдә бая эчкән чишмә суынын организмында каны белән бергә тагын кайный башлаганын тойды.

Чибәр иде шул бу җете зәңгәр күзле Марфа! Аны бая ялангач килеш күрү егетне бөтенләй әсәрләндерде. Ләкин бу ыргылу зина саналачак. Монысы дини фәлсәфә. Бал кортларынын да үз фәлсәфәләре бардыр. Ә менә Марфаны караватка күтәреп салу да шулай ук яшәеш фәлсәфәсе түгелме соң? Тик бер ягы белән генә аерыла: ул хайваннар өчен беркайда һәм беркайчан тыелмаган. Камайның шушы минутларда хайван буласы килеп китте. Үз гомерендә моңарчы кызлар кулы да тотып карамаган егет өчен бу алга сикереш иде. Хәер, ошбу ният һәр ир-атның яшерен генә күңел түрендә яткан «фәлсәфәсе» түгел микән?! Янәшәсендәге кыз-хатынның әхлак чиләге капкачы ачык булса, әлеге ике «ният-фәлсәфә» һичшиксез берләшәчәк. Мондый татлы уйлардан Камайны Марфушаның ягымлы тавышы бүлдерде:

— Мин гүзәл бит, Камью, чынлап та?

Камай җавап кайтармады, авыз эчләре чатнап кипкән иде.

— Камью ник дәшмисең? Әллә ямьсезме мин?

— Син гүзәл... — дип пышылдады Камай һәм үзе өчен серле булган яңа дөньяга таргандай, акрын гына кызга таба атлый башлады.

Марфуша күлмәк изүенең тагын бер төймәсен ычкындырды, ап-ак матур күкрәкләрнең яктысы бу мизгелләрдә син адәм баласы булсаң да, хайван булсаң да аңыңны алып, һушыңнан яздырырлык иде.

— Чынлап та матурмы, Камью?

— Ие, ие... — дип пышылдады Камайның хисле иреннәре.

— Алайса... Бу хакта Байтимергә әйтерсең, яме! Марфа кебек гүзәл бу дөньяда башка юк! Йоклап йөрмә диярсең, яме, Камью?! Әй, Камью дим! Дөньяңны оныттыңмы әллә!

Марфа имән кисмәктән бер савыт су чүмереп алды да аның бер өлешен Камайның башыннан койды һәм кырыс тавыш белән:

— Мә, су эч, егетем! — диде. Марфушаның әхлак чүлмәге ябык иде, чөнки Марфуша хатын-кыз иде шул. Ходай Тәгалә кыз-хатыннарга тыелу дигән көч биргән! Кайберләренең генә бу байлыкны алырга чираты җитмәгәндер, күрәсең. Хатын-кызны тәүфикъ кына бәхетле итәчәген бик күпләр белми дә торгандыр әле. Анысы шулай. Тик моңарчы хатын-кыз күргәне булмаган Камайның кай җиредер кытыклана башлады. Моңарчы кызлар «тиле» дип, аның янына килмиләр, ә ул килмәсәгез, кирәгегез дә шунын чаклы гына, дип яшәде. Юк, юк, сау-сәламәт егет иде Камай. Яшүсмер чакта, чынлап та, ул бераз сәеррәк булгандыр, шуңа күрә кызларга да сүз кушарга кыймагандыр... Тик... хәзер? Хәзер ни булды соң? Әмма күпме генә баш ватса да, Камай атлы яшь егет үзенең, ниһаять, кытыгы килә башлаганын белә алмады... Ә ул кытык уянды һәм аның бар гәүдәсен рәхәт кымырҗытып тора башлады. Күз алдына шулчак тол хатын Сания килде. Урамда очраткан саен ул аны өенә чакыра, ишек йозагын каратырга дип. Моңарчы Камай аның андый гозерләренә кул гына селти иде. Бүген исә, кереп чыгарга кирәк, йозагын карап, дигән фикергә килде...

Эт өргән тавыш аларның икесен дә сискәндереп җибәрде. Тәрәзәдән ишегалдында кем йөргәнлеге күренми, Камай урамга чыкты һәм Варисны танып:

— Нишләп йөрисең монда? Адаштыңмы әллә? — дип сорамыйча булдыра алмады.

— Адашмадым, Камай абый, срочно райүзәккә чакырталар. Машинаңны биреп тор әле дип кергән идем, — диде ул. Камай чит илдән гыйлем җыеп кайткан яшь мулланың гозеренә каршы килә алмады, машинасын бирде, ләкин ул юл унаеннан Марфушаны Алтын Бәртәскә дә илтеп куярга тиеш иде.

Варисны бигүк өнәп бетерми Камай. Элегрәк бик вәкарь белән генә, тавышын бөер турысыннан чыгарып сөйләшкән бу мулла кисәге соңгы арада

бөтенләй үзгәрде, дөресен генә әйткәндә, сәерләнде дисән дә була. Шуна күрә кызганды бугай аны Камай бүген.

Чукынчык маржа тәки егетнен канын кыздырып калдырды. Әле машинага утырыр алдыннан да:

— Әгәр рус кызы ислам диненә күчсә, син ана өйләнер идеңме, Камью? — дип мәгънәсез соравын кабатларга өлгерде. Хатын-кыз елан кебек ул, дип әйтергә ярата Хәсәненә фетнә Фәһимә. Хаклы, мен тапкыр хаклы иде бу очракта авылдаш хатын, чөнки бал корты өендә елан чагудан Камайның жаны урыныннан кузгалып, йөрәгендә дәрт агуы калды. Бал корты түгел, нәкь менә елан чакты... Машина кузгалып киткәч, Камай, өйгә кереп, кисмәктән янә бер чүмеч су чөмереп алды...

Сусавы басылды, тик Марфуша калдырган баягы яктылык күләгәсе киртә буендагы печән үскән жиргә сузылып яткан кебек. Күләгәсе генә. Яктылык үзе исә, аның күзәнәкләре аша үтеп кереп, кан тамырлары буенча ага.

Улының ошбу халәтен иң беренче булып әнисе сизде. Әлбәттә, әни кешенең башыннан шундук, әллә өйләнергә исәпли инде, дигән фикер яшене ялтырап узды. Сонра, ялгышканын аңлаган ана, бер дә хафаланмады, анын өчен иң мөһиме баласынын исән-имин булуы иде. Бердәнбере бит! Алай гынамы, Камалетдиннан соң бүтән балага уза алмаячагын Гөлжиһанга теге вакытта ук сиздерделәр!.. Кем, ничек житкерде бу хәбәрне? Белми. Һәм бервакытта да, ни хикмәт, төпченмәде дә. Хактыр ки, Гөлжиһан Камалетдиннан соң башка бала тапмады. Ире янында корт бакчасында чакта тотты аны тулгагы. Табуын да шунда тапты. Каен жиләге котырып уңган июль ае, матур июль ае иде ул. Хатыны авырый башлагач, Жамали янәшәдәге аланлыкта каен жиләге жыйган авыл хатыннары янына йөгерде. Алла рәхмәте, Маһишәкәр исемле апа кендек әбисе булды.

Бала дөньяга килгәннән соң күзен ачып жибәрүгә, урамда көтмәгәндә яшен яшьнәгән кебек булды. Яктылыкны тәгаен күрде әни кеше, тик яшен артыннан гадәттәгечә күк дөбердәгән тавыш ишетелмәде, яңгыр да яумый, күк йөзендә бер болыт әсәре дә күренми, жәйге көн чалт аяз. Бәлкем, ажаган булгандыр?.. Тик әлеге яшен утының яктысын ире Жамали да, кендек әбисе Маһишәкәр дә күрмәгән булып чыктылар. Тәгаен сирпелде ул яктылык, һәм әлеге хәл дөньяга түп-түгәрәк малай аваз салгач булды. Әгәр бала алты ае булды дигәндә авырып китмәсә, әлеге яктылык (Кояш күзе!) турында, бәлкем, Гөлжиһан беркайчан да исенә төшереп карамаган булыр иде. Шундук онытты ул аны. Өстәвенә аннан башка бүтән кеше күрмәгән дә бит. Сорап карады югыйсә...

Умартачының балдан гына торган малае урманда дөньяга килде. Кендек әбисе, шөкер, Апуш мәэзин кисәткәнчә, тәрәзә пәрдәләрен тартып кую турында уйлап та карамады. Яңа туган сабыйны беренче булып Кояш үзенең күз карашы белән үпте... Ходай рәхмәте белән дөньяга бигүк гадәти булмаган бер Адәм баласы туды... Бик борынгы бер милләтнең, инде әйтелгәнчә, — галәмнән килгән илаһи яктылык ярдәме илә янә баш калкытырга керешкән бер кавемнең, — баласы килде дөньяга. Илаһы элек адәмнәр арасына пәйгамбәрләрен жибәреп торган кебек, әле дә, вакыт-вакыт, могжизалы акыл ияләрен кешеләр янына жибәрә иде...

Алты айлык баланың авыру галәмәте дә гайре табигый булды: монарчы гел елап яисә тавыш биреп яткан нарасый бермәлне тынып калды. Күзләре ачык, үзе селкенә, кыймылдый, тик ими сорап та, асты юешләнсә дә, элеккеге кебек еламый. Әнисе имиен авызына каптырса, иренеп кенә суыра, әмма, гадәттәгечә, ике күкрәкнең дә сөтен ашап бетерә бетерүгән. Ләкин монарчы орчык йомгагы кебек хәрәкәтчән баланы алыштырып куйдылармыни, ул ничектер үзгәрде.

Райүзәккә хастаханәгә дип җыенганнар иде инде, нәкъ шул сәгатьтә кулына сөт бидоны күтәргән кендек әбисе Мәһишәкәр килеп керде. Ул бер сүз дә әйтмәде, өстәл өстенә бидонны утыртты да әүвәл түр караватта таралып яткан бала янына килде, аннары иреннәрен кыймылдатып, беркавым басып торды да: «Әбелхәят чишмәсенең суы бу. Коендырыйк әле шуның белән», — дип, өстәлгә таба ымлады. Баланы Әбелхәят чишмәсенең суы белән баштан-аяк коендырдылар да, бик яхшылап төреп, урынына салдылар. Беркавымнан өй эче бала елаган тавыш белән тулды, ул хәтта, тыпырчынып, биләвен дә сүтеп ташларга өлгергән иде. Кендек әби: «Син бала тапканда күргән теге тавышсыз яшенне мин бүген төшемдә күрдем», — дип әйтмәкче иде, ләкин бу фикереннән кире кайтты һәм: «Безнең чишмәнең суы бик сихәтле шул», — дип кенә куйды. Шулчак Гөлҗиһанны ток суккандай итте. Ул ишек янында басып торган ирен капылт кына ничек читкә этеп җибәргәнен үзе дә абайламый калды, тик бу мизгелдә аның ирендә эше юк, ул капкага таба барган Мәһишәкәр әбинең артыннан кычкырды: «Майшәкәр апа! Чү! Чак кына сабыр итче! Тукта! Китми тор!» — дип кычкырды да үзе янә караватт башындагы өй почмагында торган сандыгын ачты. Сандыктагы кендек әбисенә яки бала табарга ярдәм итәргә булышкан шәфкать туташына әзерләнгән бик матур күлмәклек, дүрт почмаклы ап-ак яулык алды да ишегалдына чыкты. «Кул ялын онытып торам икән бит, Мәһишәкәр апа», — дип, төргәкне Мәһишәкәргә суззы.

Кендек әби капкадан: «Әл-Варис!! Шөкер Әл-Вариска һәм бу нарасыена! Шөкер!» — дия-дия үзалдына кабатлап чыгып китте.

Рәхимле булсан иде, йа Әл-Гани, бу нарасыйга!..

## Үтерүче кем?

Сәхабинең чырае көннән-көн сүрәнләнә барды. Тикшерүчеләр Байтамакның Борис исемле кешене кем үтергәнлеген эзлиләр, ул исә, барысын да энәсеннән җебенә кадәр исенә төшерергә тырышып, гасырлар хәтере арасыннан төп гаепләне эзләү белән мәшгуль булды. Борын-борын заманнардан башлап эзләде Сәхаби... Башы мәгълүм кебек, ахыры билгесез... Борын заманнан ук эзләргә кирәклеге хак һәм көн кебек ачык иде...

Борисны кем үтергәнлеге әлегә һаман сер булып кала бирде. Алма бакчасына каравылчы булып эшкә урнашканнан бирле тирә-юньдә һәм бигрәк тә «Байтамак» агрофирмасынданиләр булып торганлыгы Сәхаби өчен сер түгел, ләкин теге канлы җинаятьнең кем тарафыннан кылынганлыгын белмәү Сәхабине дә бик борчый. Бориснын малаен да әнә акылдан язганга чыгардылар. Монысы анлашыла, чөнки Варис, әтине мин үтердем дип, тикшерүче янына үзе барган. Аны беркавым ябып тотсалар да, җинаять вакытында малайның бөтенләй башка җирдә, төгәлрәге Алтын Бәртәстәге дуслары янында булганлыгы ачыкланугa, азат иттеләр. Малай әтисен югалту кайгысын шулай бик авыр кичереп, башына бәргәндер дигән фикергә килгәннәр иде. Борис үзе дә берләнбер баласы өчен җан атып тора, әллә кайдан зур акчалар юнәтеп, ул аны чит илгә укырга җибәрде. Байтимердән үтенеп, яңа салынган мәчеткә имам иттереп тә куйдырган иде. Авылдашлары белән уртак тел таба алмау сәбәпле хәзер мәчеттә анын урынына Җәмил хәзрәт.

Алма бакчасындагы ерганактан сынган чалгы табып алганнан сон тынычлыгы югалды Сәхабинең. Чалгыны ул бакча кырыендагы кычытканнарны чабу өчен кирәк булыр дип алып кайтты. Чөнки аның сабы гына сынган, ә чалгы тимере, башы кәкрәйгән булса да, исән. Чалгынын сабы исә ниндидер тимерме, үтмәс балта беләнме махсус бәреп сындырганнар кебек. Чалгы тимере сапка

тоташкан урында ул әле кибәргә дә өлгермәгән кычыткан яфраклары һәм куе кызыл таплар күргәч сәерсенде. Башта ул бу хакта Байбулат агага да әйтмәкче иде, соңра килененең вафаты кайгысыннан исереп йөргән картны борчымаска булды, чалгыны каравылчы өе артындагы кычыткан арасына яшереп куйды. Кемне гаеплисен ди? Өстәвенә Варис гаепне үз өстенә алган дип ишетте, димәк, җинаятьче табылган дигән сүз бит.

Ләкин халыкның телен тыеп булмый. Әлеге фаҗигале һәм серле җинаять хакында төрле хәбәрләр йөрде. Байтимернең гаепсезлеге ачыклангач, шик Ябалак урманы артындагы фазенда хуҗасы Галингa төште. Имеш, ул Байтимергә үч итеп шулай эшләгән. Соңгы вакытларда Борисны салмыш баштан тол хатын Сания капкасыннан кереп киткәнлеген дә күргәннәр. Шуннан чыкмаган, имеш... Малае бозык юлда йөри башлаганга түзә алмыйча үз-үзенә кул салган дип сөйләүчеләр дә булды. Байтимергә үч итеп эшләнгән эш дипючеләр дә күп. Чөнки «Байтамак»ның эшләре гөрләп бара, көнләшүчеләр юк түгел иде. Алтын Бәртәстәге Хөллиев коттеджына кереп оялаган «Ради Христа и именем Мухаммеда и для благо Адама» дип аталган яшьләрне рухи яктан тәрбия кылу фонды кешеләреннән дә шикләнделәр. Соңгы вакытларда Борис ни өчендер алар янына барып тавышланып йөргән, имеш. Әлеге фондның җитәкчесе Радий исемле сакаллы кеше булганлыктан, аны «радикныкылар» дип атап йөртәләр иде. Ләкин бу имеш-мимешләрнең берсе дә чын хакыйкатьне ачыкларга ярдәм итә алмады.

Сәхаби ерганактан тапкан чалгыны тагын кулына алды һәм аны чүпрәккә төрде дә тимерчелеккә китте. Чалгының сабына караганда аның хуҗасы ир-ат булырга тиеш түгел, тик менә ул ирләр кулы белән бик һәйбәтләп тапалган, кайралган иде. Болай яхшы һәм дөрес итеп чалгы тапый алган ир-ат хуҗа, әлбәттә, аның сабын да адәм рәвешендә тотарга тиеш!..

Ул килгәндә тимерче ат дагалый иде. Эшен бетергәч, Сәхаби сузган чалгыны кулына алды һәм беркавым уйланып торды, аннары юан, кыска бармаклары белән аның тимерен тотып-тотып карады, шәлперәйгән кулына бәйләнгән капрон җепне күргәч, ирен читләрендә мыскыллы елмаю да кунып алган кебек булды, аннары гына Сәхабигә күтәрелеп карады:

— Таныш шикелле бу мина.

— Кемнеке соң? Хәтерләмисенме? — дип сорады тегесе. Тимерче Зыятдин ага күп сүзле кеше түгел, ачылып китәргә ашыкмады. Беркавымнан ул барыбер:

— Мин генә тапыйм чалгыны болай иттереп, — диде.

— Син генә?

— Мин генә дә дип инде... Тагын бер кеше бар...

— Кем, кем? — дип сорады Сәхаби.

— Нишкә ул сина? Әйтәм, алайса, минем малай!

— Синең малай? Кайда ул малаең хәзер? Кем ул?

— Чалгы тапамый инде ул хәзер. Китаплар яза. Казанда яши ул. Ник, телевизордан бер дә күргәнең юкмы әллә?

— Бәлки, берәрсе ана чалгысын тапап бирүне үтенгәндер?

— Авылга кайткан чагындамы?

— Әйе, авылга кайткан чагында!

— Белмим, әйткәне булмады.

— Синең тагын малайларың бармы, чалгы тапый белгән?

— Бар иде, — диде тимерче көрсенеп. — Хәзер юк инде ул!

— Кайда соң ул!

— Каен төбендә!

Сәхаби тимерченең авырткан җиренә кагылды, ахрысы, ул тынып калды. Ләкин кызыксыну хисе көчлерәк шул:

— Син миңа ачуланма инде, Зыятдин ага! Белмәдем бит!

— Күпләр белми, — диде ул нигәдер һәм чалгыны янә кулына алды.

Сәхаби барысын да белә иде, әлбәттә. Тимерче Зыятдин аганың Нияз атлы гөрнәдирдәй малаеның очраклы рәвештә һәлак булганын да, армиядән кайткач, сигез ел Мәскәүдә яшәгәнлеген дә, анда өйләнеп Эльнара исемле үзе кебек зәп-зәңгәр күзле бик матур кызы бар икәнлеген дә, һәммәсен дә... Ул гөрнәдердәй егетнең бик кече күңелле, бабасы Фәләхетдин кебек юмарт, ләкин бик кыю егет икәнлеге дә мәгълүм иде аңа. Ходай Тәгаләгә андый егетләр кирәк булгандыр, күрәсең, егерме тугыз яшендә ул аны үз катына алды. Зәһәр жилле ноябрь аеның нәкъ башында, аягы таеп китеп, бишенче кат балконыннан егылып төшеп, бертуган абыйсы кулында җан-тәслим кылуы тәкъдиренә язылган булгандыр инде... Югыйсә яшәргә теләге искиткеч зур, тормышны да, зәп-зәңгәр күзле кечкенә кызын да бик ярата иде... Аның үлеменнән соң ни генә сөйләмәделәр: имеш, үзе балконнан сикергән, имеш, болай булган, тегеләй булган! Башсыз малай иде ул, әлбәттә, матур мәгънәсендә, сынландырып әйткәндә. Тик имеш-мимешләрнең генә берсе дә хак түгел. Рәхмәт яусын, имеш-мимешләрне ишеткән бер таныш кеше дә шулай дип йөзгә бәреп әйтмәде тагы...Чөнки киң күңелле, игелекле кеше иде ул бала. Авылга кайткан чакларында да мохтаҗ булган кешеләргә һәрвакыт ярдәм итәргә әзер торды. Чү, тукта?! Исән вакытында кемгә чалгы тапап бирергә мөмкин иде соң ул? Зыятдин агай исенә төшерә алмады. Тик, ни гаҗәп хәл, шул вакыт Зыятдин аганың бу алма бакчасы каравылчысына оныгы турында сөйлисе килеп китте.

— Күптән түгел Мәскәүдән оныгы кайтты, — диде ул, Сәхабигә чалгысын кире сузып. — Капка төбендә басып торабыз шулай күршеләр белән. Һәммәбез дә бабайлар инде. Мин кырынмаган дә әле. Лапаста йөргән киемнәрдән генә. Машинадан төште дә онык, мине әллә каян танып алып, туп-туры үз яныма килде, «Дәү әти» дип, кочаклап та алды. Зур кыз булган инде. Кытайда да укып кайткан. Әллә ничә чит тел өйрәнгән. Дәү әнисе догалар белә. Һәр көнне укый ул, оныкларына теләк тели. Бәхетле балалар булырлар, Алла боерса... Кан тарта дип юкка гына әйтмиләр икән ул... Танып алды бит кызым... Югыйсә күрешмәгәнгә дә ничәмә-ничә еллар иде. Мәскәү бит, аралар ерак. Рәхмәт әнисенә, кызны һәйбәт итеп тәрбияләгән, кеше итеп үстергән. Рәхмәт инде киленгә!.. Сергач кызы ул, Фаилә исемле.

— Мәскәү киленне бик яратасың, ахрысы?

— Барысын да яратам. Олы малайның хатыны бервакыт шулай урманга җиләк җыярга киткән җиреннән адашты бит. Җәяүләп чыгып йөгердем артыннан эзләргә. Казакъстан кызы бит, бездәге шикелле урманнарны күргәне юк. Менә шул... Табып алып кайттык. И сөенүләр шул чакта. Үз кызыбыз шикелле ул безгә...

Зыятдин ага шул сүзләрен әйтеп бетерде дә, чалгыны тагын кулына алды һәм Сәхабигә гаҗәпләнеп карап:

— Кан түгелме соң монда?! Нәрсә, берәрсе чалгы белән тавык суйганмы әллә? Каны свежий бит әле! — диде. Кан тапларын Сәхаби үзе дә күреп алды. Тимерче чалгыны кире сузды. — Минем малайның үлгәненә биш былтыр инде, — диде ул һәм тимерче алачыгына кереп китте. Сәхаби аннан: «Ә олы малаен?» — дип сорамакчы иде, тик вакытында телен тешләп өлгерде. Чөнки бу вакытта әлеге вакыйгаларны хәбәр итеп утыручы өлкән малай Борис Айсинны кем үтергәнлеген үзе дә белми. Әлбәттә, ул беленәчәк, Җәбраил фәрештә ярдәме белән берәрсенә бу хакта хәбәр итәчәк... Дөресрәге, әлеге хәбәрне күк йөзенә язылган каурыйсыман болытлардан Сәхаби укыячак иде...

Зыятдин ага алачыктан кире чыкты, инде кузгалырга әзерләнгән Сәхабигә:

— Кече малай да бик кече күнелле, һәркемгә ярдәм итәргә атлыгып тора ие, дип әйттем бит әле. Аннан да сорап карармын, яме, Сәхаби, — диде житди кыяфәт белән.

— Кайчан? Ничек?!

Сәхаби аптыраашта иде.

— Тегендә баргач инде, — диде тимерче һаман да әле житди рәвештә. — Кайчан булса да барыбер бер тагын күрешәсе булыр бит. Минем абыстай китаплар укый, вакыт булганда мин дә тынлаштырам инде шунда.

Шул күрешүдән соң күп тә узмады, Зыятдин ага вафат икән дигән хәбәр ишетте Сәхаби. «Күнеле сизенгән икән!» — дип уйлап куйды ул үзалдына. «Авыр туфрагы жинел булсын!..»

Икенче бер вакыт, йомышы төшеп, тимерче алачыгына сугыласы иткән иде, якынрак килгәч, сандалдагы тимергә бәрелгән чүкеч тавышы ишетелә башлады, әүвәл сәер булып китте, аннары әлеге хисне аптырау алыштырды: чүкеч тавышына кадәр таныш — Зыятдин аганың хәбәр биреп торучы малае, сүз иясе, каләмен ташлап, кулына чүкеч алмагандыр бит инде?! Тагын да якыная төшкәч, күрде — Зыятдин ага үзе түгелме соң? Менә сина табышмак! Ул ана, тегесе Сәхабигә карап тик торалар!..

— Ие, күктән төштем! — дип куйды тимерче, аның сораулы күз карашына жавап итеп. — Ул гадәттәгечә шаяртта иде.

«Үлеме турындагы хәбәр ялгыш булган икән!..» — дигән фикергә килеп өлгергән Сәхаби нәрсә булса да сорарга һаман батырчылык итми әле. Зыятдин ага ана үзе ярдәмгә килә:

— Әйткәнием бит мин сиңа малай янына барып кайтам әле дип.

«Әллә клиник үлем булганмы моның?» Әлеге фикере үзенә дә кызык булып тоелган Сәхаби, бу юлы инде тартынмыйча, унайсызланмыйча:

— Үлгән дигәннәренә тамчы да ышанмаган идем түлке, — дип куйды. Олы кешенең хәтере калыр дип уйламады да...

— Сине үлеп тә ышандырып булмый икән инде, алайса!

— Булмый, — диде тегесе фикерле иреннәре белән.

— Йә, сөйлә, алайса!

— Һе... нәрсәсен сөйлисең инде аның? Алып киттеләр үз киемнәренә киендереп. Кызык анда: әүвәл бар дөнья ап-ак нурга күмелгән ие, аннары төрле аллы-гөлле төсләр күренде. Аннары шул юлның бер башында яктылык күренгәндәй булды. Мин шул тар жир астыннан очтым гына инде... И анда халык! Исәбе юк кешенең! Болар арасында тапталам, ахры, мин әйтәм. Юк, тапталмыйсың икән, бар да тәртип белән анда! Этеш-төртеш тә, ыгы-зыгы да юк. Малайны күреп алдым. Әйдә, мин әйтәм, өйгә кайт, кызыңны да күреп китәрсең, дим. Бер сүз дә әйтми. Үзе елмая тагын. Сөйләшмиләр икән анда...

Агач сука белән жир сөрәләр анда. Трактор да, плугларын да күрмәдем. Минем малай да агач сука тоткан. Исән чагында, фермер гына булмыйсыңмы соң, ул Мәскәүләрдә йөргәнче дигәч, жир сөреп кем баеган ди торган ие. Тимер сукалар булмагач, мин әйтәм, алайса боларга тимерче дә кирәкми икән инде дидем дә, кире кайтып китәргә булдым мин... Менә...

Берәү булса, тимерченең бу сөйләгәннәреннән эчен тотып көләр иде, Сәхаби көлмәде, кыяфәте дә бик житди, иреннәре кысылган, ләкин күзләре елтырый иде. Сулыш алуларына хәтле ешайды. Ул аңлады: Зыятдин ага, чынлап та, клиник үлем кичергән һәм шуннан арынгач, тимерче төрле төсләр дөньясына чумган. Ул үзенең ике халәтен бер итеп сөйли иде Сәхабигә...

— Алар ул агач сукага, тракторлары да булмагач, мин әйтәм, үгез жиккәннәрме?

— Элекке бабайлар кебек дисенме?

— Суканы кем, нәрсә тартып бара?

— Адәм балалары үзләре тарта, — дип куйды Зыятдин ага һәм тынып калды.

— Нәрсә, кешеләр ат урынына жигелгәнмени?

— Жигелмәгәннәр дә инде... Әллә ничек кенә.. Әәә-ә-әә! Мин анда күрше Һамисны да күрдем бит әле. Гомер буе күрше булып яшәдек, якын кеше бит инде. Исән чагында мәчет ягына борылып та карамаган ие. Мин Аллага ышанмыйм ди торган ие. Начар кеше түгел ие ул, ышанмады тек, ышанмады инде, нишләтәсең аны үзе шулай киребеткән булгач... Монда мәчеткә киеп барырга дип кәллә сайлый. Аптырап беткән үзе, түбәтәйләрнең берсен дә башына ярата алмый: кайсы кечкенә, кайсы зур. Миннән дә һаман сайлап калды әле. Исән чагында кәллә киеп өйрәнмәгәч, ярата алмыйсың кәнишне, дим. Мине ишетми, сайлавын белә...

— Үзләре сөйләшмиләрме?

— Сөйләшмиләр шул. Безнең бөтен авыл кешесе шунда. Кая ул авыл кешесе генә! Брежневны да күрдем әле мин анда!

— Шыттырасың, Зыятдин ага, синең хыялый икәнлегеңне беләбез!

— Валлахи газим менә!

— Йә, ничек?

— Бишектә ята Брежневың. Ике фәрештә бертуктаусыз тирбәтеп торалар. Туеп беткән теге тирбәлә-тирбәлә, башы әйләнә, күрәсең, күңеле болгана, төшәсе килә. Төшермиләр бишектән, гел тирбәтеп торалар. Жылый теге аптырагач, һаман төшәргә маташа.

— Кып-кыска вакыт эчендә әллә кемнәрне күреп бетергәнсең син! Карале, Зыятдин ага, Борис күзенә чалынмадымы шунда?

— Чалынды, ник чалынмасын! Сорадым дә әле мин аннан, сине кем харап итте суң, дип. Жинаятьчене тапмаган өчен Хәйбүш малае Мирзаны эшеннән чыгарып ташларга уйлыйлар, әйт инде кем үтергәнен дигәч, кул гына селтәде. Эзләмәгез, янәсе, файдасыз эш ул дигәндәй!..

— Кызык? Эзләмәгез диме?

— Шулай ди. Чиркәү ягына да кереп чыктым әле мин анда баргач... Гайсә пәйгамбәр үзе ачты капканы...

— Ну, Зыятдин ага, монысын инде...

— Юк, арттырмыйм, чын дөресен сөйлим, күргәннәрне генә... Менә, ягъни мәсәлән, Ельцинны күрдем, күпердән сикерә ие. Сикерә дә, ярга кире менә. Бүтән сикермәскә тели, тик фәрештәләр тегенә тагын сикерергә кушалар; сикерә инде, нишләсен тегеләр кушып торгач... Тагын ярга менә, күпер өстенә бастыралар да, тагын сикерергә кушалар. Шулай гел сикереп тора... Күренеп тора: тәмам хәлдән тайган мескен... Күпере дә бик биек түгел үзе... Шуннан әллә кайдан гына күпер өстенә бер трамвай килеп туктады. Ельцин шуңа утырды. И йөри дә йөри, йөри дә йөри трамвайда. Берзаман туйды, трамвайны туктатып, төшмәкче була. Төшермиләр тегене, тагын йөр әле диләр бугай. Менә шул, мин киткәндә дә трамвайда калды әле Ельцинын...

— Боларның барысы белән дә кем идарә итә соң анда?

— Белмим, — диде тимерче. — Ходай Тәгаләдер инде?

— Син аны үзең күрмәденмени?

— Юк. Кертмәделәр.

— Шунда хәтле барып та керә алмадыңмы? Менә монысы ялгандыр инде, Зыятдин ага?! Ышанмыйм...

— Кертмәделәр дидем бит инде! Ник кертмәгәннәрен дә беләм!

— Йә?

— Әтинен бер чыбык очы туганы теге заманда мәчет манарасы кисү эшендә катнашкан булган... Шуны искә төшерделәр. Мин үзем белмим дә аны. Анда беләләр икән...

— Беләләр, — дип куйды Сәхаби. — Син хәзер бар нәрсәне беләсендер инде, Зыятдин ага?

— Белмим, — диде тимерче. Аннары монысын ишетмәсеннәр дигәндәй, пышылдап әйтте: — Белмим... Ләм.Мим. Җәмил хәзрәт шулай диде. Аннан сора калганын...

— Ләм. Мим. — Белмим? Рифмамы бу?..

— Малай, рифма түгел, диде, Әлиф. Ләм. Мим. Ра... — диде.

Йа, Ходā! Бу серенне начар уйлы адәмнәреннән сакла!..

Зыятдин ага, бер караганда, аз сүзлегә охшаган гап-гади тимерче, тел ачкычлары табылган очракта тәмләп сөйләргә бик ярата иде шул. Аның Сәхабидән тиз генә аерыласы килмәде, чөнки тегесе бүлдермичә тынлый белә иде.

— Теге... кем әле? Ә-эәә, бер зур түрә дә килеп китте анда! Әлигарх бугай! Вәт, каһәр, фамилиясе тел очында гына тора инде! Вәт әкәмәт.

— Зыятдин ага. Теге сөйләгәннәренә чынлап торып ышана башлаган идем, монысы точно әкият инде! Исән кеше нишләп йөрсен анда! Юк, монсына мәңге ышанмыйм! — диде Сәхаби.

— Ышанмасаң, тыңлама, бар йөрмәгез монда мешәйт итеп,эш калдырып. Әнә, ат дагалатырга килгәннәр, — диде тимерче, Сәхабигә аркасы белән борылып. Сәхаби үзенең дорфалыгы өчен гафу үтенгәндәй, йомшак кына тамак кырып куйды. Зыятдин ага янә ана таба борылды да, сөйлимме дигәндәй, аңа күтәрелеп карады. Сәхаби дәшмәде, әмма ул тыңларга әзер иде.

— Үзе самолетка утырып килде. Теге... тавыш тизлегеннән дә катырак оча торган самолет бар дип сөйлиләр бит әле... Шул самолет бу дөнья белән теге дөнья арасын ярты сәгать эчендә уза икән! Килде бу. Әрвах халкы чорнап алды моны. Теге түрә сөйли, бертуктамый һаман сөйли дә сөйли. Жыелган кешеләр аны бик бирелеп тыңлыйлар, әмма бернәсә дә аңламыйлар. Аңлаганга салышып елмаялар гына. Халык елмайгач, теге тагы дәртләнеп сөйли башлый. Кемдер килеп жилкәсеннән сыйпый, кайсыларыдыр пеләш башын сыпырып карый. Тик теге түрә каршы килми, мин гади халык яклы кеше, пеләшемне рәхәтләнеп сыпырыгыз, пажалысты гына ди! Бер почмакта бик матур хур кызлары да жыелып тора бит инде. Бу аларга таба борылды да: «Арагызда татар кызлары бармы?» — дип сорый. Ике хур кызы кул күтәрде шулчакта. Татар кызларын аеруча яратканлыгы күренеп тора. Үзе дә яшереп тормады ул моны: «Мин татар кызларын яратам, шуңа күрә хатыннан да аерылдым әле менә!» — ди. Шулчак бер әрвах кул күтәрә, түрә ана да сүз бирде: «Син хатыныңнан байлыгыңны яшерү өчен аерылгансың дип сөйлиләр. Шул дөресме», — ди. Теге мона таба карап торды-торды да: «Анда, Жирдә, бөтен байлар шулай итә. Түлке мин аның өчен генә аерылмадым. Дөресен әйтим, монда, Христос янында, ялган сүз сөйләп тормыйм, андый максат та бар иде безнең, кәнишне. Нишлисең, байлыгы булган бар кеше шулай итә бит. Мина, түрә кешегә, калганнардан аерылырга ярамый, алайса халыктан аерылу була ул», — дип куйды. Аннан соң дөбер-шатыр түрә артыннан бик озын бер поезд килеп житте. Теге... тиз йөри торган поезд. Түлке бусы товарный поезд. И-и, шунда шыплап алтыннар тутырылган! Ялт-йолт килеп тора инде бөтен вагон, мин сина әйтим. «Жир өстендә байларга каршы каты чаралар күреләә, байлык өчен налоглар арттырылды. Монда налог юк,

шуна күрә, үзем килгәнче минем алтыннар монда торып торсын әле», — дип, халыктан рөхсәт сорый. Нишләсеннәр, рөхсәт бирделәр инде. Шуннан, мин сина әйтим, бер фәрештә очып килеп, поезд вагоннары өстеннән канатын кагып узган ие, теге сап-сары ялтыравыклы алтыннарың гап-гади тимергә әйләнеп куймасыннармы! Жыелган әрвахлар да шаккатты бу хәлгә, түрә агай үзе дә аптырап калды! Вагон-вагон алтын тиктомалдан гап-гади тимергә әйләнсен әле! Шуннан сон бу, матур итеп сөйләвеннән туктап, тынып калды, аннары үпкәләгән тавыш белән: «Килмим мин монда бүтән! Беркайчан да!» — дип, нәкъ балаларча үпкәләп китеп барды.

Зыятдин ага башын күккә таба күтәрде һәм:

— И ул тегендәге вагон-вагон тимер монда булсын иде, төрән ремонтларга да тимер калмады, — дип көрсенеп, алачыгына таба юнәлде. Тик алачык ишеген ачарга дип сузылган кулы кире төшеп, кабат Сәхабигә таба борылды:

— Искә төште теге түрәнең фамилиясе: «Хрушуп!» — диде ул, ышанычлы тавыш белән.

— Ничек Хрушев булсын!? Ул күптән үлгән бит инде!??

— Сун...үзен дә әйттен бит: тере кеше теге дөньяда нишләп йөрсен дип. Ышанмаган булганыең, менә бит, хәзер дөрес. Әле ул жыелып торган хур кызларына чәчәк урынына бер көлтә кукуруз да бүләк итте! Менә, Сәхаба, шундый хәлләр!...

— Мин — Сәхаби!

— Сәхаба син, теген нән белеп кайттым чын исеменне... — дип куйды Зыятдин ага һәм бу юлы алачык эченә үк кереп чумды.

«Малае юкка гына язучы булып йөрми икән.... Атасына охшагандыр, фантазиясе көчле, анысы да шыттырырга хирыстыр» — дип уйлап калды Сәхаби-Сәхаба анын артыннан.

Пәри чокырына су тулганнан сон анын исемен янә «Көмешле күл»дип үзгәрткәннәре мәгълүм Сәхабигә. Бу күлне юкка гына көмеш исеме белән атамадылар, мәктәп химигы анын составында көмеш барлыгын раслады. Ләкин ничек кенә атасаң да, ул барыбер Пәри чокыры иде. Бу яклар хәтерли: Пәри чокыры узган гасыр башында чынлап та мул сулы күл булган һәм исеме дә «чокыр» түгел, «күл», «Урман күле» булган.

Авылдагы соңгы кулак Себергә олактырылып, ярлы Ярулла агай, соңгы кәжәсенен мөгезеннән тотып, кызыл коммуна абзарына илтеп бәйләгәннән сон, Ябалак авылында күмәк хужалык оештырып йөрүче элеккеге бетле хәерчеләрдән укмаштырылган кызыл авызлы коммунарлар, ниһаять, жинел сулап куя ул чакта. «Наша правда» колхозы Ябалакта беренчеләрдән булып оеша һәм шул хакта өскә хисап кәгазе китә.

Бу олуг вакыйганы билгеләп үтәргә кирәк бит инде. Соңгы кулак юк ителде, ярлы Ярулланың сынар мөгезе колхоз абзарында. Бөек жинү өчен тагын ни кирәк?! Моннан сон, әлбәттә, жылы тирес астына тыгып куелган колаксыз бидонны актарып алсалар да була. Тиресекә буялган бидонлы көмешкәне банка сыман тар авызлы балчык чүлмәкләргә бүлеп чыгалар.

Мәжлесне күл буенда жыярга карар иттеләр. Кәефләре күтәрелеп киткәч, ул заманнарда әле эчәргә өйрәнмәгән коммунарлар, беркавымнан чүлмәкләрдәге сыеклыкны, күл буеннан камышлар өзеп алып, шунын көпшәләреннән генә суыра башлады. Мәжлес жыелып ашыкканнар икән. Авылда сөрелмәгән тагын бер чит элемент калганлыгын искәрмәгәннәр бит! Үз бакчасы артында мондый бозыклыкны күргән Камил мулла, манарасы киселгән мәчет түбәсенә менеп утырды да үзенен янгыравыклы матур тавышы белән дога укыганнан сон болар өстенә ләгънәт яудырырга керешә. Бер исерек коммунар берданкасы

белән Камил мулланы мәчет өстеннән атып төшерде. Ыгы-зыгы купты, авылда мәхшәр башланды.

Хәер, бу мәхшәр Пәриле күлнең үзендә дә башланган иде. Кинәт давыл купты, күлнең суы ярларына сыеша алмыйча ташыды һәм шул унайдан мәжлестәгеләрне дә юып алып китте. Шуның артыннан ук, жир убылып, кешеләр дә, күл үзе дә юкка чыкты.

Комсыз коммунар түрәләрдән котылуларына сөенәсе урынга авыл халкы пошаманга төште. Якты киләчәккә барабыз дип кенә торганда, «Наша правда» колхозы житәкче-түрәләрсез калды. Түрәләрне күле-ние белән пәри алган, кире кайта алмаслар дигән шомлы фикергә киленде. Шуннан соң «Урман күле» исеме урынына дымлы, юеш балчык кына калган урын «Пәри чокыры» дип аталып йөртелә башлады. Күле чукынмас, ябалаклыларның урман буенда ук тагын бер күлләре бар әле, иң әһәмиятлесе, халык түрәләрсез калды! Иң куркынычы, иң яманы әнә шул иде!

Түрәләрсез тормыш тормыш түгел иде!.. Халык аларны бик кызганды. Бүген түрә халкына хөрмәт шул заманнан килә. Бүген түрәләрнең караклыгына күз йому әнә шул вакыйгадан соң башланды. Авыл бу турыда бәет тә чыгарды:

Түрәләрсез халык:
Димәк, ятим калдык!
Ата-анасыз калдык,
Ашаган тагарак ярык.
Өйсез-түбәсез калдык,
Ашсыз-сузыз калдык,
Телсез-авызсыз калдык,
Һәм көмеш айсыз калдык!
Без бәхетсез халык,
Бик бәхетсез
Һәм бик ябык!..

Әлеге декламацияне кычкырып сөйли-сөйли, халык күл булган урынга агылды, кайнар яшен түкте. Шуңа күрә бу бәхетсез халык елаудан туктый алмады. Күз яшьләре белән Пәри чокыры тула язып, хәтта күл кире әйләнеп кайткан кебек булды. Тик түрәләр генә мәңге кайтмаячаклар иде!..

Түрәләрсез тормыш, чыннан да, тормыш түгел иде. Болар үз араларыннан яңа түрәләр сайларга булдылар. Түрә булачак кешеләрнең холыкларында түбәндәге сыйфатлар чагылырга тиеш иде:

— Кем күзен дә йоммыйча ялган сөйләргә сәләтле?
— Кемнең кулы озын?
— Авылда карак даны чыккан нинди нәсел бар?
— Кем иң эшлексез?
— Кемнең ояты табан астында?
— Кем кеше кайгысына төкереп тә бирми?
— Кем йөрәк урынында таш йөртә?!!

Төп шартлар менә шулардан гыйбарәт.

Шул рәвешле үктәбер инкыйлабыннан соң түрәләрнең яңа династиясенә нигез салынды. Түрә дигәч тә... Әйе, бу халык үз арасында берничә төркем-катламга бүленә. Иң югарыдагысы «Түлле түрә» була. Аннан соң «Түгәрәк түрә» төркеме. Шуның артыннан чиратта «Түм түрә» катламы тора. Әлеге сыйныфның соңгы чылбырында «Түмгәк түрә»ләр. Катламның һәркайсының, исеменә карап, үз дәрәҗәсе, вәзгыять-жәмгыятьтә тоткан урыны бар. Мәгънәсеннән аңлашылганча, Түлле-түрәнең мая төбе буш түгел, ул түрәлек итү дәверендә

шактый тул, ягъни байлык урлап өлгергән, балалары чит ил гражданнары, шунда яшиләр, моның тапкан акчалары чит ил банкларында әйләнә. Ләкин үзе бу илдә яши, балалары янына оныкларын сагынганда гына яки арка кыздырырга барып килә. Моннан бөтенләй диярлек файда юк, житәкләгән оешмасы таркалыр дәрәҗәдә, әмма акча суыру каналлары һаман эшли, алар исә чит илгә шуа тора.

Түгәрәк түрә ин шома, хәрәкәтчән катламнан. Моның балалары әле мәктәп яшендә яки студентлар. Алар һәммәсе чит илдә белем эсти. Киләчәктә шунда ук яшәп калырга өмет тота.

Түмтүрәләр әлегә түгәрәкләнеп житмәгәннәр. Боларны «клан» дигән тылсымлы көч хәрәкәтләндерә, алар үрчүләрен һаман дәвам итәләр.

Түмгәк түрәләрне «клан» туганнарының кода-кодагыйлары, кияүләре тәшкил итә. Болар аеруча әрсез, чөнки тизрәк түгәрәкләнәселәре килә. Шул активлыклары аркасында алар, һәр юлда түмгәк булып, комачаулык итеп утыралар.

Түрәләрдән гаеп эзләү, аларны тәнкыйтьләү, бар яманлыкны фәкать түрәләрдән генә күрү бу илнең канына сеңгән. Баксаң, түрә галәмнән яисә Марс планетасыннан килгән кеше түгел ләбаса! Ул да гап-гади кеше. Теге чакта авыл кадәр авыл түрәсез калгач, халык нишләде? Юк, берәү дә чәчәргә кирәк дип басуга чыгып йөгермәде, берәү дә сыерлар савылмый калган дип фермага чыгып чапмады. Һәммәсе, кайгырышып, бүре тарафыннан өркетелгән көтү кебек, клубка өелделәр, җыелыш арты җыелыш җыйдылар. Атналар буе түрә сайлау ыгы-зыгысы барды! Ярулла агайның колхоз абзарына бәйләгән сыңар мөгезле кәҗәсе ачтан тәгәрәп егылды. Ул вакытта авылда бер генә түрә дә юк иде югыйсә! Димәк, ул җыелышларны түрә җыймады, кешеләр үзләре шулай теләде, аларның түрәле буласылары килде. Чөнки бу шундый халык иде. Ленин үлгәч, хәтта кайгыдан үз-үзләренә кул салучылар булган дип сөйлиләр. Сталин үлгәч, безне ятим иттен, сөекле атабыз, дип, ил белән бергә җылаганнар. Грузинның кайчан урыс белән татарга ата булганы бар соң әле? Брежнев каен төбенә китеп баргач та, шундый хәл булды, җылады халык. Үксеп-үксеп җылады, нишләрбез дип җылады! Ельцин үзен җәлләтү өчен күпердән сикергәч тә җәлләп җылады. Шул кызгану хисе әлеге әфәндене зур түрә итте. Бүген шома егетләр юкка Мәскәүнең «сазлыклы» урамында акырып-бакырып йөргән булалар. Халык барыбер кызганмый аларны. Күпердән сикерсеннәр, йә булмаса халыкны җәлләтерлек берәр геройлык гамәле кылсыннар! Менә шуннан соң, бәлки, түрә итеп сайлап куярбыз без аларны!.. Бер җәбрәй кызының миллионнарын ФСБ алып чыгып киткәч тә еладылар. Ач-ялангач, биш тиен хезмәт хакына очын-очка ялгап яшәгән хәерчеләр,түрәләр тарафыннан мыскыл ителгәннәр кызганып җыладылар бичараны! Өйдәге сейфына гына да кайдан килгән ул дистә миллион доллар дип уйлаучы булмады, чөнки кызганып яшь түгәсе бар иде. Менә шундый халык инде без...

Кызык заманда яшибез, кызганыч заманда яшибез...

Күнеләндә иман әсәре булмаганнар, Илаһыны танымаганнар үз араларыннан пәйгамбәрләр эзләрләр, ягъни түрәләр эзләр. Милләт Пәйгамбәрсез була алмый. Бер дә бер көнне Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в) хөкеменә карак хатын китерелә. Соныннан бу хатынга җәза бирү карар ителә. Ләкин Фатыйма атлы әлеге хатын мәшһүр көрәешләр кабиләсеннән була, шуңа күрә карарны гамәлгә куюга аларның кәефләре кырыла. Моны аңлаган Мөхәммәд (с.г.в.) шул рәвешле боера: «Әй! Кешеләр! Бу дөньядан яшәп киткән милләтләр тик шул сәбәптән һәлак булганнар, аларның зыялылары (түрәләре) бурлыкта тотылса, аны җибәргәннәр, гади халкы урлашса, аларын җәзага тартканнар. Аллаһуга ант итәмен ки, мондый гамәлне үз кызым Фатыйма эшләсә дә, җәзасыз калдырмас идем».

Инде килеп, сөекле Пәйгамбәребезнең вафатыннан соң өммәт башлыгы итеп танылган хәзрәте Әбү Бәкер беренче хөтбәсендә Исламның гаделлек һәм тигезлеккә биргән әһәмиятен түбәндәге сүзләре белән ачыклый: «Әй, инсаннар! Күңелләрегез һич уйламаганда хәлифәгез булдым. Яхшы юлдан алып барсам — мина ярдәм кылыгыз. Ялгышсам — төзәтегез! Янымдагы һәр зәгыйфь вә куәтле тигезләрдер. Һәркемгә дә бертигез мөнәсәбәттә булачакмын. Аллаһыга һәм Мөхәммәдкә итагать иткәнчә, миңа да итагать итегез. Аллаһның вә Рәсүлнең әмерләреннән йөз чөерсәм, димәк, мин хөрмәтегезгә лаек түгелмен!..»

Җәмил хәзрәт янә болай дип дәвам итә: «Сирия һәм Фәләстин гаскәрләре тарафыннан азат ителгәндә Кутдус патриархы шәһәрнең ачкычларын баштa хәнәфи хәзрәте Гомәргә тапшырачагын үтенеч итеп белдерә. Хәзрәте Гомәр, кирәкмәгәнгә кан түгелмәсен өчен, Мәдинәдән хезмәтчеләре белән бергә юлга чыга. Юлда чиратлашып дөяләргә утырып баралар.

Шәһәр капкасы янына җиткәч, дөягә утыру чираты хезмәтчедә була. Хезмәтче, яңа азат ителгән бер шәһәргә дәүләт башлыгының җәяү, ә үзенең дөя өстендә керүенә унайсызланып, чиратын хәлифәгә бирергә тели. Ләкин хәзрәте Гомәр моны кабул итми. Хезмәтче дөя өстендә, үзе җәяү шәһәргә керәләр... Инсаният тарихы башка моңа охшашлы мисалны белми. Исламият гаделлек нигъмәтенең нигезен кабул иткән...»

Кем соң ул юлбашчы? Нинди дер шартларда адәмнәр һәрвакыт җиде юл чатында кала. Араларыннан берничәсенә генә Ходайдан илбашы булырлык лидерлык таланты бирелгән була. Ләкин, аның түрәге булмау яки ул «клан» агачыннан булмаганлыктан, Илбашчы итеп, гадәттә, уртакулны билгели-сайлыйлар. Димәк, гавам юлы һәлакәткә барачак дигән сүз. Талантлы түрә исә халкын бәхеткә илтәчәк!..

...Аерым бер түрәләр дигән «милләт» хакында Сәхабигә дә мәгълүм булды һәм ул, хәйран калып, башын чайкап куйды. Бер түм-түрәнең буш чокырдан күл ясаганлыгын ишеткәч, ул да, кызыксынып, шуны барып карап кайтырга дип чыккан иде. Юлдан килгән машина таптый язам дигәндә генә кырыйга чыгып өлгерде. Шоферында чак кына итагать бар икән тагын үзе, ул, машинасыннан төшеп, юлчыдан гафу үтенде һәм, машинаның үзенеке түгел, шуңа күрә җаен белеп бетермәве белән акланды, хәтта утыртып барырга да тәкъдим ясады. Аның Варис икәнлеген таныды Сәхаби. Тик юллары төрле якка булганлыктан, утырудан баш тартты, чөнки ул инде Ябалак урманына якынлашып килә, Варисның исә Алтын Бәртәскә барышы иде.

Капканы Радийның тән сакчысы ачты. Хөллиевнең бу коттеджы Вариска электән үк таныш, хәтта малай чакта Бәхти абыйсына ияреп килгәне дә бар иде. Тик ишегалдына узгач та ул аны танымый торды, диварлар төрле язулар белән чуарланып беткән, почмак саен иконага охшаш рәсемнәр чекерәеп тора. Радий үзе төрлечә киенә: аның өстендә йә руханиларның кара киеме булыр, йә алтын укалы зур яшел чалмага охшаган баш киеме.

Варис утырып килгән чит ил машинасы Радийга бик ошады: «Шәп машина эләктергәнсең, молодец!» — диде ул аның аркасыннан кагып. Варис әлеге сүзләрнең төп мәгънәсен төшенеп бетмәсә дә, мактау ишетү рәхәт иде.

— Моны бүген үк сүтеп, запчастька җибәрербез!

— Ничек сүтеп?

Варисның ерылган авызы кире җыелды.

— Аны сүтү синең эш түгел! Син үзенә тиешлесен башкардың инде.

— Миңа аны хуҗасына кайтарып бирергә кирәк бит, Радик!

— Хуҗасына? Һе, һаман аңламадыңмыни әле син, Борис!

Тегесе аны шундук бүлдереп:

— Варис мин, — диде.

— Моннан соң Борис булырсың! Әнә, без Рәиснең исемен ничек үзгәрттек, туган анасы да танырлык түгел: Вәис-Сөләйман Әл-Рэисофф! Шәп бит! Чит илдә дә шаккатканнар!

— Мин Борис түгел. Мин — Варис! — дип кабатлады Варис.

Тегесе ана борылып карады. Радийның күз карашы гади кешенеке шикелле генә түгел, бака йотарга җыенган еланныкы кебек, үзенә суырып алырга тора.

— Радик, кирәк түгел мине Борис диярга! Минем әти... әти Борис исемле иде!

— Әтиең!? Әйе, әйе шул.. Син үтердең бит әле аны, әйеме?

— Мин!

— Әллә син түгелме? Бәлки, башка кешедер?

— Юк! Юк! Мин үтердем Борис әтине! Без килештек бит инде!

— Бигүк килешенеп бетмәгәнбез, ахрысы, кәҗәләнәсең бит, Борис түгел имеш! Мин ничек әйтсәм, шулай була! Аңладыңмы!? — диде тегесе инде шактый ачулы тавыш белән.

— Аңладым, Радик!

— Аңласаң, шул... Бу машина эчендә иблис бар! Карале, кара! Яхшылабрак кара!

Варис Шевроле-джип машинасына никадәр генә текәлеп караса да алдагы көзгегә эленгән тәсбихтән башка гайре нәрсә күрмәде.

— Күрәсеңме, тәсбих эленеп тора?

— Күрәм. Бөтен машинага да эләләр аны.

— Хәзер машинаның маңгаена кара! Нәрсә күрәсең?

— Знак.

— Нәрсә знагы?

— Шевроле фирмасыныкы.

— Нәрсәгә охшаган ул?

— Тәрегәме?

— Вот, вот, үзең дә белдең, молодец! Менә шул, Борис, тәсбих машина эчендәге иблисне куып чыгарып утыра, ә тәре аны кире салонга куып кертә! Аңладыңмы инде хәзер? Кыскасы, ике көчнең, ике энергиянең бәрелеше бара. Алар икесе дә унай, плюс энергияләр. Тәсбих мөселманга уңай энергия бирә, тәре исә христианга көч биреп тора. Димәк, алар икесе дә — плюс. Ике плюсны бер-берсенә якын китерсәң, нишлиләр!? Этәчәкләр алар бер-берсен! Минус белән плюс кенә бер-берсенә тартыла. Йә, алайса, тәренең энергиясен тискәре, ягъни минус дип алып карыйк. Ләкин кем әйтә ала аны тискәре энергия бирә дип? Бар, берәр христианга шулай диеп кара! Башыңа шул тәресе белән берне генә тондырыр! Мөселманга әйтеп кара алайса тәсбих начар ул, тискәре энергия бирә, дип! Чалмасы белән буып үтерергә может. Аңладыңмы инде хәзер, Борис?

Әлеге демогогиядән берни дә төшенмәсә дә:

— Аңладым, — дип куйды Варис. Радий алдында үзен надан итеп күрсәтәсе килми иде, күрәсең.

— Аңласаң, бу машинаны тиз генә юкка чыгарырга кирәк. Алайса, ул бик күп бәла-казалар алып киләчәк!

— Әтине мин үтердем, — дип пышылдады Варис.

— Син, син! Борчылма! Докажем син икәнлеген! Син акыллы! Сразы аңладың! Димәк, озакламый җаныңдагы иблисләрне куып бетергәч, син мәңгегә

тынычланып калачаксын! Сиңа икенче задание — Галин! Галинның өенә кереп, сейфын табарга кирәк булачак!

— Галинның сейфын? — дип сорады Варис аптырап.

— Әйе, Галинның сейфын. Сезнең Байтамактагы Әллүки күле юкка чыктымы? Чыкты! Иблис эчеп бетерде аны! Шул иблисне юкка чыгарсак, Әллүкинең суы кире кайтачак! Ә иблис Галинның сейфы эченә кереп бикләнгән! Аңладыңмы инде хәзер? — дип кабатлап сорады Варистан. Ләкин Варис янә берни төшенмәгән иде, тик Радийның сүзенә каршы килү яхшы түгел. Булышам, ярдәм итәм диде бит.

— Син дини гыйлем алган имам. Иблиснең нинди явыз көч икәнлеген беләсең инде! Адәм пәйгамбәр белән Һава анабызны да шул юлдан яздырган бит! Без, адәм балалары, шуның аркасында җир йөзендә гомер буе михнәт чигәргә мәҗбүр. Чөнки атабыз Адәм җәннәттән куылган! Шуның аркасында интегә дә инде аның балалары! Тагын бер серле сейф бар әле... Хәер, анысы турында соңрак. Сейф түгел ул, тимер сандык. Сейфтан да яманрак... Син молодец! Син булдырасың! Менә бу шәп киемнәр сиңа!

— Кем киемнәре бу?

— Курыкма, өр-яңа әле алар! Бу коттедж хуҗасыныкы алар. Бер кигән дә шкафка элеп куйган инде. Син киеп йөрерсең. Карале, чын кожа бит. Чалбары да американский. Абрек абыең юк-бар кием киеп йөрмәгән инде ул. Менә күлмәге бөтенләй киелмәгән дә. Джинсысы да өр-яңа бит, карале! Сиңа ничего не жалко! Талантлы егет син!

Әлеге сүзләрдән соң Варис җанланып китте, бу аңа таныш тема иде:

— Муса пәйгамбәр дә аңа, Адәм атабызга, шундый гаеп ташламакчы була. Тик, беләсеңме, әлеге бәхәстә Адәм атабыз җиңеп чыга, чөнки ул хаклы була. Адәм атабыз белән Һава анабызның гөнаһ кылачаклары хакында Аллаһы Тәгалә ихтыярында алдан ук әйтелгән, ул Адәмне булдырыр алдыннан кырык ел элек...

— Беләм, беләм, — дип бүлдерде аны Радий. — Син — гыйлемле кеше, Иблиснең ниләр майтарганын да яхшы беләсең бит! Беләсеңме?!

— Беләм!

— Белгәч, нигә кирәк мондый сүз базары! Без шул Иблискә каршы көрәшә торган оешма икәнлекне дә беләсең булыр! Чөнки син безнең әгъза хәзер! Әгәр Адәм пәйгамбәр үзе монда булса, ул безгә рәхмәт кенә әйтер иде! Аның кан дошманы булган Иблискә каршы көрәшәбез бит! Син аны, Адәм пәйгамбәребезне, анда тыныч яши дип уйлыйсыңмы әллә?! Үзе аркасында җирдә газиз балаларының газап чиккәнлекләрен белә бит ул, күреп тора! Тыныч булсын Адәм пәйгамбәребез! Без аның күңел тынычлыгы өчен көрәшүчеләр! «Ради Христа, именем Мухаммада и для успокоения души Адама», кыскартып әйткәндә «Эр-Рахим-Иуда».

Варис яман чир белән әнисе үлгәннән соң кайтып житте авылга. Сәгүд Гарәбстанында укуы тәмамланган, дипломы кесәсендә иде инде. Әнисен югалтуын авыр кичерде егет. Аны ул вакытта бар авыл кызганды, житмәсә, күмәргә дә кайтып житә алмады бит. Варис кайтуга әнисенең каберенә китте, зират авыл артында, бәрәңге бакчалары буенда гына иде. Ана ияреп әтисе дә бармакчы иде, Варис «Үзем генә!» — диде һәм ялгызы китте. Дөньяда әнине югалтудан да авыррак бүтән кайгы бар микән?!! Юктыр, мөгаен. Варис сыгыла-сыгыла елады.

Яңа каберне тиз табып табып алды ул. Әтисе инде чардуган да ясатып өлгергән. Варис, чардуган янына чүгәләп, дога укыды. Шулчак ул гәүдәсендә ниндидер салкынлык тоеп, калтыранып куйды: агачлык эчендә утырган

зиратның салкыны идеме соң бу, әллә... әллә чардуган тимеренең суыгы шулай өшеттеме аны?! Бу салкынлык шундук аның күнелендәге кайгы-хәсрәтне кысып чыгарып, анда башка төрле хис-фигыльнең тойгысы кереп урнашты. Нигә кирәк бу чардуган? Кирәк түгел! Шулчак Варис ишегалдындагы утын әрдәсенә сөяп куелган кабер ташын исенә төшерде. Димәк, әтисе аны да монда китереп куярга алдан ук ясатып куйган! Бу бит тиеш түгел!

Ул урыныннан кузгалды да, арлы-бирле зират буйлап йөрергә кереште. Яңа каберләр арасында аңа таныш кешеләрнеке дә, таныш булмаганнары да байтак. Кайсыберләренә рәсемнәрен дә куйганнар. Аның яшьтәшләре дә, ул бергә уйнап үскән кайбер танышлары да очрый, шулай ук Варис белгән башка өлкән яшьтәге авылдашлары да бар иде араларында. Һәммәсендә авыр-авыр кабер ташлары. Варис кабат әнисе кабере янына килеп, ике куллап, чардуганга ябышты, аны урыныннан кузгатырга теләде, ләкин чардуганның дүрт аягы бетонга утыртылган, шуңа күрә ул селкенеп тә карамады. Бу исә Варисның ачуын тагын да катырак кузгалтты. Ул, кыз-кызу атлап, зираттан чыгып китте. Капканы ачып керде дә туп-туры утын әрдәнәсе янына китте, бар көче белән сөялеп торган кабер ташына китереп типте һәм, аягын авырттырып, әрдәнә янына мәтәлде. Кабергә куясы таш та җиргә ауган иде. Варис аны күтәреп торгызырга азапланып карады, тик аягы бик каты авырта, көч-хәл белән генә торып басты. Әтисе өйдә икән, капка тавышына ул да ишек алдына чыкты һәм балта белән ташка кизәнергә теләгән малаен күреп, беравык өнсез калып торды, аннары, исенә килеп, аның янына килде. Ул әле һаман Варисның ниятен аңламый иде.

— Кабер туфрагы утыргач куярбыз, улым, бу ташны. Пока торып торсын. Күз алдында тормасын дисәң, мин аны янбакчага алып кереп, алмагач буендагы коймага сөяп куярмын, улым. Син, ничек, бардыңмы әниең янына, улым? — диде ата кеше.

— Бармадым! — дип, дорфа гына җавап бирде тегесе. — Нәрсә калган анда миңа! Хәзер мин үлгән әнигә табынырга тиешмени инде!

— Чү! Туктале! Ни сөйлисең син, улым, бәгърем!

— Колагың нәрсә ишеткән булса, шуны сөйләдем!

Борис тынсыз калды, күкрәге катты һәм ул дөпелдәп утын әрдәнәсе буена егылды. Бу хәлдән аптырашта калган улы: «Әти!» дип аның янына чүгәләде.

...Безнең Мәннәви Мансарович түм-түрәләр кавеменнән иде. Әлбәттә, ул да клан ярдәме белән күтәрелде, әүвәлрәк бик озак түмгәк-түрә сыйфатында йөрде, аннары, бер түлле-түрәнең Изольда атлы үтә дә яман холыклы бик чибәр кызына өйләнеп ташлаганнан соң, дөнья акрынлап аның көенә әйләнә башлады.

Сәхаби Галинның фазендасы янына килеп житкәндә, кояш бату ягына таба бара иде. Ул, күзләрен зур ачып, күккә карады, батып барган кояшның алтын нурларында каурыйсыман болытлар йөзә, әлеге болытлар арасында күрер күз карашы да тоя алмаслык, ләкин нindiдер өченче күз белән генә сизәрлек нур көлтәсе чагыла сыман. Сәхабинең күз карашы әлеге нур көлтәсен үзенә йотты. Шуннан соң аның адымнары тагын да кыюланды, Пәри чокырында күптән түгел генә пәйда булган Көмеш күл ягына борылам дигәндә генә, Галинның ихатасы ягыннан нindiдер тавышлар ишетеп, ул туктап калды. Бәйдәге эт бер мәртәбә ялкау гына өреп куйгач, әлеге тавыш тынды һәм Сәхаби күл ягына таба атлады. Сәхаби бу тирәләрне яхшы белми иде, шуңа күрә ул ерак түгел урман буенда ышыкланып утырган икенче бер күлгә килеп чыкты. Баягы тавышларны җил ихата эченнән түгел, күл ягыннан алып килгән булган икән: Сәхаби яр буенда ике кеше күреп алды. Шуннан ерак түгел әрҗәле машина да тора. Ул алар

янына килеп исәнләште. Анын сәламен теләр-теләмәс кенә алган кешеләрнен берсе мәктәп директоры иде. Күптән түгел Сәхаби ана мәктәп яны бакчасына утыртырга дип яшь алмагач үсентеләре биреп җибәрде.

— Менә монда кирпечебез калган иде, шуны ташыйбыз, — диде ул аклангандай. — Анын сүзен Сәхабигә таныш булмаган икенчесе хуплады:

— Үзебезнен кирпечләр ул, кешенеке түгел!

Мәктәп директоры ана терсәге белән кагылып алды да:

— Курыкма. Бу үзебезнен кеше! Сатмас. Хәтерлисенме, Байтамакнын алма бакчасы каравылчысын?

— Әә-ә, әйе шул, — дип җаваплады ана каршы икенче кеше. — Танымый да торам.

— Бу безнең Хәким Нургалиев, — диде мәктәп директоры.

— Әһә, аңладым, — диде Сәхаби ана каршы. — Батырша фетнәсен кабатларга җыенган тарихчы.

— Фетнәсен түгел, бунтын, — дип төзәтте аны мәктәп директоры. — Фетнә дип кара йөрәкләр махсус атыйлар. Фетнә ул безнен халыкка хас нәрсә түгел. Бунт! Менә анысы хак!

Башка вакыт булса мәктәп директоры бу хакта сәгатьләр буе сөйләшергә әзер иде, ләкин бүген сүзне тиз тотты:

— Без ашыгабыз, туган! Киттек! Без сине, син безне күрмәден, яме! — диде ул һәм шулчак каяндыр килеп чыккан өченче кеше (яр буенда тәгаен юк иде ул, җир астыннан пәйда булды бугай!) машинаны кабызды, мәктәп директоры белән тарих укытучысы әрҗәгә сикерделәр. Сәхаби шулчак кирпеч ватыкларына абына язып чак кына күлгә мәтәлмәде. Коелган кирпеч ватыклары бая теге шофер килеп чыккан куаклык артына таба сузылган иде. Сәхаби шунда таба атлады. Мәктәп директоры белән таныш ул, тик исемен генә онытты, шуна күрә аны директор дип кенә атый иде. Менә шул директор җан атып мәктәбен зурайтырга йөри, сыйныфларда балалар саны кимегән заманда анын мәктәбендә, киресенчә, беренче сыйныфка керергә теләүчеләр арта гына икән! Өченче ел мәктәбендә 142 бала укыса, былтыр алар саны 209га җиткән, болар киләчәк биш еллыкка «прогноз» ясап карагач, балаларның саны биш елдан 1000 укучыга кадәр җитәсе ачыкланган! Мәктәп директоры үзе:

— Мәктәпнең арткы коймасын Кирилл атакайдан, алгы ягын үзебезнең Җәмил мулладан өшкерттергән идем,балалар саны арта башлады, — дип шаяртырга ярата. Чынлыкта исә зур шәһәр тирәсендә туган тел дәресләре булган бердәнбер мәктәп бу. Соңгы елларда, кирәклеген аңлап, башка милләт кешеләре дә балаларын татарча укытырга, дөресрәге, татарча сөйләшергә, язарга өйрәтергә тели икән.

XXI гасырда күп телләр өйрәнү, әлбәттә, гаҗәп күренеш түгел. Ләкин монын төп сәбәбен директор үзе татар телен яхшы белгән баланын инглиз телен дә җинелрәк үзләштерүе белән аңлатмакчы була. Ник дисән, әлеге ике телләге берничә хәрефнең әйтелеше охшаш һәм басым да бик туры килеп тора икән! Әлбәттә, директор мәсьәләне артык гадиләштерә. Сәбәп анда гына түгел, Татарстанда яшәгән һәр милләт вәкиленен дә төп халык телен беләсе, аны өйрәнәсе һәм баласын шул телдә аралаштырасы килә. Чөнки вәзгыятьнен кая таба барганлыгын иң беренче нәүбәттә ата-ана сизә, сизми хәле юк, һәр ата-ана газиз баласынын киләчәге хакында уйлый һәм шул нисбәтле аларнын алдагы көндәге язмышын кайгырта. Бу хәтта инстинкт дәрәҗәсендә бара, ягъни ата-ананың баланы яклау, аны җил-яңгырдан саклыйсы килү инстинкты. Элеккеге тарих укытучы Хәким Нургалиев фаразлаганча, Үзәк тарафыннан татар теле

һаман кысыла бара, шуның белән бергә башка милли телләр дә. Ходай Тәгалә ихтыяры һәм табигать кануннары буенча кысылган саен организм (Тел дә шул ук организм кебек тере ул!) ирек өчен тагын да гайрәтлерәк, усалрак көрәшә башлый, чөнки аңа һава җитми!. Әлеге көрәшнең нәтиҗәсе исә аның киләчәк үсешенә унай йогынты ясый.

Шунлыктан директор мәктәп кырыена өстәмә бина салырга хыяллана, ә моның өчен хөкүмәттә акча юк, бигрәк тә татар мәктәпләре өчен, нишләптер, акча җитеп бетми. Ә банкир Галинда акча да, кирпеч тә күп. Аларның Галиннан мәктәп салу өчен кирпеч урлаулары иде.

Куаклык артындагы юл нindидер мәгарә авызына алып килеп чыкты. Сәхаби, кызыксынып, эчкә узды һәм алдында киң җир асты юлы сузылганын күреп, ис-акыллары китте. Бу чынлап та җир асты юлы, аны Галин махсус казыткан иде. Сәхабинең кызыксынуы көчле булганлыктан, ул юлын дәвам иттерде. Тик бераз баргач, туннель эче дөм караңгыланды һәм ул кире борылды.

Күл буена кире чыгып җиткәндә инде кояш баеп, караңгы төшкән иде. Күл өстендә ай йөзә, камышлар арасында әллә бакалар чупырдый, әллә кыр үрдәкләре тавышы. Шулчак Сәхабинең каршысына бер карамчык пәйда булды. Әлеге карамчыкның теле дә бар икән:

— Син кем, баягы бакча каравылчысымы? — дип сорады ул аннан.

— Әйе, — диде ул һәм элеккеге тарих укытучысы Хәким Нургалиевнең тавышын танып алды.

— Сәхаби, син һаман мондамыни әле? — дип, ул да аның янына ук килде. — Эшләр харап бит! Галинның өендә кәчтүм онытылып калган! — диде ул каушаган тавыш белән.

— Нигә, кирпечне аның өеннән үк ташыдыгызмыни?

— Юк инде, — диде тегесе. — Изольда янында идем мин. Без Изольда белән теге ни... дуслар. Карангыда Сәхаби аның хәрәкәтләрен күрмәде, кулының кулга тиеп шапылдаган тавышын гына ишетте.

Алар куышлык эченә керделәр. Хәкимнең кесә фонаре бар иде, аның белән яктырткач, башны имичә дә барып була икән.

— Син болай гынадыр бит? — дип куйды Хәким артыннан атлаган Сәхабидән.

— Болай гына, — диде тегесе.

— Акчаны кызганмаган бу, ә, малай! Шундый туннель казытырга! Тик торганда бит ул! Бет котырганнан!

— Тик торганнан түгелдер инде анысы!

— Түгел инде, түгел кәнишне. Изольда сөйләде миңа. Андый-мондый хәл була калса, шушыннан гына чыгып качарга исәбе!

— Кемнән качырга уйлый инде ул? Полициядәнме?

— Нишләп полициядән булсын! Үзе полиция бит ул! Фетнәчеләрдән, гади кешеләрдән, мәсәлән, авыл кешеләреннән!

— Авылдашлардан?

— Әйе... нигә? Күпме кешенең җирен алдап үзенеке итте ул монда! Урманга җиләк җыярга да керә алмый халык хәзер! Ана үч саклаучылар аздыр дисеңме?

— Белмим шул, — диде Сәхаби һәм тыныч кына Хәким артыннан баруын дәвам иттерде.

— Авылдашлардан да гына түгел инде. Урлап баеганның җаны тыныч, аларга рәхәт дип уйлыйсыңмы әллә син! Юкю-юк! Тыныч түгел! Аның кайдан, ничек урлаганын дуслары белеп тора бит. Дуслары дип... ну... ишләре инде. Банда. Бергәләшеп урлаганда кайсысынадыр азрак та өлеш чыга бит инде ул.

Аннан соң ачу саклап йөриләр... Ә, беләсеңме, артына мин ут төрттем бит ул Мәннәви Мансаровичның!

— Ут төрттең?

— Ут дип инде... болай гына... Батырша, Пугач, Степан Разин бунтлары турында яшерен хатлар җибәреп тордым мин аның почтасына! Намек белән! Шуннан соң ныгытты бит инде ул бу фазендасын. Каравылчыларын да арттырды.

— Ә безнең монда йөргәнне каравылчылар сизмәсме соң?

— Бу юлның бар икәнлеген хәтта каравылчылар да белми. Хәер, Бурзай белсә генә инде. Үзе, Изольдә и мин. Менә хәзер син дә белдең инде.

— Бурзае кем? Этеме?

— Юк ла! Тән сакчысы.

Шул рәвешле байтак кына барганнан соң өйнең подвалына килеп чыктылар. Хәким капылт кына тагын сорап куйды:

— Мин аңлашыла инде. Ә син нишләп йөрим дидең әле монда?

— Күл эзләп килдем, — дидем бит.

— Алай... Ярый, хәзер мине монда гына көтеп тор, күлне үзем күрсәтермен. Кәчтүмне генә әләктерәм дә чыгам мин.

Мәннәви Мансаровичның подвал дигәне дә махсус бер бункер кебек. Бүлмәләргә бүленгән, һәр бүлмәдә авыр тимер ишекләр. Ләкин Сәхабинең боларның берсенә дә исе китмәде, ул тыныч кына Хәким тарихчының чыкканын көтә башлады. Дөрес әйткән икән, Хәким озак тормады, алар янә бер-бер артлы җир асты юлыннан чыгу ягына киттеләр.

Көмешле күл өстендә тулган ай утыра иде. Беркавым икесе дә тыныч кына шул күренешкә сокланып карап тордылар. Тик Хәким сүзсез тора торган кеше түгел, кыскасы, тел бистәсе иде, ахрысы ул.

— Менә бит! Шаккатмалы хәл! Пәри чокырына су төшсен инде, ә!?

— Нишләп алай дисең?

— Соң... син моның тарихын белмисеңдер әле алайса. Революциядән соң, җир убылып, бу күлнең суы юкка чыккан, ди бит. Минем бабай да сөйли торган иде әле. Мин үзем тарихчы булсам да, китаптан гына укысам, бу хәлгә ышанмаган да булыр идем. Бабайның хәтере үткен иде безнең. Туксан яшендә дә район гәҗитен шартлатып укый иде.

— Әйе, бабаңның хәтер шәп иде!

— Менә шул, бабай миңа үзе сөйли торган иде монда балык тотып йөргән чакларын. Революциядән соң бу күл тиктомалдан гына сусыз кала.Кызыл коммунарлар төне буе көмешкә чөмереп утыралар монда, бәйрәм ясыйлар. Кулакларны куып бетерәләр дә... Шуны билгелиләр. Менә шул: берзаман күл дә юкка чыга, теге коммунарларны да җир йота. Ну, ни инде, күл суы белән бергә аларны да упкын үзенә суырып ала, кыскасы.

— Бабаң үзе сөйләгәч дөрестер инде, алайса?

— Мин бу хәлгә шаккатмыйм. Син Әллүкидәге Әбелхәят чишмәсен белмисеңдер инде? Менә шул чишмә янында сүгенсәң яки акырсаң-бакырсаң... Кайда алай гына! Хәтта шул чишмә янында басып торганда күңелеңдә начар уйлар булса да шундук челтерәп агуыннан туктый торган иде. Без хатын белән Бәкер шифаханәсенә дәваланырга бардык. Анда да шундый чишмә бар. Начар уй белән шул чишмә янына килсәң, агуыннан туктый. Суы бик сихәтле икән аның да. Әбелхәятнеке кебек.

— Әллүки күленең суы да юкка чыккан...

— Мәннәви шушы Пәри чокырына суырттырды аны... Әллә кая китмәде аның суы...

— Ничек суыртты? Күл хәтле күл суынмы?

— Соң... — диде беркавым тын торганнан соң Хәким тарихчы. — Күрдең бит инде аның нинди җир асты юлы казыттырганын! Акча бер капчык бит аның! Ышанам, казыттыргандыр!

— Һай-һай, алай микән? — дип үз шиген белдерде Сәхаби. — Ходай рәхмәте белән эшләнә мондый эшләр гадәттә.

— Син нәрсә, Ходай Мәннәви яклы дип беләсеңме әллә син! Аллаһы Тәгалә аны бүген үк тәмуг утына тыгарга әзердер әле. Имансыз бәндә бит ул. Безнең күрше киленгә дә күзе төшкән! Өенә чакырттырып алган, ди. Рәнзилә исемле ул. Әле яна гына кияүгә чыккан иде. Ире бик әйбәт, күз алдында үскән малай. Алтын куллы төзүче.

— Теге... юл һәлакәтенә эләккән егетме?

— Син үзең барысын да белеп торасың тагын, Сәхаби! — диде Хәким. — Әйе, шул кеше.

— Мәннәви аны дәваланырга дип Германиягә үк җибәргән түгелме соң?

— Шпиондыр син, Сәхаби, һәммәсен белеп торасың. Хәер, каравылчы бит әле син. Каравылчы белән пожарникларның шул гайбәт җыюдан башка эшләре юк инде аларның. Вакытлары күп!

— Мин гайбәт сөйләүдән куркам, — диде аңа каршы Сәхаби тыныч кына.

— Болай гына әйттем инде, үпкәләмә.

— Бәлкем, шул яхшылыклары өчен Ходай Мәннәвигә күл суын кире кайтаргандыр?

— Мәннәви Мансарович тик торганнан гына кешегә яхшылык эшли торган адәм түгел!

— Адәм?

— Ну, әйе, андый адәм баласы түгел. Дөресрәге, кеше өчен акча түгә торганнардан түгел. Берәр сәбәбе бардыр. Бәлкем, Рәнзиләне кармакка төшерү өчен эшләгәндер? Яшь килен чибәр!!! Күрсәң син аны! Бер кашык су белән йотарсың! Ул киленгә гашыйк булмаган кеше юк бу авылда. Күз тидерделәр бугай аларның бәхетенә! Ире гарип калмаса ярый инде дә...

— Сере бардыр дисеңме?

— Әйтәм бит, җил исмичә кыл да кыймылдата торган кеше түгел Мәннәви. Алар бит үзләрен Аллаһы Тәгалә дип уйлыйлар!

— Алай ук түгелдер инде? Ходай берәү генә ләбаса... Хәер, син тарихчы. Син атеистыр?

— Җүнле тарихчы ул Ходайга табына торган булырга тиеш! Чын күңеленнән!

— Җүнле тарихчы ул нинди була?

— Камай кебек, — диде Хәким Нургалиев. Менә ул эчмаса белә! Гений ул! Лев Гумилев үзе күрсә күтәреп алыр иде ул егетне! Без дә факультативлар уздырырга чакырабыз аны. Тик хәзер вакытым юк дип зарлана, Байтимердә эшли башлаган бит. Борис урынындадыр... Менә дигән кешене, Борисны әйтәм, харап итеп ыргыттылар бит! Тагын да шул... Галин кулы дип сөйлиләр!

Күлнең аргы ягындагы кала юлыннан машина уты күренде. Һәм шуның артыннан ук күктә гөрелте ишетелде.

— Изольда, Галин кайтып җиткәнче дип, кире Казанга чыгып шылды. Ә Галин, әнә, вертолетында монда кайтып килә! Һе, вәт тормыш, ә, малай! — дип куйды Хәким. Сәхаби аны ишетмәгәнгә салыштымы, әллә игътибар бирмәдеме:

— Галин белән дошман иделәрме? — дип, баягы сүзне дәвам итәргә теләде.

— Дошман дип... Галин аларның агрофирма жирләренә кызыгып йөри бит инде. Борис ана әйткән: мин исән вакытта бер кишәрлек жир дә тәтемәячәк сина дигән!

— Шундый кыю кеше идеме Борис Илсин?

— Анын Баймурзины да төшеп калган егет түгел! Әнә, кыска гына вакыт эчендә Байтамакны бистә итте,чәчәккә күмде. Жиргә ябышып ята егет! Булдыра! Тик мин ишеткән идем әле, соңгы вакытта элек дәррәү мәчеткә йөри башлаган халык, Байтимергә үч итеп, йөрүләреннән туктаганнар диме?

— Үч итеп?

— Маржалар белән чуала башлаган диме? Үзе һәр авыл саен таш пулат кебек мәчетләр салдыра... үзе Наташалар белән маташа диме?..

— Хатыны үлгәчтер инде...

— Дөрес булса, хатыны Нурбикә дә сихердән үлгән ди. Бала тапканда түгел... Алтын Бәртәс маржасыннан сихерләттергәннәр... Матрена бит әле. Минем үземнен ул сихерче янына барганым юк. Ну халык йөри, файдасы тия диләр бугай. Белмим тагын...

— Ә син, кем... Хәким, чалгы тапый беләсенме? — дип сорады капылт кына Сәхаби.

— Чалгы? — Хәким ана сәерсенеп карап куйды. — Чалгыны аны сезнен авылнын Зыятдин абый шәп тапый бит!

— Элек, тимерчедә эшләгән вакытында кайрый торган булган.

— Әәә, — дип куйды ана каршы Хәким. — Бу айны, мин әйтәм, суга төшкән айны дим, Пәри чокыры үзенә суырып алмасын тагын!

— Борчылма, алмас. Хәзер ул үз урынына кире менеп утырачак, — диле гайре тыныч тавыш белән Сәхаби.

Шулчак жил исеп куйды. Күл өстендә әүвәл вак, аннан соң эре-эре дулкыннар йөгерешә башлады. Ай, әлеге дулкыннар өстендә тирбәнеп утырды-утырды да, аннары капылт кына үз урынына — төнге күккә менеп китте.

— Бар да синен кодрәтен илә, Әл-Баары! — дип пышылдады Сәхаби.

## Хатыннарның күтәргән йозак фәлсәфәсе

Тол хатын Сания өенә таба Камайны аяклары алып китте. Әйе, бер ялгансыз, аяклар тиктомалдан үзләре шунда таба тарттылар. Аннары тол хатыннын үтенечен кире кагарга да ярамас бит инде... Камайнын сәерлеге өстенә, теләсә нинди йозак серен ачу сәләте бар икәнлеген белмәгән кеше юк. Аны хәтта ябылып калган сейфларны ачып бирергә дип банкларга да чакырталар, бернинди белгечләр ача алмаган катлаулы сейфларны «эһ» дигәндә ача да бирә иде Камай. Бу сәләте ана кайдан килгәнлеген ул үзе дә, әтисе Жамали абый да, кыскасы, шайтан да белми иде. Камайнын куллары рентген кебек, кулын куюга, сынган-тайганны да шундук төгәл әйтеп бирә ала ул. Анын бу таланты бигрәк тә Петнә Пәймәгә ярап куйды. Фермадагы сыер-бозауларнын аяклары авыртып бик озак төзәлми йөрсә, сәбәбен мал докторлары да таба алмаганда, Пәймә Камайны эзләп китә. Малнын теле юк, кайсы жире авыртканлыгын әйтә алмый, ә менә Камай кулын тидерүгә шундук сизә һәм дөрес диагноз куя ала. Саниянен дә йозагын Камайдан төзәттерәсе килә иде, күрәсен. Тикмәгә чакыруы түгелдер.

Сания өйдә туры килде. Ул егетне кочак жәеп диярлек каршы алды. Тормышын ир-атсыз ялгыз башы алып барса да, Сания жиләк кебек хатын иде. «Ялгыз булганлыгы өчен бар ирләрнен мәхәббәтле карашы шуна төшә. Шунын өчен дә һаман кызлар шикелле йөри ул!» — дип сөйли авыл хатыннары.

Кайберләре, әлбәттә, көнләшә, кайсыберләренең буып үтерердәй булып ачулары килә.

— Камай! — диде ул керә-керешкә. — Син хәзер Байтимернең помошнигы икәнсен бит, име?

— Булса ни. Синең эшләмәгән йозагында монын ни катнашы бар? Әйе, анысы дөрес. Мине моннан соң юк-бар белән борчымагыз. Вакыт юк минем. Байтимер абый суларга да бирми.

— Юк, мин болай гына әйтәм. Берәр көнне Байтимер белән икегезне кунакка чакырмакчы идем.

— Син нәрсә, түти! Үз акылыңдамы соң! Без нишләп сина кунакка йөрергә тиеш ди әле!

— Нишләп алай дисең, наным, менә йөгереп килеп җиткәнсең бит әле! Сания апаң чакыргач, — дип кеткелдәде тегесе. Саниянең тавышына чаклы бик матур. Әбелхәят чишмәсе челтерәвенә охшаган.

— Кайда, йозагыңны күрсәт тә... шул бер йозак өчен кеше борчып йөрмәсәң! Кибет тулы бит йозак, янасын аласы да куясы! — диде инде ник килгәненә үкенә башлаган Камай. Сания, ялт кына өйалдына чыгып, аннан зур бер иске йозак күтәреп керде.

— Менә!

— Нәрсә соң бу? — дип, гаҗәпләнеп Камай аны кулына алды. Әлеге йозак бик борынгы булып, ул ачкыч белән ачылу-ябылу өстенә аның саннар ярдәмендә эшли торган биге дә бар.

— Минем бабайның бабасыннан калган бу! — диде хатын аптырап кулында әлеге ат башы чаклы йозакны әйләндереп утырган егеткә.

— Хан заманында ук ясалгандыр бу!

— Шулайдыр! Минем бабайларым бик бай булганнар. Минем хәзерге бәрәңге бакчасы урынында ашлык амбарлары тезелеп киткән булган. Үзләренең умарталары. Иии-ии, җирләре гектарлап булган инде. Бабам мәрхүм мине каршысына утыртып шул турыда бик тәмләп сөйләргә ярата торган иде.

— Мондый йозаклары булгач, бай булганнардыр шул!

— Бабамнын үзен дә кулак дип сөрә язганнар. Яна оешкан колхозга өч айгырын, ике тарантасын илтеп биргән. Җирләрен сорап та тормаганнар инде. Оя-оя умарталарын да колхозга илтеп биргән. Шуннан соң гына тимәгәннәр үзенә. Берсенә дә исем китми, менә җир, җир әрәм булды дип өзгәләнә торган иде. Лапас артындагы бәрәңге бакчасын һәр көзне, һәр язны янабаштан үзе үлчәп чыга торган иде. Казыкларын гел янартып торды. Алайса, күршеләргә ышансаң. Әнә... — Сания сүзен әйтеп бетермәде, шул урында хикәятен өзде дә, йозак белән маташкан Камайга карап тора башлады. Анын карашын егет тә сизде, ләкин күтәрелеп карарга уңайсызланды. Әлеге халәттән котылу өчен Санияне янә сөйләштерергә керешә:

— Җир белән нишләгән соң ул чаклы?

— Җире булган кеше ачтан үлми, җирне яратырга, аның белән телен аңлап сөйләшә белергә кирәк, дип сөйли торган иде бабам.

Сания янә сүзсез калды, тагын Камайга текәлеп карап торды. Менә йозак та эшли башлады. Камай аны Саниягә сузды.

— Булды бу. Монын белән өенне биклисеңме?

Хатын кычкырып көлеп җибәрде һәм көлүеннән капылт кына туктап:

— Тол хатынның йозагы үзендә аның. Теләсә ача... Теләсә гел бикле тота, — диде һәм янә матур тавыш белән көлеп куйды.

— Тик ятып күгәргән булган икән инде йозагын.

Сания янә ачылып сөйләргә кереште:

— Беләсеңме, бабам сөйли торган иде, амбарларында күпме ашлык булса да алар аны бу йозак белән бикләмәгәннәр. Чыра гына тыга торган булганнар. Әмма мондый дәү йозак барлыгын авылда бар кеше яхшы белгән.

— Бикләмәгәч, нигә кирәк булды икән мондый чуен хәтле йозак?

— Беләсеңме, бикләмәсә дә, бабай йозакны күгәрмәсенгә гел майлап тора торган булган.

— Амбарларына карак та кергәне булмаганмы?

— Булмаган.

— Димәк, байлыгы тир түгеп тапкан байлык булган. Шуңа күрә тимәгәннәр дә, — диде Камайның фәлсәфи иреннәре.

— Урламаган инде ул вакытта. Үзләре тир түгеп тапкан. Эшләгән көнетөне.

— Кызык.. Шәп йозагы да булган, әмма бикләмәгән, чыра тыккан. Әмма йозакны гел майлап тора торган булган үзе. Кызык, — диде Камай беркавым уйланып торганнан соң. — Бүген әнә миллиардлап урлыйлар. Бар амбарларның да йозаклары күгәргән.

— Ә син моны ничек төзәттең соң? Мин аны инде тимерчегә дә илтеп биреп караган идем. Ташла, тузган, диделәр.

— Белмим, — диде Камай. — Үзеннән-үзе килеп чыкты инде шулай. Кул белән тигән идем.

— Синең кулың әллә нинди шул, — диде Сания һәм тынып калды.

— Минем кул... кул кебек инде.

— Ә син авырткан җирне дә төзәтә аласыңмы? Петнә Пәймәсе безнең Камай алтын куллы ди бит?!

— Петнә Пәймәсе ни сөйләмәс.

— Алай димә, Петнә ул белмичә сөйләми инде анысы. — Сания егетнең кулын үзенең учына алды һәм күкрәк турысына китерде:

Мен ничә көн инде гел чәнчеп тора.

— Күгәргәндер...

— Ие, күгәргәндер... Килгән килгән инде... — Сания Камайның кулын үзенең изүенә куйды, шул арада халат төймәләре дә ычкынып, карт егет алдында шәрә бер яктылык ачылып китте. Камайның кай төшендәдер умарта бакчасында кузгалган кытыгы янә кымырҗып куйды. Бәрәңге бакчасы читендәге карт нарат күркәләре дә капылт исеп куйган җилдән селкенешеп алдылар. Ул, унайсызланып, кулын тартып алды һәм ишеккә таба атлады.

— Беркөн ишегалдында егылып кабыргамны сындырдым бугай. Кайсы сынганын да белмим. Барысы авырта.

— Рентгенга бар, — диде Камай дорфа гына һәм ишек тоткасына үрелде. Тик ишек бикле иде. Ул күзе белән йозак яки биккә охшаш нәрсә эзләде, тик ишектә бернинди йозак та, бик тә күренми. Камай ишекне тезе белән тагын этте, әмма аның ачылырга исәбендә дә юк иде. Әйтерсең, тышкы яктан кемдер терәү куйган. Камай ачу белән тагын этте, ишек барыбер ачылмады. Ул, аптырап, Саниягә таба борылып карады. Тегесе берни булмагандай көзге каршында озын толымнарын сүтеп тора иде. Шул озын толымнар егетне кысып буып куйдылар. Ләкин аның тыны кысылмады, киресенчә, сулыш алулары иркенәеп китеп, баягы кытыгы кан тамырлары буйлап таралды...

Камайны озатканда Сания ишекне үзе ачты. Әүвәл ул аны каты итеп эчкә таба тартты, өйалдында нәрсәдер дөбердәп ауган тавыш ишетелде, шуннан соң ишек үзеннән-үзе ачылып китте.

Монысы,чынлап та, тол хатынның күгәргән йозак фәлсәфәсе иде. Өйалды

ягындагы махсус җайланма ишек ничек ябылуга карап, аны тышкы яктан терәү белән терәтеп куя, ә инде ишекне эчкә таба тартканда ул терәү үзеннән-үзе ычкына да ишек ачылып китә икән. Сания кичләрен өйдә үзе генә булганда ишектә терәү күргән кеше, бу өйдә юк икән дип, кире борылып китә икән!..

— Бу бабам җайланмасы, — диде Сания чырык-чырык көлеп. Камай аңа таба елмаеп карады да бусагадан аска төшеп китте.

Ишегалдындагы рәшәткәгә тезелешеп утырган чыпчыклар, ул чыгуга, әүвәл чырык-чырык килделәр, аннары нишләптер, сыерчык тавышлары белән сайрарга керештеләр. Хәер, бу бер Камайга гына шулай булып тоелды бугай.

Камай урамда кеше күзенә күренмәскә тырышып туп-туры өенә кайтты. Бәхетенә күрә, кеше-кара очрамады тагын. Халыкның күзе очлы: шундук егетнең серен чишәрләр иде кебек. Тик әнисеннән сер яшерә торганмы соң! Гөлҗиһан апа бусагадан атлауга улының күзендә нииндидер яшерен сер барлыгын, алай гына да түгел, үз-үзен тотышындагы үзгәрешне сизеп алды да авызын яулык чите белән каплап елмаеп куйды. Тик шулчак йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгарга җитешкәндәй еш-еш тибә башлады. Ул, тиз генә киенеп, туганнан туганы Гөлҗамалларга йөгерде. «Вәт, җүнсез нәрсә! Тәки әйткәнен эшләгән бит! — дип, юл буе сенлесен әрләде. Тик аяк атлаган саен ачуы сүрелә генә барды. Гөлҗамалның ни гаебе бар соң әле? Ул үзе шуны теләде түгелме соң! Тау башы урамындагы Камилә атлы Камайга бик пар килерлек кыз улы артыннан йөреп-йөреп тә, мәхәббәтенә Камайдан җавап ала алмагач, үзендә андый ният туды бит! Камай хатын-кыздан курка, аның малае башка егетләр кебек түгел, ул шуның аркасында гомер өйләнә алмаячак! Монысы әни кеше фикере иде. Чынлыкта исә, Камайның җаны йә глобальләшә барган заманда нечкә хисле алиһәләр генә булып калырга тиешле женси затның ирдәүкәлегән кабул итә алмый яисә аларда күңел күзе генә күрерлек нәфислекнең, нәзакәтлелекнең тупаслана баруын тоеп, әлеге кавемнән читләшә сыман иде. Сыйныфташ кызлары аны әллә кайчан бик гади һәм кыска гына итеп аңлаттылар да куйдылар: «Кызлар тешләп алыр дип курка ул»! Бәлкем, моның өчен Камайга хатын-кыз дөньясының ана серле булган бер читен ачып күрсәтергә кирәктер?! Юк-юк! Гөлҗамалның башына килгән уй түгел бит бу! Аның, әни кешенең башына килгән бер гөнаһлы фикер! Тик шулай да аның бу эштә Гөлҗамалны гаеплисе килде. Ул әйтте бит: Сания белән сөйләшәм, җаен туры китереп, малаенны бер кочаклап үпсен, күзәнәкләрен уятсын, курыкма, шуннан артыгын эшләмәячәк ул, диде! Әлбәттә, кочаклап үбүгә генә ул үзе дә каршы килмәде килүен... Хәер, ана кеше баласы хакына ни кылмас!.. Әмма Гөлҗамал Камайның Саниядә булганлыгы турында әлегә үзе дә белми, әмма анда барырга тиешлеге тәгаен мәгълүм булса да, бу юлы апасыннан да тел яшерергә булды. Бик курыкты ул, Сания, бик чая нәрсә, артык тирәнгә кереп, егетнең башын ук әйләндереп ташламасын диган уй аңа һич тынгылык бирмәде. Юкса ният апасының кыз-хатынга битараф малаена кот индерү, хәтта алай да түгел, егетнең сәламәтлеген тикшереп карау гына иде ләбаса! Алайса өйләнмичә кала бит инде! Андый егетләр аларның авылында гына да буа буарлык. Кайберләре яшьрәк чакта усал аналары янына килен алып кайтудан курыккан, кайсыберләре үзләренә аналары сайлаган кызны ошатмыйча, тора-бара өйләнү ниятенә бөтенләй кул селтәгән, кайсылары исә кызларга сүз кушарга куркудан әлеге кавемнән яшь чакта ук читләшкән егетләр, чынлап та, авылда күп иде. Хәер, Камайны боларның берсенә дә кертеп булмый, ул үзгә иде, бүтән иде. Бәлкем, талантны учлап-учлап биргән баласын Хак Тәгалә башка табигый куәттән мәхрүм иткәндер? Моны берәүдән дә сорап белеп булмаганлыктан, хатыннар вакыйганы үзләренчә ашыктырырга карар иттеләр. Гөнаһыннан бик курыкты югыйсә Гөлҗамал...

Гөлжиһан исә баласы хакына әллә ниләр кыларга, утка-суга керергә дә разый иде шул... Бәлкем, Хак Тәгалә, аның ошбу ниятен аңлап, әлеге гамәле өчен ярлыкап та куяр әле?.. Йа, Ходаем! Үзең ярлыкый күр, зинһар, балалары өчен утка-суга керергә әзер торган аналарны!

Күгәргән йозак фәлсәфәсе, ни әйтсәң дә, фани дөнья, җир фәлсәфәсе иде шул...

Шул кич улының үз гомерендә беренче мәртәбә клубка җыенганын күргән ана, чаршау артына качып, кайнар яшьләрен түкте. Шатлык белән кайгы аралаш яшьләр булганга күрә бик кайнар иде алар... Бу ана хәзер гөнаһлы уйлары өчен тәүбә сорап яшь түгә иде...

Гөлжиһан атлы хатын икенче көнне үк намазга басты.

И тәрбиячебез Аллаһ! Без сиңа гына гыйбадәт кылабыз һәм һәр эшебездә синнән генә ярдәм сорыйбыз. И, тәрбиячебез Аллаһ! Безне туры юлга күндер! Ул юлны син әүвәлгеләргә ингам итеп бирдең, безне Синең ачуың төшкән вә адашкан кешеләрнең бидагать һәм заләләт юлыннан башка юлга күндер, ягъни Сине ачуландырмаган һәм хак юлдан адашмаган кешеләр юлына күндер. Амин, дип пышылдады дөньяга малай табып, шул газиз баласын бик тә, бик тә бәхетле итәсе килгән мескинә ананың кипкән иреннәре...

## Иң татлыдан ни татлы?..

«Уң колагы да, сул колагысының да бармаклары тигез булмаган кебек дөньяның татлы җимешләре дә, ачылары да һәркемгә тигез бирелә алмый. Адәм Ходай тарафыннан ни рәвешле яратылган (Төрле кыйтгалардагы төрле төстәге һәм төрле сыйфатлы туфрак-балчыктан) Ахирәт көненә чаклы ул аерым кавем-милләтләр булып тереклек итәчәк. Моны танымау, бер милләттән икенчесен өстен кую яки башка шундый гаделсез гамәлләр Ходай ихтыяры түгел. Ул җәннәттән куылган Иблис һәм аның шайтаннары, һәм дә шуларга ияртче имансыз бәндәләр эшедер».

Унынчы сыйныф малае Галләмов Әхнәфнең «Әхлак дәресләре» факультатив сәгатьләре өчен махсус ачылган дәфтәренең беренче битендә әлеге сүзләрне укыгач, Җәмил хәзрәтнең эченә шатлык тулды.

— Галләмов бүген дәрестә юк. Әллә авырып киткәнме? — дип сорады ул факультативка җыелган укучылардан. Арадан берсе «кыһ» итеп көлеп куйгандай итте. Җәмил хәзрәт, әлеге укучыны күзе белән эзләп тапты, ләкин шелтәләмәде, бермәл шул тарафка карап торганнан соң, дәресен дәвам итәргә уйлап, кара такта янына килде. Сыйныфта кизү торучы укучы торып басты һәм:

— Хәзрәт, Галләмов бүген мәктәпкә килмәде ул. Алар... ни... Әтисен саклап ята ул.

— Әтисе авырып киткәнме әллә?

Кизү торучы җавап бирергә өлгермәде, арадан берәү үзен бик белдеклегә санап:

— Аның әтисе күршесенең өенә ут төртмәкче булып йөри!

Җәмил хәзрәт, аптырап, кизү торучыга карады:

— Ел саен шулай инде алар, хәзрәт, бәрәңге җире өчен ике күрше талаша. Әхнәфнең әтисе кайчакларда исереп ала да күрше хатынына бәйләнә башлый. Юк, уйламагыз, әйбәт кеше ул Әхнәфнең әтисе. Эчә торган кеше дә түгел. Шул бәрәңге җире өчен күрше Сания апа белән сүзгә килгәндә генә инде. Әхнәф иртәгә килә ул, әтисе әйбәт кеше аның... Шул бәрәңге җире генә инде...

Җәмил хәзрәт, рәхмәт әйтеп, кизү торучыга урынына утырырга кушты. Кизү торучы аңа икенче бер калын дәфтәр сузды:

— Моны Сезгә Әхнәф тапшырырга кушты. Сез биргән биремнәрне эшләгән ул.

— Әхнәфнен әтисенен эченә Иблис кереп оялаган. Әхнәф догалар укып, шуны куып чыгарырга йөри ул! — дип сүзгә кысылды баягы укучы. Башка вакыт булса, Җәмил хәзрәт әлеге тел бистәсен сыйныфтан куып чыгарган булыр иде, тик бу юлы да сабырлыгын туплап өлгерде, шул тарафка усал караш ташлаганнан сон, балаларнын өй эшләре эшләгән дәфтәрләрен җыеп алды. Бүген дәрес укытырга ярамый иде, мәктәп директоры аңа балалар белән саубуллашырга бары  ун минут вакыт бирде. Хәзрәт өстеннән, дин укытып балаларны боза дигән, шикаять бар иде. Әлбәттә, бу хакта сүзләр күптәннән йөри, мәктәп директоры үзе иманлы кеше булганлыктан, монарчы алар андый-мондый сүзләрне ишетмәгәнгә салышып, факультатив рәвешендә әхлак дәресләрен дәвам итеп килделәр. Хәзер, имеш, анын белән органнар шөгыльләнә башлаган. Мәсьәлә җитди иде. Җәмил хәзрәт, ярдәм итүен үтенеп, бүген иртән Байтимер янына барды. Баймурзиннын сүзләре кыска булды: «Укытабыз әхлак дәресләрен, Җәмил хәзрәт! Тик сина бер үтенечем бар: син бүген үк Алтын Бәртәстәге поп янына, Кирилл атакай янына барырга тиеш! Ул да укытсын христиан дине дәресләрен. Мин аларнын мәктәпләрен ремонтлап бирәм. Алтын Бәртәскә хәзер күченеп кайтучы рус гаиләләре арткан ди. Укытсын шуларнын балаларын Кирилл атакай! Аннан сон безгә дә беркем бер сүз әйтә алмаячак! Аңладыңмы?

— Анлавын анладым, Байтимер. Тик ул күченеп кайтучыларнын балалары бар микән сон? Алар бомжлар ди бит!

— Бар булыр, беләм мин. Алтын Бәртәстә яшәп, шәһәрдә эшләргә теләүче рус гаиләләре күп. Шәһәр якын бит аларга. Ата-аналары авылда эшләрләр дип, вәгъдә бирмим. Ә яшәвен яшәрләр.

Әлеге сүзләр Җәмил хәзрәткә канат куйгандай итте, ул батыраеп китеп:

— Байтимер! Мин бүген үк попнын аягына барып егылачакмын! Анын белән күптән үземнен дә танышасы килеп йөри иде инде. Бүген үк аягына барып егылам! Укытсын ул да балаларга үз дәресләрен, христиан дине нигезе буенча!

— Кирилл атакай сина таныш кеше инде ул болай да, — дип куйды Байтимер анын сүзләренә каршы.

— Белмим шул, анысын әйтә алмыйм.

— Сез сельхозда анын белән бергә укыгансыз. Потапов фамилияле.

Әлеге хәбәрне ишеткәч, Җәмил хәзрәт телсез калды һәм беркавымнан, йөзләре ачылып китеп:

— Анладым хәзер. Артык кара фикерле бәндә ул. Әлбәттә, ләкин сабакташ белән уртак тел табып булыр дип уйлыйм. Аягына барып егылсам егылам түлке...

Җәмил хәзрәт, балаларнын дәфтәрләрен җыеп алды да, мәктәптән чыгып китте. Шулчак артыннан сыйныфтагы баягы тел бистәсе малай куып җитте. Бригадир Хәлфин Азат малае иде ул.

— Җәмил хәзрәт, Сез бүтән безне укытмыйсызмы инде?

— Нишләп алай дисен әле? — дип, Җәмил хәзрәт малайнын башына кулын куйды. Тегесе «белмим» дип, инбашларын сикертеп алды.

— Укытыгыз инде, ә, Җәмил хәзрәт, пожалысты!

— Нишләп алай өзгәләнәсен әле? Синен әхлак дәресләренә бик исен китми бугай бит?

Хәлфин малае бик тере, хәрәкәтчән бала иде.

— Укыйм! Укыйм! Җәмил хәзрәт! Минем дә сез өйрәткән догалар белән Иблискә каршы көрәшәсем килә! Әхнәфләр безнен күрше генә бит алар!

— Күрше булса соң!

— Менә, Әхнәф яхшы укып, догалар өйрәнер дә, атасының эчендәге Иблисне куып чыгарыр! Аннан соң ул Иблис кая барачак? Күрше булгач, йөгереп безгә кереп житәчәк! Минем әтинен эченә оялаячак! Аннан соң... теге безнен күршедәге Сания апай белән ул әрләшә башлаячак! Йә, кунакка дип инде... утынын ярып бирергә керәчәк. Сания апайнын ире юк бит анын. Хатын-кыз үзе ничек утын ярсын инде.

— Нигә, күршегә ярдәм итү яхшы эш бит инде?

— Яхшы. Беләм. Түлке анын утынын минем әти түгел, башка кеше ярып бирсен! Мин...кирәк булса, Әхнәф белән икәү ярып бирәбез. Дога укып, Сания апайнын өендәге шайтаннарын да куып чыгарабыз! Усал ул, алайса. Әни әйтә, женнәре бардыр анын, ди. Күрше Сәлим абый белән бер буразна өчен кара-каршы сугыша ала ул! Без анын женнәрен куарга ярдәм итәбез!

Жәмил хәзрәт малайны кочаклап алды да күз яшьләре белән көләргә тотынды. Тыйлыга алмыйча, рәхәтләнеп, ихлас күнелдән көлде. Малай аптырап аңа карап тора иде. Беркавымнан Жәмил хәзрәт көлүеннән туктады да малайны катырак кочып:

— Борчылма, Әмир, ул Иблисне сезнен өйгә керттермибез! — диде. Әлеге сүзләрдән күнеле булган малай мәктәбенә таба кире йөгерде. Юл буе көлә-көлә кайтты Жәмил хәзрәт. Кәефе дә күтәрелеп китте.

Жәмил хәзрәт өйгә кайткач, жанын тынычландыру өчен, балаларнын өй эшләре язылган дәфтәрләрне кулына алды. Менә Хәлфин Азатнын дәфтәре. Күн тышлы калын дәфтәр инде язу белән тула язган. Малай чынлап та әтисенә ярдәм итәргә тырыша, ахрысы. Ул бик кызыксынучан бала. Жәмил хәзрәт матур кул белән язылган дәфтәрнен беренче битен ачты. Ул аларга өй эшенә моннан бер ай элек үк төрле китаплардан дини хикәятләр күчереп язарга кушкан иде.

«Ибраһим (с.г.) бик юмарт күнелле кеше иде. Ибраһим йортында берәр тәмле ризык пешсә, урамга чыгып, берәр күршесен чакырып керә иде. Кыскасы, бик юмарт иде ул.

Менә бер дә бер көнне Ибраһимнен (с.г.в.) ишеген шакыйлар. Ачса, бер мосафир икән. Тамагы бик каты ачкан мосафирнын.

— Ялгышмасам, син юмартлыгын белән танылган Ибраһим буласынмы? — дип сорады ул.

— Анысын Аллаһ белә. Ә исемем, чыннан да, Ибраһим, — дип жавап бирде.

— Әй, Ибраһим, мин тамагы ач бер мосафир буламын. Әгәр тамагыма ризык бирсән, мин сина бик рәхмәтле булыр идем.

— Әй, өс-башы сәфәр тузанына баткан мосафир! Синен тәнрен кем, син кемгә табынасын?

— Минем тәнрем — ут, мин утка табынучылардан булырмын.

— Мин Аллаһтан башка тәнреләргә ышанучыларга, Аллаһны танымыйча, утка табынучыларга ярдәм кулы суза алмыйм шул. Аллаһны бер дип таны. Шулай итсән, минем малым — синен малын. Теләсән, жанымны да бирергә әзер булырмын.

Утка табынучы мосафир Ибраһим (с.г) әйткән сүзләрне бик игътибар белән тынлады да:

— Әй, Ибраһим. Мин туганнан бирле утка табынып яшим. Синен бер сынык икмәгең өчен ата-анамнан мирас булып калган динемнән ваз кичмәячәкмен! — дип, чыгып китте.

Күп тә үтмәде Аллаһы Тәгалә Жәбраил фәрештә аркылы Ибраһим

пәйгамбәргә эндәште: «Әй, Ибраһим, ул бәндәгә ярдәм итмичә син бик ялгыштың. Бу бәндәмә житмеш яшь, шул гомер буе ул утка табына. Әмма мин аны бер көн дә ризыксыз калдырмадым. Син ничек, Минем колым, аңа ризык бирүдән баш тарттың? Бар, эзләп тап ул мосафирны һәм разый ит». Ибраһим (с.г.) пәйгамбәрнең әлеге сүзләрдән соң күзенә яшь килде, ул тиз генә теге мосафирны эзләп китте.

— Әй, мосафир, зинһар, син мине гафу итә күр! Ходай Тәгалә синең өчен мине бик каты шелтәләде. «Мин бу бәндәмне житмеш ел буе ашатам, эчертәм, ә син ни өчен аны разый итмичә чыгарып жибәрдең!» — диде.

Әлеге мосафирның күзләре кайнар яшьләр белән тулды.

— Әй, Ибраһим пәйгамбәр, синең раббың миңа карата шундый мәрхәмәтлелек кылганы өчен мин Аңа инанмыйча, Аны бердәнбер Алла дип танымыйча ничек булдыра алыйм!? — диде һәм иман китерде: — Ләәә илләһе илләллаһ!..»

Әлеге сүзләрне укыгач, Жәмил хәзрәтнең күзенә яшь килде. Әхнәф әлеге вакыйганы Шәрәфетдин хәзрәт китабыннан күчереп алганлыгы аңа мәгълүм иде. Күчерүе әйбәт, ул аның барыбер исендә калачак, башкаларга сөйләячәк. Төп хикмәт монда малайдан мулла ясауда түгел, ә, бәлки, баланың иман дигән нәрсәнең ни икәнлеген аңлавы, яшьтән үк шушы ише нәрсәләрне күңеленә сеңдерүе кадерле. Мондый бала зур үскәч, яманлык кылучы адәм булмас, миһербанлы бер гүзәл кеше булыр, Алла боерса!.. Ул хәзердән үк атасы күңеленнән шайтан коткысын куып чыгарырга тели. Хәерле булсын! Әхлак дәресләре балаларга беркайчан да зыян кылмаячак. Бәгъзе бәндәләр дә моның шулай икәнлеген белмиләрме? Белә, яхшы беләләр... Шулай да бу дәресләрне укытудан тыялар...

Жәмил хәзрәт укуын дәвам итте: «Әюп галәйһиссәлам үзенең халкына пәйгамбәр итеп жибәрелгән иде һәм Аллаһы Тәгалә аны башка пәйгамбәрләрне сынамаган сынаулар белән сынады. Әюп галәйһиссәламнең мул алмалы бакчалары, әдәпле гаиләсе һәм нык сәламәтлеге бар иде. Житешле булуына карамастан, Әюп галәйһиссәлам Аллаһы Тәгалә үз өстенә йөкләгән бөтен эшләрне төгәл эшләп баручылардан иде. Менә бер дә бер вакыт аңа төрле сынаулар килә башлады. Әүвәлдән алма бакчасы харап булды. Шайтан аның янына килеп: «Ташла гыйбадәтеңне, бераз үзеңне кайгырт», — дип әйтте. Ләкин ул: «Без Аллаһныкы һәм янадан аңа гына кайтачакбыз. Ул үзе бирде, үзе алды, шуңа күрә мин ничек итеп аңа ачуланыйм!» — диде дә шайтанны куып ук жибәрде. Алда тагын сынаулар бар иде әле. Әюп галәйһиссәламнең төрле авырулардан балалары үлә башлады. Кеше сурәтендәге шайтан тагын аның кырына килеп: «Әй, Әюп, мин кызганам сине, бакчаң һәлак булды, балаларың үлеп бетте, ә син һаман Аллаһ, Аллаһ дисең. Ташла бу эшеңне! Акылыңа кил!» — дип котыртты. Әюп болай дип җавап кайтарды: «Без Аллаһныкы һәм аңа кайтачакбыз. Ул үзе бирде, үзе алды. Биргән әйберен кире алганы өчен ничек мин аңа ачуланыйм!» — дип, шайтанны янә яныннан куды. Бу сынаулардан соң Аллаһы Тәгалә Әюп галәйһиссәламнең сәламәтлеген алды. Авыруы көннән-көн көчәя барды. Чирең безгә йокмасын дип, аны авылыннан да кудылар.

Әюп галәйһиссәламнең хәле начарайганнан-начарайды. Янында янә кеше кыяфәтле шайтан пәйда булды: «Әй, Әюп, мин сиңа шаклар катам! Малың, балаларың юкка чыкты. Үзең авырыйсың, хатының кулына калдың, ә үзең һаман Аллаһ дисең!» дип котыртты аны шайтан. Әюп галәйһиссәлам аңа каршы тагын: «Без Аллаһныкы һәм аңа кайтачакбыз! Үзе бирде, үзе алды!» — дип тегенең авызын томалады.

Хәле тагын авырая башлагач, ниһаять, Аллаһка мөрәҗәгать итте ул:

«Әй, Раббым, торып гыйбадәт кыла алырлык сәламәтлек насыйп итсәнче!» Шуннан соң Аллаһы Тәгалә сабырлыгы өчен аның догасын кабул итте һәм югалтканнарының хакын ике мәртәбә арттырып кайтарды. Әюп галәйһиссәлам фани дөньялыкта дөнья хөрмәтенә, ахирәттә ахирәт бәхетенә ирешә».

Ошбу хикәятләрне бик тырышып, пөхтә итеп күчергән Әхнәф. Дәфтәр битләренә бер тап та төшермәгән, мондый пөхтәлек малай кеше өчен гайре табигый хәл иде, әлбәттә. Димәк, бик тырышкан малай, чын ихластан башкарган эшен. Әле өстәвенә хикәят ахырында үз сүзләрен дә өстәп куйган: «Иблис, шайтан коткысы аркасында күпме бәла-казалар кичерә кешеләр. Әмма барыбер шуның коткысына биреләләр! Без шул шайтаннардан да түбәнрәкмени!?» Бу сүзләр Җәмил хәзрәтне тетрәндерде.

«Әгәр поп балалар укытырга риза булмаса, аягына егылам, үтенеп-ялварып сораячакмын! — дип уйлады ул күз яшьләрен сөртеп. — Күрше мәктәптә христиан дине нигезләре буенча әхлак дәресләре укытылган очракта безгә дә сүз әйтмәсләр!»

Балаларның күңелләре бәллүр пыяла кебек, хисләре бик нечкә. Аларга ялгыш зыян салудан Ходай үзе сакласын! Ул киләсе дәрестә балаларга Коръән хакында бер галимнең яна ачышы хакында сөйләргә уйлаган иде. Әле ярый сабыр иткән, ашыкмаган. Чөнки әлеге галимнең фикерләрен дәлилли торган мисалларны үзе дә тапты бит ул. Әгәр киләчәктә дәресләрне дәвам итәргә рөхсәт алып булса, сөйләр, Аллаһ боерса, рәхәтләнеп, тәмләп сөйләр.

Аны Алтын Бәртәскә алып барып кайтырга капка төбенә машина килеп туктады. Рульдә Камай үзе икән. Камайны күргәч, Җәмил хәзрәт сөенеп куйды, чөнки сөйләшәсе сүзләре бар иде. Тик Камай бүген никтер кәефсез. Җәмил хәзрәт сәбәбен сорарга ашыкмады, чөнки егетне белә, бераздан барыбер ачылып сөйләшә башлаячак иде ул.

— Юлга чыгар алдыннан су эчтеңме соң, хәзрәт? — дип куйды ул дорфа гына.

— Эчтем, — диде тегесе тыныч тавыш белән, әйтерсең, Камайның дорфалыгы аңа кагылмый иде.

— Мин дә су эчтем, — чак кына паузадан соң: — Беләсеңме, Иван Грозныйның Казанны басып алуы ул татарларга каршы тәре походы булган! — дип куйды. Әлбәттә, юлдашның тиктомалдан гына шундый сүз башлавы Җәмил хәзрәтне аз гына гаҗәпләндереп куйды, тик җавап кайтармауны кулайрак күрде, чөнки Камай юктан гына сүз башлый торганнардан түгел, ул йомшак итеп тамак кына кырды.

— Дмитрий Донскойдан үрнәк алып, Иван да үз походын... Казанга каршы походын диюем, Коломнадагы храмга барудан башларга уйлый. Тик Кырым ханы Дәүләтгәрәйнең гаскәрләре Тула астына тупланган дигән хәбәр аның юлын кире бора. Мәскәү митрополиты Макарий барыбер үз максатына ирешә, Казанга барганда ул Иванның игътибарын патша нәселенең изгеләре саналган Петр белән Февронияне чиркәү тарафыннан искә алу вакыйгасына юнәлтә. Муромда июнь аенда чиркәү әлеге көнне зурлап бәйрәм итә. Казанга барыр алдыннан Тула астындагы җиңүе белән канатланган Иванны хәйләкәр Макарий Муромдагы изгеләргә баш иярга чакыра. Муромга килеп җитүгә Иван Макарийдан зур хатнамә ала. Макарий анда Петр белән Феврониянең кешелек дошманы аждаһага каршы көрәшүләре хакында яза, аны канатландыра, Муромдагы изгеләрнең аңа Казан походында ярдәм итәчәкләре хакында тәкрарлый. Шул рәвешле ул яшь патшаны дин исеменнән, ягъни кулына тәре тоткан сурәттә татарларга каршы барырга чакыра! Патшаның төп эше христиан динен саклау булырга

тиеш, ди баш поп. Һәм Иванның Казанга каршы булган барлык походлары да, шул исәптән башка татар ханлыкларын басып алу идеологиясе дә, нәкъ Макарий теләгәнчә, имеш, христиан динен басурман изүеннән коткаруга нигезләнә. Аурупа державалары каршында аклану өчен кирәк була әлеге сәясәт Мәскәүгә. Алар без җир өчен, байлык өчен түгел, христиан динен бәладән коткарабыз дип шапырыналар! Шулай булгач, Иван ул вакытта тәре походлары оештыра булып чыга түгелме соң?

Җәмил хәзрәт аның әлеге фикерләренә каршы бер сүз дә әйтмәде. Аның үз уйлары иде. Кирилл аларның бүгенге сәяхәтләрен ничек кабул итәр, элек дин ягыннан консервативлыгы һәм үҗәтлеге белән аерылып торган Потапов үзгәрдеме икән? Үзгәрсә — кайсы якка? Тагын да каралганмы, әллә бераз гына булса да, яши торгач, күзе ачыла төшеп, дөнья мәсьәләләренә аек карый башлаганмы?

— Ә син беләсенме, Камай, Коръән дөньяга ингәнче үк Библиядә адәм балаларына Коръән киләчәге хакында әйтелә бит? — диде ул үзенең соравына җавап ала алмагач, кинәт тынып калган егеткә борылып. Камай әлеге сорауны үзенчә кабул итте:

— Миннән көлүенме, Җәмил хәзрәт?! Мин чын хәлләрне сөйләдем, тарихи фактларны! — диде ул.

— Нишләп көлим! Ышанам мин сиңа, безгә карата андый походлар бүген тукталган дип уйлыйсыңмы син. Мин сиңа Библиядәге Коръән турындагы хәбәрне генә әйтәм.

— Чынлап тамы, Библиядә Коръән хакында искә алынганмы? Мин бит сине, минем сөйләгән сүзләргә ышанмыйча, мине котыртып, шаяртып утырасың дип торам!

— Чын! — диде Җәмил хәзрәт. — Второзакониенең 32нче бүлеге 10нчы шигырь юлында шундый сүзләр бар, русча әйтәм, яхшырак аңлашылсын өчен: «Он нашел его в пустыне, в степи печальной и дикой, ограждал его, смотрел за ним, хранил его, как зеницу ока Своего». Хәер, инде сиңа бу хакта җентекләп аңлатып утыра алмыйм, кыскасы, «Коръән» дигән сүз ачыктан-ачык язылан анда. Септуагинтада ул. Христианнарның пәйгамбәрлек китабы. Христос исеме дә шунда беренче тапкыр әйтелә.

«Зеница ока, глазное яблоко», ягъни күз алмасы хакында сүз бара анда һәм латин хәрефләре белән: «Koran ofthflmou» диелгән! Гарәпчә коръән «уку» дигәнне аңлата. Һәм шул уку аша Илаһы һәрвакыт адәм баласына багып тора, гел күзәтеп тора, үзенең хәер-фатихаларын җибәрә. Шул күз алмасы аша бара барысы да!..

Әлбәттә, богословлар моны бары фонетик охшашлык белән, ягъни очраклы охшашлык дип аңлатмакчы булалар. Йә, хуш, шулай да булсын, ди. Мин шуннан соң үзем эзләнә башладым. Коръән Пәйгамбәргә борынгы гарәп телендә иңә, Библия борынгы грек телендә. Шуннан мин әлеге ике телне чагыштырып өйрәнергә керештем һәм шаклар каттым! Беләсенме, бу ике телдә охшаш сүзләр, төшенчәләр байтак икән бит! Димәк, Библиядәге «Коръән» сүзе дә очраклы хәл түгел.

— Ничектер барыбер ышанып бетәсе килми, Җәмил хәзрәт. Чөнки без һәрвакыт үзебезнең якны каерырга күнеккән, христианнар — үз ягына...

— Соң, балакаем, ышанмасаң, тыңла дальше! Ник бүлдерәсен?! Мисал өчен грекларның Зевс атлы алласының исеме борынгы гарәп теленнән! Гарәпчә «зевс»... Тукта, әүвәл әлеге телләр турында, алайса аңлату кыен булыр. Борынгы гарәп теле һәм шулай ук борынгы грек теле дә семит телләре семьялыгына керә.

Камай яшьлеге белән түзмәде, бик тәмләп сөйли башлаган хәзрәтне бүлдереп:

— Ләкин алар шартлы рәвештә әлеге семьялыкка керә, — дип сүз кыстырды.

— Әйе, әйе, минем сүзем дә шул хакта. Менә шул: семит семьялыгына кергән телләр грамматик яктан да, килеп чыгу урыннары белән дә һәм хәтта таралулары белән дә охшаш түгел. Бу, Библиядә әйтелгәнчә, әлеге халыкларны генеалогик классификацияләү сәбәпле килеп чыккан. Борынгы яһүди телләренә якын сөйләшләрнең һәммәсен дә Нух улы Сим токымына кертәләр. «Сим»нан «семит» килеп чыккан. Үле семит телләре дә бар, аралаша торганнары да күп. Шулар исәбеннән гарәп теле һәм иврит телләре. Зевс дидем бит әле? Көндезге күк, яктылык, яшен Алласы бит инде ул. Менә әлеге сүз гарәпчә яктылык дигәнне аңлата. Гректа мондый сүз юк, Алла аларда «теос» була. Гера, белгәнебезчә, Зевсның хатыны. Гера бик көнче хатын була. «Гера» дигән сүз исә гарәпчә «көнче» дигәнне аңлата. Тагын мисалларны? Рәхим ит: мәсәлән, Зевсның туганы, дингез давылы алласы Посейдон. Ишеткәнең бардыр инде: «...мчался по морю на колеснице, запряженной длинногривыми конями, с трезубцем, которым вызывал бури». Посейдон грекча бернәрсә дә аңлатмый диярлек. Ә гарәпчә ул «давыл чыгаручы»! Мәхәббәт Алласы Афродитаны алыйк соң: Гефестның хатыны бит ул, мәхәббәт һәм матурлык алласы. Гарәпчә ул «грива» дигәнне аңлата. Татарчасы ничек була торгандыр... Ялмы? Мәсәлән, Геракл. Ул Зевсның уйнаштан туган малае бит. Шуның өчен көнче Гера Гераклны яратмый, ана акылдан яздыра торган сихер җибәрә. «Геракл» гарәпчә «акылдан язган». Мондый мисаллар белән буа буарлык. Шулай булгач, нинди фонетик, яки очраклы охшашлык булырга мөмкин ди монда!

Камай, башын чайкап куйды.

— Күреп торам, бу мәсьәләне шәп өйрәнгән син, Җәмил абый!

— Шуларны Кириллга аңлатмакчы булам да...

— Ышанмыймы?

— Тыңлап та тормый, кулын гына селки. Бүген менә ничек кабул итәр инде?

Камай дәшмәде. Ул күнеленнән генә Гайсә, Ходай тарафыннан инҗил иңдерелгән Гайсә пәйгамбәр хакында уйлана башлаган иде. Аның хакында ул үзе укып белә. Баксаң, Аллаһы Тәгалә Адәм, Нух, Ибраһим пәйгамбәрләрне, Ибраһим нәселеннән килгән башка пәйгамбәрләрне, Гыймран гаиләсеннән Мәрьямне, аның улы Гайсәне бер кавемнән итеп яраткан. Болар барысы да бер нәселдән. Шулай булгач, араларында нинди ызгыш алмасы булырга тиеш ди?! Ә бар! Нинди генә ызгыш бар әле! Ә бит чынлыкта менә ничек булган: «Гыймранның хатыны Хәннәнең Раббысына ничекләр итеп ялварганын хәтерләгез. Гайсәнең барлыкка килүе шуннан ук башлана бит инде. Гыймран Гайсәнең бабасы, чөнки ул Мәрьямнең әтисе бит. Чынлыкта, Гыймран белән Хәннәнең балалары булмый. Көннәрдән бер көнне агач күләгәсендә утырганда алар янындагы агачка бер кош кила һәм баласын ашата башлый. Моны күреп торган Хәннә Раббыга ялвара: «Йә, Раббым, миңа да бер бала бирсәң, аны дин юлына куяр идем», ди. Аллаһ аның теләген кабул кыла: Хәннә Мәрьямгә йөкле була. Хәннә Мәрьямне тудыргач: «Һәй, Аллам, кыз бала тудырдым, ир бала булса, дин хезмәтенә яхшы булыр иде», — ди.

Бу хәлләр хакында Камай Коръән аятьләре аша белде, тәфсиренең бер өлеше исә сүзгә сүз, җөмләгә җөмлә түбәннән гыйбарәт иде. «Аллаһ белүчерәктер, нинди бала тудырганыны. Хәннә әйтте: «Ир бала, әлбәттә, кыз бала кебек түгел, аның исемен Мәрьям куштым, бу баланы вә аннан туачак балаларны рәхмәтеннән сөрелгән шайтан шәреннән Синең саклавыңа тапшырдым». Мәрьямнең анасы

Хөннә, Зәкәрия пәйгамбәрнең хатыны белән бертуган иделәр. Мәрьямне Раббысы мәсҗид Әкъсага күркәм кабул итү белән кабул итте һәм яхшы тәрбия белән тәрбияләде, һәм тәрбияләп үстермәк өчен Зәкәриягә тапшырды. Хөннә Мәрьямне тудыргач, мәсҗид әкъсага алып барып, андагы намаз укучыларга: «Бу бала Аллаһ юлына нәзер әйтелгән, кабул итеп алыгыз», — диде. Мәсҗид әһелләре баланы кабул итеп алдылар һәм тәрбияләп үстерү хакында һәрбере: «Мин алам», — дип, үзара бәхәсләштеләр. Бу бәхәскә нокта кую өчен Аллаһтан юл күрсәтелде: «Барчагыз да каләмнәрегезне суга салыгыз, кемнең каләме суга батмаса, Мәрьямне шул кеше алыр». Әйтелгәнчә эш кылдылар. Зәкәриянең каләме суга батмады, Мәрьям ана тапшырылды. Зәкәрия мәчет эчендә бер урын хәзерләп Мәрьямне шунда тәрбия кылды. Мәрьям зекер, гыйбадәт белән мәшгуль булды. Зәкәрия Мәрьям янына кайчан гына керсә дә алдында җимешләр һәм башка ризыкларны күрер иде. Бер килгәнендә: «Ий, Мәрьям, бу ризыклар сиңа кайдан килә?» — дип сорады. Мәрьям әйтте: «Бу ризыклар Аллаһ хозурыннан килә. Аллаһ, әлбәттә, үзе теләгән бәндәсен ризыкландыра». Мәрьямнең дәрәҗәсен Аллаһ күтәргәнне күреп, Раббысыннан ялварып дога кылды. Әйтте: «Ий, Раббым, рәхмәтеңнән миңа бер бала бирче! Шиксез, син минем догамны ишетәсең». Зәкәрия михрабта намаз укып торганда Җәбраил килеп кычкырды: «Ий, Зәкәрия, дөреслектә, Аллаһ сине Яхъя исемле изге угыл белән шатландыра. Ул Яхъя Аллаһтан булган сүзгә ышанучы булган хәлдә, ягъни Гайсә пәйгамбәргә иң беренче иман китереп, ярдәмче булыр. Янә ул Яхъя каүме арасында хөрмәтле вә олугъ булыр, һәм дә хатыннар белән собхәт итүдән сакланучы изге пәйгамбәрләрдән булыр». Зәкәрия әйтте: «Ий, Раббым, миңа кайдан угыл булсын, дөреслектә, миңа картлык иреште, хатыным да бала тудырмаучыдыр». Аллаһ әйтте: «Ий, әнә шулай Аллаһ Тәгалә теләгәнен кылыр». Зәкәрия әйтте: «Ий, Раббым, хатынымның йөкле булуына миңа бер галәмәт бир». Аллаһ әйтте: «Синең кешеләр белән сөйләшә алмавың сиңа галәмәт булыр, кешеләр белән өч көн сөйләшә алмассың, мәгәр ишарәт белән генә сөйләшерсең». Хатыны йөкле булгач, Зәкәриянең теле бәйләнде, зекер тәсбихтән башка сүзләрне сөйли алмас булды. Аллаһ әйтте: «Ий, Зәкәрия, Раббыңны күп зекер ит вә көндезләрен һәм кичләрен намаз укы! » Фәрештә әйтте: «Ий, Мәрьям, дөреслектә, Аллаһ сине сайлады вә сине гөнаһтан пакълады һәм бөтен дөнья хатыннарыннан сине өстен куйды. Ий, Мәрьям, Раббыңа итагать һәм рәкүгъ, сәҗдә кылып намаз укучылар белән намаз укыгыл!» Бу Мәрьям кыйссасы Коръән инмәс борын синең өчен яшерен иде, инде вәхий белән белдерәбез. Мәчет Әкъса мөселманнары шобага өчен каләмнәрен суга салганда, син алар арасында юк идең, һәм Мәрьямне тәрбиягә алыр өчен тартышкан вакытларында да яннарында булмадың. Җәбраил әйтте: «Ий, Мәрьям, Аллаһ сине бер бала белән шатландырадыр. Ул бала атасыз, Аллаһның «бар бул» дип әйтүе белән булыр, ул баланың исеме Гайсә (Иисус, сын девы Марии) булыр, ул бала дөньяда һәм ахирәттә дәрәҗә иясе вә Аллаһка якыннардан булыр. Ул бишектә чагында һәм үсеп житкәч тә хикмәтле сүзләр белән сөйләшер һәм ул изгеләрдән булыр». Мәрьям әйтте: «Ий, Раббым, миңа бала кайдан килсен, чөнки миңа ир затының кулы тигәне юк». Аллаһ әйтте: «Әнә шулай Аллаһ үзе теләгән нәрсәне халикъ кылыр. Берәр нәрсәне булдырырга ниятләсә фәкать: «Бул!» — дияр, ул нәсрсә Ул теләгәнчә бар булыр». Аллаһ Гайсәгә язу белемен, шәригать хөкемнәрен һәм Тәүрат, Инжил китапларын өйрәтте. Вә Ягъкуб балаларына пәйгамбәр итеп кылды. Гайсә рәсүл булгач, Ягъкуб балаларына әйтте: «Мин, Гайсә, сезгә Раббыгыздан пәйгамбәремә ачык дәлилләр һәм галәмәтләр белән килдем. Ул хикмәтләрнең берсе шул булыр: мин балчыктан кош сурәте ясармын да ана өрермен. Аллаһ әмере белән ул кош булып очар. Янә Аллаһ әмере белән сукырларны күзле итәрмен, ала тәнле кешеләрне сәламәтләндерермен. Янә

мин сезгә нәрсә ашаганыгыздан, өйләрегездә яшереп саклаган нәрсәләрегездән хәбәр бирермен. Бу хәлләрдә, әлбәттә, минем пәйгамбәрлегемне хак кылучы дәлилләр бардыр, әгәр хаклыкка ышанучылардан булсагыз. «Миннән әүвәл иңдерелгән Тәүратны тәсдыйк иткәнем хәлдә, һәм сезгә хәрам булган кайбер нәрсәләрнең кайберләрен хәләл иткәнем хәлдә, Раббыгыздан галәмәтләр белән сезгә пәйгамбәр булып килдем. Шулай булгач, Аллаһыдан куркыгыз, мина итагать итегез һәм карышудан сакланыгыз. Хакыйкатьтә, Аллаһы мине дә, сезне тәрбия кылучыдыр. Тәрбияче булган Аллага, әлбттә, гыйбадәт кылыгыз! Аллаһка итагать итү һәм Аңа гына гыйбадәт кылу — иң туры юл бит. Гайсә, мөшрикләрнең һаман-һаман көферлекләрен дәвам иткәннәрен күргәч: «Аллаһ диненә мина кем ярдәмче була?» — диде. Гайсәгә иярган мөэминнәр: «Аллаһ динендә без сина ярдәмче булырбыз, без Аллаһка нык ышандык. Аллаһка итүче хак мөселман икәнлегебезгә шаһит бул», — диделәр. Ий, Раббыбыз, син иңдергән китапларга ышандык һәм пәйгамбәргә иярдек. Безләрне Синең берлегең вә исламның хаклыгы белән шәһадәт бирүче мөселманнар белән бергә кыл! Кяферләр исә Гайсәгә карата явыз хәйлә кордылар. Аллаһ исә аларга каршы тагын да көчлерәк хәйлә әзерләде. Кяферләр Гайсәне гаепләргә, үзләрен дөресләргә дәлил тапмагач, ниһаять, ачуларыннан Гайсәне үтерергә карар кылдылар. Мөселманнар арасында кяферләргә сатылган бер монафикъ бар иде, кяферләр Гайсәне үтерергә әмер иткәч, шул монафикъ Гайсә кергән өйгә кяферләрне җыеп алып килде. Ләкин бу вакытта Аллаһ Гайсәне күккә күтәргән иде инде. Монафикъ, Гайсәне тотабыз дип өйгә кергәч, Аллаһ аның сурәтен Гайсә сурәтенә кертте. Кяферләр аны Гайсә дип белеп, тотып астылар. Менә аларга Аллаһның бер гамәле шул булды. Аллаһ әйтте: «Ий, Гайсә, Мин, әлбәттә, сине үтерүче һәм хозурыма күтәрүчемен һәм сине кяферләрнең явыз хәйләсеннән саклап, пычрак йогынтыларыннан пакълаучымын. Янә,ий, Гайсә, сина иярган мөэминнәрне кыямәт көненә кадәр кяферләрдән өстен кылырмын. Кяферләр белән арагызда булган бәхәсле эшләрдә гадел хөкемдар булырмын. Әмма Коръән белән гамәл кылмыйча кяфер булган кешеләрне дөньяда һәм ахирәттә каты газап кылырмын, Минем газабымнан котылырга аларга ярдәмче булмас. Әмма иман китереп изге гамәлләр кылучы мөэминнәрнең әҗерен Аллаһ тулысынча үзе бирер. Ләкин Коръән белән гамәл кылмаучы залимнәрне Аллаһ һич тә сөйми. Ий, Мөхәммәд с.г.в., Без сина укыган кыйссалар синең пәйгамбәрлегенә ишарәт итүче дәлилләр. Вә без вәхий кылган сүзләр, барча хикмәтләрне зекер итүче Коръән Кәримдер. Гайсәнең атасыз халыкъ кылынуының мисалы Аллаһ хозурында Адәм галәйһиссәлам кебектер. Адәмнең тәнен балчыктан ясады да соңрак аңа: «Бул» дип әйтүе белән булды. Гайсә хакында булган хак сүзләр Раббыңнан килә, шикләнүчеләрдән булма!»

Гайсә пәйгамбәрнең анасы Мәрьям икәнлеге, бабасы Гыймран атлы булганлыгын бел!.. Моңа Ходайдан иңгән Коръән Кәрим бәхәссез һәм ачык дәлилдер, Иншаллаһ!..

— Син барлык диннәрне дә бергә берләштерергә уйламыйсыңдыр бит? Килешү хакында?

— Никогда! — дип кычкырып җибәргәнен үзе дә сизми калды Җәмил хәзрәт. — Аллаһ бер, диннәр төрле, халыклар, милләтләр төрле. Алар аерым-аерым, һәркайсы үз юллары белән, ләкин үзара тату яшәргә тиеш, — дип кенә уйлыйм мин. Максатым да шул. Ызгыштан ни мәгънә! Хәер, ни мәгънә икәнлеген тарих сабаклары күп күрсәтте бит инде! Бөтен хикмәт тә татулыкта. Беләсеңме, гаилә табынында иң татлыдан ни татлы?

Сүзләре шунда капылт өзелде, алар Бәртәскә килеп җиткәннәр, юл аша дуңгыз көтүчесе малларын чыгарып маташа иде. Камай мәхлукләрне таптатмас өчен машинаны туктатты.

— Җәмил хәзрәт, карале, дуңгыз очраткан мөселман кешесе нинди дога укырга тиеш әле? — диде Камай авызын ерып.

— Нәрсәгә авызыңны жырасың, энем. Соравың дөрес бит!..

Җәмил хәзрәт җөмләсен тәмамлый алмады, Камай дуңгыз көтүчесенә таба төртеп күрсәтеп, кычкырып җибәрде:

— Карале, кара! Хөллиев бит бу! Абрек!!!

Җәмил хәзрәт тә сискәнеп куйды:

— Чынлап та охшаган бит, ә?!

— Охшаган гына түгел! Үзе ул! Нәкъ үзе!!! Вәт, олигарх, ә! Налоглардан качу өчен, кыяфәтен үзгәртеп, дуңгыз көтүчесе булып йөри бит, ә! Менә нишләтә ул акча! Югыйсә миллиардер иде бит ул! Шулай, шулай, налоглардан качып йөри ул, Җәмил хәзрәт! Мин аны бүген үк полициягә заявить итәм!

— Итмә, кирәкми, — дип куйды Җәмил хәзрәт тыныч тавыш белән. — Алайса ул дуңгызларны кем көтәр?..

— Көләсең инде син, Җәмил хәзрәт, көлгән буласың... булабыз... Хәерчеләр байдан көлеп утырыр заман җитте, ә? Олигархлар дуңгыз көтүе көтәр көн килеп җиткән... хәерчеләр байдан көләр көннәр килеп җиткән!..

— Кем хәерче әле?

— Юк, юк, сине әйтүем түгел! Син гыйлем кеше, Коръәнне беләсең...

— Коръәнне белеп, аңлап бетерү өчен бер кеше гомере генә җитми, энем, — дип куйды Җәмил хәзрәт һәм авыз эченнән дога укырга кереште. Чөнки бу вакытта көтү дә, көтүче Абрек Хөллиев тә тыкрыкка кереп күздән югалганнар иде инде...

— Борчылма, сындырабыз аны! — дип куйды шулчак Камай һәм машинасын кабызды. Сүзне шулай капыл Кирилл атакайга борган иде ул. Чөнки әле генә алар тап булган тамаша икесенең дә хушларын алган, алар бик каушаганнар иде. Камай машинаның арткы утыргычыннан шешә алып, Җәмил хәзрәткә сузды:

— Су эчеп куй, Җәмил абый.

Тегесе бер йотым эчте дә күршесенә сузды:

— Үзең дә эч, — диде.

Алар Кирилл атакайны чиркәүдән кайтып килгәндә очраттылар. Янәшәсендә таныш булмаган берничә ир-ат та бар иде. Поп киемнәрендә булуга карамастан, Потаповны шундук танып алды Җәмил хәзрәт. Ни гаҗәп: эшләр Җәмил алдан фаразлаганча барып чыкмады, Потапов сабакташын күрүгә шат иде, алар кочаклашып күрештеләр һәм тегесе икесен дә өйгә чакырды. Ләкин Җәмил хәзрәт үтенечен... юк, үтенеч түгел, тәкъдимен тиз генә әйтеп, китеп бармакчы иде, шуңа күрә алдан ук үзенең вакыты чикләнгән икәнлекне сиздереп куйды. Аның тәкъдимен Кирилл атакай яхшы кабул итте итүен, ләкин аның үз мәшәкатьләре чиләк авызына чаклы тулган.

— Кемнәрне укытыйм соң? Нинди балаларны? — диде ул җилкәләрен сикертеп.

— Элеккеге спирт заводына шәһәрләр кайтып, йортлар салган бит. Аларның балалары юкмыни?

— Бар, тик алар шәһәр кешеләре бит. Җәйләрен генә монда кайтып торалар. Үзең дә беләсең бит, кыш көне бу якларга машина түгел, кар ерып җәяү дә йөрерлек түгел!

— Байтимер монда дамба төзетәм ди. Быел ук.

— Алай булса гына. Хәзергә өч бала бар барын, алайса, мин шуларны укыта башлыйм.

Алар кул сугып килештеләр. Тик шундый җылы мөгамәлә булса да араларында барыбер ниндидер салкынлыкмы, яки башка берәр төрле каршылыкмы бар

кебек иде. Камай алар сөйләшкәндә Кирилл атакайның ихатасына кереп чумды, шуңа күрә ул моны сизмәде, юлда кайтканда Жәмил хәзрәт бу хакта аңа үзе сөйләде.

— Миннән күзләрен яшерә нигәдер, — дип куйды ул.

— Сез студент вакытта ук чәкәләшеп, бәхәсләшеп яшәгәнсез бит инде?

— Анысы шулай... Беләсеңме, бу Потапов белән бергә укымаган булсам, бәлки, мин дин юлына кереп тә китмәгән булыр идем, дип уйлыйм кайчакларда. Аның белән бәхәсләшкәндә җиңеп чыгу өчен мин тырыша-тырыша Коръәнне өйрәнә башладым. Шул үзенә алып кереп китте дә инде.

— Планнары нинди синең сабакташыңның? Сөйләдеме?

— Юк... нишләптер бик канатланып яшәми ул монда. Үзе Байтимер ярдәмен дә кире какмый. Аңламассың аныкын... Ничектер серле тоелды ул миңа...

— Һе, аптырама, Җәмил абый, бу авылда бөтен нәрсә сер белән тулган! Мин шуларның берсен ачтым бит тәки!

— Нәрсә ачтың инде тагын?

— Хөллиев белән күрештем бит мин! Теге... дуңгыз көтүчесе белән!

Аның әлеге сүзләреннән Җәмил хәзрәт сискәнеп китте һәм, томырылып, аңа карады:

— Йә, сузма!

— Абрек Хөллиевнең үзе түгел ул... Малае!..

— Кит аннан! Булмаганны!

— Ант әгәр!.. Тик уйнаштан туган малае. Аның дөньяда барлыгын Абрек үзе дә белмәгән, имеш! Менә сиңа тагын бер табышмак, ә!

— Табышмак шул! Нишләп йөри ул монда. Көтү көтеп?..

— Эзәрлеклиләр икән аны. Әтисенең бер компаньоны. Абрек аны заманында кидать иткән! Хәзер малайдан атасының акчаларын таптыралар. Имеш, Хөллиев бар байлыгын әлеге малайга калдырып киткән, ди.

— Юктыр, бомж булып йөрмәс иде.

— Тегеләрдән качкан ул. Бомжлар арасына качкач кына эзне югалта алдым, ди.

— Ә нишләп нәкъ бу тирәгә качкан?

— Бәлкем, кон саен атасының каберенә дога укырга бара торгандыр?

— Көлмә! — диде Җәмил хәзрәт әңгәмәдәшенә үпкәләп. Камай моңа игътибар итмәде, баягы сүзен дәвам иттерде:

— Кирилл атакайдан гайре буларак, бу малайның күңелендә ниндидер планнар бар! Шулай сизелә...

— Әйе, мондагыларның планнарын мин дә белдем. Тизрәк шәһәргә таю ягын карап йөриләр.

— Шулай микән?

— Мондагы авыл эшеннән гарык без диләр. Кирилл атакай, чынлап та, хуҗалыгын киңәйтеп җибәргән. Үзенең көтүләренә чаклы бар. Тик түләвен аз тамыза. Бушка кемнең эшлисе килсен!?

— Шулайдыр шул, — дип җөпләде Җәмил хәзрәт. Бу вакытта машина Байтамакка якынлашып килә иде инде. Тау башыннан авыл уч төбендәгедәй күренеп тора. Байтамак үзе елга буендагы үзәнлектә утырса да, аның кырыенда әлеге тау булганлыктанмы, әллә башка сәбәп беләнме, байтамакларны «тау башындагылар» дип атаулар бер караганда сәеррәк тә. Бу авыл кешеләре бик үзенчәлекле, алар горур, вәкарь белән генә сөйләшәләр, үзләре эшкә уңган, үзәндә утырсалар да, күрәсең, авыллары белән бергә үзләрен дә җирнең биек ноктасында — тау башында итеп хис итә торганнардыр.

— Күнел колачының чикләре юк шул, йа, Ходай! — дип куйды Җәмил хәзрәт.

Соңгы вакытларда үзгәрде Байтамак. Баймурзин — каты куллы егет, җир җимертеп эшли. Тик... тик соңгы вакыттагы хәбәрләр генә Җәмил хәзрәтнең күңелен тырнап тора иде. Камай аның уен сизгәндәй кинәт әйтеп куйды:

— Алтын Бәртәснең Марфа белән бер класста укыдык без. Шәп укыды ул, «биш»легә генә. Нишләп авылда калырга уйлагандыр?

— Байтимер тирәсендә чуалган кәнтәйне әйтәсеңме?

Камай хәзрәтнең тавышын да, үзен дә танымады. Кемгәдер ачулы иде ул, усал иде Җәмил хәзрәт.

— Кәнтәй түгел ул. Әйбәт кыз, — диде Камай. — Әтисе умартачы иде аның, Гена абый әти белән дуслар иде. Җәмил хәзрәт, капылт кына руль артында утырган Камайның кулына кагылып куйды һәм кырыс тавыш белән:

— Туктат әле машинаңны! — дип боерды.

— Туктатам. Нишлибез?

— Күрәле син безнең Байтамак авылын! Бөтен Рәсәендә юк бүген мондый авыл, мондагыдай агрофирма! Халык авылдан качып беткән бер заманда кешене эшкә сайлап кына, конкурс белән алалар! Хәтта көтүчеләр дә махсус аттестация уза түгелме соң?! Элек колхоз көтүләрен көтәргә Маридан яллый торганнар иде. Хәзер әнә чират. Урта мәктәп белеме белән генә чыбыркы да ышанып тапшырмыйлар... Бар кешенең өсте бөтен, тамагы тук. Элгәре Байтимергә рәхмәт укып туя алмыйлар иде. Хәзер әнә халык мәчеткә йөрми башлады. Халыкны сарык димә син, сизә ул! Үзе мәчетләр салдырган кеше куенына тиктомалдан тәре яшереп куйсын әле!

— Җәмил абый. Килешәм мин синең белән. Әмма... Хәер, үзең дә беләсең, — дип җөмләсен өзде Камай.

Чыннан да, алар гына түгел, Байтамакны хәзер Рәсәй күләмендә сөйли башладылар. Дүртәр йөз гектар җир алып та адәм рәтле эш кыра алмаган инвесторлар белән чагыштырганда җитмеш гектар җире булган «Байтамак» агрофирмасы төрле яклап күп алга китте. Өйләр нәкъ шәһәрчә, бөтен уңайлыклары бар. Халык үзе шәһәр шартлары белән яши, үзе җирдән аерылмаган.

— Кайтып җитәбез бит инде, машинаны кабызыйммы, Җәмил абый? — диде Камай.

— Кабыз. Бар да житеш, бар да бар. Тик халык Гарасат мәйданында кебек хис итә үзен. Мондагы халык кына түгел, бөтен җир шары халкы!

— Җәмил абый, нигә дулыйсың! Мәхәббәткә манка мишәйт итми дигән сүзне беләсеңме син?!!

— Итә!.. — дип сузды хәзрәт, — ничек кенә итә әле. Манкасы агып торган чибәр кызны үбәсең килер иде микән, энем?

— Син бигрәк инде, Җәмил хәзрәт! Мә, су эчеп куй әле булмаса!

— Үзең эч суыңны, — диде хәзрәт төксе генә һәм мәчет каршында машинаны туктатырга кушты.

Әлбәттә, Камай хәзрәтнең үзе янында гына сүзне шаяртуга борырга тырышты. Байтимер белән Марфаны уйлап хәсрәтләнүе түгел иде егетнең, әлбәттә. Кышкы озын кичләрдә Җәмил хәзрәт белән күп сөйләшеп утырганы бар. Гарасат дигән сүзне ул күптән әйтеп килә. Бу минутларда уйлары шул яссылыкта иде аның. Чукынсын шунда Марфалары!.. Беркемне дә гаепләргә уйламый ул, чөнки бу мәсьәләдә үз эшләре дә көйле түгел. Теге чакта кытыгы уйнаганнан соң, егет кара кайгыга батты. Әлеге кайгының сәбәпчесе аннан яшьрәк булган тау башы кызы Камилә иде. Камилә шул, шул четеркән кыз. Алар мәктәпкә күрше авылга йөреп укыдылар бит әле. Юлда өелешеп бергә йөриләр, зуррак сыйныфлар да,

түбәнрәкләр дә. Шул өч чакрым араны барганда, кайтканда нинди генә хәлгә тармыйлар иде канә! Ул вакытта да хәзерге кебек кием фасоны гел үзгәреп торучан иде. Хәтерли, берзаман балагы кин булган, аны «клеш» дип атыйлар иде бугай, чалбар модага керде. Бер атна эчендә бар авыл малае шундый чалбар тектерде. Аннан сон вельвет чалбарлар модасы башланды, бар авыл малае әти-әнисеннән елый-елый шундый чалбар таләп итте. Берзаман әле хәзер таксистлар кия торган кара пластмасс «козеруклы» кепкалар модасы булып алды, тагын, тагын... Әгәр модадан «төшеп» каласын икән, син мәктәп каршында жүнле егетләр рәтендә түгел инде. Бигрәк тә авылдаш кызлар алдында хурлыгы ни тора. Андый модалы кием кия алмыйсын икән, димәк, син хәерче. Ә хәерчегә кем һәм нинди кыз кызыксын! Ә бу вакытта Камайнын нәкь менә Камиләгә күзе төшеп йөргән көннәре иде. Шул Камилә бер көнне юлда кайтканда анын башыннан «таксист» кепкасын бәреп төшерде дә сыйныфташы Фиргатькә суздды. «Менә бу Фиргатькә килешәрәк икән!» — ди тагын үзе жүнсез нәмәрсә! Бу булды бер. Икенчесендә ул анын куе зәнгәр төстәге яна вельвет чалбарына бармагы белән төртеп: «Кайсы кибеттән алып кайтып бирделәр моны?» — дип мыскыллап көлгән кебек булды. Кыз, бәлкем, шаяртткан гынадыр. Әмма анын әлеге сүзләре Камайны суйды да салды. Шунын белән бергә күнелендә бөреләнә башлаган иләс-миләс хисләрен, очкын-чаткыларны да. Укуында эленке-салынкы гына булган Камалетдин, жен ачулары белән китапка ябышты, бер чирек эчендә «отличник»лар рәтенә күтәрелеп, район, шәһәр олимпиадаларында әүвәл призлы урыннар, тора-бара беренче бүләкләрне дә яуларга керешә. Анысы анысы, теге көннән башлап Камай Камилә ягына таба борылып та карамас булды. Авылдашындагы мондый үзгәрешне, әлбәттә, беренче булып кыз сизде һәм, кирәксә-кирәкмәсә дә, кырыкмаса кырык төрле сәбәпләр тапкан булып, Камайга «бәйләнә», ана үзенең барлыгын сиздерә башлады. Ләкин Камай анын теге чактагы мыскыллы көлүен кичерә алмады, дөресрәге, кичерергә теләмәде! Тора-бара яшүсмер, кыз-кыркын турында бөтенләй онытып, башы-аягы белән укуга кереп чумды. Кыз Камайдагы икенче үзгәрешне дә беренче булып сизде: Камай хәзер бөтенләй башка, сыйныфташ малайларга охшамаган, алар белән аралаша, ләкин кызлар катнашкан кичәләрдә катнашмас булды. Укыды Камай, көн-төн белем эстәвендә булды. Кулында дини китаплар да күренә башлагач, иптәшләре егеткә сәерсенеп тә карый башладылар бугай. Камай шул вакытта үзенен беренче «ачышын» ясады, бернинди генә фән дә, физика да, химия дә, бигрәк тә ул яраткан биология дә дини тәгълиматлардан башка дөньяны анлатып бирергә сәләтле түгел! Мәктәп тәмамлаганнан сон аны муллалыкка укырга китәр бу дип уйладылар, ләкин ул тагын барысын да шаккатырып, биология факультетына барып керде. Әмма алдыннан да, үз артында да «тиле», диючe булмады егеткә, бары «тигәнәк» кенә ябышып калды. Халык егетнен холкына, кылган гамәлләренә ин югары шигърият кимәлендә бәя бирде, зур сәнгать югарылыгыннан чыгып фикер йөртте: «Тиле тигәнәк буе сикерер!» Димәк, Тигәнәк!

Теге чакта, мәктәп елларында, Камиләгә карата кабынган хис очкын гына булмаган икән, күрәсең. Ут булган ул шул вакытта ук! Хәзер янә дөрли башлады!.. Тик әлегә Камай ни эшләргә кирәклеген үзе дә белми. Кыюсыз иде Камай... Кыюсыз булса да йөрәгендә зилзилә, давыл башланырга тора иде! Жәмил хәзрәт теле белән әйтсән, зилзилә шул гарасат була түгелме сон инде ул?! Юкю-юкю! Хәзрәт аны башка мәгънәдә әйтә. Хәтта ки Коръәнгә салынган мәгънәсендә дә түгел... «Күкләр төтен белән капланыр. Бу барча кешеләрне сорып алачак»... Коръән аятьләре аша ингән Гарасат мәйданында булачак хәл бу! Әлегә бу карангылык күкләрдән дә бигрәк, күнелләрне сорып

алмактыр!.. Бу Гарасат мәйданы түгел, бу — Гарасат кына әле, зилзилә генә әле!.. Ул төтен адәм балаларының башларын әйләндерер, ул аларны исертер. Адәмнәр исә әлеге исереклектән ашыга-кабалана мал җыярга керешерләр, киемнәренә сеңгән «гарасат төтене»нең исеннән котылырга теләп, кабалана-кабалана чишенеп ташлап, шәрә калырлар. Берсеннән күреп икенчесе чишенер һәм әлеге кыяфәтләре, һәммәсе шундый хәлдә булганлыктан, оят тоелмас. Әлеге куе төтен адәмнәрдәге хөсетлекне арттырыр, миһербансызлык, шәфкатьсезлек, намуссызлык орлыклары бар Җир шары буйлап таралыр. Иблис үзенең мунчаладан ишелгән себеркесе белән әлеге төтенне төрле кыйтгаларга таба куып торыр. Ул төтенне эчәрләр, исererләр, башлары әйләнеп, күзләре акаер! Җир өстен иген басулары урынына киндер, мәк чәчәкләре басып алыр. Әле Мәһди килергә дә миллион еллап вакыт арасы булыр. Тик адәм балалары Ходайның гамәл дәфтәренә язылган Гарасат мәйданына сарыклар кебек тупланыр көннәрен үзләре ашыктырып, чакырып китерерләр...

Иң татлыдан ни татлы дигән сорауга, бишектән яңа төшкән сабый бала да «Әнием күкрәге!» дип түгел, «Тимер тәме!» — дип җавап бирер. Ул тимерләр сугыш кораллары, алтын-көмеш сурәтендә булырлар...

## Кабер куптаручылар

Айсыз бер төндә, кемнәрдер килеп, Абрекның каберен актарып аттылар! Мондый хәлнең Байтамакта гына түгел, тирә-юньдә дә булганы һәм ишетелгәне юк иде!!! Полицияне дә аякка бастырырлык, шул тирәдәге түмгәк-түрәләрне дә үрә торгызырлык шомлы бер хәбәр иде бу!..

Әлеге вакыйга бигрәк тә Байтимер өчен аянычлы иде. Ни генә әйтсәң дә, ул Байтамакта хуҗа кебек кеше. Хуҗа икәнсең, димәк, син беренче чиратта халыкның тынычлыгын, куркынычсызлыгын, иминлеген кайгыртырга тиешсең. Күнеленне иркен тот, хуҗа әфәнде!

Иң алдан имеш-мимеш хәбәрләр китте. Янәсе, Хөллиевнең үзе белән каберенә күмелгән бик күп алтыннары булган икән, имеш, элеккеге дошманнары аннан үч ала, үлгәч тә тынычлыкта калдырырга теләмиләр, имеш. Ябалак урманы артындагы Галинга һаман җир җитми; ул халыкны өркетеп, Байтамакның нигезен корытмакчы була, бу җирләргә үзе кызыга! Имеш-мимешләрдән генә аркан ишеп булмый иде шул. Милиция «полиция» дип кенә түгел, «чуртым» дип үзгәртелсә дә, әлеге җинаятьчеләрне табачакларына, әлбәттә, берәү дә ышанмады.

Байтимер өчен вакыт узган саен хәят төеннәре һаман төйнәлгәннән төйнәлә бара, берсен чишсә, икенчесе калкып чыга. Инде зур эшләр башкарылды югыйсә! Бар нәрсә дә җитеш, кешеләрнең эшләре бар, эшләре булгач, ашарларына бар, кияргә киемнәре, утырып йөрергә күбесенең шәхси машинасы бар. Авыл булса да өеннән чыгуга кеше хәзер пычракка түгел, таш тротуарга яки асфальтка баса... Ни җитми соң? Кай җире килештерелеп бетмәде икән?..

Байтимер ярдәм сорагандай күккә карады. Күк җавап бирмәде фермер Баймурзинга. Күк дәшми, күк ләм-мим... Байтимер телефоннан Камайны чакыртты. Камай кулын сындырган дип ишеткән иде, шулай булса да барыбер чакыртты: киңәшергә кирәк иде. Камай тиз килеп җитте, тик аның кулы сынмаган, уң кулындагы чәнчә бармагы гына бәйләнгән иде. Шуны күргәч, Байтимер бүген беренче мәртәбә елмайды.

— Кул сынды дигән хәбәр тараткансың!

— Мин хәбәр таратып йөрүче түгел, Байтимер абый. Хәбәрне җилләр тарата аны...

— Ул җилләрен зират ягыннан да берәр хәбәр алып килмәгәндер ич?

— Алып килде. Байтимер абый, берәр стакан суынны эчеп куйыйм әле, ә? Мөмкинме?

— Мөмкин, Камалетдин Җамалиевич!

Камай өстәл читендә торган графиннан су алып эчте дә кесәсеннән алма чыгарды:

— Моны сиңа Сәхаби бирде, — дип, Байтимергә сузды.

— Алма кайгысы түгел әле монда!

Икесе дә беркавым тынсыз тордылар. Әлеге тынлыкны ачык тәрәзәдән кергән җил бозды. Чөнки ул шул мизгел эчендә өстәл өстендәге кәгазьләрне тузгытып ташларга өлгерде.

— Хөллиев каберен бер генә кеше казыган. Сәхаби күргән. Таң атып килә иде инде ди.

Байтимер, кызыксынып, Камайның сүзен әйтеп бетерүен көтте, ләкин тегесе ашыкмады, нәрсәдер сузды, көттерде.

— Шуннан?! Сәхаби танып калганмы соң ул кешене?

— Юк. Сәхаби безнең авылда яңа кеше әле, төс-кыяфәткә бөтен кешене дә белеп бетерми. Син борчылма, Байтимер абый! Ул кешене сиңа үзем табып бирәм мин! Дөрес, мин сиңа полиция булып эшкә урнашмадым урнашуын. Шулай да..

— Нәрсә шулай да?..

— Борчылма, Байтимер абый, табарбыз! Кем икәнлеген белербез!.. Минем сиңа башка, әһәмиятлерәк соравым бар: нишлибез?

— Ничек? Нишлибез?

— Менә, — Камай уң кулын алга сузды, — үзем бармакны каерып сындырдым бүген!

— Камай! Беләсеңме нәрсә? Надоели синең табышмакларың мине! Аңладыңмы!? Сөйлә әле барысын да бәйнә-бәйнә!

— Тагын бер стакан су эчим, Байтимер абый?

— Икене эч!

— Врачка приемга бару өчен... ни инде... шуңа сәбәп булсын дип сындырдым бармакны! Ә врач янына барырга үзем һаман куркып йөрим.

— Кайсы врачка? Бездә икәү бит алар хәзер?

— Яңа эшли башлаганы янына, Камилә, безнең авыл кызы.

— Йә, шуннан?

Камай куен кесәсеннән өчкә бөкләнгән кәгазь кисәге чыгарды:

— Байтимер абый, менә шушы хатны Камиләгә тапшыра алмыйсыңмы син, ә?

Берни аңламаган Байтимер аңа карап торуын дәвам итте.

— Мәхәббәт хаты бу! Яратам мин ул кызны. Үзем әйтергә куркам...

Байтимер шаркылдап көлеп җибәрде. Озак көлде ул, күзләре яшьләнгәнче, эчен тота-тота көлде һәм шул арада аңа күзләрен мөлдерәтеп карап торган Камайның җилкәсенә сугып:

— Ну, Камалетдин! Үтерәсең син!

— Юк, Байтимер абый, мин түгел, алар үтерә! Мине дә, сине дә!.. Әйе, әйе, сине Марфа, мине Камилә яндырып үтерәләр инде.

Камай үзе дә Байтимергә кушылып көлә башлады.

Ә хәлләре, чынлап та, бер караганда, көләрлек тә, икенче караганда еларлык та иде.

— Байтимер абый, беләсеңме, Сәхаби миңа бүген нәрсә сөйләде? Ишетсәң, шаклар катасың! Марфа белән Нурбикә апа туганнар икән бит, туганнар булганнар!

— Син нәрсә, энем?!

— Әйе, Марфаның әтисе Василий абый умартачы бит. Безнең урманда булган аларның умарталары. Әтиләре бер, әниләре генә икенче. Икесенең дә биологик әтиләре Василий дәдәй.

Камай Сәхабидән ишеткәннәрен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

Нурбикәнең әнисе Нургаян апа авыл хатыннары белән урманга җиләк җыярга барган җиреннән адашып калган. Авылдашлары аны эзләп-эзләп тә таба алмагач, Нургаян җиләкле урынга тап булгандыр да, шуңа күрә тавышсыз-тынсыз гына күп итеп җиләк җыядыр дигән карарга килеп, авылга кайтып киткәннәр. Нургаян ул көнне чынлап та җиләкле аланга туры килгән. Ул җиләкле аланны иптәшләреннән аерылып калган Нургаянга гомерен урманда үткәргән Василий-Бачылый күрсәткән. Аңа кадәр ялгыз башы урманда кайтыр юл эзләп йөргән хатынны умартачы өенә алып кайта. Хатыны Мария белән ачыккан-талчыккан Нургаянга якты йөз күрсәтеп, чәй эчерәләр, кунак итәләр. Бачылый белән Мария икесе генә умарталыктагы йортларында гомер итә торган булалар. Балалары юк, Ходай Тәгалә Марияга бала бирмәгән. Ләкин бик ачык йөзле, чылтырап торган көмеш сыман яңгыравыклы тавышлы Мария һәрвакыт көр күңелле, яхшы күңелле хатын була.

Шуннан соң Бачылый лым тулы җиләкле чиләге белән бергә үз атында Нургаянны авылга ук илтеп куя. Әлеге вакыйгадан соң алар дуслашып калалар, Нургаян монда ире Нурулла белән бергә дә килеп йөри башлыйлар. Нурулла ат җигүче булганлыктан, ат белән киләләр. Җәй көне булса, кайткан чагында алар умартачы печәнлегеннән күп итеп хуш исле урман печәне, көз көннәре утын төяп кайталар. Бу дуслык бигрәк тә Нурулла белән Нургаян өчен бәхет була. Чөнки утын белән печәннең алтын бәһасе торган вакытлар, бу байлыклар исә алар өенә бушка кайтып тора! Нургаян — тирә-якта дан тоткан оста тегүче, хатын Марияга матур-матур күлмәкләр тегә торган була. Бу дуслык салырга яраткан Нурулла өчен икеләтә куанычлы, чөнки Бачылый җиренә җиткереп медовуха ясый белә. Тора-бара әлеге ике гаиләнең дуслыгы шулчаклы ныгый, алар бер-берсеннән иң нечкә, иң тирән серләрен дә яшерми башлыйлар. Мария бала таба алмый бит, ул һәрвакыт шул хакта сөйләп елый, Нуруллага сиздермичә генә бер бала алып кайту теләге булу хакында килгән саен Нургаянга зарлана. Мария бар нәрсәгә дә, барлык сынауларга да риза, тик өендә бала тавышы гына яңгырап торсын. Менә шул рәвешле алар Нургаянны үзләренә бер бала бүләк итәргә күндерәләр. Тик ул бала Бачылый орлыгыннан оешырга тиеш була!.. Умартачы Василий белән татар хатыны Нургаяннан балдан гына ясалган бер матур кыз туа...

Бу вакыйганы ишеткәч, Байтимер эченнән генә уйлап куйды: «Менә нәрсә тарткан икән Марфаны мәчеткә!? Ата каны...» Ә аны Марфага нәрсә тарта? Нурбикәне сагынумы? Байтимер хәзер генә Нурбикә белән Марфаның бер-беренә охшаган булуларының сәбәбен аңлады. Икесе дә бер әнидән туган кызлар икән ләбаса!..

Марфа да Нурбикә кебек бик чибәр, яшьрәк булганга күрәме, хәтта күпкә матуррак та иде. Марфага гашыйк булмаган ир-ат ул матур җәйге иртәдә таң атканны күрмәгән кеше! Аның тавышының матурлыгын ишетмәгән кеше ул үз гомерендә беркайчан да сандугач сайравын ишетмәгән ир-ат!.. Болар барысы да Байтимерне үз эченә бөтереп алды дию дөреслеккә хилафлык булыр, әлбәттә. Ләкин кызның мәхәббәтенә каршы җавап бирмәү, туң йөрәкле булып кылану тагын да зуррак хилафлык түгелме соң?

Марфаның төз басып йөрүләренә сокланмаган ир-ат ул, гомумән, матурлыкның ни икәнлеген күрә, таный алмаган кеше!..

Тик вакыт бар нәрсәгә дә дәва дисәләр дә Нурбикә вафатыннан соң Байтимер күкрәгендә ясалган җәрәхәт йомылып бетә алмады, аннан гел кан саркып тора торган булды.

Кайнар йөрәкле Марфа исә Байтимергә тынгылык бирмәде, кайда барса юлында әлеге зәңгәр күзле кыз пәйда булды, Нурбикәнең чагылышы очрады. Марфа ярата һәм шул исәптән үзен дә яраттыра белә торган бер асыл зат иде... Ләкин акыл белән генә яратып булса икән, йөрәккә әмер биреп булса икән лә! Булмый, мәхәббәт ул адәм балаларына Ходай Тәгаләдән иңгән бер могҗиза, хикмәттер... Мәхәббәт ул канны дуылдата, ул күктәге Кояшны, якты нур көлтәсе итеп, мул итеп күкрәк читлегенә сала, яз көне агач бөрегә уянган сыман тәндәге генә түгел, җандагы күзәнәкләрне дә уятып җибәрә... Җан да күзәнәкләрдән торамы икәнни, Ходаем?!!

Әгәр Байтимер, кыз белән очрашкан вакытларында, аның кайнарлыгыннан акыл-аңын югалтырлык халәт кичермәсә, бәлкем, ул Марфаны кабул да итә алмаган булыр иде. Ул аны Нурбикә, бары Нурбикә итеп кабул итте, дөресрәге, әлеге теләк-нияте үзеннән-үзе җанына шундый бер гүзәл нур салды...

Ир-ат нәсел дәвамына нигез салучы, хатын-кыз шул дәва оеткысына җилянгыр тидермичә саклаучы үзе бер Илаһи зат сыман. Күп вакыт ир-атны әлеге инстинкт әйди, акыл-аңнан бәйсез рәвештә кыз-хатын янәшәсендә табигый гармоннар кайнарга керешеп, алар дөньялыкка чыгып янә бер гүзәл гармоннар белән кушылырга ашыга торгандыр. Очрашулар ешая башлагач, Байтимер беренче мәртәбә кызның кулына орынып, әлеге гамәл аның бар гәүдәсен пешереп алгандай иткәч, җәһәт кенә кире тартып алганын үзе дә сизми калды. Тора-бара кулы, бөтен тәне әлеге кайнарлыкка ияләшә башлады кебек, кайнарлык рәхәт бер җылылыкка әйләнде һәм анда кызның тәмен тоясы килү теләге уянды. Һәр өлгереп җиткән балигъ кыз-хатынның үз тәме, кабатланмас искиткеч тәме була. Әгәр организмда андый тәмне тоярлык күзәнәкләр бар икән, ул ир-ат ошбу гүзәлне, әлбәттә, үбеп караячак; зәвык тәмне үзе сайлый, тәмле конфетны тозга манып ашап булмаган кебек, әгәр ул тәмне тоя алмыйсың икән, хатын-кыз «тешләтеп» карарга никадәрле генә әзер булса да, теләк ничек тиз кабынса, шулай тиз сүрелер дә. Әлеге хиссият дөньясы барлык ир-атка да кагыламы, юкмы икәнлеген, әлбәттә, Байтимер белми, әмма аның үзенең «конституциясе» нәкъ шундый иде.

Дөньялыктагы күп чишелмәс табышмакларны кешеләр гади тел белән «очраклылык» дип атаган хәл-вакыйга хәл итә. Һәрхәлдә, Ходай Тәгалә ихтыярында бернинди очраклылык булмаса да...

Печән өсте иде ул. Байтимернең гел печән генә җыя торган бер болыны бар, исеме дә «Чәчәкле». Чөнки күпме генә сукаласаң да, башка орлык чәчеп карасаң да, әлеге болында бары печән генә мул булып уңа һәм маллар аның печәнен дә прәннек ашагандай итеп кенә ашый. Шуңа күрә елның елында «Чәчәкле»гә печән чәчелә. Киптерү ысуллары да үзенчә иде ул печәнне. Хәзер кипкән печәнне полиэтилен капчыкларга төрү җайланмалары да, силос итүнең дә күп төрле ысуллары бар. Тик бу болындагы печәнне алар күләгәдә киптерәләр, аннан соң вак-вак чүмәләләргә өеп, тагын бераз җилләтеп алалар. Малларга «прәннек» әнә шул рәвешле әзерләнә. Мондый чүмәләдә вакытында «тәмле»печән бурларның да күзен кыздыра иде.

Байтимер кояш баер алдыннан кара айгырда «Чәчәкле»не урап кайтырга булды һәм басуга керүгә, аты тарткалавына да карамастан, елга буена чаптырып алып китте. Кара айгыр юкка гына бу тарафка әйдәмәгән икән: елга яры

буендагы чүмәлә янында иярле, ләкин хуҗасыз байтал чемченеп йөри иде. Байтимер шиккә калды, чүмәләне бер мәртәбә урап чыкты ул, икенче тапкыр әйләнде, ләкин теге атның иясе күренмәде. Менә берзаман ул чүмәләнең селкенгәненә игътибар итеп, тагын да якынрак килде. Шулчак чүмәлә өстеннән бер тавыш ишетелде: «Абау, төшәргә куркам! Ярдәм итегез!» Чүмәлә өстендә күрше Алтын Бәртәс кызы Марфа төшәргә куркып утыра иде.

— Ничек менден, шулай төш! — диде Байтимер төксе генә.

— Мин монда менмәдем, мин чүмәлә өстенә төштем!

— Кайдан төштең син анда?

— Атым дулап китеп чөеп җибәрде дә менә чүмәлә өстенә очып кундым, Байтимер абый!

— Мин сиңа абый түгел!

— «Бабай» дип әйтергә кушмыйсыңдыр ич? — Кызның урысча оешкан теле татар телен бик матур әйләндерә иде.

— Үзем шуып төшәм. Син аста мине тотып кал!

Тотып калды Байтимер Марфаны. Тегесе аңа сөлек кебек ябышты. Хәер, Байтимер бу минутларда үзе дә сөлектән ким түгел иде. Алар бер-берсенә дә, болай да бүтән сүз катмадылар. Кызның чәч толымнары исенә яңа чапкан печәннең хушбуйлары кушылды. Ул исерде. Марфа исә күптән исергән иде.

Күктәге баеп баручы кояш шул чакта басудагы йөзләгән кибән арасыннан нәкъ менә шунысын гына аралап алгандай көлтә нурларын алар өстенә сипте. Марфаның күлмәк төймәләре бер-бер артлы черт-черт коела һәм өзелгән берсе печән чүмәләсе арасына кереп югала иделәр. Бәлки, алар гадәти табигый юллар үтеп, көз көне янә шушы басуга әйләнеп кайтырлар. Бәлки, сизгер маллар аларны төкереп ташлар?..

Офыктагы алсу шәфәкъ шәрә кыз баланы үзе төсле күлмәккә киендерде...

Шулчак ак байтал кешнәп җибәрде. Кара айгыр аңа җавап кайтарды. Шул мәлдә Байтимернең ирennәре салкын тимер тәме тоеп, ул куырылып килде һәм, сискәнеп, күзләрен ачты: шәфәкъ нурлары кызның муенындагы алтынны куе кызыл кан төсенә керткән иде...

Ак байтал, кара айгырны тешләп алды да, үз артыннан елга буена алып төшеп китте. Атлар туйганчы су эчтеләр... Елга буенда шуннан ары табигый дә, гайре табигый дә хәл булмады, чөнки бу вакытта кояш үзе дә урман артына төшеп утырган иде инде...

...Камай Байтимерне Алтын Бәртәскә алып китте, чөнки тегесенең Хөлли каберен кем казыганлыгын бик тә беләсе килә. Байтимернең үзенең дә бу якларга күптән киләсе килеп йөри иде. Кирилл атакай, аның белүенчә, артык мәшәкатьләнмичә генә, берничә гектар җирне чәукәләр оялаган чиркәүгә беркетеп куйды, урман, елга буендагы кара туфраклы иң уңдырышлы җирләрне! Өстәвенә Алтын Бәртәскә урыс гаиләләре дә кайтып тора дип ишетте. Бу тирәләрдә каладан җәй көннәрендә генә кайтып яшәүчеләр әүвәл дә бар иде, тик аларны ул хуҗалык санына кертми, кыскасы, алар «дачниклар» гына һәм күршедәге Байтамакка аларның зыяннан башка бүтән файдалары юк. Зыяннары исә күбрәк «Кыяр» бригадасына төшә, чөнки байтамаклар анда җәен-кышын яшелчә үстерәләр.

Бу тирәләрдәге җирләр уңдырышлы булса да Байтимер аларга нәфесен сузмады, чөнки хуҗалыкның җире житмеш гектардан артып китсә, аны файда китерерлек итеп алып бару бу илдә шактый кыен эш. Ләкин, аның җирләренә кызыккан кебек, бу яктагы басуларга да күз кыздыручылар күп, чөнки арзан бәядән генә сатып алып, соныннан шунда йә йортлар салып яисә бәяләрен

биш-алты тапкыр арттырып сатып җибәрү өчен иде. Шуна күрә Байтимер монда элеккеге урыс авылын торгызырга һәм жирнен әрәм-шәрәм ителмәвен тели, бик тә тели. Чиркәүгә ремонт ясыйм дип Кирилл атакайга вәгъдә итте ул һәм вәгъдәсендә торачак та. Чиркәве булса, авыл халкы да иманлы булыр, ә күршеләрнен иманлы булуы бик мөһим иде.

Теге чакта печән кибәне төбендә очрашканнан сон Марфа белән бүтән күрешкәннәре булмады. Ул очраклы рәвештә авылда кызны очратудан куркып, Камайны рульгә утыртты да үзе артка чүмәште.

— Байтимер абый, син юкка Кирилл атакайның чиркәвенә ярдәм итәм дип йөрисен! Анын алтыннары бер сандык дип сөйлиләр! — диде Камай авылга килеп кергәч.

— Сөйлиләрдер анысы... — дип куйды Байтимер, әмма сүзе шунда өзелеп калды, хәтта ул телен тешли язды, урамнан Абрек Хөллиевкә охшаган бер кеше атлый иде.

— Әйдә, тиз! Шунын артыннан! — дип боерды хужа һәм машина әлеге кеше турысына якынлашуга, ишекне ачып аңа дәште:

— Туктале! Сүз бар!

Байтимер килә башлагач, әлеге адәм, башын якасы эченә яшереп, тиз генә качып китәргә теләде, ләкин Байтимер анын арткы чабуыннан эләктереп калырга өлгерде. Аны таныгач, икесенен дә өннәре китте:

— Варис!?? Нишләп йөрисен монда?!! Машина кайда? Сине атна буе полиция эзли бит инде!

— Жибәрегез! — дип кычкырды тегесе үрсәләнеп.— Жибәрегез! Мин Варис түгел! Мин Әл-Рәхим-Иуда!

— Әй син, Иуда! Кайдан табып алдын Абрек Хөллиев киемнәрен?

Варис әче тавыш белән: «Коткарыгыз!» — дип кычкырып жибәрде, Абрек Хөллиев йортынын капкасы ачылып, аннан сакаллы биш-алты кеше чыктылар да автоматтан атарга керештеләр. Байтимер Варисны жибәрде. Машина чиркәүгә таба ыргылды, шунын артыннан ук ату тавышлары да тынды.

Байтимер белән Камай икесе дә агарып катканнар иде, байтак вакыт сүз әйтә алмыйча тордылар.

— Кемнәр булды ул, Камай? — дип сорады бераздан Байтимер хәрәкәтсез утырган юлдашыннан.

— Иудалар! — диде тегесе. Прокуратора ОМОН белән килеп тикшереп карады инде аларны, бернинди гаеп тапмаганнар, беләсенме?

— Белми идем...

— Башлыклары Мәскәү түрәләре белән турыдан-туры элемтәдә тора ди. Хәер, монысы имеш-мимеш кенә, ышандырмый.

— Киттек Кирилл атакай янына! — дип боерды Байтимер. — Чиркәүгә ярдәм итмә дисен син! Хәлемнән килсә, бу кабахәтләрне юкка чыгару өчен ун чиркәү салдырыр идем әле мин монда! Секта бит болар! Христианга да, исламга да каршы алар!

— Анын каравы ике дин байрагы астында эш итәләр!

— Төкердем мин аларнын байракларына! Киттек!

Машинаны Кириллнын капка төбенә туктатып, ишегалдына үттеләр һәм өй эчендә нинди дер тавышлар ишетелгәч, икесе дә шым булдылар.

О, Всеблагий Господи, я знаю, что великое счастье мое зависит от того, чтобы я Тебя любила всею душею и всем сердцем моим, и чтобы исполняла во всем святую волю Твою. Управляй же Сам, о Боже мой, душею моею и наполняй сердце мое: я хочу угождать Тебе Одному, ибо Ты Создатель и Бог мой.

Камай Байтимерне урамга таба тартты, ләкин тегесе «юк» дип баш айкады да, алар атлар-атламас кына өй ишегенә таба киттеләр.

— Нигә куркып калдың? Киресенчә, сөенергә генә кирәк. Күрдең бит теге иудаларны, — дип пышылдады Байтимер. Өй эченнән һаман дога укыган тавышлар ишетелеп тора иде: Святый Ангеле, предстояй окаянней моей души и страстней моей жизни, не остави мене грешнаго, ниже отступи от мене за невоздержание мое.

Не даждь места лукавому демону обладати мною, насильством смертнаго сего телесе; укрепи бедствующую и худую мою руку и настави мя на путь спасения...

Кирилл атакай үз каршысына ике хатын-кызны утыртып дога көйли. Хатыннар икесе дә кара кулмәктән-яулыктан, кулларында иконалар иде. Камай каты итеп Байтимернең җиңеннән тартты. Тегесе ирексездән аның артыннан ияреп өйалдына чыкты.

— Киттек, — дип пышылдады Камай һәм җил-җил атлап капкага таба китте. Әлегә берни аңламаган Байтимер дә теләр-теләмәс кенә аның артыннан иярде. Машинага утыргач кына Камай телгә килде:

— Хатыннарның берсен таныдыңмы? — дип сорады ул Байтимердән.

— Икесе дә таныш шикелле тоелды.

— Әйе, берсе Екатерина, попка кияүгә чыккан дип сөйлиләр, ә тегесе... Беләсеңме, кем иде? Марфа!

— Үзем дә таныдым, — дип куйды аңа каршы Байтимер. Машина янә, юллары шуннан булганлыктан «иудалар» оялаган элеккеге Хәллиев коттеджына якынлашкан иде. Әйләнечтән юл туры дисәләр дә, бу тирәләрне әйләнечтән дә узып булмый, бердәнбер юл бары баягы шомлы коттедж яныннан уза. Шул яктан тимер тавыш белән укыган сүзләр ишетелде. «Молитва о спасени России» иде бу.

Господи Иисусе Христе, Боже наш! Прими от нас, недостойных рабов Твоих, усердное моление сие и, простив нам все согрешения наши, помяни всех врагов наших, ненавидящих и обидящих нас, и не воздав им по делам их, но по веле Твоей милости, обрати их неверных ко правоверию и благочестию, верных же во еже уклонивших от зла и творит благое...

Камай инде алгы утыргычка чумәшкән Байтимер ягына борылды да:

— Карале! Бу кабахәтләр нинди дога-молитва укыйлар бит, ә! — дип куйды.

— Нинди?

— «Молитва о спасении России!..» дип атала.

— Су эч, Камалетдин! — диде Байтимер. Тегесе кулына шешәле су алды һәм үзе йотып куйганнан соң Байтимергә сузды:

— Син дә эчеп куй, Байтимер Байбулатович!

— Безнең егетләрдә ничәләп ау мылтыгы булырга мөмкин? — дип сорап куйды Байтимер шулчак.

— Ау мылтыгы гына түгел, «калаш» та бар!

— Кит инде! Камай, мин сине вертолетта очарга өйрәтәм әле, яме?

— Юк, мин биеклектән куркам бит, Байтимер абый!

— Син, энем, биеклектән курыкма, бөеклектән курык... Күпләр шулай ычкынды бит... Бөеклек каланчасыннан мәтәлеп төшеп!..

— Мәтәлеп кенә түгел, кадалыплар китеп...

Икесе дә су эчтеләр. Әмма бу юлы Байтамак зиратындагы кабер такталарын кемнәр кубарганын тәки белә алмады егетләр...

**Алма**

Аю булып тапта, җаным!
Таралып китсен каным!..
Йомычкадай тирбәләм мин,
Юк минем туктар ярым.

Ярым да юк, сөйгәнем дә,
Өзгәләнә бу җаным.
Сиңа кияүгә чыгармын
Әзерлә миңа калым.

Оча җаным, чайкала
Диңгез кебек дөньяда.
Туктап кунарлык урын
Табылырмы бу җанга?

Күңлем күбәләк минемдер,
Дөньям түгәрәк иде.
Түгәрәк бу дөньяларда
Үзем күбәләк инде...

— Иза! Син гений!

— Среди удобрений! — диде Изольда Рафинадовна, гитарасын диван башына сөяп куеп. — Гарәфәнеке бу! Сүзләре аныкы, көен үзем маташтырдым...

— Мин чынлап та!

— Ә мин шаярып кына! Менә моның сүзләре дә үземнеке:

Шаярып кына сөйгән идем,
Утында менә көйдем.
Янып бетәм дигәндә
Ярый әле син килдең!..

Бу сиңа багышланган җыр булачак, Харакери!

— Харакери түгел! Хәким!

— Хакимушка! Әйдә, мин синең өстеңә менеп сикерим әле, ә?

— Сикергечеңә зыян килмәсен, яме, Изольда Рафинадовна!

Изольда «пых!» итеп куйды да, караватында аркылы яткан килеш тәгәри-тәгәри көләргә кереште.

— Ну, Хакимушка! Ты мой дорогой! Ә нәрсә ул сикергеч, Хакимушка?

— Скакалка! — диде Хәким житди генә һәм торып киенә башлады. — Ычкынырга вакыт! Йә Галинның берәр бурзае күреп алыр!

— Күрсен, күрсен, Хакимушка! Курыкма! Мине аерырга курка ул! Беләсеңме мин аннан сколько отсужу?! Сволочь ул! Япь-яшь кызларны боза башлаган!

— Кыз түгел бит инде, яшь килен.

— Да какая разница! Карт айгыр! Уф, Хакимушка! Миңа что-то һава житми!

— Һава житәргә! Түбәгезгә кадәр бакырдан бит сезнең!

— Ну, анысы аның против разных излучений гына.

— Барыбер инде...

— Миңа болай һава житми, Хакимушка! Йәле, тагын, воздух качать ит әле!

Изольда Рафинадовна, Хәкимнең күлмәк итәгеннән эләктереп алып, үзенә таба тартты.

— Насосның мае бетте! — диде Хәким, аның үзе кебек шаяртып һәм, читкә тартылып, киенүен дәвам итте. Аның әлеге җавабыннан соң Изольда янә тәгәрәп көләргә тотынды һәм беркавым шулай онытылып көлгәннән соң, күз яшьләренә буыла-буыла:

— Хакимушка! Как я тебя люблю! Не бросай меня, ладно! — диде.

Не брошу никогда, любимая!
Я только твой, весь твой!
Сердце твое, душа моя твоя,
А где моя, где же моя?!

— О, Хакимушка, ты тоже сочиняешь? Складно!

— Юк ла, болай гына телгә килде.

— Ә минем, беләсеңме, кайчан вдохновение килә, берзаман һава җитми! Бар нәрсәгә аллергия була башлый да...

— Ә син балаларың янына барып кайт. Англиядәме әле алар?

— Алар минем үз балаларым түгел, Хакимушка! Приемный балалар алар... Я жертва оборта! В молодости! Галин он сволочь!

Әле генә гитарада үзе уйнап, матур тавышы белән җырлаган, йә бармак күрсәтсән дә, тәгәрәп көлгән бу чибәр хатынның кара күзләрендә моң чагылды. Ул Хәкимгә кызганыч булып китте. Хәким Изольда янына караватка утырды һәм тузгыган чәчле башын күкрәгенә кысты:

— Син яшь бит әле, Иза! Үзеңнекеләр дә булыр!

— Юк! Или мин, или Галин үзе бесплодный! — диде хатын, башын Хәкимнең күкрәгеннән алып. — Может миндер, Хакимушка? Чөнки минем бар нәрсәгә дә аллергия! Хәзер инде Галинга да аллергия! О, беләсеңме, Хакимушка, мин «Птицеферма» ачам! Необычную! Не с инкубатором! Әтәчләр белән! Идеяме?! Ооо! Минем мең, миллион үз чебиләрем булачак! Классно? Һәм мощный әтәчләрем!

— Синең аларга да берзаман аллергияң башланмасмы соң?

— Юк, башланмас, Хакимушка! Элек миндә бернинди аллергия юк иде! Хәзер барлык фрукталарга даже аллергия! Бәрәңге генә ашап торасымы соң инде әллә? О, беләсеңме, Хакимушка, син алып килгән теге алманы ашап бетердем бит мин! Бернинди аллергия булмады? Кайсы кибеттән алган идең син аны?

— Кибет алмасы түгел иде ул, Иза. Алма бакчасы каравылчысы бирде аны, Сәхаби дигән бер адәм.

— Таныштыр әле шул каравылчы белән мине, Хакимушка. Ә?

— Таныштырырмын, Иза. Только аңа гашыйк булмаска!

Изольда Рафинадовна янә матур тавышлары белән көләргә кереште.

— Әллә көнләшәсең инде, Хакимушка?

— Көнләшәм, — диде Хәким һәм хатынның битеннән үбеп алды да ишеккә юнәлде.

— Көнләшәсең, димәк, яратасың!? Это здорово, Хакимушка! Миннән бер кешенең дә көнләгәне юк иде монарчы! Хәтта Галин да! Мине үзенә мөгез куяр дип башына да китерми ул! Чөнки мине бәйдәге бер ана эт дип исәпли!

— Пока, Иза!

— Пока! Пока!..

...Изольда Рафинадовна, нинди генә бай ата кызы һәм олигарх хатыны булмасын, ул барыбер асылда гап-гади хатын-кыз иде. Хәким биргән алманы ашаганнан соң аны алыштырып куйган кебек булды. Хатынның монарчы күкрәген кысып торган ниндидер билгесез төер эреп юкка чыкты, яшисе килә

башлады, монарчы әлләни мәгънә чагылмаган күз карашына чаклы үзгәрде, аларны мон басты. Изольда хәзер еш кына гитарасын кулына алып монлана торган булып китте. Илһамы да әллә кайдан гына килеп тора, ул яраткан шагыйре Гарәфә китабыннан үзенә ошаган берәр шигырь табып ала да әлеге сүзләргә күнелленнән көй эзли һәм иң кызыгы шул: көй бетмәс-төкәнмәс иде.

Мин монлы бер бала бугай,
Мин бер ялгыз ана бугай.
Язга килеп керде бу күңелем,
Күкрәгемдә
Гөлләр чәчәк ата бугай...

Изольда гитарасын болан мөгезенә элеп куйды да тиз-тиз киенә башлады һәм лифт белән генә гаражга төшеп машинасын кабызды. Кая барасын әле үзе өчен дә анықламаган хатын, урман артына таба сузылган юлга борылды. Машина үзеннән-үзе башка якка, Байтамакның алма бакчасына таба юнәлде. Алма бакчасы каравылчысы Сәхаби шунда иде. Затлы машинада кәттә хатын килеп туктагач, ул бер дә аптырамады, аны күптән көткән кунагы кебек каршылады. Дөресрәге, соңгы вакытларда күпләп алма сатып алырга килүчеләр күбәйгән иде, ул аны шуларның берсе дип уйлады бугай. Тик әлеге хатын-кызны күрүгә әлеге уеннан кире кайтып, Сәхабинең зур күзләрендә сораулы караш кына эленеп калды. Шулай да итагатьлек өчен:

— Алмага килгәнсеңдер бит инде? — дип сораган булды.

— Алмага! — диде хатын. — Тик мина машиналап кирәк түгел! Миңа бер генә алма кирәк!

Сәхаби дәшмәде, әүвәл бик озак бу чибәр хатынга карап торганнан соң, карашы күккә юнәлде һәм ул шунда эреп югалды да! Әйе, әйе, бу хәлне Изольда үз күзләре белән күрде, әмма ул бу мәлдә сүз әйтерлек хәлдә түгел, алма бакчасы каравылчысы аны сихерләгән иде.

— Мин сихерче түгел! Мин алма бакчасы каравылчысы! — диде Сәхаби һәм капка янындагы алмагачтан бер алма өзеп алып, таныш булмаган хатынга сузды. — Алма бик файдалы. Ләкин берзаман ул туйдырачак, күп ашасаң, аллергия башланырга мөмкин...

— Мин алма яратам.

— Алманы бар адәм баласы да ярата. Хәзер аны ашау гаеп түгел инде. Җирдә яшибез бит. Ә җирдә алма үсә. Кайчандыр ул бер генә алмагач булгандыр, хәзер күп инде.Чөнки адәм балалары да күп хәзер җирдә...

— Күп, — дип җөпләде аны чибәр хатын.

— Синең чибәрлегеңә күз тигән. Әбелхәят чишмәсе белән битеңне юарга кирәк тә... Тик...

— Тик ул чишмә хәзер юк инде, әйеме?

— Бар ул, үпкәләгән генә...

— Чишмә суы үпкәли беләме?

— Су җанлы ул!.. Алмада да су күп. Алма аша.

— Рәхмәт, Сәхаби!

— Чишмә суы белән битеңне юарсың...

— Юармын, Сәхаби!.. Тагын бер алма алыймчы! Иремә...

— Галин алма яратмый бит ул, теше камаша.

— Ә син ана иң ачысын сайлап бир, ачы алма тешне камаштырмый, чөнки аны күп ашап булмый. Үтен сытса, шул җитә.

— Үтеңне сытарлык ачы алмалар да бар монда. Менә монысын ал!

Изольда кире өенә таба кузгалды. Галин да кайтып кергән, хезмәтчегә төрек мунчасын кабызып җибәрергә әмер биреп тора иде. Изольда ана баягы алманы сузды:

— Сиңа бу, берәү генә! — диде хатын. Галин алманы кулына алды да тешләп куйды. Алма бик баллы иде, ул елмаеп башын кагып куйды һәм:

— Мондый тәмле алма ашаган юк иде әле! — диде.

— Галин, әйдә мин тавык фермасы ачып җибәрим әле!

— Син? Тавык фермасы?

— Әйе, тавык фермасы. Тик бройлер түгел. Гап-гади әтәчләр белән.

— Хәзер гади булмаган әтәчләр дә күп анысы. Карале, Иза, шәп идея бит бу! Химикат белән симергән тавык итеннән туйган бит инде халык! Деликатес булачак андый тавыклар салган күкәйләр дә!

— Только исем кирәк, шәп исем. Мин бер исем таптым, сиңа ошаса инде?

— Йә, йә, Иза?

— «Галин күкәйләре»!

Аның әлеге сүзеннән Мәннәви сыгылып төште һәм беркавым тынычланганнан соң:

— Иза! Син — гений! Әйдә, «Галин» дип түгел, «Галия күкәйләре» дип атыйбыз тавык фермасын! Беләсеңме, безнең әни күп итеп тавык асрый иде, шул күкәйләрне Сабантуйга берәр ай кала эчкән көрәшче һәрвакыт батыр кала торган иде. «Галия күкәйләре» дигән даны чыкты шуннан соң. Әни тавыкларына үзе белгән әллә нинди дару үләннәре генә ашата иде. Әтәче дә особый була торган иде! Особый дип... гел яшь әтәчләр. Чөнки әтинең әтәч кычкырганны җене сөйми, шуңа күрә ул атнага бер мәртәбә утын пүләне бәреп аякларын сындыра да, әни, каргана-каргана, тагын яңа яшь әтәч табып кайта торган иде!

Изольда дәшмәде, ул баядан бирле иренә аптырап карап тора иде: «Нәрсә булган бу Мәннәвигә? Алыштырып куйган кебек бит?»

— Ну, алмасы шәп, Иза! Кайсы кибеттән алдың?

— Кибетнеке түгел ул! Байтамакта алма бакчасы бар. Шунда үскән алма.

Галин дәшмәде. Өстәлдән коньяк шешәсе алып, тустаганга эчемлек агызды. Тик, иснәп карады да, кире куйды һәм янә хатынына күтәрелеп карап:

— Иза, мин мунча ягарга куштым. Әйдә, гәүдәләрне язабыз бераз! — диде.

— Гөнаһларны юабыз диген.

— Гөнаһлары да юылыр инде шунда бергә.

— Әйдә, — диде хатын һәм, үзенең «коренной» җырын көйли-көйли, бүлмәсенә кереп китте. Әлеге җырны Мәннәви Мансарович та исендә калдырган иде, ул да бер-ике куплетын шыңшыды:

Булмагач син, утлар сүнде.
Бары төтен керә күзгә...
Кышларымны җәй иттең син,
Мин яз идем сары көздә.

Ялкын сүнде, очкын калды —
Күзгә керә бары төтен.
Югалтканны табармын күк,
Ташлап китмә, өметем!..

Җырның авторы сәер фамилияле, берәр гарәп яки фарсы шагыйре микән: Изольда аны икенче иҗеккә басым белән «Гарәфә» дип үзенчә әйтә.

Галин мунчадан соң, машинасына утырып, каядыр китеп барды,галәттә үзе белән тән сакчыларын да ияртә торган иде, бу юлы руль артына да үзе утырды.

— «Странно...» — дип калды аның артыннан хатыны.

Бер караганда, Галинның бу гамәлендә әлләни гаҗәп нәрсә юк иде, руль артына үзе утырса да, Бурзайга икенче машина белән ияреп барырга кушты ул.

Изольдә биргән алма Мәннәвинең күңелен ачып җибәрде. Монарчы дөнья мәшәкатьләреннән арына алмаган Мәннәви Мансарович Галин кинәт иркенәеп, бушанып калгандай булды. Күңел ачылу исә аның өчен галәти күренеш яки халәт кенә түгел, бу олуг һәм зур вакыйга иде. Чөнки бик нык үзгәрә, бөтенләй алыштырып куйган сыман булалар аны андый вакытларда. Ә андый вакытлар, кызганычка каршы, сирәк була, хәтта юк дәрәҗәсендә иде соңгы елларда. Ул хәтерләгән беренче җилпенү күптән түгел теге яшь килен белән очрашкач булды, менә хәзер тагын кабатлана шул хәле. «Бүген үк яна мәктәп төзелешен башларга кирәк!» — дип уйлады Мәннәви эченнән. Һе, кызык... Яшь килен белән очрашкач, сәерләнде җаны, хәзер менә хатыны кулына алма тоттыргач? Нигә булыр бу? Әллә бөтен сәбәп хатын-кыздамы? Әнә шул сорауга җавап эзләп чыгып китүе иде Мәннәвинең. Машина юлы туп-туры алма бакчасы капкасы янына алып килеп чыкты. Монарчы күргәне булмаса да, каравылчыны ул шундук танып алды, әйтерсең, күптәнге танышлар, хәтта дуслар шикелле.

— Менә юл уңаеннан сугылдым әле. Быел алма бик уңган диләр, — дип сүз башлады ул.

— Алма кызыгырлык җимеш, — диде Сәхаби үзенең мәгънәви ирennәре белән.

— Кая, сыйлыйсыңмы соң?

Сәхаби капка янындагы алмагачтан бер алма өзеп алды һәм аны кунакка сузды:

— Мә!

— Берне генә бирәсеңмени?

— Әнә бит, — диде Сәхаби, — аргы очка төртеп күрсәтеп. — Бурзаең агачыние белән умырып ята теге башта.

Мәгънәвигә үз гомерендә беренче тапкыр уңайсыз булып китте, ул кесә телефонын алып, төймәсенә басты һәм боерулы тавыш белән:

— Бурзай! Ананны сатыйм! Туктат хәзер үк мародерстванны! — диде.

— Ярар, тыйма инде. Сезнең урлап ашамасагыз тамагыгыз туймый бит, — диде Сәхаби тыныч тавыш белән. Сүзләр ябышмасын сизгән Мәннәви аның бу ачулы сүзләреннән соң машинасына таба борылды һәм утыруга шатырдатып кулындагы алманы тешләп алды. Алма суы бар тәне буйлап таралып, ул рәхәтлек дөньясына чумды.

Бу аның хәтерен ачып җибәрде: йомгагы сүтелә башлап, ул Мәннәвинең яшьлегенә таба тәгәрәде. Ә яшьлеге кайнар иде Мәннәвинең. Гомер дисбесенә илле дистәне җыйганнан соң ул давыллы елларның хатирәсе тагын да якынрак кебек, монарчы гел алга карап кына яшәргә өйрәнгән адәм баласы, аз гына тукталып торып, хатирәләрен яңартып алучан; вакыт узган саен әлеге истәлек-хатирәләр үткәннең көзгесендә тагын да ачыграк булып шәйләнә. Кызганыч, Мәннәви Җәмил хәзрәт белән таныш түгел, югыйсә, аның: «Алла рәхмәте белән адәм баласының хәтер дигән могҗизасы аны гомере буе озата барып, күпмедер мәгълүм яшькә житкәч, аңа бала акылы үк кире кайта; кем генә булмасын, ул кем дигәнең ни генә кылмасын, ул барыбер үз кавеменең иманы яссылыгындагы юлдан барыр, муенына чорналган гамәл дәфтәреннән котыла алмас. Хәтерне

янарту ул иманны янарту белән бер. Бу могҗиза Аллаһы Тәгаләдән» — дигән сүзләрен ишетер иде. Байтимер белән якыннан аралашып, аның галәмдәге кичерешләрен белә алыр һәм, бәлки, байлыгын галәмгә турист булып бару өчен сарыф итәр дә, җирдә тапкан малына шул югарылыктан карап, фикер йөртер иде... Әлегә хатирәләр генә. Аның әтисе гомер буе сарык көтүе көтте. Гомумән, нәселләрендә барысы да урта-кул хезмәт кешеләре, югары уку йортларында белем алучылардан Мәннәви беренчесе иде. Мәктәп тәмамлагач, укырга керә алмады ул, армиягә алып киттеләр. Анда десантчылар полкында хезмәт итте. Мәннәви шул чакта әтисе сарык көтүе көтеп йөргән җир өстен болытлар биеклегеннән күрә алды. Парашют белән һавада йөзгәндә тирә-юнь уч төбендәгедәй күренә, монарчы авыл белән авыл, авыл белән шәһәр арасын, урамдагы тыкрыклардан китә алмаган егеткә югарыда алган тәэсирләре гаҗәеп булып тоелды. Ул күк карашы югарылыгында миллионлаган сарыклар утлап йөрергә мөмкин булган зур җирләр күрде. Дөньяның зур һәм киң иканлеген тойды шулчак егет. Аның һәрчак шул биеклектә каласы килү теләге уянды!.. Армия вакыты тәмамланыр алдыннан әлеге хис отыры көчәя генә барды. Ике елга якын солдат шулпасын чөмергәннән соң армия хезмәте шактый җиңеләйгән, тормыш иркенәйгән вакытлар иде бу. Парашюттан сикергәндә кабынган теләк (иптәшләренең дә һәммәсе диярлек шундый хис кичерә иде) казарма эчләренә, койма белән әйләндереп алынган полк коймаларына гына сыймый иде инде.

Хезмәтендә аны бик яраттылар. Ул аеручa взвод командиры капитан Михайлов белән дуслашты. Михайловны бүген-иртәгә бригаданың башка ротасына командир итеп билгеләргә тиешләр. Ләкин шул вакыт нәкъ аның взводыннан ике автомат юкка чыкты! Бу коточкыч вакыйга, бу әйтеп-аңлатып биреп булмаслык гадәттән тыш хәл («ЧП») иде. Кая ул рота командиры булу турында хыяллану, моннан соң Михайловны армиядән үк сөрергә мөмкиннәр иде. Әлеге гадәттән тыш хәл хакындагы хәбәрне, моның өчен үзенең дә башы киселәсен чамалаган рота командиры Клименков, бер-ике көн генә рота эченнән чыгармаска җан тартышты.

Автоматларны Мәннәви урлады. Капитан Михайловның үзе яшәгән хәрби шәһәрчектә сөяркәсе бар иде. Беркөнне Мәннәвине ул үзе белән ияртте. Мәннәви әүвәл капитанның мондый гамәленә аптыраган иде, соңыннан ачыкланды: сөяркәнең дәрте ташып торган туганнан туган сеңлесе бар икән, шуна иптәш кирәк булып чыккан да, капитан инде армия вакытын тутырырга озак калмаган сержантны шуның белән таныштырды. Любаның сеңлесе Люда бик чибәр яшь маржа иде. Ул беренче күрүдә, гашыйк булып, егеткә капланды. Кичләрен, рота командиры кайтып киткәч, алар капитан белән икәүләшеп уҗымга йөрделәр. Тора-бара Мәннәвине Людага өйләндерү турында сүзләр чыга башлады, моның өчен нигез дә бар икән, кызларның бабалары сугыш вакытында монда украин кызына өйләнеп калган Казан татары булып чыкты. Люданы Мәннәвигә, күрәсең, шул татар каны тарта иде. Алар башта дүртәүләшеп Любаның бер бүлмәле фатирында кәеф-сафа корып утыралар, соңыннан Люда егетне аулакка, абыйсының буш фатирына алып китә иде. Беркөнне Люданың шул абыйсы кайтып керде. Люда аны булачак киявем дип таныштырды. Прапорщикка булачак кияүнең Казан татары булуы бик ошады, алар дуслашып киттеләр.

Кавказда халык уяна башлаган вакытлар иде бу. Прапорщик шунда командировкада булып кайткан икән. Ул ана беркөнне эшлекле тәкъдим ясады: дембелгә җыенган егеткә зур акчалар эшләү мөмкинлеге бар икән! Вакыты җиткәч, үзем әйтермен диде. Әлеге вакыт озакка сузылмады тагын,

прапорщик серне чиште: ротадан калашников автоматлары урларга кирәк икән. Зур акчаларга! Кавказдагы боевикларга җибәрү өчен! Акчасы-акчасы, әлбәттә, шәп нәрсә! Тик анда Мәннәвинең мөселман туганнары азатлык өчен көрәшкә күтәрелгәннәр икән! Шуларга ярдәм итәргә кирәк! Өстәвенә прапорщикның бабасы да мөселман кавеменнән бит әле!.. Аның тамырларында да бабасы каны уйный!

Ул акчалар белән «гражданкада» нәрсәләр эшләп булачагын Мәннәвигә исәпләп тә бирделәр: Киевның үзендә яки Казанда бер бүлмәле фатир алырга мөмкин һәм кооператив ачарга була икән! Заманалар башка бит хәзер: форсаттан файдаланып калырга кирәк!.. Рәсәй халкында урлау (төркемнәр арасында канлы бәрелешләр, дәүләт малын бүлешүләрнең нәкъ башланган вакыты. Казармадагы телевизор көне буе автоматлар күтәреп йөргән башкисәрләрне күрсәтеп тора) психологиясенең чәчәк ата башлаган еллары иде бу! Әлеге гамәлнең ахыры хакында Мәннәви уйлап та карамады, чөнки тиздән өйгә кайтасы, укырга керә алмаса, кая бара да, ни эшли! Әтисе кебек көтү көтеп йөрмәячәген, әлбәттә, егет үзе өчен күптән тәгаенләгән иде!..

Моннан бер ай элек кенә, «картлачларның» мыскыл итүенә түзә алмаган бер хохол малае автоматы белән урманга качты. Аны бер атнадан тотып алдылар алуын. Бу вакыйга армиядә дә хаос башланганын хәбәр итә иде.

Бер атнадан аларның бригадасы зур хәрби уенда катнашырга тиеш. Рәсәй президенты Ельцин үзе киләчәк икән! Әлеге уенга әзерләнү ыгы-зыгысы башланды. Рота урмандагы полигонга күчте. Шул вакытта сержант Галиев ике урынына дүрт автомат һәм бер тартма «лимонка» гранаталары урлап, урманга яшерде. Рота командиры нишләргә белмичә ут йотып йөргәндә, әлеге хәл штабка барып ирешкәнче, коралларны бик ерак яшереп өлгерделәр. Прапорщикның планы алдан уйланган иде. Ләкин моның белән генә эш бетмәде әле, хәбәр штабка барып җитүгә, чынлап торып эзләүләр башланачак һәм Галинның да, прапорщикның да эзенә төшәргә мөмкиннәр. Прапорщикның бу нисбәттән дә планы булган икән. «Ротада син күралмаган берәр солдат бармы?» — дип сорады ул беркөнне сержанттан. Андый кеше бар иде, әлбәттә, ул буйга ике метрлы украин малае Павловский фамилияле сержант. Павловский рота командирының «стукачы» иде. Галиевнең төнлә хәрби шәһәрчектә кунып калганын рота командирына ул сатты. Ротный исә аңа, үз чиратында, дембельгә иң актыккы кеше булып китәсен дип, янады. «Дембел» вакытының бер көнгә генә сузылуы да өенә кайтып китәргә әзерләнгән солдат өчен иң зур, иң авыр җәза иде!..

Ул көнне сержант Галиев рота буенча кизү торды. Мәннәви, прапорщик өйрәткәнчә, аягы гөмбәләп, уенга бармыйча палаткада аунап яткан Павловскийны полкка җибәрде. Янәсе, аны тиз арада рота командиры чакырткан! Кичке якта сазлыкта «стукач» хохолның пилоткасын гына табып алдылар, шуннан ерак түгел урланган автоматларның берсе табылды, анда сазлыкта һәлак булучының бармак эзләре калган иде. Шуның артыннан ук калган кораллар белән сержант Павловский сазлык төбенә китеп барган дигән хәбәр дә таралды. Рота командирын эшеннән алдылар, шуннан соң, уен вакытында взводының яхшы күрсәткечләре өчен, Михайловны үзенең ротасына командир итеп билгеләделәр...

Мәннәви Киевта калмады, Людага, фатир сатып алгач, сине дә килеп алырмын дигән вәгъдәләрен калдырып, Казанына кайтып китте. Казанда акчалы егет өчен яңа тормыш башланды. Беренче эш итеп ул, әлбәттә, бер бүлмәле фатир юнәтте, аннан соң финанс-икътисад институтына читтән торып укырга керде (әлбәттә, акча төртеп!.) һәм әтисенең бертуган абыйсының малае Юлбарыс

белән «НОРД» дигән кооператив ачып җибәрделәр. Аннан ун яшькә өлкәнрәк Юлбарыс таксист булып эшли, үз вакытында бер зур түрәне дә йөрткән шактый шома адәм иде. Эшләр җайлангач, Украина да, Люда да онытылды. Бернично айдан прапорщик суккан: «Ты нас кинул!» — дигән телеграммадан башка, Украина ягыннан бүтән җилләр исмәде. Мәннәви фамилиясен алыштырды.

Мәннәви армиядән кайткач, десант формасын тиз генә салмады, шуның белән укырга барып керде һәм әле тагын өч атналап киеп йөрде. Көтүче Мансарның малаена әлеге кием килешә иде килешүен, тик, әүвәл малаеның күкрәгенә ялтыравыклы калайлар тагып кайтуына сөенгән Мансар абзый, аның киемен алыштырмавына үзе үк көенә башлады. Эчтән калтырасалар да, тыштан «ялтырарга» тырышу аларның нәселендә бар иде. Мансар абый яшь чакта үзенең «Мансур» исемен кешедән аерылып торасы килеп «Мансар»га үзгәрттерде, абыйсының малаена дөньяда булмаган ят исем «Юлбарыс» дип куштылар. Тик ни генә кылансаң да, язмышың койрыгы көтү көткән чыбыркың кебек гомерең буе артыннан сөйрәлеп барыр, ди. Мансар абзый, көтү көтүен инде күптән ташлап, яшелчә бакчасында каравылчы булып урнашса да, ул авыл халкы өчен барыбер сарык көтүчесе Мансур булып калды.

Ул елларда авыл халкы күпләп сарык-кәҗә асрый иде бу якларда. Сарык йоны оекбаш, бияләй, киез итек кебек салкын кыш өчен бик кирәкле кул-аяк киемнәре бәйләргә бик яхшы (ите дә ярап куя!) булса, кәҗә мамыгы шәл өчен үтергән инде! Бу төбәктә «көтүче ашату» дигән гадәт-тәртип бар. Көтүче ашату үзенә күрә бер җаваплы эш булып тора: ул көнне өйдә өчпочмак, пәрәмәч кебек тәмле ризыклар пешә, иртән дә сарык көтүчесе, чираттан берәрсенә кереп, көтүгә тамагын туйдырып чыгып китә. Мич ашлары, гадәттә, төш вакытына өлгерә, аннан соң аны, суынмасын дип, ашъяулыкка һәйбәтләп төреп, болынга көтүчеләргә илтәсе. Ул көнне гаиләдә бәйрәм! Бигрәк тә малайларга: көтүчегә әбәд илткәндә болында рәхәтләнеп бер чыбыркы шартлатсаң, өстәвенә сыйланырга да җае чыгачак — ашъяулыкта сиңа дигән берәр өчпочмак яки пәрәмәч тәгаенләнгән була! Җиләк вакыты булса, кайтканда рәхәтләнеп җир җиләге, йә урман кырыенда каен җиләге белән сыйланасың! Көтүчеләр үләнгә кырын ятып, тамак ялгаган чагында Ашкын суында чумып чыгуың үзе генә дә ни тора!.. Мондый бәйрәм исә көтүчегә җәй буе, көн саен! Көн дә мич ашлары гына ашап тора бит алар! Аллай, кадерле кешеләр! Мансар ага авылда менә шундый кадерле кешеләрнең берсе иде. Тик шунысы гаҗәп: көн дә бәйрәм, көн дә туй дигәндәй, җәй буе шундый хасияттә яшәсәләр дә, көтүче булырга атлыгып торган кеше булмый торган иде авылда! Берән-сәрән генә алар!.. Әле өстәвенә сарык яки кәҗәләрнең баш саны буенча һәр хуҗалыктан көзен бәрәңге җыеп чыгасың бит! Үзенә бәрәңге утыртып, җәй буе эт эчәгесе чүпләп азапланасы да юк. Печән-саламын — әгәр җүнле колхоз булса, — мир көтүен көткәне өчен көтүчегә колхоз рәисе бирә торган иде! Һәр хуҗалыктан сарык башы буенча җыелган игене генә ни тора! Менә шул: гади сарык көтүчесе генә иде Мансур — Мансар абыен, тик авылда иң кадерле кешеләрнең берсе иде. Салырга яратты ул, тик «кыек баш»тан азып-тузып йөрмәде. Салу кизүе башланган атналарда ул чираттагы хуҗалыкта ашап тормады, иртән, көтү куар алдыннан шул тиешле йортына кереп, тамак ялгыйсы урынга берәр чүмеч әче бал гына чөмереп чыга да аннан соң өйләгә чаклы шул кәеф белән чыбыркы шартлата, төш вакытында чираты үзендә булган хуҗабикә янә берәр банка әче бал кыстырып килә, кабымлыкка булары чыгып торган пәрәмәч.

Малаеның да мулла кушкан исеме Мәннән иде, авылның аргы очында тагын бер малай туып, ана да Мәннән кушканнан соң, ата кеше малайның исемен авыл советына үзе барып «Мәннәви»гә үзгәртеп кайтты. Дөресрәге, ул

анын койрыгына «бәй» дигән койрык кына өстәтмәкче иде, жиде класс кына тәмамлаган сәркатип хатын «Мәннәви» дип ялгыш яздымы, әллә махсус шулай (ул чакта «Вий» дип аталган пәри турындагы кино бик популяр иде, бәлки, шунын шаукымыннан айнып житә алмаган булгандыр апаң?) эшләдеме, анысы — карангы.

«Көтүче малае» булу анын артыннан көтүче чыбыркысы кебек бертуктаусыз өстерәлеп йөрде. Югыйсә, көтүче алар ягында дәрәжәле һөнәр иде, чөнки көтүче бурга теләүчеләр булмаганлыктан, анын урыны түрдә, исеме хөрмәт белән телгә алына иде.

Атасын да, анын чыбыркысын да яратмады Мәннәви. Хурланды. Яшүсмер чагында кызлар янына якын килә алмады, гүя аны «көтүче малае» дип мыскыл итәрләр кебек тоелды. Һәрхәлдә алай дип берәү дә мыскыл итәргә уйламаса да, Мәннәви моны үзе уйлап чыгарды бугай. Гомере буе «көтүче малае» дигән исемнән котылырга хыялланды ул. Кооператив оештырып, хәлләнә башлагач исә авыл белән дә, ата-анасы белән дә араны өзде, дөресрәге кунакка да алмады, үзе дә кайтып йөрмәде. Мансар агай, аптыраганнан, көтүен ташлап, яшелчә бригадасына эшкә дә урнашып карады. Тик малай «йомшармады».

Өйләнер алдыннан барыбер әти-әнидән качып булмый иде, туганы Юлбарыс Мансар агайны гаиләсе белән шәһәр янындагы бер бистәгә күчерде, Мәннәви акчасына ике катлы коттедж салдылар һәм алай гына да түгел, инде пенсия яшенә житкән Мансар агайны шул бистәнен советына эшкә керттеләр. Укый-яза белмәгән, кул урынына тамга гына куя белгән Мансар агаебыз беркавымнан зур түрә булып китте. Хәер, Рәсәй илендә түрә булу өчен талант һәм гыйлем әлләни кирәкми дә инде. Терәген генә яхшы булсын!..

Көннәрнен берсендә десант киемнәрен салырга өлгермәгән Мәннәви Әтнә автобусында Казанга барырга чыкты. Ул көнне Дөбьязнын үз автобусы нигәдер йөрми иде, аларны станциядан Әтнә автобусы алып китте. Автобуста кеше күп түгел, берзаман ыспай киемле десантчы янына, иптәшләреннән аерылып, Әтнә кызы күчеп утырды. Кыз бик чибәр булу өстенә, үтә дә чая булып чыкты, үзе янына килеп утырды, үзе сүз башлап сөйләштерергә кереште. Мәннәви дә рәхәтләнеп сөйләште анын белән һәм автобус Дәрвишләр бистәсенә якынлашканда ул Тәнзилә исемле әлеге шаян матуркайга гашыйк булып та өлгергән иде. Кызнын тулай торакка абыйсы янына барышы икән, медицина институтынын икенче курс студенты, хәзер авылында каникулда. Мәннәви аны Калинин урамындагы тулай торакка кадәр озата барды. Ишек төбендә Тәнзиләне берничә иптәш егете белән абыйсы каршы алды, алар адресларын алышырга гына өлгереп калдылар.

Яшьлек үзе гүзәл шул! Үзе дә укырга кергәч, Тәнзиләне эзләп тапты Мәннәви. Әтнә кызы егетне башы-аягы белән сихерләп өлгергән иде. Конгырт күзле, уртача буйлы, матур тавышлы бу кыз гүзәлләрнен гүзәле булу өстенә, бик итагатьле-әдәпле кыз да. Баштарак егет анын кулын да тота алмады. Кыз үзе төрекөмеш кебек хәрәкәтчән, тиктормас, ләкин икесе генә ялгыз калып, аңа якын ук килгән егетнен сулыш алулары ешая башлагач, ул капылт югалып кала, жиргә сенеп, бөтенләй юкка чыккандай була. Кыз үзе дә ярата иде бугай Мәннәвине. Берзаман алар бер-берсеннән башка тора алмас булдылар.

Тик донья дигәнен шулчак бик тиз генә башка сукмактан тәгәрәтеп алып китте. Юлбарыс абыйсы аны элек үзе йөрткән бер түрәнен кызы белән таныштырды, таныштырып кына калмады, хәтта димләде дә. Бу түрә абзыйнын ихтыяры иде. Чөнки анын бердәнбер сөекле кызы, атасынын сүзен тынламыйча, көйләр язып сәхнәдә жырлап йөрергә кереште. Өстәвенә ниндидер бер мактанчык һәм жилбәзәк артист калдыгы белән дә әвәрә килә башлаган.

Яшь «кооперативчы», кызны үзенә каратып, әлеге гамәленнән биздерергә, алар бергәләшеп матур гаилә тормышы төзергә тиеш иде. Менә шуннан бирле алар Изольда Рафинадовна белән матур тормыш төзү эшендә... Ә Тәнзилә гомерлеккә йөрәгендә калды егетнең!.. Төзәлмәс җәрәхәт булып калды, ин-ин көчле бер нур булып, яктылык булып калды. Еллар уза торган саен ул аны ешрак сагына башлады. Ун-унбиш еллап вакыт узгач, ул аны эзләтеп тә карады, тик эзләве ул чакта шулай гына булдымы икән (кияүгә чыгып, фамилиясен үзгәрткән хатын-кызны табу җиңел эш түгелдер инде ул), алар бүтән кавыша алмадылар.

Күрше урам килене Мәннәвинең ялкынлы яшьлеген исенә төшерде. Килен тач аның яшьлегендәге Тәнзиләгә охшаган. Шуңа күрә, икенче тапкыр күрешү алдыннан, Мәннәви Миша Бурзайга аның әнисенең исемен ачыкларга боерды һәм, үз күңеленә килгән фаразларның дөреслеккә чыкмавын теләп, әлеге кыз-хатын белән очрашуны көтте.

Галин абыйсының ире Мансурга кыйммәтле операцияләр ясату өчен зур акчалар түләгәнен белә иде яшь килен. Шуңа күрә Миша Бурзай артыннан, кем әйтмешли, барса да барды, бармаса да барды. Тән сакчысы аша мәгълүмат алырга өлгергән Мәннәви Минлегөл атлы хатынның гүзәл кызын аеруча дулкынлану белән көтте. Шулчак Мәннәвинең башына бер фикер китереп сукты: ул Рәнзиләгә гашыйк булган иде! Аның танышлары-дуслары, әлбәттә, бу мәсьәләдә башкача эш итәләр. Алар әүвәл берәр ышанычлы кеше аша авылыннан кубып киткән яшь һәм саф татар кызы белән танышалар, хатыннарына сиздермичә генә аның белән дингез буйларына кыйммәтле сәфәргә йөриләр, шул рәвешле дә, башкача да аралашып торалар, «объектны» өйрәнәләр, әгәр кыз күңеленә ятмаса, икенчесенә алыштыралар, мәгәр инде әлеге саф татар кызы җаннарына бик хуш килә икән, хатыннарын аерып, шуңа өйләнүчеләр дә бар. Тик бу гамәлләр, өйләнгәнче, кырык йозак астында саклана һәм, әлбәттә, хатыннары бу кыек эшләр турында белү түгел, хәтта ике ятып бер мәртәбә төшләренә дә кереп карамый. Сәркәтип кызлар белән чуалулар чутка керми, барыбер минем янга кайта ул, дип фаразлый байбикәләр. Хәер, артык көнчеләре сәркатип кызны да эзәрлекли. Түм-түрәләрнең яшәеш рәвеше әнә шул рәвешлерәк бара иде... Шунысы да мәгълүм булсын: әлеге түрәләр, билгеле, исемнәре ишетелгән кешеләр түгел! Алар телевизор экраннарында ялтырамыйлар, журналистларны якын китермиләр. Ләкин алар, заманында хөкүмәттән арзанлы милек эләктереп калган, хәзер инде бик бай адәмнәр! Галин Юлбарыс абыйсы белән бергә кооператив ачып йөргәндә тегесе авыр сулап әйтеп куя торган иде: «Энем, барып чыгар микән эшебез? «Рожденные ползать летать не умеют!» — диләр бит! Безнең нәсел гомер буе, шул исәптән бабалар да ярлы-ябагай рәтендә йөргән!..» Ләкин шулай дисә дә, алар күңелләрен төшермичә, янә яна «Наполеон» планнары кора башлыйлар, җиң сызганып эшкә чума торганнар иде. Беркавымнан исә үзләре дә шуны аңладылар: бу илдә чиста эшмәкерлек белән шөгыльләнү гаять кыен мәсьәлә! «Җонлы кулың», әйбәт терәгең булырга тиеш, әгәр дә син берәр «түлле-түрә» шәҗәрә агачында бер нәни яфрак кына булсаң да, моңа шөкер итәсе генә, чөнки эшләрең, нинди каршылыклар булуга да карамастан, барыбер такыр юлдан тәгәрәячәк. Рәсәй тормышының бик ачы һәм кабахәт аксиомасы иде бу! Үз көчләре белән күтәрелгән егетләрнең һәрберсенә һәйкәл куеп чыгарлык лабаса! Ул вакытта Мәннәвинең үҗәтлеге көчле иде. Ул үҗәтлек әле дә бар аның җанында. Бер күрүдә күңелен яулап алган Рәнзинә атлы кыз-хатынны көткәндә йөрәге гөрт-гөрт тибеп, әлеге очрашуны күз алдына китергән Мәннәви чак кына борчылса да, әлеге үҗәтлек барыбер үзенекен итәчәк!..

Изольданы алдагы көндә үк шәһәргә озатты Галин. Үзе югында монда кемнәр

килгәнлеген хатыны барыбер беләчәк, анын «разведкасы» да шактый нәтиҗәле эшли иде. Ләкин бу мәсьәлә аны борчымый, аны бу минутларда күбрәк татлы очрашу борчый. Мәннәви өстәлдәге вазага Миша Бурзай Сәхаби бакчасыннан урлаган алмаларны да куярга кушты.

Яшь киленнең күзләрендәге куркуны ул килеп керешкә сизеп алды һәм бу аны шактый каушатты. Дөньяның мөгезеннән тотып торган дәһшәтле Галин үз-үзен танымады, югалып калды, җебеп төште, теле көрмәкләнде, әйтәсе килгән сүзен әйләндереп чыгара алмыйча азапланды. Әүвәл киленнең кайнар, йомшак кулыннан тотты, тегесе карышмады, бары башын түбән иеп күзләрен генә яшерде, аннары, чак кына кыюлык инә башлаган «кияү егете» яшь бичәнең башын үзенең күкрәгенә куеп, чәченнән килгән хуш исләр дөньясына кереп чумды. Шунда гына теле ачылып китте сыман, ул тыныч тавыш белән:

«Син мина бик ошыйсын!» — диде. Бу сүзләрдән соң бичәнең гәүдәсе дерт итеп куйды, ул артка тартылды. Ләкин Мәннәвинең көчле куллары аны каты итеп кыскан иде. Көтүче Мансар малае, хәзер инде дөньясының артына тибеп яшәгән Мәннән Галиев үз гомерендә беренче мәртәбә эреп аккандай булды. Чынлыкта исә, әллә анын куенындагы яшь килен шулай эреде, әллә анын тыгыз, ак күкрәкләре арасында Мәннәви үзе югалды. Бу чаклысын икесе дә аңлый алмадылар бугай...

Кыз чыгып киткән чагында да Мәннәвинең үз кыюлыгы кире кайтмаган иде әле. Ул өстәлдән алма алып Рәнзиләгә сузды. Тегесе шундук алманы тешләп алды һәм шунын артыннан ук кычкырып җибәрде: «Әнием!»

— Бик ачысы эләктеме әллә? — дип сорады аптыраган Мәннәви. — Әллә әниең Миңлегөл ханымны сагынып куйдың инде? Кирәк булса, хәзер үк машина бирәм, янына барып кайт. Кайда яши ул?

— Хәзер Әтнәдә яшиләр инде, — диде кыз һәм шунын артыннан өстәп куйды: «Тәнзилә исемле ул, паспортында шулай. Тәнзилә. Миңлегөл мулла кушкан исеме. Миннәре күп булгач... Авылда әле дә шулай дип йөртәләр». Ул шулай диде дә аннары, авызын ачып, аптыраган кыяфәт белән Мәннәвигә карады.Янәсе, минем әниеңң исеме нигә кирәк булды әле сина, абый кеше?

— Су эч! — диде шулчак кемдер Галинга. Галин су алып эчте һәм кинәт кылкына башлады, сулышы кысылып, буылам дигәндә генә Миша Бурзай каты кулы белән аркасына китереп сукты. Бу вакытта Тәнзиләнең Рәнзилә атлы кызы бүлмәдә юк иде инде...

Ул өстәлдән бер алма алып, бар көченә учына кысты, яшькелтем алманың әчкелтем суы күзләренә чәчрәде һәм битләре буенча агарга кереште... Мәннән Галиев чын күз яшьләре белән елый иде...

*Ахыры киләсе санда*



Фәйрүзә
Мөслимова

# МИЗГЕЛЛӘР ЕЛЛАРГА БИРГЕСЕЗ

## Ярлыка!

Ашыктым, йөгердем туктаусыз —
Ышандым тылсымлы әкияткә.
Эзләгән табылыр дип белдем,
Таянсам тынгысыз йөрәккә.

Чын сөю эзләдем талпынып,
Яраттым онытып дөньямны:
Үкенеп укырга язганмы,
Хәтерем каләме язганны?

Ашыктым, абындым, егылдым —
Кулларын сузмады беркем дә.
Һәммәбез шундый ук халәттә —
Адашып йөрибез төркемдә.

Атама-анама таяндым,
Дусларга, балама, ярыма...
Аккан су шикелле барысы —
Сон барып житте шул аныма.

Ниһаять, мәңгелек Сөюгә
Күзләрем ачылды: яраттым!
Аһ, озак сынадың Син мине,
Ташлама, ярлыка, йа Раббым!

Фәйрүзә МӨСЛИМОВА — *шагыйрә, прозаик; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. С.Сөләйманова исемендәге әдәби бүләк иясе. «Ярату яралары», «Апрель кары», «Алтын йозак» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Кисәтү

Шәбез аша тагын күпер киткән,
Алда мине сынау көтәдерме?
Аргы ярга, шиксез, чыгу кирәк
Таштан ташка сикереп үтәрменме?

Шәбез аша күпер тагын киткән —
Сынау көтсә мине, шул төш керә:
Текә ярдан әкрен генә төшәм,
Талгын суы инде өшеттерә.

Юлга чыксам, имтиханнар бирсәм,
Минем хәлне Шәбез уртаклаша:
Күпер киткән чакта, басма сала
Шаулап аккан язгы ташу аша.

Кичеп чыгам кыен булганда да —
Мондый төшләр бер кисәтү кебек:
Туган ягым ярдәм кулын суза
Хәлләремне ерактан ук сизеп.

## Гафиллектә

Яулыгыма карап, елмаясың,
Гөнаһларым эзләп, сынагандай.
Ә үзеңне фәрештәгә тиңләп,
Кимчелектән азат санагандай,
Акланасың:
«Гөнаһым юк минем, берәүгә дә
Залимлекләр кылмадым мин җирдә.
Үз-үземне чикләп, эш калдырып,
Намаз укып йөрим әле нигә?

Укысыннар, әнә, «авышканнар»,
Маңгайларын җиргә бәрә-бәрә.
Беркем кайтмый мәңгелеккә киткәч,
Барыбыз да керә шул ук гүргә!»

Бәхәсләшеп көчне сарыф итмик,
Адаштырыр көчләр азмы әллә?
Фәрештәләр тик күкләрдә яши,
Ә гөнаһлар безнең түбәләмә!

Гафиллектә үткән елларымны,
Кичерер дип бары Хак Тәгалә,
Сиңа түгел, Аңа башым иям,
Маңгаемны куеп сәҗдәләргә.

## Үз татарым

Үз телеңне белмәү оят,
Дип әйтеп кара гына —
Татарчасын өйрәнмәгән,
Татарың ябырыла.

Сылтый ата-анасына,
Һәм сылтый заманына.
Чит ил телен өйрәнергә,
Керешкән яңа гына.

Рәхмәт яңа заманына,
Заманга тиң аңына,
Төкерә нәсел-нәсәпкә,
«Модасыз» татарына.

Милләтеннән еракларак
Китәргә дип ашыга.
Хыянәтче икәнлеге
Барып житми башына.

## Хәлләр...

*«Тәтәй күлмәк алып кисәм,*
*Яхшырыр кебек хәлем...»*
Роза Хәлиуллина сүзе

Озын кара толымнарны
Сүтә икән вакыт жиле.
Тарата да, агарта да —
Юк дәвасы, юктыр име.

Егетләрнең һушын алган
Күзләренә күзләр тия.
Синең кебек башка кызны
Башка егет өзелеп сөя.

Тәти күлмәк дип борчылмый,
Толым да юк иңнәрендә.
Джинсыдан да — зифа, сылу
Гамьсез яшьлек илләрендә.

Бүген ул яшь, бүген матур.
Һич эше юк иртәгәдә.
Үзен сөеп карап калган
Карашлардан иркәләнә.

Ул да бер чак картаермы,
Уфтанырмы синең кебек:
— Яшәрер дә идем әллә,
Куйсам яңа чалбар киеп...

## Үпкәләмә

Рәнжеттеләр... Үпкәләден.
Таш хәзер куеныңда.
Томырырсың йөзләренә —
Чыксын тик жае гына.

Ләкин жае ерак йөри,
Авырая бара таш.
Бөкрәйде инде билен,
Жимерелде күз вә каш...

Рәнжеттеләр, үпкәләден —
Жибәр сонга калганчы,
Чүп шикелле бер үпкәләү
Яман чиргә азганчы.

Очып китсен, онытылсын,
Нур кунсын күзләренә.
Гомер буе үпкә саклый
Җанында — җуләр генә.

Алга таба атла да кит
Борылмыйча үткәнгә.
Көлке булып тоелыр бер
Рәнҗүен дә, үпкән дә.

## Өмет

Җәйләр буе чәчәк аткан,
Җимеш биргән бакчаларны
Кай арада көзге төсләр,
Көзге хисләр биләп алды?

Озын кышлар кичәсе бар
Кабат чәчәк атар өчен.
Уйлый бакча, шуна кадәр
Җитсә иде, диеп, көчем.

Шул бакчаны үстерүче
Әби-бабай һич тик тормый:
Алла боерса, яз чәчәрбез,
Дия-дия орлык җыйный.

## Шигырь язма, Натали!

«Үземнекеннән дә туйган,
Шигырьләрен укымыйм», —
Дип язган хаты сакланган
Хатынына Пушкинның.

«Үземнекеннән дә туйган»...
Туйдырадыр шигырь дә
Хискә тулы һәрбер юлы
Көйдереп тамса бәгырьгә.

Һәрбер сүзе — кан тамчысы,
Кадерле — балаң кебек.
Сулкылдый тирән ярадай,
Җаныңны меңгә телеп.

Такмакны тиңләп шигырьгә,
«Аю биетә» кемдер.
Чын шагыйрьләр, ай-һай, сирәк,
Шигырьчеләр йөз, меңдер.

Натали язганнарда да
Куркадыр алданудан.
Кадерле яр!.. Кадерле сүз!..
Гомер тора янудан.

Бу турыда тарихта тик
Хатирә калыр инде.
... Аһ, Натали, язма шигырь,
Борчыма шагыйреңне!..

***

*«Очты-очты, торналар очты...»*

Онытылган тәрәз төбемдә
Син бүләк иткән китап.
Кояш нуры төсен алган,
Актаргандыр җил кат-кат.

Яткан тәрәзә төбемдә -
Беткәнгәме укылып?
Зарланган, күрәсең, җилгә:
«Китсәң иде очырып...

Очырыплар китсәң иде
Калмагач кадерләрем.
Оныттылар
шигырь аша
Аралашкан көннәрен».

Үткән шул яшьлек таңнары,
Хет сагынма, хет сагын...
Җиле көчле булган ахры,
Очкан... очкан китабым!

## Узма, гомер!

Үтмә, җәй, үтмә, көз, үтмә, кыш,
Никадәр ләззәтле бу гомер!
Бүгенгә сөенгән күңелем
Кичәне сагынып тилмерер.

Үтмә, төн, үтмә, таң, үтмә, көн,
Челтәрдәй үрәмен һәрберсен —
Җаныма, тәнемә сеңдереп
Һәр яңа бизәген, һәр төсен.

Киләсе көннәрдән куркаммы?
Ник сузам вакытны — билгесез...
Арсам да, талсам да, янсам да,
Мизгелләр елларга биргесез.

Бер туктау, бер яну, талпыну —
Минеке, минеке барыбер.
Инәлеп сораган чагымда
Узмыйча торсанчы син, гомер!

**Редакциядән.**

*Каләмдәшебез бу айда үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Рөстәм
Зарипов

# МИЛИЦИЯНЕҢ ЙӨЗ КЫЗЫЛЛЫГЫ

БӘЯН

**Беренче бүлек**

## ИГЕЛЕК ҖИРДӘ ЯТМЫЙ

### Кереш

«Кешене каторга җәзасына тартасын килсә, көндәлек язарга куш», — дигән Марк Твен. Андый җәзага түзәрлек ихтыяр көчен үземдә юк дип санап, тормышымдагы кайбер вакыйгаларны урык-сурык булса да теркәп бару белән канәгатьләнергә булдым. Уку — энә белән кое казу икән, язу да иләк белән су ташу кебек буш эш ахры... Тик, ни хикмәттер, язасы килү ихтыяҗы хәтсез, ә каторжан буласы килми... Чын язучы өчен үз-үзенне буйсындыру, җиңү зарур, әмма минем ише каләм тибрәтүчегә артык кырыс шартлар кабул итүнең зарурияте юк дип исәплим... Роман сырларга алынмыйм лабаса, исәбем, тормышымдагы кайбер гыйбрәтле хәлләрне истәлеккә генә калдыру.

«Түшәм»ем шулай гына булды бугай, мәгълүм биеклектән өскә таба миллиметр да артык «үстермиләр». Дөнья рәхәте чигеп, тормышның артына тибеп яшисе килә, ә көн дә җигәләр, сүгенеп каулыйлар, булдыксызлыгымны фашлап, чырайга чәпиләр. Түрә булсам, кемне ничек биетергә мин дә бик беләсе, кул астымдагыларның әле берсен, әле икенчесен чиратка салып, тиле калдыру әмәлен тиз табар идем кана... Әйтик, иртәнге планёркада бәгъзе белгеченә шомлы тавыш белән:

— Әйбәт кенә эшли идең, үзгәреп киттең, син бит мондый түгел идең?! — дисең. Яки:

— Егетләр, әзрәк башыгызны да эшләтегез, һаман утыра торган төшегезгә авырлык китерүдән туктарга вакыт...

Һәм башкалар, һәм шуның ишеләр. Бүтәннәрне көн дә «тәрбияләү» барышында үзеннең, якыннарының тормышын көйләү җаен чыгарасың.

— Юк, болай булмый, мин әйтәм, «КПСС карары — фәләнемә ярады», дип сафсата сатудан туктарга вакыт...

Ә партиягә югары белемлеләрне алырга ашыкмыйлар икән... Әмма төшенкелеккә бирелергә кирәкми, максатка ирешү юлы «әнә» генә. Сатучылар үтемле товарга үтемсезен, әйтик, дефицит хәлвәгә жете тозлы кильки балыгын таккан заманда яшибез, димәк, миңа да һич югы ике-өч эшчене фиркә куенына

өстерәтергә яки мәсьәләне жинел хәл итәрдәй зат белән дуслашырга кирәк. «Дәрт иткән жингәсен үпкән», диләр, абзагыз, жәйге ял вакытында шабашкага чыккач, райкомның оештыру бүлеге мөдире фатирына сыйфатлы ремонт уздыру насыйп булды. Игелек жирдә ятмый икән, әлеге агаем бердәнбер көнне:

— Син нишләп партиядә түгел? — дигән сөаль бирә...

— Лаеклы микән соң мин ул бәхеткә?

— Лаякыл! — диде абзыкай, кет-кет килеп.

Кем уйлаган шушындый очсызлы гына шаярту кәефне шулкадәр күтәрер дип. Ихластан кушылып көлдем.

КПСС сафларына кандидат булып теркәлеп күп тә үтмәде, бер кичне ишегемне форма кигән әфәнделәр какты.

## Нәкъ синдәй безгә кирәк

Әлеге икәүнең озынрагы, пожарниктыр дип чамалаганым Эчке эшләр министрлыгының кадрлар бүлегеннән булып, икенчесе районыбызның милиция житәкчесе иде. Үзләренә кодалыйлар, хәзерге эш хакым белән кызыксыналар.

— Өстәмәләре белән йөз алтмыш биш сум, — дим.

— Ә бездә ике йөз утыз. Хәрби дәрәжәң нинди әле. Сезнең институтта хәрби кафедра булгандыр ич?

— Запастагы өлкән лейтенант.

— Менә бит. Мин сержанттан башладым, ә син өлкән лейтенант, ә бәлки капитан булып ук керешәсең. Ә иң мөһиме — партияле булуың.

— Мин бит әле кандидат кына.

— Зарар юк. Райком белән килешенгән. Район үзәгенә толковый участок инспекторы кирәк. Тора-бара урынбасар да булып куярсың. Райком синең турыда бик унай фикердә. Йә, килештекме? Син безнең таләпләргә туры киләсең.

— Бераз уйларга, туганнар белән киңәшергә вакыт бирерсез бәлки.

— Әйдә, иртәгәгә кадәр. Казаннан килгән иптәш белеп китсен, югыйсә сиңа дигән штатны кире алулары бик тиз.

Хатын да, әни дә, туганнар да минем яна эшкә китүемне хупламадылар. Әмма чорыбызның «Свияга» атлы ин кәттә суыткычы ике йөз утыз тәңкә торган бер заманда, шуны ай саен сатып алу мөмкинлегеннән баш тартырга ана бит тай типмәгән...

## Үзгәрерсез

Яна урындагы хезмәттәшләр ят итми: мөнәсәбәтләр дустанә, ә өлкәнрәкләр бик теләп минем белән эш тәжрибәләрен уртаклаша. Беркөн шулай бүлегебез коридорында университет белемле тикшерүче Хәлил Әмирович очрый, бик канәгать кыяфәттә кулларын уа, сул йодрыгының өслегенә уң кулының учы белән шапылдатып сугып та куя һәм елмая.

Сәламемне алгач, шатлыгының сәбәбе белән кызыксынам.

— Әле генә берәүне кулга алдырып, камерага озаттым.

— Эшли башлаганда да мондый хәлләргә куана идегезме?

— Юк. Беренче тапкыр берәүне кулга алгач, камерасы тирәсен өч тапкыр урадым. Мин аны судка кадәр иректә дә калдыра ала идем, дөрес эшләдемме икән, дип борчылдым. Ә хәзер, күреп торасыз, шатлыгым эчемә сыймый. Ничава, Зәет Зарифулыч, сез дә үзгәрерсез. Безнең начальник та:

— Маймылдан милиционер ясап була, милиционердан кеше ясап булмый, — ди әнә.

## Беренче чирканчык

Курсларда укырга киткәнче башкалар тирәсендә өйрәнә торырга куштылар. Тәүге эш көнемне участковый Ногман агай белән башладык. Каяндыр Бөгелмәдән бер совхозга торба урлап ташыганнар. Ташучы шофёр да билгеле, әмма ул дөресен әйтмәячәк икән. Менә шунын телен чишәргә кирәк. Шофёрга карата эш кузгатып, кулга алып, камерага япканда, әңгәмә нәтиҗәлелеге артырга мөмкин, әмма прокурор рөхсәт бирми, дәлилләр сыек дип киресенә каткан, имеш.

Совхоз үзәгенә урнашкан авыл советы бинасындагы участковый бүлмәсенә киләбез. Коридор тулы халык, көтәләр, теге шофёр да шунда. Ногман агай, исереп эшкә чыкмаган, хатынын тукмаган, күршесе белән низаглашкан һәм башка шундый агай-түтәйләр белән шактый кырыс кылана, ә мин, мыегыма урап, милициячә сөйләшергә өйрәнеп, шыпырт кына бер почмакта утырам. Менә чират теге шофёрга житте. Ул таза гәүдәле, ир уртасы кеше,үзен тыныч, ипле тота, бер дә кабаланмый. Алай да:

— Ногман абый, рейска чыгасы бар бит, бик кирәгем булмаса тоткарламагыз әле, — дип, үз чираты житкәнче, без утырган бүлмәгә алдан пеләшләнә башлаган башын тыгып алырга өлгергән иде.

— Сабыр ит, апаем, — диде анаНогман агай. — Без дә бит монда юкны чәйнәп, су эчеп утырмыйбыз.

Инде чираты житкән, керде, тора бер урында таптангалап.

— Менә бу иптәш Минзәләдән килде, — ди Ногман ага, минем якка ымлап. — Син өченчекөн төштән соң монын ике сарыгын бәрдереп качкансын. Машинанның төсе килә, номерын шул. Бик әтәч кыяфәттә керден дә керүен апай, давай яхшылык белән сарык бәясен түлә, хакын килешегез, и эшне шуның белән бетерәбез.

Шофёр, көтелмәгән яңалыктан аптырап калды.

— Кайчан дидегез?

— Сангырау түгелсеңдер бит?

— Мин таптаттыммы, инәнне сигез-тугыз тиен? — ди бу мина, ыжгырып һәм якама үрелә.

— Күрүчеләр житәрлек анда. Тузаннар туздырып качтың, сбулыч.

— Бездә хулиганлык өчен дә маддә бар энекәш, үзенне ипле генә тот, ярыймы, — ди Ногман ага, тавышын күтәрә төшеп. — Боларның Минзәләсенә утырмага китмәгәен.

—Ногман абый, валлаһи, таптатмадым.

— Хәзер, ышандым.

— Өченчекөн диденме? Соң ул көнне мин бит Бөгелмәдә идем.

— Әкиятенне әбиенә сөйлә, нишләп соң путёвканда Минзәлә тора алай булгач? Диспетчерын да шулай дип чата-кама килә.

— Башта Минзәләгә дигәннәр иде, аннары директор Бөгелмәгә ычкынырга кушты.

— Барып, буш кайттым дисен инде?

— Нишләп буш, торба төяп.

— Мә кәгазь. Кайчан чыгып киттен, кайчан кая барып керден, кем төяде и кайчан кайтып керден? Язганнарын расланса, котыласын.

— Ничек котыла? — дип, ярсып, монын каршына ук килеп басам. Түләсен ике сарыкны, әле берсе анын буаз иде!

— Абый, валлаһи, мин түгел.

— Бөгелмәдә минем энекәш торба заводында эшли, хәзер очына чыгабыз, бармадын син анда!

— Бардым.

— Кем төяде? Кранчы кем иде?

— Торбаны заводтан түгел, аннан ерак түгел ПМК ихатасыннан төяделәр. Кранчы Сергей исемле, сары чәчле урыс малае.

Арага Ногман агай керә:

— Ярый, энекәш, әйткәннәреңне тиз генә сырла да рейсыңа ычкын. Кем төяде анда, кем эләктереп торды, кайчан и кем бушатты?

Шофёр мина каш астыннан караштырып язарга керешә, ә мин телефонга тотынам, «Бөгелмә»гә шалтыратып, Сергей атлы егет хакында белешкән атлы кыланам.

Шофёр киткәч, Ногман агайның авызы ерылды:

— Чуваш әйтмешли, пулты пу, — дип куйды. — Калганын Хәлил Әмиреч хәл итеп бетерә моның, — дип, кеткелдәп көлде һәм — Милиционер чыга синнән болай булгач, — дип мине купайтырга да онытмады.

## Фашистларча җәфалау

Прокуратурага район чигендәге авылда яшәүче ханымнан көчләнүе хакында гариза кергән. Урынга чыгарга төркем оешып, прокурор урынбасары Жамалыев, җинаятьләр эзләү бүлегеннән оперативник Галявин һәм мин, яна кеше, шунда укталабыз. Тегеләрнең кыяфәт шәп, зифа буй-сын, кара мыек, күзләр майлы, кыскасы, хатын-кыз игътибарын җәлеп итәрлек ир-атлар. Мин генә әллә кем түгел, сап-сары калын каш, сипкелле аксыл йөз, әле тегеләр сыман уклау кебек тырпаеп та тормыйм.

Зыян күрүче ханымның өен тиз таптык, ире, дүрт баласы бар, ә олысы армиядән кайтып, тракторга утырырга өлгергән. Хатын хәлне сөйли, юлдашларым алмаш-тилмәш уңайсыз сораулар биреп, мәгълүмат сыгалар. Өйдә дүртебез генә, Галявин башкаларны ихатада бер-бер эш эшли торырга кушып озатты.

Сораша торгач, шул ачыкланды: хатын инеш буендагы мунчаларына су ташыганда, бергә фермада эшләүче терлекче егет килеп чыга һәм моңа бәйләнә.

— Карышуыма карамастан, ул мине мунчага алып кереп, башымны тупсага салып, чатлы багана ясап, фашистларча яфалады, — ди хатын.

— Килеп ябышкач, кычкырдыгызмы?

— Әллә нәрсәсенә кычкырасы итмәдем.

— Киемнәрегезне ертмагандыр бит?

— Юк.

— Бу аның сине беренче тапкыр көчләве идеме, әллә элек тә көчләгәне булдымы?

— Әллә ничә тапкыр яфалады инде ул мине.

Егетләр, күзгә-күз карашып, елмаешып куйдылар һәм тәфтишләүләрен дәвам иттерделәр. Аннары, хатынга сөйләгәннәрен үз кулы белән кәгазь битенә яздырдылар һәм имзасын куйдырдылар. Аңлатма Галявин папкасына кереп урнашкач, опер кинәт кырысланды, хатынның күзенә батырып карап:

— Син нәрсә бер гаепсез малайны төрмәгә тыгарга азапланасың?! — дип җикерде.

— Шакир бит, — диде хатын, тәрәзә тирәсендә кайнашкан ире ягына ымлап, һәм шул мәлдә аның күзләре ялтырап, керфекләренә яшь тамчылары эленде, — тукмап яздыртты. Менә бу төшләрем кара янып чыкты...

## Йөгерттереп кенә барып кайтсын мәллә?

— Бүген, Дәет Дарифулыч, сез минем карамакта.

Көмеш чәчле милиция капитаны ОБХСС инспекторы Фәйзи агайның сарыга буялган «Урал» матаенда Кырынтау авылына юнәләбез. «Кыдыл бодау» диалекты белән сөйләшергә ятратканын белә Зәет Зарифулла улы, шуна үпкәләми...

Матайны совхоз идарәсе каршында калдырып, бинаның караңгы болдырына, аннары эчкә үтәбез.

Директор чирләп хастаханәгә эләккән, баш бухгалтер район үзәгенә киткән, кассир белән терлекчелек бухгалтеры гына эш урыннарында иде.

Фәйзи агай боларны әйбәт белә:

— Сәрия сенел, бар йөгерттереп кенә директорыгызның шоферын чакырып кил, кая торганын беләсеңдер, — ди.

— Әнә генә, — ди Сәрия, тәрәзәдән күренеп торган диварлары зәңгәргә буялган фин йорты тарафына төртеп күрсәтеп. — Өендә булса кирәк, әле генә ихатасында кайнашадыр иде.

Сәрия чыгып киткәч, бухгалтер ханымның да теле ачылды:

— Әллә утын урлады дип язганнармы?

— Бар инде. Нindirәк егет ул Мәсгуть, әти-әнисе исәнме?

— Бригадир ярдәмчесе булып та йөрде, заффермылар да булып эшләп алган Гыйсметдин малае инде.

— Хатыны почтадамы?

— Әйе.

— Бу егет кайда иде соң үзе? Бер дә күзгә-башка чалынганы булмады?

— Себердән баеп кайтты. Жигулигә утырып. Аннары лесникка ялланды. Ярты ел чиләнде микән, директор чакыртып, өр-яңа «Нива»га утыртты, иске директордан калган фатирны, әнә шул фински йортны бирдертте. Моннан көнләшүче күп инде хәзер. Үзенең абыйсының катыны сырламады микән әле хатны, бер дә тормышларының рәте юк.

— Алайса, юкка йөрисез дисең инде син?

— Тагын нәрсәләр язылган соң?

— Утын дигән дә икмәк дигән.

— Безнең лесник Сәлахтан рәже игелек күреп була. Икмәген ни диярgә дә белмим.

Әңгәмә шушы урында өзелде: ишектән Сәриягә тагылып диярлек, борчылуы чырена чыккан, чандыр гәүдәле Мәсгуть килеп керде.

Аны күрүгә, Фәйзи агай.

— Һи, моның ише чикләвекләрне «вату» берни түгел дигән кыяфәт чыгарып, миңа борылып елмайды һәм күз кысып куйды. Аннары, кырыслана төшеп:

— Мәсгуть Гыйсметдин улы Гыйльметдинов син буласыңмы? — дип сорады.

— Әйе, абый. Бер-бер хәл бар мәллә?

— Укы. Синең өстән язганнар. — Һәм Фәйзи ага анонимканы Мәсгутькә тоттырды.

Егетнең куллары калтыранды, кәгазь бите дер-дер килде. Ниһаять, язылганнарның очына чыкты ахры, тамак кыргандай итте, һәм:

— Абый, биш йок имән утынын лесник үзе бирде, хезмәтемне утынлата бәхилләтте, язуы бар, — диде.

— Утынны оныт. Сәләхи сиңа түгел, миңа да утын арттыра торган адәм түгел. Күзе очлы. Бәк вакчыл. Син эпи турында сөйлә.

— Өй әнә, күз алдыгызда. Абыйлар, пожалысты, кай төш кирәк, әйдәгез, ачам да күрсәтәм.

— Һмм... Бик кыю сүләшәсең бит әле син. Димәк, эпи синең өйдә түгел... Әйдә. Кабыз «Нива»ны, әтәннәр ихатасына урап киләбез.

Машина, капка төбенә житеп туктагач, егетебез бар кыюлыгын учына жыеп димме, сорау бирергә батырчылык итте:

— Абый, сезнен өйгә керергә санкциягез бармы соң?

— Ә-әә-ә, — дип суздьг Фәйзи агай, сары керфекле ачык зәнгәр күзләрен түгәрәкләндереп. — Сина капылт кына санкция кирәк булдымыни? Үзеннең өйгә чакырганда кирәк түгел иде бит... Ярар. Менә бу абыең ихатагыз янында калып торыр, ә без, синең белән икәү прокурорны урап килербез...

Егет сүзсез калды. Әмма дәшми озак түзә алмады.

— Абый, урлаган идем, — диде ул, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

— Шулай диген аны, әнәңне эт жыккыры малай. Атаң хәтле абзаңны алдап торасың. Сүлә. Нәрсә алып кайттың? Кая урнаштырдың?

— Арпа. Базга бушаткан идем.

— Берәр тонна бармы?

— Артыгы белән.

— Тәк. — Фәйзи агай кесәсеннән каләм алып, язып, нидер чутлады һәм жинаять эше кузгатырлык күләмдә, ягъни илле бер сумлык арпаны төяп, амбарга илтеп, үлчәтеп тапшырырга кушты.

— Калганы белән нишлим?

— Тапшырган кадәрең житеп торыр.

Егет, каяндыр дус-ишләрен табыштырып, әйтелгәнне үтәде һәм арпа тапшырылуы хакындагы язуны Фәйзи агайга кайтарып тоттырды.

Ике ай чамасы вакыт узгач, шул материалны «эш» итүче тикшерүче Хәлил, Фәйзи абый белән икебезне бергә туры китереп:

— Егетләр, күреп торасыз, эшләр муеннан, утыра торган жиргә кыл да сыймый, үз материалыгыз буенча эшне хезмәт коллективына житкерергә, жәмәгать гаепләүчесе яки яклаучысы сайлатырга кирәк, профилактика буенча эш планы шуны таләп итә, зинһар иренмәгез, — ди.

Янә сары матайда совхозга укталабыз. Таныш конторга керүгә, безне зурлап каршылыйлар, директор кабинетына уздыралар, кабинет хужасын һәм шофёрын рация аша эзләү хәстәренә керешәләр.

Алар табылганчы дип «эш» белән танышырга керешәбез.

— 89 нчы матдәнең өченче чәстен кулланган бит бу! — дип кычкырып куя Фәйзи ага.

— Нәрсә каралган инде өченче кисәктә?

— Ювелирный магазин басучы белән тигезләгән Мәсгутьне безнең Хәлил. Ин киме өч ел мона.

— Ничек алай?

— Күрәсезме, протоколда ничек язылган. Ул аннан урысча беләм дип кул куйдырткан да статьяны бәхәссез тегеп булырлык итеп жавап бирдерткән. «У меня в голове зародился умысел» дигән жөмлә дә бар монда хәтта. Өстәвенә «үтеп керү» теккән. Ә үтеп керү өчен какраз өченче чәс.

Хактан да сорау алу беркетмәсендә «безнең ындыр табагы әйләндереп алынган, мин бикле коймадан үтеп, арпаны үз машинама төяп урлап алып чыктым һәм әтием яшәгән йортның базына бушаттым», диелгән иде.

— Дәет Дарифулыч, бу бит үз машинамда, дигән. Димәк, жинаять чарасы буларак машинасы конфискациягә эләгә.

— Инәннең койрыгы, — дип куйдым мин, аптыраудан гажиз калып. — Себерләрдә бөкресен чыгарып алган машинасын алалар, үзен төрмәгә тыгалар, көл-талкан килә бит егетнең тормышы!

— Хәлил Әмиреч артыграк тырышкан. Ул кадәр зурга җибәрү пычагымамы? «Үтеп керү» дигәне артык монда. Югыйсә беренче бүлек чәпәрләр дә ин күбе ике ел дәвамында айлыгыннан 20% тотып барырлар иде һәм вәссәлам.

Телефонга ябышам. Бәхеткә Хәлил урынында икән.

— Син нәрсә кешене шул кадәр колагыннан батырасын? — дигән соравыма анын артык исе китмәде.

— Урлашмасыннар! — диде ул кыска итеп.

— Беренче бүлек кенә җитми идеме?

— Мин элек судка сез әйткән төсле җибәргәләдем. Ә анда тагын да йомшарталар да эш бракка чыгып куя. Шуна күрә гер тагам хәзер. Юкка хафаланмагыз, ул ахырдан таман гына булып кала.

Мин трубканы куям да аптырап Фәйзи агайга текәләм.

— Барып кайтсын, йөгерттереп кенә, — ди өлкән хезмәттәшем.

Ана җавап табарга өлгермим, директор, ана тагылып шофёры килеп керә. Күрешәбез.

— Эшләр кай тирәдә инде безнен? — дип кызыксына директор.

Хәлнен хөрт булуын анлатам һәм Фәйзи агай ярдәм итәргә алынса гына яктылык күренү мөмкинлеген төшендерәм.

— Дәет Дарифулыч, туктагыз әле. Бәлкем бу мәсьәләгә Рәхим Сабирычнын карашы бөтенләй үзгәдер?

— Шәхси шофёрымны утыртулары мина абруй өстәр дип уйлыйсызмы? Егетләр, пожалыста. Берни вәгъдә бирмим, ОБХСС кешеләреннән үзем дә шикләнәм. Ә сездән, Фәйзерахман абый, бигрәк тә. Сезне бит, артыгызда аты-юлы белән «туры фәлән» дип сүгәләр, хәтта абзарыгызнын стеналары да юкә кабыгыннан, шул кабыкларнын аскы, бер метр чамасы өлеше зәнгәргә буялган имеш. Дөресме? Бетермик егетне.

— Урамда торган йөк машинасыннан урлау бер нәрсә, ә биләмәгә үтеп кергән өчен закон каты. Тәк, энекәш... Кил әле монда. Утыр, директор абыен белән минем арага һәм борынына киртләп бар.

Мәсгуть, дер-дер килеп, күрсәтелгән урынга кысылды.

— Судта прокурор әйтер, энем бу бит ап-ак, дияр. Син дә анын ак икәнен күрерсен. Әмма, юк иптәш прокурор, бу кап-кара, дин. Чигенәсе түгел, анладынмы?

— Э-э.

— Синен яшь бәрәннәрен бармы?

— Ә? Нәрсә? Сарык бәрәннәреме? Өчәү.

— Яхшы. Судта болай сөйлисен: минем өч яшь бәрәнем бар. Аларга көн дә яшел үлән чабып алып кайтам. Шунын өчен кабинада кыска саплы чалгы йөртәм. Директор сүгә, машина утыргычын яшелләтәсен, ди. Шуннан мин үзем белән капчыклар йөртә башладым. Сизденме аерманы? Капчыкларны урлау нияте белән түгел, ә үлән тутыру өчен йөртә башладын. Директор сүккәнгә! Рәхим Сабирыч, сез дә анышып барасызмы?

— Таныйм, сүктем.

— Урып-җыю ничек барды быел? Комбайннар ватылып бик интектермәдеме?

— Һәй, Фәйзерахман туган. Ватылмаган кайларда... Берсе-бер калмый кырылган көннәр булды.

— Бик хуп. Энекәш, киртлә колагына. «Ул көнне без әбәд алдыннан басуга сугылдык. Бөтен комбайннар ватылып туктаган иде. Директор мина кайтып ашарга һәм зернотокка менеп күтәргә кушты. Үзе, комбайннар эшли башлагач, беренче олау белән кайтырмын, диде. Мин кайтып әбәдне ашагач, зернотокка машинам белән кереп, аны күләгә урынга куеп, көтәргә керештем». Анышып бак, бернинди үтеп керү юк, син директор кушканга кергәнсен!

— Мин куштым! — дип куя Рәхим Сабирович.

— Син кергәндә биләмә ачык булган. Эпи һаман кайтмагач, ындыр табагы эшчеләре өйләренә таралган. Ә син, урып-җыю вакытында рәтле йокы күрмәвен сәбәпле, мәмрәп йокыга талгансың. Уяндың, директорың һаман кайтмаган. Аннары анда куныл булмый ич, кайтырга җыендың. Ә бәкәйләргә печәнен чабылмаган. Капчыклар буш кайтмасын дип тоттың да көшелдән арпа тутырдың. Арпа авыр ул, күп кирә. Ну шуннан зерноток капкасына эленгән ялганчы йозакны алып куеп, чыгып киттең. Ул бикле түгел иде. Аның нинди икәнен хәзер эт тә исбат итә алмый.

— Мин бит тикшерүчегә бүтәнчә сөйләдем.

— Син ана русча беләм дип кул куйгансың. Ә судта, мин русча начар беләм, әрмиядә дә, Себердә дә йөреп кайткач, белмим дип әйтергә яхшысынмадым, тикшерүче кырыс иде, курыктым, һәр әйткәненә аңламыйча риза булып тордым һәм кул куйдым, дисең и прокурор күпме кысса да чигенмисең.

— Әле бит моның машинасы конфискациягә эләгә.

— Анысын болай. Мин үзем йөрткән совхоз машинасын үземнеке дип йөрим. Авылда да аны Мәсгуть машинасы, диләр. Аннары үз Жигулиемне җәлләмичә ничек аның белән йөк ташыйм, яңгырдан соң безнең урамга «Нива»сыз кереп тә булмый дисең һәм фәләненнән ассалар да сүзеннән кире чигенәсе түгел.

Бер ай чамасы вакыт үткәч, кабинет ишегемне кемдер кыюсыз гына шакый. Ачсам — Мәсгуть.

— Абый, суд булды, сез әйткәнчә 20% түләү ясадылар, инде мина нишлисе?

— Бар, бер ярты алып кил, Фәйзи агаеңны кичә генә майор дәрәҗәсенә күтәрделәр, котлыйк үзен.

Мәсгуть йөгерттереп кенә кирәк-яракны алып килде.

— Бүтән урлашып йөрмә, әнәнне эт җыккыры малай, — дияргә онытмады Фәйзи ага, кабарга дип печеньегә үрелгәндә.

## Честьне кайчан бирәсе?

Казаннан фәрман килеп төшкәч, өч айлык әзерлек курсларына китеп бардым. Производстводан милициягә рекрутланучылар байтак икән һәм һәммәсе дә диярлек буйчан, эре гәүдәлеләр. Кайчак шыкаеп та куям, бу әзмәверләр җәберли башласа нишләрмен, дим. Спортзалда дәресләр башлангач кына шик-шөһбәләрем җилгә очты. Байтак курсташлар бирелә дөм бөрешеп калды, кайсы-берсе турникта бердән артык тартыла алмый. Ә ике потлы гер хозурында иң тазаларның да әлләкем түгеллекләре фашланды. Мин уң кул белән унбиш, сулы белән уникене чөеп, герне идәнгә куйгач, башта аю гәүдәле Мәскәү асты урысы килеп арканы какты, тумышы белән Бөгелмәнеке булуы исенә төшкән:

— Молодец, земляк, татарча көрәш белән шөгыльләнгәнен әллә каян күренеп тора, — диде ул, һәркемгә ишетелерлек итеп. Аның артыннан Ульян ягыннан килгән мишәр егете дә шатлыгын белдереп,

— Рәхмәт, туган, нацию поддержал, — диде. Ә алдагы көндә генә шушы егет, аркама каяндыр йоккан тузанны кагып:

— Не позорь нацию, — дип киткән иде...

Ай ярым укыгач, кандидатлык срогым тулды һәм, өйгә кайтып, партиягә кереп килдем. Кайтышлый, райкомның пропаганда һәм агитация (коткы һәм үгет) бүлеге мөдире Фәләх абзый очрап, каян кайтуым белән кызыксынды:

— Хатының беләме кайтып килүеңне, телефоннан хәбәр бирдеңме? — дип кызыксынды.

— Юк, — дим. — Ара тар иде.

— Ялгыш эшлисең, егет, — ди бу ,көлсу бөдрә чәчле юка башын чайкаштырып.

— Әнә Сәгыйдулла да хәбәр итми-нитми кайтып кергән иде, неудобный положениедә калды... Алай ярамый, юл бүлегенә кереп булса да башта шалтырат, аннары өенә керерсен, — дип киңәш бирә бу авызын беткәнче ерып.

Менә укулар тәгәлләнде. Погонга тиешле йолдызлар да кунды. Октябрь бәйрәме көн, парад киемнәремне киеп, тәртип сакларга чыктым. Башлыгыбыз безне төрле урыннарга билгели, мин Фәйзи агай янәшәсенә туры килдем.

Октябрь бәйрәмен һәркайдагы кебек безнең райүзәктә дә матур уздыралар. Кызыл комачка төрелгән «ГАЗ-53» машинасы әржәсенә район житәкчеләре менеп баскан һәм Кызыл мәйдан хужаларыннан ким кыланмыйлар. Анда райком, райкомол сәркатипләре, военком, прокурор, судья һәм бер-ике гади хезмәт алдынгысы. Ә безнең башлыкны, яна гына бу вазифасында эшли башлаганга яшьсетеп микән, югарыга алдыруны әлегә зарур санамаганнар. Ул аста, әлеге «президиум» итәгендә басып тора һәм аның пеләшләнә башлаган башы тегеләрнең башмагы югарылыгында...

Котлаулар, матур теләкләргә кадәр гимн тынлыйсыбыз бар икән әле, аны мәктәп оркестры башкара булып чыкты. Күршем Фәйзи агайдан:

— Честь бирәбезме? — дип кызыксындым.

— Һи, Дәет, — диде Фәйзи агай һәм, трибунага ымлап. — Әнә аннан торып, матур гына честь биреп торсаң, алай начар чыкмас иде дә, ә биредә, ыгы-зыгы килгән гавәм арасында, терсәк тырпайтып... Хәер, үзенә кара.

Як-якка күз салам, начальниктан гайре беркем дә честь бирми. Ул, башын бормый гына безне барлый, гимнга хөрмәт күрсәтмәвебездән хәбәрдар. Әмма укучы малайларның гимнны, кайтарып-кайтарып, татарча бормалар кушып уйнаулары аның безгә ябырылуын тоткарлый. Ниһаять, көй төкәнде, башлыгыбыз йодрыкларын йомарлап, күзләрен шарландырып, безнең якка ыргылды һәм иң әүвәле мина акырынырга тотынды. Акланырга сәбәп тапмый, тик торам, башны аска иеп. Мине «урыныма» куйгач, чират Фәйзи агайга икән...

— Фәйзи Сәгыйтеч! Ярый, Мирзануров әле генә укып кайтты, ул белеп бетермәскә мөмкин, өлкән, акыллы остазга чутлап, сездән үрнәк ала торгандыр. Синең бит инде сыртың саргаеп беткән милициядә эшли-эшли. Син пачыму гимн уйнаганда честь бирмисен?!

— Гимн булды микәнни соң ул? — дип үтә гаҗәпләнгән кыяфәт чыгарды Фәйзи ага. — Мин бит аны татарча бию көе диебрәк тынлаган идем...

Марсель Гыйбатыч мондый җаваптан гаҗиз калып, ни диярга белми буылып торганда, безнең яннан җинаятьләр эзләү бүлеге оперативнигы Фәһим Рәшит улы узып бара иде.

— Фәһим!

— Тыңлыйм, иптәш начальник.

— Син нишләп честь бирмәдең?

— Честьне бит аны гимн уйнаганда гына бирәләр!

— Соң гимн уйналды бит?

— Гафу итегез, иптәш майор, мин ишетмәдем, — диде Фәһим, гөнаһсыз күзләрен мөлдерәтеп.

Начальник әле беребезне, әле икенчебезне утлы карашы белән «ашап» торды-торды да, кулын кисәк кенә селтәп, янибыздан китеп барды. Фәһим һәм Фәйзи агай, бер-берсенә көлемсерәгән караш ташлап, җилкәмнән кактылар:

— Үрәнерсең әле җавап бирергә, тормыш үрәтә ул, — диде Фәйзи агай, Фәһим янибыздан китеп баргач. — Күрдеңме уголовный розыск хезмәткәрен. Боларның «исәнме» дигәненә дә ышанырга ярамый... Настаяшшый опер!

Мин тирән итеп сулап куйдым.

— Кая, кемнәр арасына эләктем бит, шайтан алгыры...

## Участковый Илсур

Илсур — чибәр милиционер. Үзешчән сәнгать йолдызы. Милли киемдә оча-оча «һавадан чирәм йолкып» кем бии дисәгез, ул булыр. Бер дигән спортчы. Баскан урынында мәталчек ясый торганы. Көләч йөзле булгангамы, аны бөтен кеше ярата. Әмма кайчагында онытылып китә, «салгалый» торган гадәте бар. Сүккәнне бер дә күтәрми. Бүлегебез башлыгын бермәлне чак кына тәрәзәдән ыргытмаган, ярты гәүдәсе тышкы якка чыгып асылынган булган, имеш. Әлбәттә, түрәбез теләнә хужа булмаган, Илсурның канын катырырдай нәрсәләр ычкындырган күрәсең, ә ул саф күңелле, ихлас зат, теләсә нәрсә әйткәнне йотып барырга күнекмәгән. Инде эше буенча гаепләп, «соңгы вакытта исерекләргә беркетмәләр төземисең», дип каезлый башласалар, үзе белән бергә сыйланган «иптәшләрен» дә аямый, «кер, алкаш!» дип, сугә-сугә бүлеккә алып кайта һәм протокол төзеп, айнытып, өйләренә озата.

Илсур биләмәсенә бару чираты житте. Ул мине «чик буенда» каршы алды һәм моның белән икәү, узган-барган машиналарны туктаткалап, тикшергәләргә керештек. Гаеп тапсак та, эшне артык катлауландырмыйча, кисәтү белән генә чикләнәбез. Ул да булмады, Илсур катында әллә ничә егет кайнаша башлады: кайсы безгә эштә булыша, ә кайсылар юлдан ерак түгел елга буенда шашлык пешерә, бүтән сый-хөрмәтне кайгырта. Мин Илсурдан:

— Болар кем соң? — дип кызыксынам.

Ә ул канәгать кыяфәттә, елмаеп-балкып:

— Болар минем правый рукалар! — дип белдерә.

Баксаң, ярдәмчеләребез шушы тирә колхоз-совхозның урта буын белгечләре икән.

Илсурның хатыны күз явын алырлык чибәр иде. Моңа прокурор урынбасары да игътибар иткән, ничектер жаен туры китереп:

— Син интегәсең бер исерек белән, мин туры киллем бер жәфага, әйдә болардан арыныйк та, китик минем белән Чаллыга, эш тә, фатир да хәл ителә, — дигән.

Әмма хатынның күңеле эремәгән, арада булган сөйләшүне Илсурга тишкән.

...Илсур ул көнне туган көне уңаеннан бераз ял итәргә дип күл буена дәшкән иде. «Правый рукалар» һәм аны якын иткән хезмәттәшләре учак янына жыелыштык. Ә дустыбыз юк та юк. Менә бер мәлне иске ак Жигули күренде. Илсур машинасыннан төшеп, елмаеп-балкып, барыбыз белән дә күрешеп чыкты. Кабинада арткы рәттә утырган танышыбызга сәлам бирмәкче идек.

— Егетләр, хайван ул, — дип дустыбыз тегенең ягына терсәге белән кизәнгән хәрәкәт ясап алды, — утыр урынында гына! — дип жикерде.

Булачак прокурор шыпырт кына сенеп кабинада кала, ә без мәжлесне башлап жибәрәбез.

Бераздан Илсурдан көндәшен гафу итүен сорыйбыз.

— Әйбәт кешеләр сез, бөтенегез дә, — ди Илсур. — Ну фәләнемне дә аңламыйсыз. Ярар, кайтканда өе янында калдырырбыз, утырсын әле без ашаган-эчкән чакта төкереген йотып. Жәза шул ана...

## Сафин

Милициягә эшкә кеше кодалау ай-һай кыен иде ул елларда. Әйтик, юл хәвефсезлеге буенча хезмәткәребез Хәким күрше районныкы, алты ел элек безгә кунакка килгән жиреннән жирле егетләр белән кызлар өчен сугышып китеп, милициягә эләккән. Ә начальник өстәлендә милиция уку йортына озату таләбе язылган хат ята. Моңа әйтә шеф:

— Яки эш кузгатабыз, яки укырга китәсең.

Бу укырга китә. Инде менә, кайтып, юлларда тәртип саклый.

Спорт буенча техникум тәмамлаган Сафин Әнвәр исемле егетне гади милиционер сыйфатында эшкә алган идек, бик тиздән бу кешегә конвоир вазифасын тапшырып булмавы ачыкланды. Ул кушылган эшне оныта икән. Начальник әлеге хәлдән чыгуның оригиналь юлын тапты.

— Әйдә без моны дежур-офицер итеп күтәрик, кырыенда акыллы сержант булганда, бәлкем өч көнгә бер кизү бүлегендә зарар салмый утыра алыр? —диде ул пеләшен сыпырыштырып...

Кайвакыт, хезмәткәрләргә пистолет бирүне чикләү турында югарыдан фәрман килә. Башлык урынбасары Сафинны фәрман белән таныштыра. Ул да булмый, Чаллыдан нindидер хулиганнар төркеме кайсыдыр авылга килүе хакында хәбәр алына. Инде урынбасар Сафинга шунда барачак хезмәткәрләргә пистолет бирергә куша. Сафин кушканны үтәүдән баш тарта, кемдер бирмәскә кушты, кем икәнен оныттым, — ди.

— Соң, мин кушкан идем бит, — дип өзгәләнә урынбасар.

Сафин ышанып бетми, начальник әйтмичә биреп булмый, — ди.

Теге тузына башлагач «сына».

— Сез замнач, ә мин бәләкәй кеше, ул-бу булса, сезгә җавап бирәсе, миңа түгел, — дип кораллар бүлмәсенә кереп китә.

Бер елны Бөгелмә төрмәсеннән зеклар качуы, шуларның берсе, безнең район кешесе булуы хакында хәбәр алынды. Тиз арада төркем оештырып, әлеге качкынның авылы башына поскын куйдык. Ягъни иске Жигули кабинасында өч хезмәткәребез гражданский киемдә сыйланган кыяфәттә юл уртасында «ял итә». Төне буе утырып чыксалар да, теге качкын авылына кайтмаган. Ә участковый Сәгыйть, эч пошканнан пистолеты белән уйный торгач, «уймак чыккан», кабинада ату тавышы яңгыраган. Пуля уйнаучының учын тишкән, ә сержант Хөснетдиновның беләген сыдырып узган. Табиблар тиешле ярдәм күрсәтте, берсенә дә гариплек янамый дип тынычландырдылар, әмма бу хакта министрлыкта белсәләр безнең баштан сыйпамаячаклар иде. Мин яралanучыларның өйләренә юл тоттым. Сәгыйть хатыны хәбәрне тыныч кабул итте, ә Хөснетдиновныкы акырып елап ук җибәрде.

— Хатының сине бик ярата ахры? — дигәнемә Хөснетдинов:

— Яратмаска. Бер кич тә борчымый калмыйм бит мин аны, — дип мактанды.

Эшебезне тикшерергә тиздән комиссия киләсе иде, инцедентны йомдык, югарыга җиткермәдек. Егетләрнең яралары тиз төзәлде, ә Сәгыйть йодрыгы ныклыгын сынап карарга да өлгерде...

Көзге пычрак вакыт иде. Бик хөрмәтле укытучы апаны Жигулига утырган егет аламасы баштан-аяк пычрак белән коендырып узып киткән. Моны күреп торган Сәгыйть тиз генә матаена атланып тегене эзәрлекләгән һәм каршына чыгып, юл читенә кысып туктаткан. Янәшәдә беркем юклыктан файдаланып, кабинасыннан чыгарга кыймыйчамы, иренепме утырган егетне тартып алган да, сулагайлап колак төбенә сылаган.

— Аңладыңмы нәрсә өчен икәнен?

— Аңладым.

— Син әле минем өстән жалоба юлларсыңмы?

— Юк, абый, юлламам.

— Алайса, бар ычкын, карабрак йөр, әгәр тагын бер тапкыр берәрсен коендырсаң, болай ансат котыла алмыйсың!

Бу кыланмышы өчен начальник нык орышты Сәгыйтьне. Кул озайту аркасында бүлегебез элегрәк ике тәҗрибәле хезмәткәрен югалткан булган инде, шуны искә алды. Прокуратура бик тырышкан егетләребезне батырырга.

Баксан, нәкъ шуларның берсе прокуратура тикшерүчесен броконьерлыкта шик астына алып, кешесен әйтми генә, атылган пошы факты унаеннан җинаять эше кузгаткан булган. Арага райком җитәкчесе кереп, эшне йомарга куша. Ә тегеләр үч саклаган, форсат чыгу белән эш кузгатып, аны күрше районга биргәннәр, ә болары калага ук күчереп арканлауга ирешкәннәр. Һәм бу юлы райком секретаре берни кыра алмаган, егетләребезне хөкемгә тартканнар...

...Менә комиссия килде, эшләребезне тикшерде. Спорт ярышлары уздырып, тиешле нормативларны да үтәдек. Башлыгыбыз боларга көн дә сыйхөрмәт оештырды: балыгын да тоттылар, шашлыгын да куырып кимерделәр. Тикшерүнен сонында кызыл почмакка җыелдык. Комиссия рәисе эшләребездән канәгать икән, кайбер хезмәткәрләребезне мактады да. Шулай матур гына утырганда кинәт ату тавышы яңгырамасынмы?!. Начальник, үткен кеше,

— Кизү бүлегендә сейф ауды. Күчерергә кушкан идем, — дип аңлатма бирде.

Рәис монын белән килеште күрәсең, сүзен дәвам итте. Әмма кинәт ишек ачылып, анда йөзе ап-ак булган Сафин күренде.

— Әнә, — диде ул, шомлы тавыш белән. — Теге дурагыгыз тагы атты!

Баксаң бүлектә кизү ярдәмчесе булып утырган Сәгыйть янә пистолеты белән шаярган. Бәхетенә, бу юлы һичкем яра алмаган.

— Ничек тагы атты? Монарчы кайда аткан иде ул?

Һәм комиссия рәисе без йомганны ансат кына казып чыгарды.

Нәтиҗәдә, башлыгыбыз әлеге «кунакларны» тагын бер көн сыйларга мәҗбүр булды. Ходай саклады, тикшерүчеләр юньле егетләр булып чыкты, эшне олыга җибәрмәделәр.

## Профилактика

Тикшерүче Хәлил белән ОБХСС инспекторы Фәйзи агай, әлеге дә баягы сарыга буялган Урал матаена утырып, каяндыр кайтып барганда, арбасына азык чөгендере төягән «Белорусь» тракторы очрый...

— Кая аппара бу чөгендерне? — дип аптырый Фәйзи агай. — Бу якта ферма фәлән юк, ә халыкка әле берни дә өләшенмәде, тукта, бу бит теге атаклы звеновод Илдар Билалов.

— Билалов бугай шул, — дип килешә Хәлил. — Быел да узган елгы кадәр уныш алсан, сиңа бүләккә җинел машина — «Москвич» бирәбез дип беренче секретарь уныш бәйрәмендә шушыны котлады бит инде.

— Үзе үстерә. Колхозныкы булса да үзенеке саный инде ул чөгендерне.

— Әйдә туктатабыз.

Һәм Хәлил, ГАИ хезмәткәрләреннән алып торган таягын болгап, Билаловка туктарга боера. Билалов, шактый ара китеп туктый, иренеп кенә кабинасыннан төшә?

— Нәмәгә кирәк булдым апайлар?

— Кая алып барасың чөгендерне?

— Өйгә.

— Колхоздан сатып алганга язуың бармы?

— Пред рөхсәт итә, мин бит көне-төне гел шушы эштә, үз хуҗалыгым дип бүленә алмыйм. Первый үзе әйткән, бөтен шартларны тудырыгыз дип.

— Хәзер барабыз да чөгендеренне үлчәү аша уздырып, силос чокыры янында бушатабыз.

— Сез үзегезне кем дип беллегез соң. Мин хәзер Исмәгыйль Вәлиевичкә шалтыратам. Ул сезгә эш кешесеннән көләргә ярамаганын тиз төшендерер.

— Ә безгә ул карак тотарга, чөгендерне, икмәкне саклауны йөкләде. Рәхим ит, шалтыратырсын, авто-үлчәгечегездә телефон бар ич сезнен.

Агай, үлчәнергә кергәч, телефон аша «беренче»не эзләп карый, әмма тегесе ашыгыч рәвештә Казанга киткән икән, ә бу форма кигән кешеләр аның китүеннән хәбәрдар ахры, каһәр суккырлары, әшәке итеп тәк елмаялар.

Нәтиҗәдә, чөгендерне үлчәтеп кире тапшырталар, аннары колхоз бухгалтериясенә кереп, касса кенәгәсен күтәртеп, агайдан акча кермәвен тәгаенлиләр, акт төзиләр һәм әле генә рекорд уныш үстерәм дип канатланып йөргән колхозчыны, хезмәт кешесен милиция бүлегенә алып кайтып, камерага ябып куялар. Кылынган җинаяте унаеннан Җамалыев эш кузгата да Бөгелмәгә шалтыратып, агайны шундагы КПЗга озату хәстәрен күрә, вазифалы сабакташыннан «бүген алып китмәсәгез, первый кайту белән азат итеп, эшемне бракка чыгара, зинһар булыш», ди.

Бер атнадан агайны алып кайталар, ә эше инде судта. Моны, сүз чынлыгы өчен нәни генә җәза билгеләп суд залында ук азат итәләр.

Фәйзи агай белән бергә шул колхозның рәисенә колхоз бәясеннән бал сорап барган идек. Рәис, план үтәү зарурлыгы аркасында бераз шикәр комы өстәгән идек дип боргаланды. Фәйзи агай папкасыннан химик карандаш алып, балга манды, язып карады, «бер утыз проносит томыргансыз икән», диде. Баксаң, бал саф булса, каләм үзеге җебеп, кәгазьгә буяу таралмый икән.

Менә шул балны алып, кассага акча түләгәч, колхоз рәисе белән бераз гәпләшеп алдык. Теге агайга вәгъдә ителгән бүләк бирелмәгән. Үзе исә, бер атна югалып торган җиреннән кайткач:

— Миңа чылбырлы трактор бир, балчык урламам әле, — дигән. — Камерада утырганда ике яшүсмер белән туры килүен, үзен төрлечә каһәрләүләрен сөйләгән. Иртән торуга моңа әле берсе, әле икенчесе атланып ала да касыгына тибә-тибә чаптыралар, ара-тирә фәлән тукталыш, төгән тукталыш дип әйттерәләр икән. Арып егылгач та тынычлыкта калдырмаганнар, мәлгуньнәр...

— Тәҗрибә юклык. Әгәр тукталыш исемен әйткәч кәничний дисә, ул уенны туктаткан булырлар иде, — дип куйды Фәйзи ага.

— Их, Фәйзи ага... Менә сезнең тырышлык нәтиҗәсе...

— Алай димә, Дәет Дарифулыч, — диде Фәйзи агай каударланып. — Бу настаяшший прафилактика. Урлашмагыз дип лекция уку чепуха ул, аннан бер файда да юк. Ә монда безгә бер-ике ел килми йөрсәк тә була хәзер.

## Башын да ашыйбыз, ашын да

Минем Фәрих атлы дусны баш инженерлыктан башлык итеп күтәрделәр. Озак та үтми моның өстеннән шикаятьләр яварга тотынды. Шул шалтырата:

— Бүген кич, эшеннән кайтышлый кагыл әле, — ди.

Барып керсәм, дус табын әзерләгән, матур гына сыйланып утыралар. Фәрих кызып ук алган:

— Урлавын урладым, әмма тота алмыйсың, койрыкларым җыелган минем, — дип шапырына. Мине күреп алгач:

— Ооо, нинди кешеләр! Әйдүк, түрдән уз, — дип кыстарга керешә.

Мәҗлесне өчәүләп дәвам итәбез.

Ике көн узгач, Фәрих тагын шалтырата:

— Теге мәлгунь, бер көн калмый сыйлавыма да карамастан, һаман казына, — дип зарлана.

Иртәгесен Фәйзи агадан сораштырам:

— Йә, эшләр ничек. Алай көн дә кунак булгач, һаман актарыну кыен түгелме?

— Кайгырма, Дәет Дарифулыч! — дип тынычландыра хезмәттәшем. — Ашын да ашыйбыз без аның. Башын да!

## Кавказ эзе

Таң тишегеннән кизү бүлеге хәбәр ала, «төн уртасында «Алексеевский» совхозы идарәсе бинасындагы касса бүлмәсен басканнар, тимер идәнгә эретеп ябыштырып беркетелгән сейфны кубарып алып чыгып киткәннәр».

Сәгать үттеме икән, барча хезмәткәрләр «кызыл почмак» атлы, стена буйлап Брежнев һәм башка Политбюро әгъзалары портретлары урнашкан җыелышлар залында утыра идек инде. Болай да бәләкәй буйлы башлыгыбыз Марсель Гыйбатыч тагын да кечерәеп калган. Биш минут саен министрлыкның төрле бүлекләреннән шалтыратып:

— Җинаятьне ачтыгызмы әле, нинди чаралар күрдегез, нинди версияләр калкыттыгыз, — дип йөдәтеп бетергәннәр.

Безгә ярдәмгә политбүлектән бер хезмәткәр киләчәк, аны аэропортта каршыларга тиешбез икән. Җыелдык, сөйләштек, таңда ук җинаять кылынган урынга укталган оператив төркем кайтып җитеп, аның җитәкчесе Хәлил Әмиреч хәлгә ачыклык кертте:

— Йөз мең сум эш хакы кайтасы булган, әмма банкта акча җитмәү сәбәпле, буш борылганнар. Сейфта ун мең сум тирәсе акча сакланган (заманы өчен зур сумма). Җинаятьчеләрнең акча кайтудан хәбәрдар булулары, хәл үзгәрүен искәрергә өлгермәүләре мөмкин. Сейфны кубарганда каравылчы урында булмаган, көндәгечә чәй эчәргә кайтып киткән. Әле ярый киткән, безгә мәет кенә җитми иде. Каравылчы һәм кассир безнең белән кайтты, алар белән Фәһим Рәшитеч шөгыльләнә. Сейф авыр, өч, яки дүрт кеше күтәреп алып чыккан булырга тиеш. Идарә янында туктап торган ике тәгәрмәч эзен гипс ярдәмендә төшереп алып кайттык. Эзләр комбайн тәгәрмәченеке булып чыкты. Совхоз механигы, «Нива»га да шундый тәгәрмәчләрне куйгалыйлар, ди. ГАИ егетләре районндагы комбайн тәгәрмәче куйган «Нива»ларны барлый башлады. Күрше районнар белән әлегә элемтәгә чыкмадык.

Икенче көнне политбүлектән Мәмлиев Әнвәр Зиннурович атлы капитан килеп төште. Элегрәк комсомол комитетында эшләгән, өстенә бер җаваплылык та алмый, кирәкмәгән төшкә кысылмый, гомуми сүзләр белән генә сөйләшә торган, шома битле чибәр кеше икән. Кичен янә «кызыл почмак»та җыелдык. Мактаныр нәрсә юк иде. Беркемнән төпле сүз яки тәкъдим ишетелмәгәч, мөнбәргә башлыгыбыз Марсель Гыйбатыч чыгып басты.

— Менә өч көн чабабыз, оперативниклар йокыны онытты, тикшерүче кабинетында йоклый, ә җинаять ачылмый. Политотделдан кеше ебәрделәр, ә толк юк. Менә Фәйзи абый син бередә иң өлкән кеше, милициядә эшли-эшли сыртың саргаеп беткән, ать (Гыйбатыч дулкынланганда үзенең мишәрчәсенә күчә иде), күзгә бәреп ать, мин кайда ялгышам и нәрсә эшләп җиткермибез?

Фәйзи агай урыныннан торды һәм бер авык гадәтенчә уйланып, дәшми торды. Аннары тамак кырды һәм сөйләргә кереште:

— Марсил Гыйбатыч, иң элек сезнең политбүлектән кеше килүдән файда юк дигән сүзегез белән килешмәскә рөхсәт итегез. Бик толковый иптәш килде. Төрлесен күргән бар, Казаннан килеп, эшкә аяк чалып, югары җитәкчелектә безгә карата тискәре мөнәсәбәт тудырып, бутап йөрүчеләрне дә күргән булды служба дәверендә.

— Сез хаклы, иптәш партия оешмасы секретаре. Әмма ары таба сүзенне милиция майоры буларак дәвам итсәң иде.

— Әйтәм. Әгәр бу эш артыннан опергруппа гына йөрсә, эш чыкмаячак. Чөнки җинаятьчеләр тәҗрибәле, паспортларын төшереп калдырмаганнар. Хәзер уголовный розыск егетләренә тегеләр калдырган тәгәрмәч эзенә термометр куеп карап, эзләр суынган икән дип әйтергә генә калган.

— Фәйзи агай, син әллә кая кереп киттен түгелме?

— Хәзер, иптәш начальник, әз генә сабыр итегез. Әмма җинаятьне ачып була!

— Менә шуны сөйлә син.

— Була. Тик бу эштән беребез дә читтә калмаска тиеш. «Мин балалар белән эшлим», «минем эш паспорт тикшерү», «мин янгынга каршы көрәшәм»нәр булмаска тиеш. Барыбызнын да конкрет эше бар. Хәзер һәркемгә берәр авылны бүлеп бирәбез, һәм барыбыз да урыннарга барып һәр кешедән рәсми кәгазь тутырып аңлатма алабыз. Кәгазь боткасы алдашулар булмасын өчен кирәк. Шунсыз булмый, чөнки барыбыз да юрист, алдашырга өйрәтәсе юк, һәммәбез дә һушлы, сораштым, нәтиҗә юк дип рапорт сырлап котылу бер нәрсә, ә бер пачка аңлатма төяп кайту буладыр чын эш. Иманым камил, әгәр райондагы һәр кешене сорашып чыксак, нәтиҗә булмый калмас, бер йә ике шаһит тапмый калмабыз.

Марсель Гыйбатовичнын карангы чырае яктырып китте һәм ул:

— Фәйзи ага тәҗрибәле кадр, дөрес сукалый, хәзер Хәлил Әмиреч һәммәгезгә эшне бүлеп бирә, сезгә вакыт бер тәүлек, иртәгә шушында төштән сон җыелабыз, «вакыт китте», — диде.

Әлеге «җәтмә салып сөзү ысулы» нәтиҗә бирде, шул төнне, дөресрәге тан алдыннан мәхәббәттә аңлашып авыллары урамыннан йөрүче кыз белән егетне бәрдерә язып ак «Нива» узып киткән.

— Машина тулы кеше иде, йөкләре авыр булгандыр, күпергә кергәндә юл чокырына төбе бәрелеп алды, — дигән күрсәтмә бирде гашыйк егет.

Мондый мәгълүматтан сон янәшә-тирә райондагы ак төстәге «Нива»ларны барларга керештеләр һәм күрше районда җылы яктан килгән шабашчыларнын да ак «Нива»лары барлыгы ачыкланды, җитмәсә ике тәгәрмәче комбайнныкы. Чагыштыру нәтиҗәсендә гипста сакланган эзләге һәм әлеге тәгәрмәчләрдәге аерымлыклар шактый охшаш булып чыкты. Шабашниклар туганнар иде, «берсен кулга алсак җитеп торыр, болар бер-берсен калдырып кача торган халык түгел», — дигән фикерне Хәлил Әмиреч әйтте. Әмма Казан белән киңәшкәч, икесен кулга алу хакында карар чыгарды. Кулга алынучыларнын яшьрәге, Муса исемлесе, озын буйлы, гел мускул һәм сеңгердән торган егет ярты кирпеч салып корылган утын сараебыз дивары янынннан үтешли кинәт сикереп тибеп куйды һәм җимереп төшерде. Кизү бүлмәсендә дә капылт сикереш ясап түшәмгә туфлие эзен калдырып, һәммәбезне шаккатырды. Конвоир сержантлар моны саклап йөрткәндә кобурада көнбагыш түгел, ә Макар пистолеты булырга тиешлеген төшенеп, көрсенделәр...

Сорау алулар нәтиҗә бирмәде. Берсен Казанга алып китеп карадылар. Тик болар сүзләреннән чигенмиләр, сейф турында берни белмиләр, ә кайдадыр тәгәрмәч эзе калдыруларын расламыйлар һәм кире дә какмыйлар. Имеш Муса «Нива» белән авыллар аша йөргәләгән. Рульдә йөрергә өйрәнү өчен төнне сайлаган. Осталыгы чамалы булу сәбәпле як-ягына бик игътибар итмәгән, күбрәк юлны күзәткән.

Казанлылар да эш чыгара алмагач, башлыгыбызга:

— Сейфны эзләгез. Сейф табылмаса боларны азат итәсе була, — дигәннәр.

Тагын «кызыл почмак»ка җыелдык. Башлыгыбыз бу юлы да акыл эстәп Фәйзи агайга мөрәҗәгать итте.

— Йә, Фәйзи абый, инде нәрсә дисен? Чыгарып җибәрәбезме җинаятьчеләрне, гафу үтенеп?

— Андый нәрсә булырга тиеш түгел.

— Ә сейфны каян табабыз сон?

— Сон аны болар әллә кая куймаган, суга томырган инде.

Паспорт өстәле башлыгы капитан Фарук Зиннәтовнын чәрелдек тавышы яңгырады:

— Җәмәгать, сизәсезме, Фәйзи агай бөтенесен дә белә! Үзе катнашкан ул сейфны урлаганда!

Марсель Гыйбатыч дөртләп кабынып китте һәм Зиннәтовны «матур» сүзләрне мул кулланып сүгеп ыргытты. Фәйзи агай исә башлыкның тынычланганын сабыр гына көтеп алды.

— Һе, суга ташлаганнар, — дип авыр сулады Гыйбатыч. — Бездә бит судан күп нәрсә юк, күлләр, буалар, житмәсә «Ык».

— Иптәш начальник, болар моны буага да, күлгә дә илтми, чөнки сейф әкәмәт зур, яр кырыеннан ташлый башласаң, күренеп, чыгып калырга мөмкин. Болар моны «Ык»ка томырган.

— «Ык» та озын бит.

— Ярдан төшерсәләр шулай ук чыгып кала торган була. Күпердән аткан булырга тиешләр, ә алар бездә ике.

— Ике шул.

— Анын берсе әнә генә. Анда өзлексез машина йөреп тора. Җәяүлеләр дә тик тотмый. Ә Сагындык авылы янындагысы аулак, агачтан ясалган, тәбәнәк. Болар бит безнен районга шул күпер аша килгән булырга кирәк. «Ык»нын агымы көчле, астанрак әзлисе булыр дип чамалыйм.

Икенче көн әбәд вакыты җиткәндәрәк әлеге күпердән егерме метр чамасы аста эзләгән сейф табылды һәм анын эченнән бер эшченең ертык иске киеме, ә киеме кесәсеннән шабашчыларнын адресы, исем-фамилиясе язылган конверт һәм хат та табылды. Дөрес, бераз җебегән иде алар, әмма экспертлар укырлык иде.

Хәлил Әмиреч, судья белән прокурорны йә сатып алулары, йә куркытулары мөмкин, җинаятьче өендә тентү узмауны сылтаулап, эшне кире бормасыннар өчен кемгәдер анда барып, формаль булса да тентү ясап кайту кирәк дип беллерде. Фәһим, тиз арада шул төбәкне урап, шәпләп кунак иткәннәр үзен, алар бер дигән халык, дип кайтты.

Эш судтан шома узсын өчен шаһит булуы отышлы, дип Хәлил янә үз линиясен бөкте. Һәм Мусаны бар гаепне үз өстенә алырга, ә туганнан туган абыйсын шаһитлык итәргә күндерде.

— Ике кеше төркем чутлана, төркем белән китсәгез срок күбрәк эләгә, болай син ансатрак котыласын. Аннары син яшь, таза, авырлыкларга түзәрлегең бар, ә абыен кайта да алмаска мөмкин, — дип инандырган ул аны.

Муса, берсүзсез ризалашкан һәм җинаять эше суд аша, Хәлил теләгәнчә, терекөмеш кебек тәгәрәп үтте. Дөрес, тикшерүче, шабашчылар белән башка шартларда вәгъдәләшкән диючеләр дә булды. Хәер, тел ни сөйләмәс.

Ә эшнен уңышлы төгәлләнүе унаеннан макталуга һәм бүләкләнүгә лаек хезмәткәрләрне тәгаенләгән хатны мин әзерләдем һәм имза салдыру өчен башлыгыбызга алып кердем. Гыйбатыч, иртәгә Казанга үзем барам дип алып калды. Катлаулы җинаять ачу өчен ярдәмгә җибәрелгән Мәмлиев тә искә алынган иде хатта. Озак та үтми министрлыктан приказ кайтты.

Барыбызны да зурлаган министр. Тик нигәдер Фәйзи агай гына онытылып калган. Күрәсен, акыллы кинәшләре белән коллектив алдында унайсыз хәлдә калдыруын Гыйбатыч гафу итмәгән, фамилиясен сызып аткан...

## Халык үч алучысы

Фәйзи абыйнын кабинеты ифрат тар, Достоевскийнын мәшһүр романында тасвирланган, табутка охшаш Раскольников фатирын хәтерләтә. Анда бер тимер сейф, бер өстәл һәм анын баш башына ике урындык сыйган. Тагын бер урындык өченче кеше өчен, анысы ишек катында.

— Кемнедер көтәсез ахры.

— Әнә кереп килә, — ди Фәйзи агай тәрәзәдән тышка ымлап. Мин сине хәзер бер дус белән таныштырам. Сина да Дәет Дарифулыч киләчәктә андый дусларның кирәге чыгар дип уйлыйм. Бу настоящший опер. Халык оперы...

Капылт ачылган ишектән базык гәүдәле, бөдрә чәчләренә көмеш йөгергән мөлаем йөзле ир кеше килеп керде.

— Шакып тормаган өчен гафу итегез, эш сәгатендә кәрт сугып ятмыйсызмы дип тикшерәсе иттем, сездәге кайбер сотрудниклар, бикләнеп шул уен белән мавыгалар, дип ишеткән бар. Исәнмесез?!

— Гомерең озын булыр, Габделхак, синең хакта сөйләшә идек, бу безнең яңа зам — Дәет Дарифулыч.

— Бик әйбәт. Менә синең өстән шикаятемне белдерим әле үзенә. Фәйзи картайды. Мин язганнарны рәтләп тикшерми, һәм хөрдәләп кенә җавап бирә. Түгәрәкләндермә күзләреңне, район башлыкларының Башкортстаннан май ташып, районның сөт планын үтәүләре хакында әйтүем. Куркасыз. Куркасыз егетләр беренче секретарьдан. Ә үзегез коммунистлар.

— Синең мөмкинлекләр бер, безнеке — икенче. Фәләнкем әйтте дә, факт расланды дип нәтиҗә ясап булмый. Аннары синең жалобаң мина килеп җиткәнче итәк-җиңне җыештырырлык вакыт үтә.

— Сезнең хәлне дә аңлыйм. Фәйзи, әйт, тагын каян ташый алар ак майны, сөт планы һаман үтәлә бит. Ә Башкортстанга чыгып йөрүләр, минем сигналдан соң чикләнде кебек.

— Шуны да белмисеңме? Чаллы ягында, «Круглое Поле»дәге склад белән элемтә урнаштырдылар...

— Алайса шунда барып бер засада оештырмый булмас. Фотога төшерәм үзләрен. Ә син, төлке, тикмәгә генә ычкындырмадың бу информацияне... Первыйны минем һөҗүм астында калдырып, берәр эре балык каптырырга җыенасың ахры? Прокурор яшь, яна кеше, артык басым ясый алмый билгеле...

— Син аның белән таныштыңдамы? Әллә өстәл дә суктың?

— Сайлаулардан соң кереп чыктым. Өстәленә дә суктым.

— Сарык булып яшәмим, арыслан булып үләм диден инде?..

— Әйттем кәнишне. Энекәш, минәйтәм, син яшь кеше. Хезмәтеңне хыянәттән башлама. Узган атнада безнең сайлау участогында закон боздылар, кузгат эш, менә сина минем исемнән гариза! — Абый, аңлатып сөйләче, — ди бу, йомшара башлап.

— Безнең участокта сайлауларда «беренче»гә 100% тавыш бирелде дип район газете язып чыкты. Менә гәҗит! — дим. — Шуннан ни? — ди бу. — Мин һәм гаиләм каршы тавыш бирдек, минәйтәм.

— Сайлау комиссиясе эшендә хилафлык тапмыйм. Бәлкем сез хәзер генә шулай тыпырчынасыздыр? — дип карыша прокурорым.

— Комиссиядә минем алдынгы комбайнчы улым утырды. Кыскасы, безнең участок рәисе районныкына шалтыратып: «Бездә ЧП, первыйга алты кеше каршы тавыш биргән», — дип әйтә. Ә «беренче»нең алтылы чыбыгы Дифгать Сираевның коты ботына төшә, артык бюллетеньнәр бармы, — дип сорый. Бар, ди рәис. Сал шуларны. Ә бозыкларын яндыр, юк ит, ди.

Агаебыз үзе сөйләгәннәренең эффектын чамалар өчен әле мина, әле Фәйзи абыйга текәп карый һәм дәвам итә:

— Менә шундый хәлләр, Фәйзерахман. Прокуратурадан чыккач, шул тирәдәге каен ышыгына посып торам. Ярты минут та үтмәде, закон сакчысы атылып чыкты, як-ягына каранды һәм райкомга төбәп йөгерде.

— Синең шикаятең буенча эш ачылмаячак, — диде Фәйзи агай көлемсерәп.

— Бигрәк тә шәп. Мина Үзәк Комитетка язар өчен җай ачыла. Бар бит КПСС Үзәк Комитетының «Гражданнарның хатларына, үтенечләренә игътибарлы мөнәсәбәт» турындагы карары. Шуның нигезендә мин теләсә кайсы инстанциягә хат язам һәм алар миңа мәгълүм срокларда җавап бирергә тиешләр, кулларын «по швам» куеп, мина Хөрмәтле Фәлән Фәләнеч дип, түбәнчелек белән...

## ГКЧПга алхәбәр

Телефон шалтырый. Райкомның хокук органнары белән эшләү йөкләтелгән инструкторы Гуляемжанов кушаматлы Мөнәвир Гыйлемҗанов икән.

— Карале Зәет, әле генә сыра кайткан. Синсез арткы ишектән кереп булмый. Тимерҗан абыйның да бик барасы килә, бәлкем шул тарафка шуышырбыз?

— КПСС карарына каршы чыгу булмасмы соң? Хәмер эчәргә ярамый бит халыкка. Ә коммунистларга бигрәк тә. Указда, беләсеңме, ни дип әйтелгән?

— Ташла әле юләр сатуыңны. Әйт, барабызмы, юкмы?

— Фәйзи абыйны ияртүгә каршы түгелсездер бит, арт ишекләрне ул тагын да ансат үтә.

— Сез икенче каттан төшеп, урамга чыкканчы, без килеп җиткән булабыз!

Хактан да, киенеп урамга чыксам, Мөнәвир белән Тимерҗан абый килеп баскан. Тәмам сусаганнар, коргаксыганнар ахры.

— Сәлам!

— Сәлам! Кая Фәйзи абый?

— Әз генә сабыр итик, хәзер чыгып җитәр.

— Уф, егетләр, сезгә ияргән мин карт җүләр. Эш сәгатендә сыраханәгә баруыбыз Сәет Хәйриевичкә ишетелсә, бетте баш.

Көн төшкә авышкан, карангылы-яктылы мәл, һәм ябалак-ябалак кар ява. Урам уртасыннан ике исерек бара. Кочакланышканнар, авырдан атлыйлар. Минем формадан икәнне дә аңларлык хәлдә түгелләр. Безнең яннан узып, бераз киткәч, тазарак гәүдәлесе кырт туктый. Ә юкасы әлеге көтелмәгән манёвр нәтиҗәсендә сөрлегеп тезләнә һәм, ташбакага охшап, аркасына әйләнә. Әмма хәле бар икән әле, ничек кирәк, алай аяклана.

— Апайлар, бу Болынкырмы? — дип сорый тазарагы.

— Әйе.

— Әйттем бит, — ди бу, юлдашына терсәге белән кизәнеп. Ә тегесе дәшми.

Болар юлларын дәвам итәләр, әмма базык гәүдәле кабат туктап, юкасы кабат карда аунап ала.

— Иртәме, кичме?

— Кич.

— Әйттем бит! — ди базык гәүдәле һәм юлдашына тагын терсәген күтәрә.

Болар ничек кирәк, алай юлларын дәвам итәләр. Әмма озакка түгел. Ике-өч адым китүгә, инде юкасы туктый һәм инде көрәрге карга барып кадала.

— Стоп! — ди чандыр гәүдәле ир, бармагын иреннәренә куеп. — ГКЧПланды...

Шаккаткыч хәл, әлеге әңгәмә ГКЧПга бер ел кала булды.

## Мичкәләр арасында

Ул арада Фәйзи агай да чыгып җитте һәм без урам тутырып сыраханәгә таба ашыктык. Райкомда парткомиссия рәисе вазифасындагы Тимерҗан агайның кылтаясы килеп китте ахрысы:

— Нәрсә, егетләр, исерекләргә карата чара күрү әллә беттедәме? Сез бит форма кигән кешеләр, битарафлык күрсәтергә оялмыйсызмы? — дип сайрый башлады.

— Борчылма, Тимержан Мирхафизәнеч, бу исерекләрне безнең сержантлар әллә кайчан тәрәзәдән күрде инде. Милиция бүлеге турыннан алып керү яхшы түгел, райком тирәсенә житкәннәрен көтәләр булыр...

Сырахәнә мөдире мине күргәч балкып ук китте. Егетне сырага су кушканы өчен жавапка тарта башлаган булганнар. Шуның бертуган апасы минем уң як күрше.

— И, Зәет абый. Яхшылыгыңны ничек кайтарыйм дип йөри идем. Менә әйбәт булды. Сез складка үтегез, хәзер яңа мичкә ачам, — дип өтәләнә егеткәй.

— Әлбәттә, яңаны ачасың, әнәнне эт жыккыры малай. Дәү абыйларына су кушканың эчертмәссең бит инде, — дип сукранып куйды Фәйзи абый. Кара аны, икенче кат эләксәң, Дәет Дарифулыч әйтте дип тору юк, ишетсен колагың!

Складның тимер рәшәткәле бәләкәй берданбер тәрәзәсеннән яктылык әллә ни төшми икән. Тезелеп киткән мичкә рәтләре арасыннан түргәрәк узып, шакмаклы ашханә өстәле тирәсенә урнашабыз. Ул арада сырахәнәче егет алдыбызга икешәр бокал сыра китереп куя.

— Сыра өчен акча алам, ә бу ярты — күчтәнәч, — ди ул һәм өстәлебез уртасына тантана белән бер шешә «Столичный» чыгарып утырта.

Без карышып тормыйбыз, хәзинәдә барыннан житешеп, тотасын тотып бетергәч, караңгы һәм шыксыз бүлмәдән тизрәк яктыга чыгарга омтылдык. Тимержан абый белән Мөнәвир сигарет кабызды һәм без салмак кына кайту якка атладык. Райпо идарәсенә житәрәк барыбызны да уртак фикер биләве ачыкланды.

— Егетләр, аракы Дәлифә складында. Тик ул аны райпо рәисе язуыннан башка жибәрми, — диде Фәйзи абый.

— Кабинетында ут бар, сугылып чыгыйк булмаса, — диде Тимержан агай, кет-кет көлеп.

Хозурына тезелешеп, берсеннән-берсе хәтәр ир-егетләр килеп кергәч, рәис каушап калды.

— Бер-бер хәл бар мәллә? — дип ысылдады, кинәт тавыштан өзелеп.

— Әлегә юк, — диде Тимержан абый. — Әмма безнең гозерне үтәмәсәң, дөнья хәлен белеп булмый.

— Рәхим итегез, нинди гозер?

— Безгә хәзер үк ике, юк, ике аз булыр, өч ярты кирәк.

Рәис калтыранган кулы белән числолык битен йолкып алып, нәрсәдер сырлады һәм Фәйзи агайга тоттырды...

## Исәнме, Мәүҗидә апа!

Текә, тар баскыч буйлап икенче каттан төшеп барганда, Зәлифә очрап тора. Ул тулы гәүдәсе белән һәммәбезне рәттән стенага сылап уза.

— Дәлифә, чәк кенә сабыр ит, үскәнем. Кая бик хәтәр ашыгасың? — дип эндәшергә өлгерә Фәйзи агабыз.

— Түрә чакырта, — ди Зәлифә, дәү мут күзләрен уйнатып һәм райпо рәисе кабинеты ишегенә ымлый. Аннары калку күкрәген хәрәкәткә китереп тирән итеп бер көрсенә дә, юрамалый хафалы кыяфәткә кереп, аты-юлы белән, — и, Ходаем, тагын фәлән итәргәдер инде, — дип өсти һәм, чәк кенә түзегез, хәзер чыгам, — дип, кабул итү бүлмәсенә йөзеп кереп китә...

Бернишләр хәл юк, көтәбез. Мөнәвир ниндидер мәзәк очрак турында сөйли. Шаркылдап көлешәбез. Тимержан агай гына көлми.

— Сезгә рәхәт, — ди ул. — Сез котылдыгыз.

— Сон, нәрсә аптырап торасын? Син дә барып кил койма буена.

— Шту син. Әгәр берәрсе күрсә? Сәет Хәеричкә барып ишетелсә? Койманың теге ягында Мунча Мәүҗидәсе яши бит...

Мәүҗидә дигәч, сискәнешеп куябыз. Хактан да хәтәр хатын. Ике бите кып-кызыл булып, кызышып, эссе бәреп, ә шәле астыннан саргылт чәчләре ташып чыгып, тузгып тора. Урамда узып барганда, теләсә кемне тәк дуамал туктатып, син фәләннәрнең кызын боздың, җирбит, төгән юньсезлекне эшләгән идең, анаң тегеләй, атаң мондый иде дип бөтен урамны сасытырга, кем булуына карамастан, йөзенне җыртырга күп сорамый. Райпо складлары тирәсендә дә уралырга ярата: «Фәлән кемнәргә итәк астыннан нәрсә озаттыгыз, миңа да бирегез», — дип теләгән-теләмәгән әйберен алмый калмый.

Ә Зәлифә чыкмый да чыкмый. Тимерҗан агайның да сабыры төкәнде, күрәсең, ул да без юешләгән такта коймага барып капланды... Тик маңгае белән койманы озак сөзеп тору насыйп булмаган икән, Мөнәвир, ап-ачык итеп:

— Исәнме, Мәүҗидә апа, — дип куймасынмы?

Тимерҗан абый «ә» дигәнче чалбарын төймәләп, безнең якка «ялт» борылып, тураеп басты. Әле бер, әле икенче якка каранды. Баксаң, Мөнәвир шаярткан гына, Мәүҗидә апа һич кайда да күренми булып чыкты.

— Әле ярый беткән иде, — дип куйды Тимерҗан агай, сүрән генә.

Ниһаять Зәлифә дә күренде. Шешәләр һәм закускага дип бер пачка печенье алып, мәдәният йорты артындагы бакчага киттек. Шундагы агач диваннарның берсенә чүмәшеп, мәҗлесебезне янартып җибәрдек. Башта агач диван утыру өчен салкын сыман тоелган иде, ике шешә бушагач, зыянын тоймый башладык.

— Егетләр, сезгә мине күтәреп алып кайтырга туры килмәгәе, — дип куйды парткомиссия рәисебез, унайсызланып кына.

— Сез нәрсә инде, Тимер абый. Бу суыкта моның белән генә кем исерсен?

— Минем монда балак катты. Менә бу тәре, — Тимерҗан абый бармагын Мөнәвиргә төбәде, — менә бу җүнсез... Дурак. Тотлыга торган булып калсам шунда...

## Кувалдин

Ул көн, каядыр тоткарланып, эшкә соңарып килдем. Бусаганы атлап узганда, иртәнге җыелыш тәмамланган, ә бер төркем хезмәткәрләр, таралырга ашыкмыйча, кизү бүлмәсе янында таптанып, мине көтеп торалар иде.

— Егетләр бер-бер хәл булды мәллә? Кайда Марсель Гыйбатыч, машинасы күренми?

— Ул прокурор белән бергә ашыгыч рәвештә Казанга китте.

— Ә ник җыелып торасыз?

— Дәет Дарифулыч, сед Кувалдинны белә идегезме? Беднең якташ. Чаллыда яши иде? Бик чибәр нәселләр инде, сенелләре дә күд явын ала торган, музыка укытучысы.

Кылт итеп ике-өч ай элек кенә ГАИ хезмәткәре, чи урыс егете Сергей Кувалдин белән саф татарча сөйләшеп торуыбыз искә төште.

— Син өйләнденме әле? — дигән соравыма:

— Әй, б... к... маржа алдым инде шунда, — дип биргән җавабы хәтергә килде.

Егетләрнең кыяфәтләре шактый сүрән иде.

— Кувалдинга ни булган?

— Асылынган.

— Китсәнә! Тиздән әти булам дип торганда. Ничек алай...

— Алабуга-Чаллы юлында бер лихачны эзәрлекли. Теге буйсынмый. Ахыр чиктә тәгәрмәчләренә ата.

— Һәм теге шофёр җан-тәслим кыламы?

— Пычак та булмый. Машинасыннан йолкып чыгарып, Кувалдин моны бүлеккә алып кайта, беркетмә тутыра. Беркетмәгә кул куяр өчен ике пунәтәй кирәк бит, үдегез беләсез, беддә генә шундый валакита. Японнарда андый нәрсә юк дип укыдым. Кувалдин ике удгынчы хатынны пунәтәйлеккә көндереп алып керә. Чибәр, ягымлы бит, хатын-кыдга сүде үтә торган. Әлеге ханымнарның берсе корсаклы да икән. Беркетмәне ядып бетереп, теге хатыннар кул куя башлагач, теге лихач сикереп торып көмәнле хатынның корсагына тибә. Һәм Кувалдин, үден тыеп кала алмый, моның ияк астына сылый. Ияк чатный. Баксаң лихач дигәне бик дәү түрәнең малае икән. Кувалдинга прокуратурада да теш кайраучылар булган, аларның дусларын да правасыз калдыргалаган чөнки, үтенечләрен санга алмаган. Әнә беддә эшләп китте бит, Илсурның хатынына бәйләнгән Җамалыев. Шул анда өлкән тикшерүче икән хәзер. Кувалдинга әйткән бу:

— Гаебенне танысаң, судка кадәр иректә калдырам, югыйсә хәзер үк яптырырга кыжрыйлар, — дигән.

Кувалдин гаебен танып кул куйган да кайтып асылынган... Бүген күмәләр. Менә без, бернечә хезмәткәр коллегабызны озатырга бармакчы булган идек, Гыйбатыч рөхсәт бирмәде. Асылынып үлүче солдатларны да төнлә күмәләр, андый үлем белән китүчегә хөрмәт юк ул, ди.

— Прокурор барында шулай диеме?

— Әйе.

— Ә нишләп ул барында сорадыгыз.

— Нишлик соң, Дәет Дарифулыч?

— Барыгыз. Марсель Гыйбатыч — мәнле егет, прокурор катында гына шулай әйтергә мәҗбүр булгандыр...

Соңгы вакыйгадан соң әллә нишләп озак дәверләр кулга каләм алынмаган. Ихтимал, мин дә үзгәргәнмендер. Үзең өчен отышлы булмаган хәлләрне язасы да килми бит ул. Әмма, стаж тулуга пенсиягә аткарылгач, язмаларыма кабат әйләнеп кайтылды... Йомгаклый торган өлешкә тотындым. Монарчы язганнарымда чынлыктан бигрәк шаярту күбрәк. Милиция мәктәбендә ул фәнгә дә өйрәтәләр бит. Ә менә бусы, соңгысы — чын... Бары чын гына...

### Икенче бүлек

## ИБЛИС ХОЗУРЫНДА

### Фәнни эзләнү

Галиханның совхоз башлыгы булып эшләп китүе үзе бер әкәмәт. Исеме совхоз, асылда, үзбаш яшәсә мантымасмы дигән өмет белән, аптыраганнан «Йолдыз» колхозыннан башка чыгарылган бригада, ягъни утызынчы елларда ук, ә бәлки аннан элегрәктер дә, арурак кешенен беләге, дим микән инде, юанлыгындагы усак, юкә бүрәнәләрдән бурап салынган, эчтән-тыштан балчык сылап катырылгач, известь белән агартылган, әмма төс ташлавына да байтак гомерләр узган, түл түбәле, җиргә сенеп утыручы, капка коймасы йә юк, йә авыш шөкәтсез өйләрдән гыйбарәт Шабан атлы урыс авылы иде ул. Яңа оешкан совхозга идарә бинасы итеп, район үзәгендәге мәдәният йорты бәдрәфен хәтерләткән, шуның кебек үк санэпидимстанция таләбе буенча ала-кола акшарланган каравыл өен тәгаенләделәр. Урамнары саз да чокыр, ә район үзәгенә барыйм дисәң, юлы — юк. «Халкы ялкау, үнәрсез, самогон чөмерәләр, кулларыннан өч тиенлек эш

килми, ә лыгырдарга һәм шикаять юлларга булдыралар», дип зар елап, район житәкчеләренен байтак колак итен ашаган мактаулы «Йолдыз» колхозы рәисе, әлеге авылдан котылуын ай буе «юган» дип сөйләделәр.

...Төн йокламый чиләнүләре бушка китмәде Галиханның. Баксаң, рәтле хуҗа булганда кем дә жир жимертеп эшли икән, район үзәгендәге мактау тактасында кепка кигән озынчарак йөзле, саргылт чәчле һәм зәңгәр күзле урыс агай һәм маржа түтәйләрнен дә елмаюлы сурәтләре күренгәли башлады... Шабан үзгәрде, татарлаша төшеп, олайды, урамнары асфальтланде, стадионлы һәм иркен спорт залы булган урта мәктәпкә, фонтан атып торган ихаталы мәдәният йортына, ике катлы, тышы мәрмәр оны белән штукатурланып, эчке диварлары полировка дип аталучы, өслеге ялтыравыклы, пычкы чүбен катырып ясалган такталар белән зиннәтләнгән идарә бинасына, бассейнлы балалар бакчасына, автоматика белән жиһазланган өр-яңа фермалар, гаражлар, техника төзәтү үзәкләренә тиенде, яшь гаиләләр өчен төзелгән йортлардан яна урамнар барлыкка килде. Совхоз, үз көче белән район үзәгенә кадәр юл күтәртеп, чуерташ түшәгәч, өстенә битум агызып, асфальт ягып, «үтүкләүне» районның юл оешмасы хәл итте. Гомергә рәтле сулык күрмәгән авыл янәшәсендә балык күле хасил булды, хуҗалыкның карабодай басуларын читләүче каенлыкларны умарталыклар тутырды, мал асрыйм дигәннәргә нәфесе күпме, шулкадәр силос, печән һәм катнаш азыкны «К-700» тракторы белән өй борынча китереп, ишегалларына аудару гадәткә керде. «Асрасыннар, эшләсеннәр, мантысыннар, эшләп кеше үлми, терлек азыгы белән проблема булмаска тиеш», — дип куырды Галихан. Берзаман совхозда эчеп йөрүчеләр гел төкәнде. Директорнын үзен исәпкә кертмәгәндә, әлбәттә.

— Нишләп урып-жыю чорында берүзең урамда мондый хәлдә? — дип кызыксынучы район вәкилләренә аның җавабы гел бер булды:

— Фәнни эксперимент бу. Мин Русиядәге авылларны чәчәк аттыру турында хезмәт язам, фән хакына кайбер сынауларны үз өстемдә үткәрергә туры килә...

«Русияне татар гына рәткә кертә ала», дигән нәтиҗә чыгаручы да табылган Шабанда. Харитонов фамилияле отставкадагы подполковник авызыннан янгыраган әлеге ачыш.

Тора-бара яна совхозда жинел машиналарга ия булырга хыялланучылар борынлый башлый. Галихан, кызылармияче тапкырлыгы күрсәтә, машина житештерүче заводлар белән уртак тел табып, кышын, мәшәкать кимегәнрәк чорда арзанлы эшче көчләрен шуларга юллый, юнь хакка итен, балын озата һәм совхоздашларын район өлешенә керми генә тәгәрмәчле итү жаена ирешә...

Шулай инде, безнен авылнын Минзифа апа әйтмешли, хәерчене алъяпкычына бер соскы жылы борчак салсаң, хисләнеп китә икән дә, борчагы чәчелә, имеш... Шабаннар рәхәткә чыгып яши генә башлаганнар иде, көннәрдән бер көнне капылт кына районда житәкчелек алмашынып куйды...

## Чуан өстенә кутыр

Яна башлыкны өлком сәркатибе Ганиевнен авылдашы дип юрадылар, чөнки ул райкомны райкум дип әйтә, имеш... Башлыкка ияреп аның бер көтү яраннары килде һәм болар үз абруйларын яна жирлектә ныгытуны урындагы унганрак, фикере булганрак житәкчеләрне типкәләүдән, тапаудан башладылар. «Биредә халык бик өркәк, катырак кычкырсаң, артларына да утыралар», — дип, чикы-чикы көлә-көлә мактанышты, куанышты якташлар үзләре генә калган чакларда... Аларга булышырга теләүче жирле «түзәм ич!»ләр (тузумецлар) дә табылды урыннарда һәм, шикаятьләр ташкыны хут алып, тикшерү оешмаларына, шул исәптән безгә дә эшне арттырды.

Бер кичне Галихан фатирым ишеген какты. Байтак хуҗалыклар сөт планын үти алмый иза чиккән, чит өлкәләрдән ак май сатып алып кайтып, шуны әвеш-тәвеш ясап, «дәүләт алдындагы бурычларын» ничек кирәк алай каплаган бер вакытта, Галихан мәсьәләне урында хәл итү әмәлен тапкан. Халык контроле егетләре атна буе казына торгач, аноним хатта язылганнар раслана дип тапкан, өч центнерга кадәр сөт тапшыручыларга ул да литрына, башка хуҗалыклардагы кебек үк 22 тиеннән түләгән, ә инде ярты тоннага кадәр житкезүчеләргә, базардагы кебек 30дан тамызган, аны да арттыручылар өчен бәя 50гә һәм тонна чиген үтүчеләр өчен 75 тиенгә сикергән... Халык контроленә ярдәмгә өстәмә көч, КПСС райкомының парткомиссия житәкчесен дә юнәлткәннәр.

— Нәфес бөек көч, мина хөрәсәнлеккә чыккан кешеләрне игә китерү мөһим, татар игосы да игә китерү дигән сүздер әле, мин үз кешеләребезне жиргә беректерәм, дип чата-кама килгән Галихан. Ә нишләп хәзер генә ябырылдыгыз, нигә элек бер дә дәшми идегез, дип ярсыган. Ә тегеләрнен үз туксаннары туксан, моннан язмача аңлатма таләп итәләр, имеш...

— Аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума дигәндәй, сина сугыласы иттем. Ниемә ниндидер анонимка аркасында дөнья кубара соң болар? Элек андый хәл юк иде, ләбаса, — дип сукранды алдынгы хуҗалык житәкчесе.

— Яңа себерке каты себерә, дип аңлап була моны.

— Халык контроле белән парткомиссия инде атна буе казына. Чуан өстенә кутыр дигәндәй, сине дә китереп кушарга мөмкиннәр, имеш. Мина нишләргә боерасыз соң инде хәзер?

— Прокурор белән судияне мунчалар кертә-кертә, ничә еллар кунак иттен, фаразлап кына утырмасыннар, ярдәм итсеннәр!..

— Безгә материал килеп кермәде бит әле, диләр. Бер киресенә катса, уртак тел табу кыен, үзен сөйләшеп карамыйсыңмы, дип сиңа сугылырга кинәш итте акыллырагы...

— Яңа хуҗалар алдында котлары ботларына төшкән, шуңа сылтау табып, боргаланалар.

— Алай гына микән?.. Синдә компромат булуы да ихтимал, имеш. Аңлап житкермәдем, әллә үзләрен, әллә мине күздә тоттылар.

— Пычак йөзеннән йөри торган эштә бит, алны-артны, унны-улны киртәләми булмый. Ә райкомнын бюро члениары? Алар ничек? Очраганда сине кочаклап күрешәләр иде шикелле? Жил-янгырдан ышыклыйлармы әз генә булса да?

— Асларына жибәрүләреннән оялган сыман, очраганда йә читкә, йә аска карыйлар.

— Аңлашыла. Берәрсе синен белән сөйләшсә, икенчесе күреп, әләкләргә мөмкин.

— Кыенлык килгәндә беленә икән кемнәрнең кемлеге...

— Асыл хакыйкатьне аңлавынны хәерлегә юрыйк. Ә инде сөт белән әвеш-тәвешендә жинаять составы бар икән, безнен бер ГАИ жегете авылдашларына әйтмешли, «хәлегезне аңлыйм, но помочь не могу».

— Нинди состав? Төзелештә аккорд премия системасы кулланыла, Зәет. Бу прогрессив ысул санала. Мин аны сөт житештерүдә үзебезнен эшчеләргә карата да кулландым. Безнен хуҗалыкта һәр ихатала диярлек үзенә күрә капиталь кечтеки шәхси ферма хәзер. Малны күп асрыйлар, һәм терлек-туар люкс шартларда, хуҗаларынын яратуын, мәхәббәтен тоеп яши. Шул абзарларны кушылышта күзалласан, шактый мәйданда фермалар шәһәрчеге килеп чыгар иде. Ә андый шәһәрчекне авыл читенә чыгарып салыр өчен, беләсенме күпме чыгым кирәк? Коммуникацияләр уздыруы гына да алтын бәясенә төшә. Юлын күтәрергә, капка-

коймасын корырга, каравылчылар штаты булдырырга, белгечләр китертергә, ә алар өчен фатир мәсьәләсен хәл итәсе була... Әле бит һәммә корылманы карап, ремонтлап тәртиптә тоту бар. Һәм маллар ул очракта, яхшы дигәндә казарма шартларында яши. Эшкә барып кайту өчен дә артык вакыт сарыф ителә дигән сүз. Мал да интегә, терлекче дә эшерелә. Әле терлекче, караган малының авызыннан өзеп өйдәгесе өчен урлаша башлаячак. Сөткә өстәмә түләү, күренеп торган чыгымнар янәшәсендә төкерек кенә. Әле бит шул кызыксындыру аркасында бездә ел да терлекнең баш саны арта, нәсел эше яхшыра, һәр сыердан сөт елдан-ел күбрәк савыла. Син бит беләсең, җинаять составы өчен, усал ният булу шарт. Бездә, кайбер... кабакбашлар, ирек куйсаң, халыкның үз хуҗалыгында җитештергән сөтен кибеттәгенең чирек бәясенә җыярлар иде! Аларның нияте изге, минеке явызмы? Ә бит планнарны арттырып үтим, хезмәт хакы лимитына сыешам. Әнә, «Йолдыз» рәисен герой ясар өчен ана планнар ел да әзәйтеп җиткезелә, һәм ул аларны беренче кварталда ук «үтәп», республика матбугатында һәр бирмеш ел мөрәҗәгать белән чыга... Мин, аннары Дилүс абый, тагын бер-ике эш аты бар әле районда, «Йолдыз» хуҗасы ишеләр йолдыз алсын дип кәҗә маебызны чыгарабыз. Эшләре дөм бармый торган хуҗалыклар, әрмән яллап, ничек шәп типтерәләр, ә? Үз татары эт чутында, аларга тишек тиеннәр генә оча, кызларын көньяктан килүче кара кавем бозып бетерә, нигә шуларда казынмыйсыз?

— Синдә дә шабашчылар житәрлек. Дөрес, синекеләр татар, әмма схема шул ук ич. Яшерен-батырын түгел, милициянең мондый җинаятьләрне фаш итү мөмкинлеге дә чикле.

— Ә ник чикле?

— Чөнки хәерче авыл клублары һәм мәктәпләрнең финанс эшчәнлеген, әнә, Казан карамагындагы текә КРУ инспекторлары тәфтишли, ә миллионнар туздыручы колхоз-совхозлар тирәсенә аларны якын җибәрмиләр. Районның авыл хуҗалыгы идарәсе штатындагы, идарә башлыгы күрсәтмәсеннән карыш та тайпыла алмый торган бердәнбер исерек ревизор гына бимазалый сезне еллар дәвамында. Ә ул, кирәкмәгән полосага танау тыкмый гына түгел, безгә борын төртер өчен җирлек калдырмый, койрыкларын җыештырырга булыша... Менә синдә инде җиде ел шабашник Сәгыйдулла бригадирлык итә. Агызмаса да, тамызмый калмыйдыр?

— Кулыма аннан тиен дә алган юк. Син минем эш өстәленнән беркайчан да ришвәт дип бирелгән тамгалы банкнотлар таба алмыйсың. Ә андый гаепне бүтәнчә дәлилләү әмәле әле уйлап табылмаган!

— Кардан ак, судан пакь дисеңмени үзеңне?

— Эш барсын өчен кемнәрнедер көйләми булмый билгеле. Ә Сәгыйдулла кирәк чакта тирәмдә урала һәм, әйтик ресторанда, официанкага яки бүтән өчен чыгымнарны үз кулы белән үз кесәсеннән, үз ирегә белән чыгарып түли. Бәлки икенче юлы мин, яки башка мәжлестәш түлидер?

— Ләкин син үзеңне артык акыллыга санап, ялгыша күрмә. Олы абзыйлар кыздырып торганда кемне дә булса таш капчыкка җиткерүнең әллә ни катлаулылыгы юк. Кәшилүк булып йөрүченне дә койрыгына басып, сайрату жаен тапмаслар дип хаталанма.

— Зәет Зарифулыч, син бит дөнья күргән кеше. Законга гына карап торсаң, авыл халкын хәерчелектән мәңге йолып булмый.

— Ә бәлки авылда эш барырга тиеш тә түгелдер? Карл Маркс авылны идиотлар оясы дип санаган. Ленин, крестьяннан бау ишеп була дигән. Казанда, таныш тел галименнән ишеткәнем булды, крестьян сүзен татарчага тәрежан дип тәрҗемә иткән... Ә менә син шул тәрежаннарга якты көн тудырам дип азапландың...

— Соң син дә авыл малаедыр ләбаса!

— Авыл малае дигән төшенчәнең юридик мәгънәсе юк....

## Китә белеп киту

— Ау сезоны ачылды дисен инде, алайса? — дип куйды Галихан, авыр сулап.

— Совхозын халкын шәп яшәтеп, район башлыкларын һәм бер очтан хезмәттәшләренне, коллегаларынны авыр хәлдә калдыруынны анламый иденме? Килгән абзыйлар алдында икенен бере: яки үз булдыксызлыкларын тану, йә синнән арыну.

— Их, булмады берәр жавапсыз эштә эшләп. Совхоз директоры бик жаваплы эш бит ул, Заәт Зарифулыч, — дип куйды Галихан, тирән көрсенеп...

— Ә нинди жавапсыз эш бар сон бу дөньяда, син кызыгырдай?

— Райкомнын беренче секретаре, мәсәлән. Хужа булып «трай» тибеп йөри, берни өчен жавап бирми, ә бүтәннәрне утка тыга...

— Утка тыгуы бер хәер, яманрагына турыламасын. Сина, бүгенге шартларда ин кулае — районнан чыгып таю.

— Арттан түбәгә ормассынмы сон? Ормаслармы? Хәзер бит күпчелек районнарда Ганиев койрыклары...

— Хәстәрен күрмәсән, анысы да ерак йөрмәс...

— Сон, бәлки берәр акыл бирерсен? Салып сөйләш димме сон? Кая, берәр нәрсән бармы?

Суыткычта яртылаш башланган «ак» табылды, аш тәлинкәсенә банкадан тозлы кыяр бушаттым.

— Хәзинәдә бары.

— Исәнлеккә!

— Сездә отставкадагы подполковник Харитонов... — дип керештем мин, кыяр кисәген йотып жибәргәч.

Галихан мангаена сугып алды, урыныннан жәлт кенә сикереп торып, тәрәзә янын урап килде.

— Димәк, шикаятьне Харитоша сырлаган, — диде ул, йөткеренә башлап. — Ә бит мин ана, жәяү йөрмәсен инде бу мескен дип, калдык бәягә совхознын «ГАЗ-69» машинасын сатмакчы идем... Тот ите ашасын инде, алай булгач.

— Шикаятьне кем оештыргандыр, белмим. Белсәм дә әйтмәс идем, әлбәттә. Тикшерүчеләрен үзләре сырласа да гажәп түгел... Килеп ябышырга сәбәп кирәк, рас эш кушылган, үтәми булмый. Ә Харитонов әйбәт кеше. Дөрес, ялкаурак бераз, бүтәннәрнен терлек асрап, мантуларын авыр кичерә. Язса да үпкәли алмыйсын... Машина дип ымсындыргансын да сузгансын. Бүген үк күр шуны. Кысмырланма, эт күнеле бер сөяк, алып бар ярты әржә аракы. Сыйласын Усаклы авылынын ферма мөдире Зәкиев белән ветфельдшер Нурыевны. Эшләре хөрти ул егетләрнен, чучка балалары кырылудан килгән зыянны өлешчә болардан каерып алалар. Шуларны кырый калдырды прокуратура. Бик унай момент, сайратам дигән кешегә.

— Тукта, мин бернәрсә дә анламадым?

— «Беренче»гә ияреп килгән баш ветврач Заһидуллин белән танышмы син?

— Анын монда ни катнашы бар?

— Сабыр ит... Менә шул Заһидуллин, Нурыев белән Дәкиев күз алдында әрмән бригадиры Погосяннан күпмедер акча алып, кесәсенә шудырган.

— Шудырса нәрсә?

— Әрмәннәргә төзегән ферманы акшарларга кирәк. Сиптергечле махсус машинага бу бер көнлек эш. Заһидуллин оешмасында андый агрегатлы машина бар. Баш ветврач шуны жибәрергә вәгъдә биргән һәм жибәргән. Менә

шуларны яздырып аласы иде Харитонның кесә магнитофонына. Вәт, язманы алып каласын аннан, ә «Газ-69»ны, рас вәгъдә иткәнсен, бир, тилмертмә яхшы кешене.

— Һаман берни төшенмәдем?

— Минем исемгә шушы хакта аноним хат һәм магнитофон кассетасы салынган бандероль килә.

— Кемнән?

— Син оештырасың!

— Миннән стукач ясап маташасын чтоли?

— Тыңлап бетер. Хат авторы, әгәр чара күрмәсәгез, Мәскәүгә хәтле тәпилим дип яный! Мина яный... Һәм шунда ук синең һәм Дилүс агай кебек булдыклы кадрларның хаксызга җәберләнүләрен бәян итә. Аныңча, сезне, нидер өмет итепме шунда, кысалар, бөгелмәгән өчен эзәрлеклиләр! Мин бит үзең яз димим. Харитоннан үтенсән, сүзеңне аяк астына салмаячак...

— Һәм син моңа законлы ход бирмәкчеме?

— Юк, билгеле. «Беренчегә» «күчтәнәчегезне» күтәреп керсәм, ни диярсең? Сине, яхшылык белән районнан китәргә күндерү хәерлерәк булуын сендерсәм? Артыннан ук түбәнә җинаять эше белән тондырмасыннар дисәң, юлы шушы. Заһидуллин бит беренчегә туган тиешле... Заһидуллинның үсәсе бар. Һәм «беренче»гә аның пычрануы кирәкми. Сине тыныч кына озату мина йөкләнер дип фараз кылыйк...

— Ә нәрсәгә дип син мина яхшылык эшләргә булдың соң әле? Тәк, дуамал?

— Юньле егет булганың өчен дисәм, житеп торырмы? Килмешәкләрнең узынуы мина да ошамый, дип тә өстисеме? Чират бит Зәеткә дә житәргә мөмкин, рас мөстәкыйль кадрларга, үзең әйтмешли, ау сезоны ачылган...

— Ә аңлатма белән нишләргә? Халык контроленнән бүген өч рәт шалтыраттылар.

— Язмасаң, эт котырту була. Язсаң — утырган ботакны чабу. Яшьрәк чакта ат жигеп фермада эшләүче бер колхозчыны тоткарлап, вак караклыгы хакында протокол төзегәнем хәтергә уелып калды. Әбәдкә, брезент астына силосын, көрпәсен салып өенә кайтканда эләктергән идем. «Гаебемне таныйм» дип, менә бу турына үз кулың белән язып, кул куй, дим моңа. Язуын пажалысты, үзең мәтәштер, кул калтырый, минем сырлаганны эт тә таный торган түгел, сәнәк сабыннан нечкәне тоткан юк, имзаны кая кирәк шунда хет унны куям, аннары авылдашларны да шаһитлыкка чакырып хур итә күрмә, гаепне 200 пронсит таныйм, ялгышлык миндә, дип сиптерә бу. Икенче көнне судия каршына баскач, жен алмаштырды диярсең, күз дә йоммый алдаша, гаебен танымый. Баксаң, беркетмәгә дә, имза шикелле сырлап, «Алмадым» дип язган икән. Хет майлы буяу белән киндергә рәсем төшер — хөкем залы, мантия кигән судия аптыраштa, терлекче мыек астыннан астыртын елмая һәм мин торам, формадан, кара коелып... Чыктык урамга.

— Үпкәләмә, Мирзануров, акча да юк чак, мин ул курмыны көн дә алып кайтам, бүтән берәр вакыт тотып җәзага тартырсын, исән-сау тор, яме, — диде дә китте дә барды шул тапкыр кеше.

— Шуннан?

— Утырган да шуган. «Ун кулны каймыктырдым», дип аңлатманы үзләреннән яздыр да, «Әкият» дипме анда, бүтәнчәме «имза» сырла... Асылкош аягыннан эләкте, уен тузы бездә, дип куана торсыннар... Кодрәтле күренү бик күнелле, ахмак калулары бик яман...

## Чүлмәкне өч тапкыр тотыру

Ай да үтмәде, Галиханыбыз исән-имин күрше районга күчеп урнашты. Ана анда да хәерче һәм өметсез, бармый да, таралмый да торган хуҗалык тапшырганнар. Икенче көнне үк шул совхозның ферма мөдире кереп:

— Малларга ашатырга юк, — дип зарланган.

— Суй бер сыерыңны, — дигән Галихан. Һәм түшкәне машинасына салып, каядыр чыгып та киткән. Икенче көнне үк, әллә Бөгелмә элеваторыннан әллә Чаллыдагы ниндидер тегермәннәнме, «отход» исеме астында очсыз бәягә көрпәле он кайта башлаган... Яна ел бәйрәмендә үз хуҗалыгында эшләүче өлкәннәрне, ә икенче елны Җиңү көнендә районның барча сугыш ветераннарын почта аша кучтәнәч тулы пакет юллап куандырган. Әздән күңел була, әздән хәтер кала, ди безнең татар. Аннары әле аның «олыласаң олыны, олыларлар үзеңне» дигәне дә бар. Кыскасы, Галиханны биредә күпләр, бигрәк тә «прастуй» халык үз күрә, сүзен тыңлый, зурлый һәм ярата башлаган. Ә илдә «үзгәртеп корулар» хутка киткәч, тумыштан бирелгән эшмәкәрлек талантына тагын да хут ачылган... Төрле калаларда кибетләр, кафелар, рестораннар ачкан Галихан, аракы заводлары төзеп, сафка бастырган. Әмма авылны да ташлый алмаган... Бакчы, нинди хан сараенда яшәп ята Дәүләтхан малае, шаклар катмалы... Чит яктан кайтартылган саргылт һәм аксыл кирпечләрдән чигеп салынган зиннәтле өч катлы йортның тәрәзә пыялалары, тыштан күзгә булып күренеп «алдаша». Йорт артындагы офыкка ялганган зәңгәр күл дә, олуг күзгене хәтерләтә. Мине көткәннәр ахры, биек таш коймага бер өзеклек булып, челтәрле тимер капка ачык тора. Өй түрендә — жете яшел чирәмлек.

Үтә күренмәле зәңгәрсу күпертмә түбә астыннан бераз баргач, киң баскычлардан өскә күтәреләм, холлга үтәм һәм әкәмәт зур Татарстан гербы төшкән, боздай ялтырап торган шома мәрмәр идәнгә аяк басам. Диварлар, беренче катта кытыршы йөзле эре, зәңгәрсу төсләге шакмакланган ташлардан өелсә, өске каттагылары чыршы борыслардан бурап күтәрелгән. Югары катларга алып менүче баскычлар иркен. Каен, имән паркет идәннәрдә аю, юлбарыс, тагын ниндидер шәп җәнлек тиреләре ауный, урыны белән калын иран келәмнәре түшәлгән. Зур авызлы камин каршындагы ханзакәдән асылташлар белән бизәлгән саплы кылычлар чыгып тора. Ә түрдә, төрле-төрле алтатырлар беркетелгән кызыл бәрхет эчлекле тәрәзә сыман пыялаланган күргәзмә тартма астында, камыштан үрелгән баскыч шүрлеккә берничә концерт гармуны кунаклаган. Күрәсең, бирегә халкыбызның сәнгать осталары да эзләрен суытмый...

Юыну бүлмәсенә кергәч, күзгеләрдән ян-як, ас һәм өскә ябыштырылган төрледән-төрле тәтиләрдән, ялтыравыклы тотка һәм ырмаулардан кайтарылган нурлар чәбәләнүенә юлыгасың... Алтын йөгертелгән торбалардан гади генә су акмыйдыр кебек. Хактан да, составында көмеш кушылмалары бар дип табылган, Октябрь революциясенә кадәр аракы ясауда файдаланылган изге чишмәдән килә икән ул бирегә...

— Ашханәгә үтик, — диде, шушы хан сараеның иясе Галихан әфәнде.

Хатыны Фәридә ханым иң әүвәл алдыбызга коштабак белән җинелчә тозланган кара сарык ите китереп куйды. Анысы белән эш бетүгә, табынга ак гөмбә ашы, аннары каз ите турап пешерелгән тирән эчле бәлеш килде...

— Хәдистә ашказаныңның өчтән бер өлеше ризык тагын шул хәтлесе су, ә калганы һава өчен диелгән, — дип куйдым мин.

— Ә синең бер савытны өч тапкыр тутыру турында ишеткәнең бармы? — дип елмайды Галихан.

— Чүлмәккә башта таш, аннары ком, һәм су салыпмы?

— Нәкъ...

...Колхозлашу елларында Дәүләтханны, кулак дип гаепләп, гаиләсе белән бергә чатнама кышкы суыкларда ат чанасына төяп сөрәләр. Хатыны да, ике кызы да, юлда үпкәләре шешеп, гомерлеген алып әрәм булалар. Егерме елдан соң алтмыш яшен тутырып кайта Дәүләтхан абзый туган авылына. Кара күн куртка киеп, кыекча кызыл яулык бәйләп, боларны сөрүдә башлап йөргән комсомолка кыз кияүгә чыкмаган, кырыкка житеп килә икән инде, тота да шуна өйләнә... Галихан туа...

Алтмышка житкәч, нәрсә дип бәби апкайттыгыз, тинтәкләр, диеп гаеп итүче әче телле авылдашларга: картайгач, улым минем тамагымны туйдырыр, әле минекен генә түгел, бик күпләрнекен туйдырыр ул, дигән Дәүләтхан ага....

## Бәйрәм ашы — кара–каршы

...Хак әйткән... Менә мин дә анын улында сыйланып утырам бит әле.

— Килүен әйбәт булган, — дип каршы алды Галихан. — Синен чират иде. Синдә сыйланган бар иде бит, бәйрәм ашы — кара-каршы булса яхшы.

— Исәп тигезләшә дисен, алайса?

— Безгә элегрәк үк аралашасы булган, — дип елмая Галихан. — ...Прокурор һәм судия белән бик әйбәт яшәгән идек, кана...

— Икесен дә кесәгә салган идем дисен инде?

— Эш кешесенә алар белән араны жылы тоту хәерле.

— Синенчә ничек, кесәгә салынмый торган прокурор була аламы?

Галихан житдиләнә төште.

— Мин анлыйм, — диде ул, ияген чайкаштырып. — Ике икен дүрт кебек сорауларга реакциямнән чыгып, алдашканмы, дөресен әйтәме, дип тәгаенләмәкче буласын?

— Әнгәмәдәшеннен ихласлыгына ышанмыйча торып, нинди житди сөйләшү булуы мөмкин?

— Ярый. Алайса, логиканы эшкә жигеп карыйк. Юрфакка укырга «төртми» кереп булмый. Конкурс су буе. Ә ни өчен зур? Кешене төрмәгә тыга торган вазифага каян килә шундый кайнар мәхәббәт? Эш хакы ул кадәр баш китмәле түгел ләбаса закон капчыкларынын? Шик-шөһбәләргә, гайбәткә жирлек житәрлек... Булачак хөкемдарларнын остазлары кем һәм нинди? Ике пләмәш юрист булырга жыена минем, укырга керткән өчен дә буш итмәдек, сессия барышындагы имтихан-зачётлар өчен дә кыркыштыра торалар. Димәк, яна пешкән хокук сакчыларынын беренче адымы, остазларынын шәхси үрнәгенә ияреп, белем эстәгәндә тоткан чыгымнарны кайтару икән, аклап булмаса да, анлап була торгандыр?.. Ә башланган эш — беткән эш. Әйткән ди бит бер прокурор, безнен хезмәт хакы ташка үлчим, әле ярый отпускнойлар зур, дип.

— Милиция пуля астына керә-керә каптырган жинаятьчеләрне дә коткара бит шул эргә сөмекиләре, — дип куям үзалдыма һәм тешләрем шыкырдавын сизеп алам. — Аннары безнен егетләр эштән сүрелә, ялгыш юлга да кереп китә башлыйлар!..

— Син сүрелмәгән иден дә, озаталар икән дигән сүз чыккан. Бәлки ачыктан-ачык сөйләшербез? Артка су кергәндә, адәм рәтле егетләрнен фикере кыйммәт йөри, шәхси тәжрибәмнән чыгып әйтүем.

Галихан, елмаеп күз кыса. Мин дә көлемсерим.

— Һаман шул ахмаклык,беркатлылык харап итә... Бәлки ишеткәләгәнсендер, ничә еллар инде, һәр айны диярлек, бер «КамАЗ» машинасы югалды, ике «КамАЗ» машинасы югалды, дип гел хәбәр алып торабыз. Мона артык ис тә китмәде, калада шундый көчле идарәләр бар, эзләсеннәр, тапсыннар, дия

идек. Ә бер көн, завод капкасыннан чыгарылган безнен районга кайтасы ике йөк машинасы «эрегәч», әллә нәрсәсенә тыкшынасы иттем. Җинаятьләр эзләү бүлегендә сәләтле егетләр бар минем, йон төбенә төшә торган, текәләр арасында элемтәләре шактый гына. Өч көн дигәндә машина каракларын таптык, җиде кешене кулга алдык, гаепләрен көнендә таныдылар. Кыскасы, чибәр егетләрнең вазифалары бүленгән: кайсы машинаны кала читенә чыгара, кайсы шуны күрше шәһәргә куа. Анда кузов һәм двигатель номерларын үзгәртәләр, кабаттан буйыйлар, документларга төзәтмә кертәләр дә жылы яктан килгән кара малайларга тапшыралар... Еллар буе боларны борчучы булмаган. Кулга алган көнне үк өйләрендә тентү дә уздырдык, әллә ни мактанырлык байлыклар табылмады. Җинаять, беләсең микән, кылынган биләмәдә тикшерелергә тиеш, егетләрне икенче көнне бездән алып киттеләр. Һәм шуннан бирле тынычлык бетте. Комиссия арты комиссия килә, тырнак астыннан кер эзлиләр, эшләргә дә ирек бирмиләр, тегесен-монысын чокып чыгарып табалыйлар. Хәер, нәрсә сөйләп торырга, унайсыз кадрларны аулау һәркайда бертөрле...

— Сина болай да күп түзделәр.

— Үзенне бел инде. Татарстан гимны көе өчен Рөстәм Яхинга «Ока» бирделәр, ә син, урып-җыюда үзен күрсәткән комбайнчы малаена «Жигули» ачкычы тоттырып, асылда шулардан аһаһайлап көлдең. Дәү абзыйга кереп, әй унган да инде бу Галихан, ниләр майтарып ята бит, районнарында президент итеп куярлык егет ул дип олылыйлар аны, диебрәк берәрсе кереп мактаса, беттең бит?!. Минем, гафу ит, алай ук чиктән чыккан юк әлегә. Ә тешләрнең үткенлеген чынлап торып бер сиздереп алырга күптәннән кыҗрыйм.

— Гел сорыйсым килеп йөри, ни ашкындыра сине? Гаделлекме? Анларга тиешсен, бездәге дәүләт милкенә кул сузу дип аталучы гамәл, ул бит Мәскәү атлы гуҗдан бер толыкман өлеш йолку гына. Үзәк, ил өлкәләренең җелеген суырып, аларның яшәү һәм исән калу шартын шулай көйләгән. Син байтак кыю һәм һушлы җитәкчеләрнең кулларына суктың. Ни пычагыма? Күр, машина каракларын ничек биеткәнсез, ай күргән, кояш алган. Әлбәттә, алар пешка. Син бит тузларны «яндыра» язгансың, инәннең баш бармагы. Машина саткан акчаларның еллар дәвамында кемнәр кесәсенә акканын белмәскә, син бит дивана түгел. Нигә күрәләтә утка керергә? Нәрсә алгысыта?

— Ау комары... Ишетүемчә син дә ауга хирыс. Лицензия алып, пошига, кабанга тәвәккәллисең дип беләм. Киек үтерүнең ни кызыгын табасыздыр, мин дә аңламыйм. Гөнаһлымын, бер мәлне хезмәттәшемә ияреп, аэрочанага утырып, үземнең дә җан кыярга чыкканым булды. Очраткан бүребез әллә ничә көнгә җитәрлек итеп, бүселгәнче туенган булган. Куабыз. Ул бичара коса-коса, йомышларын үти-үти интегеп чаба. Атып алгач, тиресен салдырыйк дисәк, тотар җире калмаган... Вәт шундый хәл... Ә җинаять кылган кешене аулау күпкә кызыграк. Бик көчле, зирәк, талант иясе шәхесләр очрый... Алыш дисән алыш. Аларга ярдәм итүче «көчлеләрне» сүрелдерү, алаштыру исә сәнгать дәрәҗәсендәге уен. Мизхәт Исмаевны белсәңме?! Бөтен нәрсә буенча ялтырый бит инде, оешмасы ихатасын— түрен Яна ел унаеннан да иң матур итеп шул бизәтә, үзешчән сәнгать, спорт ярышларында да оешмасы гел беренчелекне тота. Беләсең инде.

— Мидәкне әйтәсеңме?..

— Әйе. Вәт шуңа карата эш ачтылар бервакыт. Чакырганны да көтми үзе килеп, кабинетта ят кешеләр бар дип тә тормый тезләнде. Һәм аякка ябышып, акырып еларга тотынды. «Мин ятимлек күрдем, башны бетермә, ни кушсаң үтим, кемне сатарга кирәк сатам, ярлыка гына, бер юлга калдыр», — дип үрсәләнә. Бар, ычкын, күземә күренмә, — дип көч-хәл сөреп чыгардым.

— Аны Казандагы башлыгы да эшеннән алып атарга омтылып караган.

Алдына тезләнеп, елаган, дип сөйләделәр. Күзенә терәп, шул хакта төрттергән идем, Мидәкнең тамчы исе китми.

— Мин бер тезләндем. Аның каравы миңа хәзер бүтәннәр мең тезләнә, дип аһаһайлап көлә. Үзеннән баш тарткан хатын-кызны да өч көн дә тотмый эшеннән куа, имеш... Һәм синә да ярдәм күрсәткәли дип сөйлиләр...

— Мәгълүмати өлкәдә генә.

## Аскы катта

Йортның подвалы аша күрше бинага күчәбез. Ансында мунча, ындыр табагыдай бассейн, бильярд, кино залы, тагын әллә ниткән хөҗрәләр урнашкан. Үлгәнне белми чабынганнан соң, салкын сулы бассейнга чуму бик хозур икән, тәнемә меңләгән инә кадалгандай була. Ирексездән тизрәк күп баскычлы ләүкә буйлап югарыга үрмәлисең. Анда кызгач, тагын салкынга чумасың. Шәбәреп чыгасың да, янә эссе кирәк.

Коенып аргач, мең сихәтле үлән суларын өстән коеп, сөртенми кибендек тә чишенү залында махер халатлар киеп алдык. Галиханның хезмәтчеләре уңган, күзгә күренми генә барысын да уңайлап торалар... Без чыгышка табын әзер, хәмер-шәраб, җиләк-җимеш, яшелчә һәм кабымлыкларның ниндие генә юк. Сусынны басыйм дисәң, куыклар атып торган тәмле сулардан авыз ит, яки кайнап торган самавырдан чәй дә эчәргә мөмкин.

Диварда, майлы буяу белән киндергә ясалган һәм шактый мәйдан биләгән рәсем игътибарны җәлеп итте. Картинаның астына «Җенләнгәнче» дип язып куелган. Анда мәҗлес сурәтләнә. Мул табынны ярым шәрә хатын-кызлар һәм ир-атлар сарган. Мәҗлестәшләр сәрхуш, күзләрендә ут уйный, ә кайберләренә йөнтәс койрык һәм тояк чыга башлаган...

— Минем сиңа килүнең сәбәбен тәки сорамадың? — дидем мин, мөлдерәмә рюмкага үрелеп.

— Һәрхәлдә, кулга алырга килмәгәнсеңдер? Зәет, син уңайсызланма, яхшы машинада йөрисең килә икән, китереп ат, сүз чынлыгы өчен черек Москвичыңны, баш на баш алмаштырам да бирәм. Бәлкем улыңны берәр чит илгә укырга кертәседер? Мондый вакытында аякта нык торып калу өчен кайбер позитив үзгәрешләр кирәк ул тормышта.

— Безнең эштә бер сатылып дан чыгарсаң, очсызланган, сорап та тормый төртеп аударылуга калган кыз хәленә төшәсең... Син мине теге дусларың белән бутама.

Галихан көлеп җибәрде.

— Өч айдан пенсиягә аткаралар түгелме соң?

— Каударланма, галстугыңа басарсың.

Әңгәмәбезне телефон чылтыравы бүлде.

Галихан трубканы алды, кем тынлавын әйтте. Аңа борчучы озаклап нидер сеңдерергә азапланды. Азактан Галихан, анысын үзегез карагыз, диде һәм трубканы элде.

— Минем белән кызыксынмыйлардыр ич?

— Чираттагы янау... Бизнесмен булуның уңайсыз яклары бар инде аның. Очасың икән, мылтык төбәгәннәренә аптырыйсы юк.

— Моны болай калдырып булмый бит инде?

— Минем телефон «контора»га ялганган. Теләсә нишләсеннәр.

— Алардан да төрлесен көтәргә була...

— Кит дип әйтмим, ник килдең, дигән ди бер җингәчәй, абыйсы юкта кырына килеп яткан каен энекәшенә. — Эш кирәк икән, рәхим ит. Миңа, күреп торасың, синдәй егетләр кирәк. Ике катлы коттедж әнә, тәрәзәдән күренеп

тора, машина бирәм, урынбасар кәнәфие бушады, әле күптән түгел генә атып киттеләр, ишеткәнсеңдер?..

Ашыкмый гына торып, каршыбыздагы тумба өстенә кунаклаган телевизорны кабызам. Якубовичның «Могжизалар кыры» дигән тапшыруы бара икән...

— Ишетүемчә синдәй акча капчыклары өчен мондый уенның үзгәрәге бар? «Иблис хозурында» дип атала. Сине шул уен аша мантып киткән, диделәр, бездән киткәч?

— Бар андый уен.

— Менә мин шуна килдем.

— Әй беләсеңме, уенга эләгү өчен кабахәтлегеңне расларга кирәген.

— Тәүбә итәсеменi?

— Тәүбә ул ваз кичү белән бәйле. Үлгәч җәннәт өмет итеп. Ә монда, киресенчә, шул әшәкелеген өчен бу дөньяда әҗер дәгъва итәлә...

— Булдыра алмам дип уйлыйсыңмы?

— Кем, кем, әмма син — кабахәт түгел!

— Ә үзең? Үзеңне ничек раслый алдың соң андый сыйфатта? Син бит бездә эшләгәндә совхозың халкын коммунизмга чыгара язган кеше. Әле яна урында да мантып киткәч, дини календарь чыгаручыларга булышкансың, язучыларга кафе ачкансың, мәчетләр, янә килеп чиркәү дә салдыргансың. Тау халкына ярдәм юлларга да йөрәген житкән диделәр.. Ә бит «акыллы кешеләр» мәчет хозурында халыкара рок-фестивальләр, «арткы якның алтыны» дигән конкурслы сыра бәйрәмнәре уздыра, галим яллап китап яздырып фәнни исемнәр, бонуслар ала...

Галихан тирән көрсенеп куйды .

— Әле алар минем каладагы «Аргамак» ресторанымда бушлай тыгына. Эчеп исереп алсалар — сугыш чыга. Тәртипкә чакырган сакчы егетләрдән, сезнекеләрне җәлеп итеп, үч алалар... Фәттахны беләсеңдер, бурычы миллионга житте, кайчан түлисең дигән идем, кодасына зарланган. Анысы бездәге катыборыңга шалтыраткан. Өчесе пайга кереп мине акылга утыртырга керештеләр бер мәл. Кызлар белән мунча кергәннәрен видеога төшертеп бәйләнүләреннән чак туктаттым. Болардан халыкка ни тоз, ни он, игелек кылу мәҗбүрияте алдында калсалар, әти мәрхүм әйтмешли, тизәкләрен мыскалга салалар...

— Ә син нәрсә саласың мыскалга?

— Мин чиновник түгел, ә ирекле бизнесмен. Үзем бер дәүләт. Яшермим, һөҗүмнәр булгалый, чолганышта калгаларга туры килә. Адреаналинга кытлык юк. Хәлбуки, кешеләргә игелек эшләмәсәң, куандырмасаң, мондый йоккә түзәрлек тә түгел.

— Ничек уенга үтә алдың соң, алай әйбәт тә булгач?

— Күпме генә изгелек эшләсәм дә, минем урыным тәмугта, — диде ул, ачы сагыш белән. — Аракы бизнесы белән шөгыльләнәм, — дип белдерүем булды, мониторда «уенга керден» дигән язу чыкты. Уйнадым һәм оттым да бугай. Инде тагын уйныйсы килә, һәм бүтән юл да калмады кебек, минем бит егерме дүрт миллиардлык мөлкәтне законга турылап, талап димме, акцияләштереп диясе микән, сеңдереп маташа кәнәфиле агайлар... Уенга кабат керә алмыйм. Кагыйдә кушмый. Ә бүтәннәрне тартырга ярый, тик үтмиләр... Инде кемнәрне генә чакырып бакмадым. Хәтта киллерны да. Экраннан «син рухи бирәмлек түгел, чара гына» дигән җавап чыкты. Күрше районның райпо преды: «Мин карак, официант һәм зиначылык халиме дә» дип әтәчләнгән иде, «эш урыныңның язылмаган вазифалары сиңа акча янчыгы булу, килгән кунакларны кызлы мунча кертеп, ашатып-эчертеп озатуны йөкли, уенга үтмәдең», дип язу чыкты. Янә бер таныш житәкче дус бар, хатын-кыз мәсьәләсендә ут бөрчәсе, ә компьютер, «син шәхес түгел, ә фәлән нәрсәнең гәүдәләнеше» дигән бәя чыгарды.

— Мин үтәчәкмен.

— Жаны теләгән — елан ите ашаган. Бел: өч теләге үтәлә отучының. Берсен мина сарыф итәсең. Дума депутаты мандаты кирәк. — Галихан, муенын кулы белән ышкып куйды, ачы көлемсерәде. — Менә болай кирәк. Калганын үзең кара. Татарстанга суверенитет сорасаң да, сүзем юк...

## Хәсислеккә имтихан

Тәвәккәлләп компьютер каршына утырам. Бармакларым клавиатурада бии башлый...

Мәктәптә укыган чакта, кыш көне бәдрәфкә йөгереп керүемне һәм пес итеп торган бер сабакташымның баш киемен салдырып, кая борылса да үз «чишмәсе» астында тотуымны, ә аптыраганнан, бүрекне коткару ниятеннән чүгәләгәч, шуны башына батырып киертеп чыгып йөгерүемне язам. Ә компьютерда «зек менталитетлы халык яшәгән илдә мәктәпләр өчен табигый шаяру, уенга үтмәдегез» дигән язу чыкты.

Гөнаһсызга гаепләнеп, камерада җәберләнеп, асылынып үлгән бер бичара язмышын бәян итәм.

— Дәүләт — көчләү аппараты. Үтмәдегез.

— Болай булмый, — диде авыр сулап Галихан. Соңгы мөмкинлегең калды дускай, кая ашыгасың? Синең төнге уникегә кадәр вакытың бар. Яз, рәхәтләнеп бер шәп роман. Гонарары җилле булачак!.. Ялганлауда табибларга һәм сезгә тиннәр юк лабаса. Табиблар, фәлән-фәләннәр итеп дәваладык дип фантазияләрен сырлый, соңыннан, пациент үлә калса очын таба алмаслык итеп һәм сез... Каза күрүче үзе тотып тапшырган җинаятьчене көн-төн, армый-талмый еллар дәвамында каулавыгыз турында...

Сөялгә басты Галихан, шәхси мәнфәгате үлчәү тәлинкәсенә салынгач, итагать саклап торуны урынлы санамый күрәсең... Ярый. Рас суга кердек, димәк йөзәргә кирәк. Янә бармакларны эшкә җигәм. Роман тек роман...

*«...Мәктәптә укыганда хикәяләр-шигырьләр язып мавыктым. Унны тәмамлагач, университетның татар филологиясе бүлегенә барып кердем. Укуым тәмамлангач, язмаларыма мәйдан биргәләгән газетага эшкә урнаштым. «Икмәк булса җыр да була», «Дуңгызчылык — табышлы тармак» дигән мәңге искермәс исемнәр астында мин дә мәкаләләр сырладым... Телевидениегә чакырдылар. Татарча авылга кагылышлы тапшырулар бер калыпка куыла икән биредә, һаман бер балык башы: персидәтел әйбәт, малларга курмы бирә, авылда яшәргә була! Тора-бара, үз бүрттерүләремә үзем ышана башлап, каланы калдырасы иттем. Ә авыл мәктәбе укытучысының вазифалары тавык чүпләп бетерешле түгел... Баксаң, балаларны укыту, дәфтәр тикшерүләрдән тыш аның җилкәсенә сайлауларны уңышлы уздыру, авыл хуҗалыгын тауга күтәрү максатында агитаторлык, үзешчән сәнгатьне алга сөрү, кара көзгәчә, өстән өшәндергеч яңгырлар коеп торганда, колхоз басуыннан бәрәңге чүпләү, кышын колхоз базында чери башлаган шул бәрәңгене аралау кебек мәшәкатьләр өстәлә икән... Бу бит гомерлек җәзага үз теләгең белән күнү... Әле бит киләчәктә укытучының дәрестә һәр әйткән сүзен, уйлаган уен, хәрәкәтен бер әмтекләп теркәү шайләнә...*

*Тукай Шүрәлесе сыман «Бу баладән кем килеп йолкыр мине» дип гаҗиз калып торганда, өебез ишеген погон таккан кешеләр какты. Милициягә эшкә кодаларга килгәннәр, участковый вазифасын башкару өчен педогог белеме кулай, диделәр.*

*Беренче эш көнем истәлекле булды. Киләм урам буйлап. Каушыйм.*

*Кызарынам. Әле бит минем чәч тә жирән, каш-керфекләр дә ак һәм, өстәвенә сипкелләр дә мул булгач, йөз ерактан ук янып күренгәндер инде, балигъ булмаганнар белән эшләүче инспектор Хәмидуллин мина ымлап кычкырып жибәрмәсенме:*

*— Егетләр, карагыз әле, карагыз, милициянен йөз кызыллыгы килә!*

*Тәмәке тартырга дип урамда, бүлегебез ишеге катында бөялеп торган булачак хезмәттәшләр дәррәү көлеп жибәрделәр.*

*Эшләп киттем ару гына. Өч айлык әзерлек курслары үтеп кайткач, бишекле матай бирделәр. Колхозда белгеч булып эшләүче, мин укытучы чакта иренеп кенә кул чугы сузган яшьтәшләр йөгереп килеп күрешә башламасыннармы!..*

*Хезмәтемнен асылына тиз төшендем, ин мөһиме — үзенә беркетелгән биләмәдә кылынган жинаятьләр ачылырга тиеш. Әйтик, ун жинаять теркәлеп, алтысы ачыкланса, ачылганлык алтмыш процент. Шул санын узган елгыдан түбән төшмәсә, мактаудан башка сүз ишетмисен. Әмма жинаятьчеләр тәжрибәле, этлек кылган урыннарда паспортларын төшереп калдырмыйлар. Менә монысы тез астына суга, тормыш арбасы тәгәрмәченә тәпәч тыга. Димәк, сан матур саклансын өчен нишләргә? Теркәтмәскә! Ачылгач та теркәп була ич аны, нигә ашыгырга? Башкача хут калмый, теркәлгән, әмма ачылмый калганнарыннан да арыну жайлары бар. Әйтик дунгыз фермасыннан чучка малаен «суктылар», ди. Кемнәрдер шашлык куырып, учак урынында эч-башларын, тире-тоякларын калдырып киткән. Ин әвәле арба төбенә терлек азыгы түшәп өенә кайтып баручы терлекчене туктатып, анлатма аласын. Ул инде, урлаган силосы-сенажы өчен беркетмә төзеп вакланмасан, ферма тирәсендә бүреләр йөрүе хакында рәхәтләнеп сөйләп бирә. ...Банка белән өч литр сөт чәлеп кайтучы сыер савучы апа монын сөйләгәннәрен шулай ук очынып раслый... Ферма мөдире дә яна туган чучка малайларын көн дә санап, керемгә алдыра башламавын хакына рәхмәт йөзеннән, терлекчеләрен куәтләргә, яшь пионер сыман, һәрвакыт әзер... Менә милиция бүлегенә кайтасын, килеп керәсен начальник кабинетына.*

*Житәкчен, ут йотып сорый синнән:*

*— Ачып кайттынмы, асыпмы?*

*Кәгазьләренне китереп саласын өстәленә. Анда чучка малаенын урланмавы, ә бүре тарафыннан харап булуы бәйнә-бәйнә дәлилләнгән. Житәкчен, эш кузгатылмау турындагы карарына ашыгып имзасын сырлагач, прокурорга юл тотасын. Сукрана-сукрана булса да анысы да кулын куя. Нәтижәдә, эш күрсәткечләрен ал да гөл.*

*Шеф, минем эшчәнлектән мәмнүн икән, ОБХССка, яки жинаятьләр эзләү бүлегенә оперативник булып күчәргә тәкъдим ясады. Шунсыз синнән урынбасар ясап булмый, ди. Яна эштә очраклы ачылган жинаятьләр унаеннан хикәя, повесть хәтта роман уйлап чыгару зарур булып чыкты, имеш син жинаятьчене эзәрлеклисен, бер-бер артлы берсеннән-берсе тапкыррак чаралар күрәсен, ә ул тоттым дигәндә генә һаман-һаман ычкынып китә, шамбы балыгыдай кулдан шуа, күз алдында парга әйләнә! Әмма муенына ыргыткан элмәген көннән-көн кыса бара һәм мәкерле жинаятьче, жилкә чокыры белән синен сулышны тоюдан гажиз булып, каушый, ялгыша башлый да жып-жылы килеш салган жылымына үзе ук барып керә... Талант та бар, фантазия дә житәрлек, университетта алган белем дә ярап тора. Әле бит милиция мәктәбендә каракларны, канун бозучыларны төпсез чуманга утырту фәнен дә сендерделәр. Әлбәттә, сырты саргайган жинаятьчеләр бу китапны синнән күбрәк укыган. Шуннан ни?.. Аларны алдый алмасан аптырыйсы юк. Анын каравы гавәм күзенә шул махсус белеменә таянып күпме кирәк төтен жибәрәсен...*

*У-уу, мин язган кыйссалар: теләсә кайсы буенча хет спектакль куй, хет кино төшер. Иманым камил, экраннарга чыккан фильмнар безнең ишеләр сырлаган әкиятләргә нигезләнгән... Тагын бер ысул бар икән әле безнең арсеналда. Ачылмый асылынып калган «эш»ләрне берәр житдирәк жинаять кылып эләгүчегә «тегеп» була . Аны шуна күндерәсең. Бездә бит Америка түгел, кылган жинаятьләр өчен каралган сроклар кушылмый... Авыр жинаять өчен тиешле зуррак срок, бүтән жинаятьләр өчен тиешле бәләкәйләрен «йота»... Кыскасы, милицияне финанслап куәтләндермичә дә күрсәткечләрен күркәм тоту өчен хутлар калдырылган... Бездә бит һәр ведомство закон проектын үзенә кулай итеп үзе әзерли. Ятим бала үз кендеген үзе кисә диләрме әле. Ә депутатлардан шуларны хуплату, кем әйтмешли, «үзе бер роман».*

*Мин үстем. Калага күчерделәр. Министрлыкка алу хакында да сүз булган бугай. Әмма ана хәтле булган бер вакыйгага тукталмый үтү ярамастыр. Мөгаен нәкъ шул чактагы гамәлләрем уенга узу-узмавымны хәл итәр дә... Эш болайрак булды.*

*...Бер эшмәкәр, бурычка алган акчасын түләмәгән. Тимер юлда озаткан товары вагоны белән югалган һәм бу алган кредитларын каплый алмый. Менә яныйлар. Бүтән чарасы калмагач, безгә килгән. Ә бүлекнең мөмкинлеге чикле, яныйлар дип килгән һәркемне сакларлык хәле-куәте юк. Шеф менә шуны төшендерде, үзең ялласаң гына инде, — ди.*

*— Акчам булса түләп кенә котылыр идем, — ди бу.*

*Әңгәмәгә мин кысылдым. Үземнең этне алып торырга тәкъдим иттем. Эт зур минем, ашарына һич житкереп булмый. Эш өчен файдалы югыйсә, әмма бүлегебез чыгымнары исемлегендә шуны туендырырлык паек каралмаган. Алдырны үзем алып бардым гозерчебезгә. Эшкуарның хатыны әкәмәт чибәр икән. Күренеп тора, бер-берсе өчен өзелеп торалар. Әлеге егет бизнеска да хатынын бәхетле итәм дип керешкән булган күрәсең һәм башта эше тәгәрәп барган. Аннары чатаклык чыккан. Кредиторы әйткән, хатыныңны миңа сөяркәлеккә озат, бурычыңны кичерәм, дигән. Бу тегенең бугазына ябышкан. Нәтиҗәдә срок куеп, типкәләп озатканнар...*

*Атна үттеме-юкмы, бар да тәмамланды, оператив төркем белән фажига булган урынга миңа чыгарга туры килде: үзен дә, хатынын да, минем этне дә өйләренә кереп атып чыгып китканнәр... Кайткач, начальник кызыксына:*

*— Ачып кайттыңмы, асыпмы?*

*Белеп торам инде, хәле мөшкел, узган атнада министрлыкта, коллегиядә өшкереп кайтарганнар, күрсәткечләр тагын да түбән тәгәрәсә артына тибеләсен төшендергәннәр. Агаем, өметсезлек белән кулын алга селте.*

*— Заказлы үтерүнең кайчан ачылганы бар? — дип авыр сулый.*

*— Бернинди заказлы үтерү дә булмаган, — дим мин, татлы көлемсерәп.*

*— Нәрсә, нәрсә?*

*— Ул яшәгән элитный йортта безгә очып кергәли торган бер төнге күбәләк бар. Анда шул очрап тора. Әлбәттә очраклы рәвештә. Ул минә нәрсәләр хакында житкерде, рәхим итеп аңлатмасы белән танышыгыз. Бу хакта «күбәләгебез» гәжит журналистының да колагына токмач элде.*

*— Кая, бир әле монда...*

*Аңлатмада «төнге күбәләк» бик тә гыйбрәтле кыйсса бәян итә. Баксаң ул бизнесмен хатынының танышы булган. Хатын бәлагә таруларын сер итеп кенә миңа «тишкән», ирен коткару хакына хәтта панельгә чыгарга әзер булуын әйткән, бай клиент табасы иде дигән. «Күбәләк», бизнесмен ире өйдә юк көнне моны төнге клубка алып бара һәм шунда бер бай оригинал белән таныштыра. Артыграк хәмердән авыз иткәнгәме, ханымыбыз чишелеп китеп, хәлен тәфсилләп ана да аңлатып бирә, «на всё согласна» дип тә ычкындыра.*

*Теге агай шунда ук кесәсеннән алып, пачкасы белән валюта тоттыра һәм өенә чакыра. Өйдә шул ачыклана: ханым белән ир үзе түгел, ә анын эте кавышырга тиеш, имеш... Бер атна вакыт узгач, хатын әлеге бәндәне үзе эзләп таба... Теге риза була. Ханым үзе кичергәннәрне энәсеннән җебенәчә «күбәләк»кә яшермичә сөйләп барган. Ә фаҗига көнне бизнесмен ире көтмәгәндә кайтып кереп хатынынын мажарасына юлыккан һәм башта аны, аннары этне, аннары үз-үзен атып үтергән...*

*Шеф укып бетерде һәм авыр сулап:*

*— Мәрхүмнәрнең туганнары тавыш-тын чыгармас микән соң? — дип куйды.*

*— Мондый гайбәтнен кемгә кирәге бар?*

*— Ә син бер дә курыкмыйсынмы?*

*— Нәрсәдән? Теге «күбәләк»не тынлаган журналист, шушы унайдан мина да сораулар яудырды.*

*— Ни диден инде?*

*— Күк бия саташуы, — дидем.*

*— Ә теге кредиторны йолкып карасак?*

*— Өметсез эш. Ул бит Ганиевкә туган тиешле. Аннары безнен кулда нәрсә бар соң ул кадәр?*

*— Шулай дисенме?..*

*Икенче көнне үк «журналист тикшерүе» гәҗиттә дөнья күрде. Башта андагы «версия» белән килешмәгән халдә, мәрхүмнен туганнарын тинтерәттек. Гәҗиттә фамилияләр язылмаса да, ямьсез фаразнын кем хакында икәнен алар тиз төшенде. Һәм чын гаепләләрнен фаш ителүенә өмет өзеләр күрсән, эшебездән нәтиҗәлелек таләп итеп йөдәтүләрдән тыелдылар. Һәм абзагыз, тәвтишләү срогы чыкты дигәндә, «журналист версиясе» белән килешеп, эшне ябып та куйды... Башлыгыбызнын артына типмәделәр. Туган ягымда мин кызыккан урынга вакансия ачылу белән, мөмкинлекләрен эшкә җигеп, ул миннән котылды, мине үзеннән коткарды...*

Язудан туктадым. Ә компьютер дәшми, гөжли дә гөжли... Галихан бер утыра, бер тора, бер сәерсенеп беренче күргәндәй мина карап ала... Дулкынлана... Менә монитор тарафыннан авыр сулаган сыман тавыш ишетелгәндәй булды, әкрен генә хәрефләр оеша башлады һәм экранда «сез уенда» дигән язу эленде...

## Уен-муен

Кинәт янәшә-тирәбез яктыра башлап, стенадагы сурәттәгеләргә җан керде һәм без мәҗлес уртасында калдык.

— Йә, бәгърем, сөйлә, ни телисең? — дип кызыксынды чибәр, мөгезе асылташлар белән бизәлгән пәри кызы һәм дустанәлек белдереп, җебеп тормау кирәклеген сиздереп, койрыгы белән җиңелчә генә сыртыма сугып куйды. Өч теләгеңнең берсен әйтеп бак.

— Галиханга Дума депутаты мандаты...

— Анда эләккәч татар телен кытай иероглифларына күчерү зарурлыгы турында тәкъдим кертүдән курыкмаса, тырыштырырбыз. Шефның таләбе шундый.

Галиханның шунда каушауданмы, тавыш киселде.

— Шул гына җитмәгән иде, — дип пышылдады ул.

— Ишетмим.

— Ризааа!!! — дип кычкырып җибәрде кинәт тавышы ачылып куйган Галихан, һәм кесәсеннән алып туташка кыйммәтле ислемай сузды... Туташ шаркылдап көлеп җибәрде, урынында сикергәләп, койрыгын уңга-сулга айкады.

— Хәзер шефны урап чыгам.

Һәм алдында чигүле кулъяулык шае альяпкычы гына бар гүзәлкәебез, кәскәс атлап, кай арада барлыкка килгән ике катлы ишек аша үтеп юк булды. Озак та үтми ул янә күренде һәм хәтәр елмаеп:

— Алы...гыз манда... тыгызны, — дип бәләкәй кенәгәне миңа сузды. Ачып карасам аһ иттем, мөһер сугылган, киләчәктә сайланачак спикерның имзасы ярылып ята... Китапчык кинәт кенә кулымнан йолкынып ычкынды һәм «канатларын» жилпи-жилпи Галиханның куенына кереп китте...

Һәм хыялындагы «катырка»га тиенгән Галихан шунда ук эреп юк та булды.

— Миңа моннан үтәсеме? — дип сорадым, кулындагы бүләк ислемаен иснәп торган туташтан.

— Тәрәзәгә күз ташлыйсыгыз килмиме соң?

Туташ чакырган тәрәзәгә якын килеп, тышка карыйм һәм сокланудан телемне шартлатам. Анда берсеннән-берсе матур агачлар, үләннәр, чәчәкләр үсә, фонтаннар ата. Бакчаны, төбен зәңгәрсу чәчәкләр сарган тирән сусыз елга урталай бүлә, ә текә ярларын өч урында утлы гирляндалар белән бизәлгән асылмалы күперләр тоташтыра. Күрше ярда заманча материаллардан корыштырылган чукча чумы, индеецлар виквамы, казакъның тирмәсе, янә килеп шалаш, чатыр, палаткалар һәм тагын әлләкемнәрнең әлләниләре тезелеп киткән. Һәркайсының ишеге төбендә ике гүзәлкәй сигарет тартып тора...

— Болар бит койрыклы түгел, каян юнәттегез? — дип кызыксынам.

— Төнге клублардан арендалыйбыз. Хакын түләгәч, кая чакырсаң шунда бара ич сезнең кавем... Иң кыйбатлылары биредә. Вакытыгыз житәрлек әле, бәлки урап килерсез, калган ике теләгегезнең берсе хисабына. Тәвәккәлләгез. Тик шунысы бар, кайтканда күпердән бик каты йөгереп чыгарга кирәк. Чабасың, ә басмалар арттан коелып бара. Шундый аттракцион.

— Кайтышлый житезлек калыр микән соң?

— Алыгыз нашатырь спирты. Шул ярдәм итәр. Сез үтәчәксез. Биредән кайсы көнне зерә дәү корсаклы абыйлар да чабыша, бот чабып, эчләр катып күзәтәбез.

— Егылып төшүчеләр жан тәслим кыламы?

— Имгәнмиләр дә.

— Алайса күпердән очудан ни мәгънә соң?

— Мәгънә бар, — дип хәйләкәр елмая туташ, күзләрен уйнаклатып. — Күрәсеңме, аста, әнә анда, комырыкта «Зәңгәр Хыял» атлы бар бар. Аска очкан кешегә бүтән юл юк, ул шунда барып кереп, һәм барланып арт ишектән чыга да әнә теге баскычтан бу якка күтәрелә.

— «Зәңгәр Хыял» дисең инде?

— Зәңгәр.

— Минем төс түгел. Шушымы ике катлы ишегегез?..

— Рәхим ит, өскә мен... менә бу баскычтан, аннары туры бар, — дип елмайды койрыклы гүзәл танышым. — Бәлки жиләнегезне монда эләрсез дип стенадагы бер кадакка төртеп күрсәтте. Чыннан да монда эссерәк икән, тирли башлавымны тойдым һәм плащымны калдырып, челтәрле баскычтан күтәрелеп, ике катлы ишек аша эчкә омтылдым. Керүгә, котым алынып кире чикмәкче идем дә, кабул итү бүлмәсенең ишек тоткасын янадан табып булмады. Кая карама астына учак ягылган корымлы казаннарда пошкырып сыеклык кайный. Үтә дә зур берсенә акбур белән «Казанга мең ел« дип сырлаганнар. Кайберләрендә «Мин монда булдым, фәлән углы фәлән, төгәненче ел» дип тә тырналганнары бар һәм әлеге исем-атлар арасында таныш кебек тоелганнары

да байтак. Йөри торгач төшендем, бу үзенчәлекле дизайн, шундый «а ля тәмуг» стилендәге джакузилар... Алар кырындагы өстәлчекләрдә «Татарстан» дигән язулы аракы шешәсе, кырлы стакан һәм өлеш тәлинкәсендә парлары чыгып торган сарделькалар. Джакузиларның кайсында нефть бокырдый, кайсында «Кызыл Шәрыкъ» сырасы чайпала, «Татарстан сөте» айкалганы да бар. Мин болар аша коенып үтеп, шәп басым белән Татарстанның минераль сулары бәргән душ астында пакьләнгәч, башлыклы йонлач халат киеп, өстәлчек янына утырам, кырлы стаканга салып хәмер уртлыйм, сарделькасыннан авыз итәм. Тәмле, шайтан алгыры, чит илдән кайтартылган чучка итеннән, ахры...

— Тукта әле. Бүген нинди көн соң? Атна кич ләбаса. Әбием, төштән соң атна кич җомга санала башлый, дия иде. Ә мин шундый изге көндә кая килеп каптым...

Түрдәрәк безнең ишеләр белән әңгәмә бара икән инде. Авыл сәхнәсе сыман гына калку урында кәнәфиләргә чумып, имтихан алучылар утыра. Мөгезләре дә бар кебек үзе, әмма калын чәчләре астыннан күренмиләр генә бугай. Һәм шулар алдында берәү, райком бюросына эшкәртергә чакыртып алынган җитәкче хәлендә, уртага басып хисап тота...

— Заманасында кабинетымда мин сөйләшкәндә бина тетри, урам янгырый, мәйдан шаңлый иде... Татар теле, татар мәдәнияте, татар мәгарифе ише вак мәсьәләләр минем рухны беркайчан да җилкетмәде. Татар телән рәтләп белмәдем, кирәген дә тапмадым, ни өчен — чөнки мин асыл интернационалист. Эшләдем дә эшләдем. Йөрисең республиканың фермаларын карап, һәм бер малне кеше йөземе ул, дуңгыз танавымы, аермасын тоймый башлыйсың... Һәм, көннәрдән бер көнне, мин тетрәтеп торган мәйданга килеп җыен әтрәк-әләм мина «долой» дип кычкыра башлады...

— Син ни телисең соң? — дип кызыксына Баш Имтиханчы.

— Утилләштерегез мине заманага яраклы итеп. Миллионер ясагыз, канса да канис.

— Уенга кергәнче синең миллионың бар иде.

— Дуллоровый. Дуллоровый миллионер булма келим.

— Тәк... Сөт короле бар инде безнең. Нефть, аракы, сыра, дару, банк, фән, дин өлкәләренең ияләре бар... Әйдә, сине ит короле итәбез. Ит дигәч тә, беләсеңдер инде, колбасаны ничек һәм нәрсәдән ясаганнарын... Булдырам дигән кешегә миллиард эшләү дә кыен булмас...

Кинәт әллә каян барлыкка килгән баскыч култыксасына охшаган, очы-кырые күренмәгән озын колбаса барлыкка килде һәм бу шуна атланып түбәнгә таба шуып төшеп китте. Бушап калган мәйданга итләч битле мәһабәт гәүдәле агай чыгып басты.

— Бөтен акча нефть белән газда. Безгә, мескен авыл районнары главаларына нишләргә? Көн-төн эш, көн-төн эш. Икмәк үстер, терлекләрнең нәселен яхшырт, һәм башкалар, һәм башка шуның ишеләр.

— Беләбез без сезнең нәсел эшен ничек яхшыртканыгызны... Бер кызыйны туеннан җилтерәтеп алып чыгучы син түгелме соң инде, киявеннән аерып?

— Эш бик авыр бит безнең. На всю катушку бушануларсыз булмый... Үз районыңда да рәхәт күрмәсәң, кая китә ул?!

— Йә, нәрсә кирәк? Акча гына сорама. Синең карамакта кеше җитәрлек, әмәлләр күп, сык, булдыра алган кадәр, авызың белән кош тотып йөрмә.

— Сыгабыз да... бүтән якны да онытмыйбыз, анысы. Әле менә район җирләрен энекәшкә турыладым. Инвестор исеме биреп. Элеккеге колхозчылар алдында чыгып сөйләде:

— Җир, — диде, — хәзер безнеке. Ни кушсак шуны эшлисез. Малларыгыз безнең рөхсәттән башка көтүлекләргә чыкса атабыз, урлыйсыз икән —

утыртабыз. Шикаять язып ерак китә алмаячаксыз — кояшны су сибеп сүндереп булмый! — диде.

— Вәт минем беренче теләк, менә шул асыл егетне, урынына малаен калдырып, кызлар күп укый торган берәр институтка ректор итәсе иде...

— Мондый ректорлар илгә кирәк, гозерең үтәлде дип исәплә. Икенче теләгенне әйт?

— Женси куәтне арттырмый булмас. Рас энекәш шундый эшкә керә, аның игелеген без дә күрмәсәк, халык дөрес аңламас, хи-хи-хи.

Баш Имтиханчы ишарәсенә буйсынып, койрыклы туташ моңа банкада ниндидер авыр исле сыекча китерде.

— Эч шуны! Борыныңны җыерма, дәү абзыегызныкы дип хис ит.

— Артыннан бер чүмеч спирт белән ярты бәкәй булса, кәкәй дә үтә!

— Сораганнарын китерегез!

Һәм агаебыз күзләрен чытырдатып йомып, сулышын туктатып, эре-эре йотымнар белән банканы бушатырга керешә. Максатына ирешкәч, бер кызарынып, бер яшелләнеп дигәндәй, укшымас өчен җан тартышты, аннары тынычлана төште, авызын киң җәеп елмайды һәм:

— Булды. Урнашты, — дип, кикереп куйды... Янә бер чүмеч спиртны җиңел генә авызына озаткач, ярты бәкәйне, кимерчәкләрен чытырдата-чытырдата ашап та бетерде.

— Өченче теләгегез? — дип кызыксынды имтиханчылар.

— Килгәндә истә иде, онытгым. Минем гел шулай: эчсәм ашыйм, ашагач хатын-кыз кирәк. Күплек санда булса, тагын да шәп! Ярый, Тукай премиясе бирерсез! Ашыгыч түгел, күләме бераз арта төшсен, түлке.

Кинәт дивар ачылып китте һәм анда асылмалы күпернең иңнәрәге күренде.

— Менә шушыннан аргы ярга тиз генә йөгереп чыгарга кирәк. Тәтәйләрнең нинди сорты кирәк, бар да аргы якта.

— Тизлекне ничек арттырырга соң? Минем тәкать калмады сезнең белән такылдап торып... «Уйлама син юк-барны, уйла бергә йоклауны», ди татар халык мәкале!

— Әнә теге өстәлдә нашатырь спирты бар, янә килеп пурген. Икесе дә булыша торган нәрсәләр... Ха-ха-ха...

— Һәй, кая килеп кая китмәгән, — диде алып агай һәм сөзәргә җыенган үгез сыман ыжгырып, күпергә кереп китте...

Мәйданчыкка, җилкәсенә төшеп торган чаларган озын чәчле, зифа буйлы интеллигент күтәрелде һәм тотлыга-тотлыга үзенекен такылдый башлады. Имеш татар халкына профессиональ музыка кирәк. Янәмәсе ул консерватория белемле композитор, өстәвенә пианист.

— Пьяница дип тә өстәмәдеме, — дип хахылдап куя кайсыдыр.

Әмма зыялы шәхес ул әйткәнне үткәреп җибәрә һәм үзенекен сайрый, имеш ки эфирда татар җырлары дип тәкъдим ителә торган нәрсәләр татар җыры булудан ерак торалар...

— Син нинди көферлек кылып монда килеп эләктең соң, хөрмәтлем? — дип кызыксынасы итте Баш Имтиханчы.

— Әллә тагы.

— Татарга чын музыка да, чын җырчы да, чын композитор да кирәкми.

— Кирәк. Сәйдәш, Фәрит Яруллин, Латыйф Хәмиди, Хәйдәр Бигичев, Таһир Якуп язмышларыннан чыгып әйтәсездер? Әйе, Габдулла Рәхимкулов, Сара апалар да хакимияттән рәтле-башлы кадер-хөрмәт күрмәде. Чөнки аларны, Зифа апа Басыйрова әйткәнчә, халык яратты!!!

— Яхшы, ни телисең соң, мон сакчысы?

— Сөембикә турында опера, Олуг Мөхәммәднең җиңүе, «Казанның алынуы» кебек тематика буенча рәссамнарыбызның күргәзмәләре, Сөембикәгә һәйкәл,чын татар мәктәпләре, чын татар опера һәм балет театры, чын татар консерваториясе, чын татар музыкасы мәктәпләре, чын Татар университеты, кыскасы милләткә тын алырга һава сорыйм.

— Тукта, син үзеңне кая эләктем дип беләсең?

— Югарыга!

— Салган баштан анда ашып була дип уйлыйсыңмы? Кем сине безгә юллады?

— Мәҗлескә дәштеләр. Сыйландылы. Аккордеонда уйнадым. Бер эшмәкәрнең бу изге җанны фәрештәләр катына озатыйк, дип хихылдаганы истә калган. Мин сезнең кемлекне чамалый башладым бугай...

— Телисеңме, бераь чит илгә озатам. Үз оркестрың булыр.

— Юк, — диде интеллигент, чал башын чайкаштырып, — койма буенда ятып, ачтан үлсәм үләм, ә Казаннан китмим.

— Озатып куегыз үзен.

— Койма буенамы?

— Ишетеп тордыгыз ләбаса теләкләрен: Казанда, койма буенда, ачтан...

Композитордан бушаган мәйданчыкка телеэкраннарда еш күренгәләүче бәндә килеп чыкты.

— Кем бу? — дип кызыксынды Баш Имтиханчы.

— Мине дә белмәгәч нишләп кенә утырасыз соң сез монда? — дип тузыныуын белде күпертмә чәч. — Милләт өчен мин эшләгәнне төясәң ат та тарта алмас. Мин — Минзур Синзурович Түбәнүбә!

— Милләтенә зур хезмәтләр куючы нишли биредә?

— Борчылмагыз тәкъсир, ул үзенең үткән гомерен шулай бәяли.

— Әйт, ни телисең?

— Милләт сәнгатен үстерү өчен уникe миллион сум акча бюджетта чагылыш тапсын!

Кинәт әллә каян чүп һәм сайлау бюллетене салына торган ачык урналар пәйда булып, Минзур Синзурович Түбәнүбә боларның берсенә уң, икенчесенә сул аягын киде дә тартмалар моны каядыр очыртып алып китте...

Менә уртага аюга атланган, нибары галәфи чалбар гына кигән ир-ат пәйда була.

— Теләгең?

— Русия илбашы булу.

— Россия — демократик дәүләт, кандидатураңны күрсәтәсең һәм лаеклы булсаң, сайланасың.

— Ул әле күп кавемле дәүләт тә. Әйтегез, төрле кавем юлбашчыларының миләрен ничек лашпырдатып әйләндереп капларга? Каты кылансам көнбатыштагылар дөньяны сасытачак...

— Алар маймыл тоту әмәленә каршы чыга алмый...

— Ысулның асылы нидән гыйбарәт?

— Папуаслар агачка тар куыш ясап, шуның эченә чикләвек салалар. Маймыл тишеккә кул тыга, чикләвекне учлый һәм эләгеп кала. Учына эләккән чикләвекне калдырырга комсызлыгы рөхсәт итми. Аңлашылдымы?

— Ахырынача түгел.

— Кәнәфи биләүче бюрократларына сортына карап нефть скважиналары, завод-фабрикалар, рестораннар, гипер-супермаркетлар, башкасын тоттырасың... Ә гади күпчелек шымытыр учлый.

— Ә иҗади интеллигенцияне нишләтим?

— Бака кабарт.

— ....

— Төрле титуллар, мандатлар биреп, шулардан югары катлам әтмәллә. Аннары, иләк белән су ташу, комнан бау ишү сымаграк вазифалар оештырып, шуларны урынбасар дипме, арбаның бишенче тәгәрмәчеме дип атап, мәзлүм каләмдәшләренең каткан ипие хисабына 80-100 мең сумлык окладларга утырт. Менә сиңа әкәмәт югары көчәнешле кыска ялганыш. Нәфрәт югарыга китми, сиңа менеп житми дигән сүз...

...Чират мина житте. Мин дә шул калку мәйданчыкка чыгып бастым, ә имтиханчыларым Т хәрефле өстәл тирәли тезелешкән. Бар да калын чәчле. Шуңа күрә чәчләре астында мөгезләре бармы-юкмы икәне шәйләнерлек түгел.

— Әйт теләгеңне!

Шулчак мина әллә нәрсә булды. Шайтан алгыры, монда бит хәсислек тарафдарлары утыра! Болар бит мине кысрыклаучы эшемияләрен якынрак күрәчәк? Их, кая килеп, кая китмәгән!

— Татарстанга тулы мөстәкыйльлек, аның егылган дәүләтчелеге торгызылуын телим!

— Кендегегез чишелмәсме икән? Кайчак ни теләгәнегезне аңлап бетермисез. Сөргеннән кайткан кырым татарларына калдырып киткән йортларын кире бирмиләр, яңа йорт салырга җир бүлми тилмертәләр. Казан татарының кабер ташлары чиркәү нигезендә ята. Мөселманнарның ае, шашлык ите кисәге сыман, тәре хәнҗәр аша үткәреп, чиркәү гөмбәзенә беркетелгән. Менә ничек раслана дәүләтчелеккә хокук! Син үз халкыңның җинүчән рухын терелтер өчен, аны шуңа охшаш гамәлләргә күтәрергә сәләтлеме соң?

— Ай-һай...

— Азатлык алу бер хәл, әле шуны кулдан ычкындырмау өчен, дошман дәүләт халкына гына түгел, ә киләчәктә куркыныч тудырырга мөмкин барча кавемнәргә каршы астыртын рәвештә этлек арты этлек оештыру кулай. Монысына ничек карыйсың?

— Тискәре. Гадирәк юл юкмыни азатлыкка?

— Бар, әлбәттә. Әйтик, сине шундый вәкаләтле итсәк, халкыгыз санынча дуңгыз үрчетүгә ничек карыйсың? Хуҗабызга багышлап башкалагызның бер матур мәйданына һәйкәл салдыруга да каршы түгел. Әйтик, Ленин бабагыз урынына. Ана табыну бетте бит инде, юкка урын били!

Каршыда экран барлыкка килеп, анда кәҗә башлы куркыныч җан иясе пәйда булды.

— Шәп бит!

— Бу шартларыгыз милләтне тәмуг кисәүләренә әйләндерүне күздә тота кебек?

— Димәк, син татар халкының дәүләтчелеге торгызылуын теләмисең булып чыга?

— Илең турында уйлама, үзең турында уйла, — дип язганмы әле бер халык шагыйрегез. Үзенә ни кирәк? Бәлки кемнедер ил-күз алдында хурлыкка калдырасыдыр?

— Сез аның кем икәнен беләсез.

Һәм мин каршымда кинәт пәйда булган ике катлы ишек аша әбәләнеп, кабул итү бүлмәсенә чыгам. Анда калакта элеп калдырган плащымны эзлим. Житмәсә мөгезле туташ та каядыр олаккан. Ул ара да булмады, ишек төбенә «м 666 дж» дигән номерлы шәп бер машина килеп туктады һәм аның шофёры мина утырырга ымлый.

Мина нидер булды, төп башына утыртулары ачысыннанмы, плащсыз калу да шуңа өстәлдеме, «Татарстан» маркалы хәмер артык куәтле идеме, теге туташның киштәгә элеп калдырган букчасын эләктердем дә машина артына

кереп утырдым. Юл буе шунын эчендәге шалтыравык нәрсәләр белән уйнап кайттым. Кайта торгач, андагы визиткалар, бизәнгечләрне идәнгә үк чәчеп җибәрдем шикелле... Әллә кемнәр белән бутала икән бу хәерсез...

Машина «ә» дигәнче өемә кайтарып куйды. Хәер, Айдамы, кайдадыр туктап кече йомыш та йомышланды бугай.

## Бәла аяк астында

Таң атарга ерак калмаган икән. Өйгә кайтып авып, бер-ике сәгать черем иттеммеюкмы, инде торырга да вакыт җиткән. Бер стакан каты кайнар чәй эчтем дә эшкә ашыктым. Озак та үтмәде, кизү милиционер «сезгә килгәннәр» дип телефоннан хәбәр итте. Килүче Галихан шоферы булып чыкты. Баксаң, «тегендә» сумка югалу зур күңелсезлек тудырган, бассейн диварындагы сүрәттәгеләр терелеп, Галиханның якасыннан бөтереп алганнар, мөгезле туташның долларлары тулмый, имеш...

— Мин алмадым, — дип мыгырдандым.

— Алгансыз. Сез бит уйнап кайткансыз. Әнә сезне кайтарган шофёр кабинада утыра. Ул шулай ди.

Мин машина ягына күз ташлыйм һәм кичәге танышым, оялчан гына елмаеп, миңа кул болгый.

— Әйе, уйнадым бугай шул... Аһ, юлда туктап һавага да чыгылды бугай... Шунда төштеләр микәнни? Бик күпме?

Минем эч «жу» итеп куя. Инәңне корт чаккыры, бу бит йөз мең доллар дияргә дә күп сорамас

— Шактый. Безнең акча белән утыз мең чамасы. Хуҗаның кесәсендә унбиш мең бар иде, калганын үзе түләсен дип, сезгә озатты.

— Чак кына сабыр ит.

Йөгерә-атлый бүлегебез коридоры буйлап алга омтылам.

Ишекләрне йолыккалыйм. Тәк, юл хәрәкәтендә тәртип саклаучылар урында түгел, каядыр китеп олакканнар. Аптырагач, тикшерүчегә барып егылам.

— Бөтен өмет синдә, дим.

— Миндә каян акча булсын? — ди бу.

— Хет каян тап.

— Тентү вакытында протокол белән алган бакслар сейфта ята, арада чыннары да бар. Шуларны алып бирсәм генә инде.

— Эшеннең срогы кайчан чыга?

— Ике ай бар.

— Бир. Чыны кирәк. Получка алуга түлим.

— Сез бик дулкынлангансыз, башыгыз да чатный бугай, менә монда участковый Зөфәр алып кайткан үлән тамырлары салып эшкәртелгән көмешкә бар, каплагыз берәр стакан булса да.

Мин акыллы киңәшкә колак салам.

Аннары банкнотларны алып чыгып шофёрга тапшырам... Ул иренмичә, кат-кат санап кабул итә. Күрәсең, аның алдында ышанычым мәңгегә югалган. Ләкин бу мине әллә ни борчымый.

## Соңгы хат

Баштан үткән әлеге хәлләр мине тәмам чыгырдан чыгарды. Хәер, яшәү маятник сымак инде ул: әле чөя, әле түбәнгә томырыла.

Стаж тулуга пенсиягә аткардылар. Галиханга барып эшләргә ният бар иде... Өлгермәдем... Кемнәрдер башына җиткән... Яман хәбәр тиз йөри, диләр,

көнендә иреште. Аннары, өч-дүрт көн узгач хаты килде. Теге дөньядан язган сыман тоелды... Күрәсең хат кайдадыр тоткарланган, почта эшендә андый хәлләр булгалый бит...

*Сәлам, Зәет туган! Сиңа бу хатны Галихан яза. Сәлам шулай ук хәләл җефетеңә, балаларына. Сәлам соңында языласак сүзләргә күчәм. Бизнес — минем өчен сәнгатьнең бер төре булды. Баштарак дәү агайлар, безнең хозурда әниләре чели алып кайтканны зарыккан кош балалары кебек кайнаша иде. Гарәп илләренә чыкканда бүләккә минем ханзәкәдән Златоуст осталарыннан эшләткән зиннәтле кылычларны алып киткәләделәр. Ваграклар, авызларына берәр айны җим салырга онытсаң, үзара, әллә сиңа да китермәде, миңа да тамызмады бит ул бу юлы — ди-ди, сукранышырга, юлга киртә-корта торгызырга керешерләр иде, рәхмәт яугырлары... Инде бар да үзгәрде, уңышлы бизнесың бар икән, өлешкә керәләр, аннары тулаем тартып алулары да ерак йөрми. Ваграклар да азды, китергәненне кулың белән бергә йолкып алырга әзерләр... Соңгы вакытта төрлесен уйлыйм. Әгәр минем белән бер-бер хәл булса, казына күрмә. Үзен дә тотынма, дусларынны да алгысытма. Җеп очы ерак, ул чәрексез һәм кайда кирәк шунда өзеләчәк.. Тәтегә басучыны табудан мәгънә дә бәләкәй — үзең беләсең, ул бер чара гына, аңа эш бирүчесе һәм корбаны кемлеген белү ни пычагыма... Ә менә гаделлек эзләгән атлы актарыну, тәфтишләү барышында гел кирәкмәгән мәгълүматлар табып, булмаганнарын да өстәп кайбер «дуслар» минем хакта гайбәт куертулары бик мөмкин. Халык күнелендә матур булып каласы килә һәм моңа хакым бераз бар дип өметләнәм. Хәтерлисеңме, син әйткән идең, безнең хезмәт, эш урыннарыннан явыз ният белән файдаланучыларга һәм спекулянтларга каршы көрәш алар җиңде, шуңа күрә ин элек БХСС ны бетерделәр, дип. Ә мин, юк, социалистик милек бетте, шуңа хезмәтегез табигый рәвештә төкәнде, ирек җиңде, аның нигезе ирекле бизнес, шул өстен чыкты, дип очындым... Баксаң, безнең сыман ирекләләр, үзгәреш дулкыны өскә чыгарган күбек кенә булган. Вакытлыча күренеш. Минем әтине талап, иленнән сөргән өер варислары дилбегәне тиз кыскартты... Хәзер һәр өлкәдә, тармакта йөзсезләр канат яра... Талантка көн бетә.Бизнеста ирек юк икән, башкача була да алмый. Теге уенның төп шартын белә идең микән, син сорамадың, мин әйтмәдем шикелле. Уенга катнашуның хакы, гомерең фаҗига белән очлануына ризалашу иде...*

Хат, көне, елы күрсәтелеп, кул куюю белән тәмамлана. Тукта, бу бит аның имзасы түгел.Монда бит имза шәкелендә сырлап, «Хушыгыз» дип язылган...

## Актыккы сүз

Галихан мөхтәрәм зат иде, мәрхүмкәй. Кайда эшләсә дә, олы була белде. Бар, әлбәттә, әллә ниткән югары урыннарга үрмәләүчеләр. Кәнәфиләре биек, вөҗданнары сыек, халыкка игелек эшләү мәҗбүрияте алдында калган очракта, Дәүләтхан ага әйтмешли, тизәкләрен мыскалга салалар... Авылдашым, бозаулар караучы Минзифа апа әйтмешли, җир җирәнгечләре...

...Кемнәр белән генә аралашмыйсың бу тормышта. Һәм бер очрашу да юкка гына түгел, ахры. Байтак еллар элек, эре генә хуҗалыкның умартачысы белән юлларыбыз кисеште. Шикаять язганнар иде өстеннән, имеш, хуҗалык балының бер өлешен керемгә алдырмый гына сатып ята...

— Син бик вакчыл кеше, — диде ул, күзгә батырып карап. — Әгәр, күпмедер өлеш керемгә алынмаган икән, димәк хуҗа шулай хәл иткән. Хуҗалыкны алып бару илдә шулай корылган. Сездән сорап тормаганнар . Минем гөнаһым юк. Бал кортлары белән намуссыз кеше эшли алмый, алар бик чиста җан ияләре, сездән

сизгер һәм мәгънәлерәк. Мина бәйләнүдән тукта һәм мин сина үземнен эш серемне өйрәтим. Пенсиягә чыккач, кангырып йөрмәскә, тормышка тотынып өчен бер үнәрен булыр...

Суырылып кереп киттем бит шул кәсепкә. Эштән озатканда бирелгән акчаларыма әрҗәле «УАЗ» машинасы алып җибәрдем. Умарталарымны бер карабодай басуыннан икенчесенә шунын белән күчереп йөртәм. Ике авыл арасындагы агач күпер генә хәвефкә сала, тәки төзәтмәделәр шуны, берәрсе җимерелеп кадалганны көтәләр булыр...

Тагын нәрсә әйтим. Язу сәләте барлар килсен милициягә, сынап карасыннар каләмнәрен... Бармактан суырып иҗат итә торганнары да унайсызланып тормасын.

Язмаларымны күздән үткәргәндә бер мәсәл искә төшеп куйды.

Чаян, елга ярында ташбакага ялына.

— Зинһар, аркана кочтырып күрше ярга алып чык, юкса бу ярда ашарыма калмады, — ди икән.

— Бик алып чыгар идем дә, чагарсын дип куркам, — дигән ташбака.

— Син мине кем дип белден, — дип өзгәләнгән чаян мона бик тә рәнҗеп.

Ташбака түзмәгән, чаянны аркасына алып күрше ярга йөзеп киткән. Барып та җиткәннәр, чаян моны чаккан да. Ташбака сыртына әйләнеп төшкән һәм дүрт аягын дүрт якка ташлап хәлсезләнеп ята икән. Менә ул көч-хәл белән телен әйләндереп:

— Син нишләден? Чакмыйм дип вәгъдә биргән иден ич, — дия алган.

Чаян кытыршы кырыс чыраен капшавычы белән кашып куйган һәм:

— Менә мин шундый хәшәрәт инде, — дип монын янынннан китеп барган...

Язганнарымны кемнәрдер укыса, минем хакта да шулай уйламагайлары дип куркып куям...

***

Милициядә эшләп ялга чыккан танышымнын язмалары шушында тәгалләнә. Ул күптән түгел генә юл һәлакәтенә юлыгып харап булды. Балалар төялгән автобусны «УАЗ»ы белән узып, килеп керүе булган, урталагы терәкнен нигезен су ашап бетергән булган икән, күпер җимерелгән. Үлеме, сабыйларнын котылуына сәбәп булган. Аны зиратка озатышырга халык байтак җыелган иде, җеназасын мин дә күтәрештем. Зиратка барып җитеп, җәсәден җиргә куйгач, авыл мулласы сорый куйды:

— Әйбәт кеше идеме бу җәмәгать?

— Бик әйбәт кеше иде. Гадел иде... Кайчандыр балалар да укыткан. Инде аңа сират күпереннән имин узуны Хак Тәгалә насыйп итсен, — диеште авылдашлары...

Әманәтне мәрхүмнен хәләл җефете тапшырды, бәлки төзәткәләп кая да булса бастырырсын, диде. Мин инде анын гозерен аяк астына салмаска тырыштым, ник дисәгез, күчтәнәчкә бер банка бал да алып килгән иде...

*2014 ел*



Чыңгыз
Мусин

# ШИГЫРЬЛӘР БИТ ҖИРДӘ ЯЗЫЛА

## Җилләр, җилләр

Исә җилләр сискәндереп,
Исә авыл өсләрендә.
Моржалардан кереп сайрый
Иртәләре-кичләрендә.

Җилгә каршы юлга чыксам,
Рухи азык биштәремдә.
Һәр сәфәрем — изге сәфәр,
Күңелемне хисләндерә.

Гомер өркеп үтә, димә,
Җилләр алып китә, димә.
Ул төннәрдә ятып йоклый
Тәмәй тауның итәгендә.

Исә җилләр, исә генә,
Җилле көннәр исәбенә.
Уйландыра, шомландыра,
Тынгысызлык шуннан гына.

Иж ярлары гүя упкын,
Иж сулары дулкын-дулкын.
Җәйләрендә кәккүк саный
Без яшисе гомер чутын.

Агымсудай агып китте
Михнәт белән узган гомер.
Замананың үзгәрүе,
Билләһи дим, бездән түгел.

Чыңгыз МУСИН (1934) — *шагыйрь; «Язмыш үзәннәрендә», «Баганалы юллар», «Карт юкәләр яшь чәчәктә» һ.б. китаплар авторы. Әгерҗе районы, Тирсә авылында яши.*

Авыл киче әвәлгедәй,
Жырлы-моңлы кичләр түгел.
Яшь буынның күнелендә
Без кичергән хисләр түгел.

Тик шулай да үткәннәрнен
Кайтавазы күнелләрдә.
Нинди бәхет тәүге моннар
Күнелләрдән түгелгәндә.

Иж буйлары язны көтә,
Әле жиргә ак кар яткан.
Кыр казлары алып кайтыр
Жир жылысын жылы яктан.

Жилләр, жилләр, жилләр инде,
Жилгә форсат килгән инде.
Жилдән житез чаклар узды,
Без кемнәргә тиңнәр инде?
Без хәзер тик кемнәр инде?

## Зур югалту хисе

Яр буйлары текә,
Үрдә каен, юкә.
Ижнең дулкыннары
Ярны юып үтә.

Яр өстендә авыл,
Килә төтен исе.
Язмыш дәфтәренә
Бары да сыйган төсле.

Тормыш бимазасы,
Үксез калган авыл.
Жимерелә бара
Чыкмаса да давыл.

Үр өстендә тормыш,
Шаулый каен,юкә.
Ләкин карт авылны
Алданиләр көтә?

Назлый язгы жилләр
Кыйбла уңаена.
Печән чапканым бар
«Нарат тугае»нда.

Гомерем буе мендем
Язмыш басмаларын.
Мин ижади изге
Гамәл башкарамын.

Гүя бүген уздым
Тормыш бусагасын.
Еллар агышына
Килми ышанасым.

Күпне күргән башлар
Гомер агышында.
Ник битараф күпләр
Кеше язмышына?

Авыл тирен түгә
Сукыр бер тиен хакка.
Иллә кайсы түрә
Уйлый шушы хакта?

Үксез калган авыл,
Нурсыз иртә-киче.
Утсыз яна жанда
Зур югалту хисе.

## Нигезең тартадыр ул

Бәхетне читтән эзләмә,
Туган ягыңнан эзлә.
Һәр таңда бәхет кояшы,
Нурланып калка бездә.

Бәхетне читтән таптым, дип
Юату сүздә генә.
Барыбер сагыш басадыр
Гомерең күзләрендә.

Туган якны сагыну хисе
Олыгайгач артадыр ул.
Балачакта уйнап үскән,
Нигезең тартадыр ул.

## Хәтер сәхифәсе

Тагын бер ел үтеп, артта калды,
Бик тиз узган кебек сизелде.
Тормыш бусагасын бер мизгелдә
Үткән кебек тойдым үземне.

Быелгы ел — атлар елы, диләр,
Елгыр атлар утлар болында.
Ат дигәндә, алар затлы жаннар,
Жырлар туа алар турында.

Безнең инде малай чаклар узган,
Йөрмәсәк тә атка атланып.
Еллар кайтавазы сискәндерә,
Хәтер сәхифәсен актарып.

Болыннарда йөрим бер ялгызым,
Үзем белән үзем сөйләшәм.
Оныкларым миңа ышанырмы
Безнең язмышларны сөйләсәм?

Газиз башта уйлар беткәнме?
Бүгенгене уйлыйм, үткәнне.
Сөйләмичә ничек түзмәк кирәк
Атлар белән гомер иткәнне?

Кыш айлары карга төренгәндә
Төрле уйлар туа күңелдә.
Күтәрәмгә калган арык атлар
Күз алдымнан китми бүген дә.

Илдә давыл купкан чакларда
Бөтен терәк булды атларда.
(Яу кырыннан «кара хәбәр» яуды
Өчпочмаклы конверт хатларда.)

Авыл саклый изге йоланы,
Сабантуйлар атсыз буламы?
Мәйданнарда узган бәйгеләрдә
Бахбайларның даны югары.

Ат язмышы — безнең уртак язмыш,
Саклана ул һәрчак йөрәктә.
Бәрәкәтле булсын атлар елы,
Калыйк шушы изге теләктә.

## Фаҗига

Яшьлегемдә бик күп шигырь яздым,
Бар кеше дә мине аңлады.
Минем гади, хисле шигырьләрне
Аңламаган кеше калмады.

Хәзер инде мин башкача язам,
Мин тормышта үзгә фикерле.
Шигырьләрем белән житәкләшеп,
Күккә ашып барам шикелле.

Бер-бер артлы поэмалар туа,
Яңа жырлар тора өстәлеп.
Тик бер көнне сездән аерылсам,
Калсын димен миннән истәлек.

Мин хыялда күккә күтәреләм,
Биеклектән жирне күзлимен.
Аякларым жирдән аерылган,
Йолдызлардан серләр эзлимен.

Мин бик гади идем, тыйнак идем,
Хәзер мине күпләр санламый.
Шигырьләрне инде укымыйлар,
Чөнки мине беркем анламый.

Үрелсәң дә шөһрәт тажына,
Шигырьләр бит жирдә языла.
Аякларым жирдән аерылса,
Ижатта бу бик зур фажига.

**Редакциядән.**

*Бу айда өлкән каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

---

*Укучы сүзе*

## УЛ «АГУЛЫ КАЗАН»НАН ИСӘН ЧЫГУЧЫЛАР АЗ

Сүзне 1нче, 2нче саннарда чыккан романнан башлыйк әле. «Патша солдаты Әхмәтнәсир» бу. Чаллыда яшәүче Хәким Галидән язган аны. Өч гасыр элек Оренбург якларында яшәгән татарлар, башкортлар тормышы сурәтләнгән әлеге романда. Борынгы бабаларыбызның яшәеш күренеше, башкарган эшләре гаять төгәл тасвирланган. Әлбәттә инде, әсәрнең төп герое Әхмәтнәсирнең образы аеруча бай сурәтләнгән. Героебыз Пётр I гаскәре сафында төрекләргә каршы Азов походында (1695-1696), аннары шведлар белән озак еллар (1700-1721) Төньяк сугышларында катнаша. Һөҗүмгә барганда каты яралана...

Һич шикләнмим, авторга рәхмәт сүзләрен укучыларыбыз күп әйтәчәк әле...

Бөек Ватан сугышының җиңү белән тәгәлләнүенә киләсе елда 70 ел тула. Шул унайдан журналда махсус сәхифә ачып, сугыш турында документаль язмалар, хатирәләр биреп барасы иде. Сугыш ветераннарының үзләреннән дә сөйләтеп. Исән ветераннар бар әле алар, бар!

Укучыларыбызның игътибарын былтыргы 12нче санда чыккан, «Нинди жир ул Суслонгер» дигән хатирәгә дә юнәлтәсем килә. Сугыштан исән кайткан Мөхәррәм Шәрипов язып калдырган аны.

«Суслонгер» дигән сүз минем өчен һич тә гади генә яңгырамый. Чөнки ул «агулы казан»да әтием Абдулла да кайнийсы булган. Ходай үзе саклап калгандыр инде. 1941 елның июнь азагында повестка килә аңа. Суслонгерга баручылар Бакалтай пристанендә инде пароходка төялергә торганда өч ир-ат чабып килеп, әтиемне кире Казанга алып китәләр. Шушы бер эшче (шорник) булмаса, «Точмаш» заводында минометлар житештерү туктап каласы икән бит!..

Бөгелмәдәге танышым Рәмзис Кадыйровның әтисе Рәхим абый Суслонгерда ачлыктан үлгәндә кала. Үзе теләп фронтка китә — бу лагерьда үлемнән котылуның бердәнбер юлы шул була. Китаплардан укып беләм, Муса Җәлил дә булган монда, аны да фронтка ашкынуы исән калдыргандыр инде.

Исләрен-акылларың китәрлек! Житмеш елдан артык вакыт узды, тик бер генә язучы да Суслонгер темасына каләмен тибрәтеп карамады әле!..

**Мансур ҖӘЛӘЛИЕВ.**
*Казан*



«Казан утлары» журналына 80 ел тулу тантанасының зал күренеше. Милли-мәдәни үзәк. 2002 ел.



Казансу ярында, Милли-мәдәни үзәк янындагы «Хөррият» сынын урнаштыру вакытында төшерелгән фото. 1996 ел.



Татарстан Язучылар берлеге карамагында эшләп килгән чуаш язучылары секциясе әгъзалары. 1973 ел.



*Авылга укучылар белән очрашуга баргач. Уңнан сулга: шагыйрьләр Рәдиф Гаташ, Мөдәррис Әгъләмов, Рәшит Әхмәтҗанов, галим Назыйм Ханзафаров. Үткән гасырның 80нче еллары.*



*Вил Ганиев (1934-2005) – тәрҗемәче, галим. Үткән гасырның 50нче еллары ахырында «Совет әдәбияты» («Казан утлары») журналында эшләде.*



*Мәскәү Сабан туенда очрашу. Шагыйрь Әхмәт Саттар һәм җырчы Альберт Асадуллин. 2001 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *алып бара.*

# БЕРЕНЧЕ БӨТЕНДӨНЬЯ СУГЫШЫНДА АЛМАНИЯДӘ МӨСЕЛМАН ӘСИРЛӘРЕ

## 6. Мөселман әсирләренең шәхси язмалары

«Казан утлары»ның алдагы санында басылган мәкаләмдә мин мөселман хәрби әсирләренең хатлары турында сөйләсәм, бу мәкаләмдә, бер караганда, шул ук сюжетны дәвам итәчәкмен. Ләкин бүгенге мәкаләмдә күбрәк әсирләрнең «үзләренә» сүз бирергә тырышырмын. Бернинди тарихчы да әсирлек фаҗигасен шул кадәрле җанлы һәм тетрәндергеч итеп бирә алмас. Бу язмаларда барысы да бар — хис тә, көндәлек тормышны яктырту да, истәлек өчен китерелгән мәгълүматлар да, әдәби яки фольклор текстлар да.

Инде искә алынган Берлин китапханәсе җыелмасында мөселман әсирләренең хатлары гына түгел, блокнот формасында көндәлекләр дә, төрле башка язмалар да сакланган.

Алар нинди максат белән язылган соң? Бу сорауга төгәл җавап бирү бик кыен. Уйлап карыйк: кешеләр әсирлектә, дошман кулында, алар иртәгә нәрсә буласын, туган өйләренә кайта алырлармы, юкмы, белмиләр, ә истәлек итеп тормышларында булган вакыйгаларны яки күңелләренә хуш килгән җыр текстларын матур итеп кәгазьгә төшерәләр. Минем уйлавымча, әсирлек шартларында язылган көндәлекләр, бер яктан, татар халкына традицион рәвештә хас, язма яки басма сүзгә булган ихтирамны чагылдыра — андый язмалар нормаль яшәү шартларында да еш очрый. Кызганыч ки, техник тәрәккыят безне бу традициядән «азат итте» шикелле — без бүген машина-компьютерга күбрәк ышанабыз, хатлар язмыйбыз, көндәлекләр алып бармыйбыз... Минемчә, зур югалту бу. Көндәлек алып бару һәр кешене тәртипкә, пөхтәлеккә, уй-фикерләрне берләштерергә өйрәтә ләбаса. Икенче яктан, әсирләрнең көндәлекләре һәм башка язмалары алар арасында сүнмәгән-сүрелмәгән туган илгә кайту хыялының көчен, мөселман әсирләренең оптимизмын да тасвирлый.

Хәзер инде бу әһәмиятле һәм кызыклы язмаларның эчтәлегенә күз салыйк.

Менә Вюнсдорф лагереннан бер әсирнең гади арифметикасы. Ул туганнарыннан алган хатлар һәм посылкаларның статистикасын алып барырга тырышкан, хәтта посылка алу таблицасын да төзегән, аларның килгән көннәрен һәм алты санлы номерларын шунда теркәп барган. Аның исеме һәм чыгышы билгесез, болар искә алынмый, ләкин әлеге статистикага ышансак, 1916 елның декабрендә ул өеннән алты посылка һәм биш сум акча алган, 1917 елның 22 маенда ике посылка алган, 29 майда ата-анасыннан хат килгән. 22 июльдә ул өеннән 9 июньдә язылган хатны алган. Шул ук 1917 елда посылкалар тагын 28 август, 17 һәм 26 сентябрьдә («авылдан сохари») килеп җиткән, ә менә 4 октябрьдә килгәнен юлда кемдер ачып, исле сабынны урлаган, шулай да 5 декабрьдә тагын бер посылка кәефен күтәреп җибәргән, анысында «чәй, ярты фунт шикәр һәм сохари» булган.

Әлеге мәгълүматлар төгәлме-юкмы, анысы бу очракта иң мөһиме түгел, иң мөһиме — Беренче бөтендөнья сугышы елларында мөселман әсирләре Алманиядә лагерьда да тулы изоляция хәлендә калмаган, сонарып, югалтулар белән булса да өйләреннән хатлар да, посылкалар да алып торганнар.

Бу фикерне раслаган тагын бер факт: икенче бер әсир, чыгышы белән Самара

---

*Ахыры. Башы 2-6 саннарда.*

губернасы Ташбулат авылыннан, истәлек итеп блокнотына русча «1916 елда Галәметдиннән — 20, Хөсәеннән — 2, Мусадан — 2, Котлыгыштан — 4, Гыйбадулладан — 1, Ишмөхәммәт каенатадан — 8, Токанайдан 6 хат алдым», дип теркәп куйган.

Әсирләр блокнотларына бик еш хәрби хезмәт вакытында яки инде әсирлектә танышырга насыйп булган иптәш солдатларының адресларын яза торган булганнар — рус һәм татар телләрендә. Кайбер авторлар вак фактларны, кызыксындырган мәгълүматларны язып барганнар, ул язмалар арасында кайвакыт бернинди бәйләнеш тә юк. Мәсәлән, бер блокнотта дисталәгән солдатның адресы язылган, аннан соң Морзе әлифбасының аңлатмасы, сыер токымы исемнәре, ин файдалы химик ашламаларның атамалары бирелә. Шул ук блокнот хуҗасы, күрәсең, әсирлек вакытында алман телен өйрәнә башлагандыр — биредә ул алман һәм литва телләреннән мисаллар китергән һәм аерым сүзләрнең татарчага тәрҗемәсен биргән. Кеше кеше булып кала шул, авыр булса да, барыбер яңалыкка, белемгә омтыла. Бәлки, кайберәүләр өчен шундый язмаларны алып бару күргән михнәтләргә каршы табигый бер реакция булып торгандыр — кеше үз дөньясына күмелеп киткән, тирә-яктагы авырлыкларны күрмәскә тырышкан. Ә бәлки бу язмалар бары тик аерым кешеләрнең холык-фигыльләре, аларның битараф булмаганлыгын гына чагылдырадыр? Ничек кенә булмасын, ул язмалар әсирләрнең көндәлек тормышын, аның авырлыгын яки бәләкәй генә булса да шатлыкларын хәзерге көн укучысына җиткерә.

Блокнотларда дини язмалар да еш очрый — Коръән сүрәләре, гыйбрәтле текстлар, догалар — алар хәтердән язылганмы, әллә башка басмалардан күчерепме (лагерьда китапханә булганлыгын онытмыйк) — анысын әйтә алмыйбыз. Ләкин шунысы бәхәссез: бу язмалар һич тә алман яки госманлы пропагандасы нәтиҗәсе түгел. Аларны без бары тик әсирләрнең дөньяга электән үк формалашкан карашларының чагылышы дип кенә бәяли алабыз, чөнки, мәсәлән, шул ук блокнотларда җиһад яки кяферләргә каршы изге сугыш алып бару зарурлыгы бер сүз белән дә искә алынмый. Әсирләргә бөтенләй башка нәрсәләр әһәмиятлерәк булып тоелган. Дөрес, ике блокнотта без төрек телендә аерым текстларны күрә алабыз. Мәсәлән, күренекле прозаик, шагыйрь, драматург Нәмык Кәмал, сәясәтче һәм язучы Мәхмәд Әмин яки кайбер башка төрек зыялыларыннан өзекләр. Шулай да мин әсирләрнең төрек текстларын блокнотларына күчерүен һич тә госманлы солтаны игълан иткән җиһад белән бәйләмәс идем. Мәгълүм ки, XIX йөздә татар-төрек мәдәни бәйләнешләре шактый интенсив булган, XX йөз башында, Госманлы дәүләтендә реформаларны яклаучы хәрәкәт башлангач, татар зыялылары бу хәрәкәт белән ихлас кызыксынганнар, шуңа күрә алдынгы һәм популяр төрек язучыларының әсәрләре Русия мөселман әсирләренә таныш булган икән, бу һич тә очраклы күренеш түгел — бу инде сугышка кадәр татар җәмгыятенең Госманлы дәүләтендә барган үзгәрешләр белән танышуын гына исбатлый торган факт.

Әсирләрнең кайбер блокнотларында чын мәгънәсендә көндәлекләр дә күрергә мөмкин. Кайберләре бик кыска, аерым, иң әһәмиятле вакыйгаларын гына искә алалар, кайберләре, киресенчә, солдат яки әсир тормышын тасвирлый торган вак детальләрне дә китерәләр. Мәсәлән, әсирләрнең берсе көндәлегендә күбрәк дини бәйрәмнәрне генә аерып күрсәткән:

«1916 елда июньнең 17се шимбә көн рамазан шәрифкә шөрүгъ кылдык Сатсун *(Цоссен. — И.Г.)* лагирында. Рамазан шәриф айның эчендә һичбер эссе көн булмады. Ләкин ягмур бик күп булды.

Дүшәмбе көн 17 июльдә гает рамазанны укыдык. Сатсунда Төркиядән Шүкрү паша килеп укыды. 10 сәгать ярымда башлап, 11 сәгать ярымда тәмам булып, зиратларга барып, 4тә кайттык.

1916 елда синтәбернең 24нче шимбә көн гает корбанны укыдык, лагир Сатсунда, 20 куй корбан өчен бирелде. Һинд вә Франса әсирләре һәм зур начальствалар хәзер булдылар.

1917 елында 8 июньдә чәршәмбе көн кич илән тәрәвих илән шимбә көн рузага шөрүгъ кылдык лагир Вайнздуруфда *(Вюнсдорфта. — И.Г.)*»

Тора-бара шул ук әсир сәяси вакыйгаларга күбрәк игътибар бирә башлый:

«1917 елында гыйнварның 9 йөмендә лагир Вайнбиргда безләрә игълан итте Галимҗан әфәнде «Йолдыз» газитәсендәге сүзләрне: 29 ноябрьдә Уфада Милли

мәҗлесендә бер үзидарә игълан итмеш. Үзидарә дийүне, риспубликаны һәм безләр моны ишетеп зиядә мәмнүн булдык. Аллаһы Тәгалә хәзрәте ярдәм биреп, киләчәктә тугры юл белән алып баруга насыйп кылса иде, амин. (...1918 елында гыйнварның 29 йүмендә Галимҗан әфәнде мәчеткә җыеп лагирдагы мөселманнарны игълан итте солых хосусында. Солых мөфәһәдәсене тәмам бетергәннәр, ләкин әле кул куймаганнар».

Икенче бер әсир Вюнсдорф лагерена килгәнче, башка әсирләр лагерьларында җәфа чиккән, анын көндәлегеннән бер кечкенә генә өзек китерәм: «Март илә април айларында халык ачлыктан җөдәп бик хәлсезләнде. Часавайлар таяк илә аркаларына «эшлә, эшлә!» дия кысып торалар. Бәгъзе берәүләре сугып, берничә көн авыру булып ятып, шул рәвешчә кайтмый торган урынга китәләр иде. Шул дәрәҗәдә тарчылык булыр икән! Сатып алырга икмәк кадагы ике марка «рус акчасы бер тәнкә» хисап итела. Кар эреп бетү илә чыккан һәртөрле үләнне халык җыеп ашый башлагач, бәгъзеләре авыру булгаладылар. Соңра аны җыюдан мәнигъ иттеләр. Тынламаган кешене җәзага боерып ярты гына пурса *(порция. — И.Г.)* бирә торган булдылар. Сахра ни кадәр матур булса да, безне монсыз итәрлек дәрәҗәгә китерә алмый. Шулай ачлык илә халык газап чигә, бәгъзе вакыт дүрт кешегә бирәләр өч кешегә бирә торган икмәкне».

Тагын бер көндәлек авторы үзенең әсирлеккә кадәр булган язмышын язып бирә — ничек ул солдатка алынганын, фронтка нинди юллар белән килгәнен, юлда нинди гаҗәп нәрсәләр күргәнен, ниһаять, сугыш газабын аерата төгәл тасвирлый: «Кояш чыгу илә атышу башланды. Сәгать 11гә кадәр һич туктамый атыш булды. 12гә 10 минут булганда, сул тарафтан дошман һөҗүм итә. «Без жиңеләбез», дип хәбәр килде. Шул сәгать үк безнең рота чигенә башлады. Хәндәкдән чыгу илә дошман тарафыннан әснәрәт ява башлады. Чыгу илә күп кешеләр җәрәхәтләнде. Һәркем «Алла, Алла!» дия үзенең башынын котылуын тели вә бәгъзесе мәхрүм хәлендә кальбенең иң тирән урыныннан чыккан тавыш илә: «Мине генә алып китсәнә!» — дип ялынып елый. Кайсынын бите, бәгъзе берләрнең кул, аяклары мәхрүм рәвештә һәмишә алга баралар. Шулай зарлап барган вакытта, туп килеп төшә дә күз алдында торган адәмләрдән һич бере күренми гаип була. Борчак яуган кеби ягмур да ява...»

Күпчелек блокнотларда без шулай ук шигъри текстлар күрәбез — җырлар, бәетләр, мөнәҗәтләр. Аларның бер өлеше халык арасында таралган әсәрләр булса, икенче өлеше әсирләр үзләре иҗат иткән, әсир тормышын эчтән чагылдырган текстлар. Әдәби яктан алар камил дә түгелдер, ләкин әсир язмышын аңлау яки күз алдына китерү өчен аларның әһәмияте гаять зур.

Укучыларыбызга минем өчен бигрәк тә кызыклы булып күренгән әсәрләрдән өзекләр китерәм.

«Туган ил» — үзенә күрә «хит» — бу җыр сакланган ике блокнотка күчереп язылган, шулай ук безгә мәгълүм хатларның берсендә дә аны күчереп Минзәлә өязе Гайнелһади Хәйретдинов туганнарына җибәргән булган.

*Сагынам туган-үскән илне,*
*Әллә кай төше бигрәк ямьле иде,*
*Сөямен, шул илемне уйлап көямен.*
*Яшел болыннардан шаулап аккан*
*Сулары да татлы, тәмле иде,*
*Бигрәк тә шул сулар тора йөрәктә. (...)*
*Атам да анам, туганнарым,*
*Дуст-ишләрем, кардәшем шунда*
*Барсын да сагынып елыйм, йөрәк ярсуда,*
*Яшьләремне түгеп еласам да,*
*Һичбер кеше миңа карамый әйләнеп.*
*Ят илләрдә калдым бәйләнеп.*
*Кайталмыйм — туган илем, сиңа —*
*Дөнья өзгән безнең араны*
*Беткән юл, туган үскән илем, исән бул.*

(Әсир Нәбиулла Зәйнуллин блокнотыннан)

Күрәсен, әсирләр арасында язмышлары охшаш булган шәхесләр турындагы язмалар популяр булган.

«Мәхбүс шаһзадә»дән бер өзек:

*Ничә еллар бу бәндә ялгыз утыра башым,*
*Бер савыт су, бер телем икмәк иде минем ашым,*
*Күрмәде һич ике күзем якты дөнья нурын,*
*Көне төне елый елый бетте инде күз яшем.*
*Кайда минем яшь чагымда назлы үскән чакларым?*
*Йөз мең алтын торыр иде минем менгән атларым.*
*Алтын илә җиз иткәндер минем утырган тәхетем,*
*Инде тәхет урнына калды утырган салкын ташым. (...)*
*Аһ, насыйп булырмы икән якты дөньяны күрү,*
*Әллә шул зиндан эчендә чыгачак газиз җаным.*
*Аһ, әткәем һәм әнкәем, йөзегезне күрмәем,*
*Иншаллаһ, без сезләрне бакый җирдә күрдәем.*

Әлбәттә, әсирләрнең ачы язмышы шигъри текстларның төп темасы булган:

*Әй, җан дустым, җылама син,*
*Хәсрәт чикмә, кайгырма,*
*Сакла күңел сихәтлеген*
*Туган илгә кайтырга.*
*Күрәсең бит, мин еглямыйм*
*Ник ул кадәр көяргә?*
*Иң яхшысы безнең өчен*
*Сабыр итеп түзәргә.*
*Онытма һәм кайгырма син*
*Ихтимал тиз кайтырбыз.*
*Ә хәзергә, газиз дустымыз,*
*Әсирбез без, фәкыйрьбез.*
*Онытма, дуст, без бәхетле*
*Үлгәннәр кардәшләрдән.*
*Котылдык, мең шөкер булсын,*
*Коточкыч атышлардан.*

Яки

*Саргаядыр көз көнендә һәр агач яфраклары,*
*Шул яфраклар күк, кардәшләр, безнең дә йөз сап-сары.*
*Саргая таллар, усаклар, алмагачлар һәм каен,*
*Иртә торгач сөйләшәбез туган илне көн саен.*
*Әй, Ходаем, бир сабырлык барчамызның күңелгә,*
*Шадланышып насыйп булсын кайтырга туган илгә.*
*Әй, туганнар, иттифакта булыйк безләр һәрдаим,*
*Тиз көннәрдә мир булсын дип әйтәек барчамыз, амин!*

Әсирлек фаҗига булса да, әсирләр күнелләрен төшерергә тиеш түгел, алар киләчәк турында уйланырга тиеш:

*Әй әсир, син нигә моңаясың?*
*Йорт, җир, балам калды, дисеңме,*
*Син белмисең үзең, кәтә сине*
*Дөнья — ахирәт, бәхет ишеге.*
*Көттең инде хәзер бик күп хикмәт,*
*Уйласаң син, бу бик зур гыйбрәт.*

*Ходайның бар нинди кавемнәре:*
*Тырышканга бирә һәм куәт.*
*Хак Тагалә биргән акылга дип*
*Әйтә бугай синең күңелең.*
*Юк, әфәндем, хәтта алай түгел*
*Фәкать тырышканга бирә әмал.*
*Тырыш син дә көн, төн атлар кеби*
*Тырышып салдыр зур-зур мәктәпләр.*
*Укыт анда ир һәм кыз балаңны,*
*Житешсеннәр бар да галимнәр.*
*Булсын синең татар фәлсәфәң,*
*Инжинир, доктор, һөнәрчең.*
*Зикерең булсын һаман авызыңда*
*Уку, тырышу, укыту, милләтең.*
*Тырыш хәзер, бер дә ялкау булма,*
*Уку, укыт угыл кызыңны.*
*Караңгы төн кояш балкыр сиңа,*
*Адашмассың һич тә юлыңны.*
*Шул вакытта гына яшәрсең хөр,*
*Милләтең хөр булыр, динең хөр.*
*Ялынмассың бер дә чит милләткә,*
*Чит милләтләр булыр сиңа кол.*

Уку-укыту перспективасы әсирләрне авыр шартларда да жылытырга тиеш булган, шуңа күрә блокнотларда ул еш очрый:

*Әй, туганнар, укыйбыз*
*Исламият юлларын.*
*Бирсен каһарман татарлар*
*Бер берсенә кулларын.*
*Әһ, туганнар, жыелабыз*
*Мәктәп авылы булмәгә,*
*Хак Тәгалә насыйп итсен*
*Милләт өчен үлмәгә. (...)*

*Әй, туганнар, бу кяферләр*
*Итмәй безгә яхшылык.*
*Әгәр шулай укымасак*
*Арттырырлар вәхшилек.*
*Әй, туганнар, без укытыйк*
*Угыллар һәм кызларны.*
*Кыяматтә нурландырсын*
*Алар безнең йөзләрне.*

Әсирләр шулай ук тарихи яки сәяси темаларга шигырьләрне яратып укыган:

*Әй, Казан, син нурлы идең,*
*Тотты сине татарлар.*
*Ул арыслан татарлар*
*Кайда киттеләр алар?*
*Урысларның арасындан*
*Иван Грозный чыкты,*
*Колымыз дип Казанны,*
*Безне аяктан екты...*
*...Урыска хезмәт итми идең,*

*Үз ханымыз бар иде.*
*Урыс дигән вәхшиләрнең*
*Куәте дә аз иде.*
*Урысларның кенәзенә*
*Безнең ханнар сар иде.*
*Әй, татар милләте, уян,*
*Йокладың инде, жытәр!*
*Гафил улма, ач йокыңны,*
*Азрак башыңны күтәр!*

Һәм, ниһаять, тагын бер шигъри текстны китерәсем килә — бу язмада татар бәетләренең стилендә әсир тормышының бер ягы яктыртыла — әсирлектә вафат булган иптәшләренә исән калганнары һәйкәл куярга ниятләгәннәр һәм, билгеле булганча, ниятләрен тормышка ашырганнар.

*Әҗәл шундый нәрсәдер: барчабызга киләчәк,*
*Ләкин үз түшәкләреңдә үлү артык булачак.*

*Менә безнең кардәшләр монда үлеп калалар,*
*Шушы алман җирләрендә гүргә илтеп салалар.*
*Шуларга ядкәр булсын — таш куймакчы булабыз,*
*Шуңар акча җыю өчен, күп иҗтиһад кылабыз.*
*Рәхмәт сезгә, кардәшләр, бик зур ярдәм иттегез,*
*Кулыгыздан килгән кадәр акча җыеп бирдегез.*
*Ташка язылачак сүзләр: «лә иләһә ил алла»,*
*Һәр вакты салават, барчабызга, иншаллаһ,*
*Ходай җәннәт насыйп итсен үлгәннәр һәм безләргә,*
*Тиз көннәрдә солых булып кайтсак иде илләргә!*

Китерелгән текстлар — сакланган мирасның бер өлеше генә. Хәтта бүген искә алынган Берлин китапханәсе җыелмасында да әле шактый күп язмалар саклана. Уйлавымча, максатчан рәвештә эзләнә һәм өйрәнә башласаң — китапханә-архивларда, шәхси фондларда андый сугыш язмаларын тагын да күбрәк табып булачак. Шул ук искә алынган «махсус» лагерьлардан әсирләр 1920 еллар башында туган илләренә кайткан бит — алар үзләре белән язма материаллар да, фотолар да алып кайткан булырга тиеш. Димәк, бүгенге көн тарихчыларына, вакыт шактый узган булса да, эзләнү мөмкинлекләре бар әле.

Гомумән, бу мәкаләләр циклын тәмамлап, тәкъдим ителгән җитди мәсьәлә бер яктан, әлбәттә, зур дәүләтләр — Алмания, Русия һәм Госманлы империясенең Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында алып барган сәясәтләрендә нинди дә булса яңа төсләр табарга мөмкинлек бирә, шул ук вакытта бу мәсьәлә татар тарихын, мәдәниятен өйрәнгәндә дә бик зур урын алып тора. Чын-чынлап ул өйрәнелә генә башлый әле. Әсирлек хәлендә аерым шәхесләрне, милләтләрне өйрәнү, гомумән, сугышлар тарихында шулай ук яңа ачыла башлаган юнәлеш. Ул аерым кешеләр, аларның психологияләре, милли хисләре, мәдәни яки сәяси көчләре экстрималь шартларда нинди юл белән барганлыгын тасвирларга нигез бирә, димәк, аерым милләтләрнең рухи потенциалларын барлау һәм бәяләү өчен юл ача. Без әле бу юлның башында гына дип саныйм.

**Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ,**
*тарих фәннәре докторы, профессор.*

**Редакциядән.**
*Галим һәм язучы Искәндәр Гыйләҗевка чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Киләчәктә дә аның журналыбызның актив авторы булуын теләп калабыз.*

# ЧОРЛАР ҮЗГӘ — МӘСЬӘЛӘЛӘР УРТАК

## Г.ИСХАКЫЙ һӘМ Г.ГАЛИЕВА ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ХАТЫН-КЫЗ МӘСЬӘЛӘСЕ

Язманың исемен укыгач, татар әдәбияты белән азрак таныш булган укучы әйтеләсе фикерләрнең, сүз сөрешенең кайсы тирәдә барачагын шәйләгәндер. Әйе, сүзем Гаяз Исхакыйның «Остазбикә» һәм «Кәләпүшче кыз», Гөлчәчәк Галиеваның «Газзәбану» һәм «Өзелгән өмет» әсәрләре турында. Ике автор төрле чорларда, төрле тарихи шартларда иҗат итсәләр дә, алар күтәргән хатын-кыз мәсьәләсе һәрвакыт актуаль булып кала. Яшәеш кыйммәтләре чорга бәйле билгеле бер үзгәреш кичерә, шунлыктан без «замана үзгәрде», дияргә яратабыз. Ләкин бит кояш чыгасы жиреннән чыга, байыйсы ягыннан байый, жир үз күчәре тирәсендә әйләнеп тора. Димәк, замана түгел, без, кешеләр, үзгәрәбез. Ничек кенә үзгәрмик, Адәм белән Хава яралтылганнан бирле, хатын-кыз мәсьәләсе — көн кадагында. Бу мәсьәлә күпгасырлык әдәбиятыбызда да зур урын алып тора.

Милли әдәбиятыбызга нигез салучыларның берсе, аның алтын баганасы саналган Г.Исхакый иҗаты белән китап укучылар узган гасырның 80 нче еллары ахырында таныша башлады: әсәрләре мәктәп программаларына кертелде, пьесалары театр сәхнәләрендә уйнала башлады, соңрак кинофильмнар төшерелде. Совет чорында никадәр генә каралтырга, халык күңеленнән югалтырга тырышсалар да, әдип, «алтынга пычрак йокмый» гыйбарәсенә дәлил буларак, яңадан халкына әйләнеп кайтты. Бөтен гомере буена үзенең милләтен, аның яшәешен, киләчәген кайгыртып яшәгән һәм иҗат иткән бу олуг милләтпәрвәр шәхес иҗатында хатын-кыз проблемасы төп урыннарның берсен алып тора. Хатын-кызның авыр һәм җаваплы роленә Гаяз әфәнде битараф кала алмый. Бу күренешнең сәбәпләрен ачарга, хатын-кызның киләчәген кайгыртып, аның милләтне саклаудагы урынын билгеләргә тырыша. Әсәрләрендә ул хатын-кызны һәрдаим яклый, теләктәшлек күрсәтә, хәлен җиңеләйтергә тырыша. Кайбер әсәрләрендә хатын-кызны «тормыш төбендә» сурәтләп, аның сәбәпләрен ачыклый, баткаклыктан чыгу юлларын күрсәтә. Күп очракта аның хатын-кызлары алдынгы фикерле, булдыклы, кыю булып калка. Мисал итеп «Кәләпүшче кыз» (Кәмәр), «Теләнче кызы» (Сәгадәт), «Алдым-бирдем» (Галия), «Мөгаллимә» (Фатыйма), «Көз» (Нәфисә), «Остазбикә» (Сәгыйдә), «Зөләйха» (Зөләйха) һәм башка бик күп әсәрләрен китерергә була.

Мин, гади укучы, гомерем буе әдәбиятыбыздан аерылмаган һәм мөгаллимә булып эшләгән шәхес буларак, Г.Исхакыйның кайбер хатын-кыз образларына дин-шәригать күзлегеннән якын килəсем килә. Күренекле әдипнең иҗаты «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең әдәбият укыту программасына кертелде. Аның күп әсәрләрен укып өйрәнәбез, шәкертләр иҗади һәм фәнни эшләр башкара. Бу уку йортында әдәби әсәрләр, әхлак тәрбиясе чарасы буларак, исламның хатын-кызга куйган таләпләреннән чыгып өйрәнелә, анализлана. Р.Фәхретдин дә, әдәбиятның шәхес тәрбияләүдәге әһәмиятен ассызыклап: «Бер халыкның әдәбияты нинди булса, халкы да шундый була», — дигән.

Дин сүз сәнгате белән тыгыз бәйләнештә. Тел һәм дин татарны халык буларак яшәткән, тарих афәтләреннән, юкка чыгудан саклап калган. Кешене рухи яктан тәрбияләү — дин һәм әдәбиятның уртак бурычы. Дин дә, әдәбият та белемгә, кешенең камиллегенә, кешеләр арасында дуслык-татулыкка өнди. Әйтелгәннәргә дәлил итеп Коръән аятьләрен китерергә мөмкин: «Кешегә без ата-анасына яхшылык

итәргә әмер иттек...» *(Локман сүрәсе, 14 аять)*; «...һәркайда кешеләрне яхшылыкка өндә, вә гөнаһлы эшләрдән тыел, вә сина ирешкән бәла-казага, катылыкка сабыр ит...» *(Локман сүрәсе, 13 аять)*. Күргәнебезчә, динебез бәндәне сафлыкка, рухи пакьлеккә, изгелеккә, мөрәвәтлеккә, шәфкатьлелеккә чакыра. Алдашу, гайбәт, хәмер куллану, харам, зина кебек һәрбер начарлыклардан тыя. Әдәбиятыбыз да бик борынгы чорлардан алып кешенең дөньядагы урынын, яшәвенең мәгънәсен ислам кануннары нигезендә күрсәтә. Әдипләр иҗатында кешенең Аллаһка мөнәсәбәте, әхлак кагыйдәләре, ислам өйрәтүләре җирлегендә бирелә. Кайсы гына чорда язылса да, әдәбиятыбызда гаделлек, миһербанлылык, хөрлек һәм фидакарьлек, мәхәббәт һәм тугрылык, гуманлылык һәм туган илне ярату кебек гомумкешелек кыйммәтләре яклана. Явызлык, хыянәт, хөсетлек, алдашу, кансызлык, бәгырьсезлек, таркаулык һ.б. кире кагыла.

Г.Исхакыйның «Остазбикә» әсәренә килик. Хатын-кыз... Кем ул, каян килгән, ни өчен дөньяга яратылган, аның җәмгыятьтәге, гаиләдәге урыны нинди? Коръәнгә мөрәҗәгать итик: «Әй, инсаннар! Сезне бер җаннан ярадткан вә ана хатынны бар иткән, аларның икесеннән ир җенесен вә хатын җенесен үрчеткән Раббе каршында гөнаһ кылудан куркыгыз...» *(Ниса сүрәсе, 1 аять)*.

Белгәнебезчә, дөньяга һәр нәрсә парлы итеп яралтылган. Димәк, инсани затлар да парлы булырга, ягъни өйләнеп, гаилә корып яшәргә тиеш. Г.Исхакыйның «Остазбикә» әсәре геройлары Вахит белән Сәгыйдә — гаилә кору чорына кергән яшьләр. Никах, туй мәшәкатьләреннән соң бер җан, бер тән булып уникe еллап яшиләр. Бергә яшәү чорында булган милли һәм гаилә проблемаларын, хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урынын автор Сәгыйдә образы аша ачыклый. Әлбәттә, әсәрдә әхлакый мәсьәләләр дә читтә калмый. Сәгыйдә — татар хатын-кызының җыелма образы. Г.Исхакый шушы образда татар хатын-кызының иң күркәм сыйфатларын туплап биргән. Сабыр, киң күңелле, холкы белән тыныч, олы җанлы, хезмәт сөючән Сәгыйдә танылган остазбикә булып китә. Авторның хатын-кызларга куйган таләпләреннән берсе — аларның белемле булуы, гыйлем алуы. Шушы максатта Сәгыйдәнең әтисе Хәйретдин хәзрәт кызы килен булып төшкән авыл кешеләренә болай ди: «...Мин кызымызны мулла Вахидка биргәндә, анасы да, кардәш-кабиләмез дә, авыллары кара, укыган, хезмәт итәчәк остазбикәгә мохтаҗлар, олы өйрәтер, намаз-ниязга алыштырыр дип уйлаган идек... Мин кызымны монда Рәхим мулланың сарык абзарын тазартырга бирмәдем». Өзектән күренгәнчә, карт хәзрәтнең максаты кызын кияүгә итүдән бигрәк, шул авыл кызларын мәгърифәткә алып чыгу. Бу хәзрәтнең алдагы гамәлендә максатына ирешкәнлеген автор бик матур итеп ача, Сәгыйдә дөрестән дә кызлар өчен чын абыстай булып таныла.

Әсәрдә күрсәтелгән гаилә бәхете — ир белән хатынның бер-берсен яратып, бер җан, бер тән булып үз халкына хезмәт итеп яшәүдә. Ләкин бу гаилә алдында килеп туган, аны борчуга салган проблема да калкып чыга: уникe ел бергә яшәүләренә карамастан, гаиләдә бала юк. Шушы хәл Сәгыйдәнең эчке дөньясында каршылыклы уйлар, фикерләр тудыра. Аның бу бәргәләнүендә үзенең ана булу бәхетеннән мәхрүм калуы гына түгел, ирне балалы итү, нәсел, үзенә һәм иренә догачы калдыру хакындагы фикерләре өстенлек итә. Чөнки: «Мал һәм балалар дөнья тереклегенең зиннәтләредер...» *(Кәһаф сүрәсе, 46 аять)*.

Сәгыйдәнең акылы белән Вахидка булган мәхәббәте, хис-кичерешләре арасында кискен көрәш башлана. Бу көрәш, рухи газапланулар, сызланулар аша үтеп, кайвакыт чарасызлыкка китереп җиткерә. Ничек кенә авыр булмасын, акыл өстенлек итеп, көндәшлек ачысы икенче планга кала. Ләкин остазбикәнең ирен өйләндерергә теләве Вахидның кискен каршылыгына очрый, чөнки ир «Сәгыйдәдән башка хатын юк», дип яши һәм Сәгыйдәнең тәкъдимен ишетергә дә теләми. Ир белән хатын арасында шактый тирәнгә киткән конфликт туа. Әмма мулланың авырып китүе, аның үзеннән соң нәсел калдырмыйча үлеп китү куркынычы алга баскач, Галимәгә өйләнү нияте туа.

Сәгыйдәнең рухи ныклыгы, көчле ихтыяры, ирен бәхетле итәсе килү хакына үз бәхетен корбан итә алуы бик күп хатын-кызларыбызга үрнәк булып тора. Хатынның ни дәрәҗәдә олы җанлы, сабыр холыклы булуы әсәрнең соңгы өлешендә, ягъни

туйнын икенче көнендә анын кодалар өенә кияү чәенә баруында чагыла. Хәзерге чор хатын-кызлары өчен күз алдына да китерә алмаслык вакыйга: иренне үзен теләп икенче бер кыз белән никахлаштыр да, әле тагы аларны тәбрикләргә шул йортка кунакка бар. Бара шул Сәгыйдә. Үзе өчен ни дәрәҗәдә газаплы булса да, героиня бөтен көчен җыеп, ире һәм Галимә алдында илаһи бер горур кыяфәттә баса.

XX гасырда әдәбиятыбызда Г.Исхакый традицияләрен дәвам итеп иҗат ителгән әсәрләрне күпләп санарга булыр иде. Аларда хатын-кыз язмышы, кеше бәхетен гаилә бәхете белән бәйләп карау мәсьәләсе чагылыш тапса да, күпхатынлылык темасына иҗат ителгән әсәрләрне атап булмый. Бу проблема Гөлчәчәк Галиеванын 2010 елда дөнья күргән «Газзәбану» әсәрендә яңадан калкып чыга.

Әдәбият белән кызыксына башлаганнан сон, үткәнне күздән кичергәндә, өч очрак хәтердә: ул да булса татар укучысынын зурдан кубып китапка-әдәбиятка ябырылуы. Анын беренчесе безнең буын — узган гасырның алтмышынчы еллары студентлары иде. «Совет әдәбияты» журналында Мөхәммәт Мәһдиевнең «Без — 41нче ел балалары» һәм «Фронтовиклар» әсәрләре дөнья күрде. Хәтеремдә: журналны китапханәдән алып уку өчен чиратка языла идек. Ниһаять, укыла торгач, журнал таушалып, тышлары төшеп бетте. Икенчесе шул ук XX гасырның сиксәненче елларында, Г.Исхакый иҗаты халкыбызга яңадан кайткан вакытта күзәтелде. Һәм менә XXI гасырда Гөлчәчәк ханымнын «Газзәбану» романы укучыларга килеп иреште.

«Газзәбану» — бүгенге көннең гаять актуаль темасына язылган әсәр. Анда тормышта ныграк урын ала барган күпхатынлылык проблемасы күтәрелә һәм автор ана хатын-кыз күзлегеннән якын килә. Вакыйгалар агышы инде бик ерак чорларда калган, ләкин анын идея эчтәлеге бүгенге яшәешебезнен күп кенә сорауларына җавап бирә.

Иң элек 1921 ел алып килгән ачлык вакыйгалары игътибарны җәлеп итә. Бу афәт турында әдәбиятыбызда әлләни җәелеп сөйләшү булмады дисәк тә хата түгел. Дөрес, Г.Ибраһимовнын реаль вакыйгаларга нигезләнеп язылган «Адәмнәр» повесте белән М.Гафуринын «Кеше ашаучылар турында поэма»сын мисалга китерергә була. Ләкин алар басылып чыгу белән үк цензура тарафыннан тыелган әсәрләр рәтенә кертелә һәм берничә буын укучы бу әсәрләр турында белмичә үсә. «Адәмнәр» һәм «кеше ашаучылар...» чынбарлыкка нигезләнгән булса да, ачлыкның реаль сәбәпләре, гомумән, күтәрелми. Дөреслек хакына бу афәтнең Идел буе халыкларының 90 процентына кагылуын, республикабыздан 232 мең кешенең читкә китүен, меңләгән кешенең фаҗигале төстә вафат булуын әйтү кирәктер. Бүген татарлар дөнья буйлап таралган, дибез. Анын сәбәпләре күптөрле. Бу таралу, Казан ханлыгы җимерелеп, халкыбыз үз дәүләтчелеген югалткан чорлардан ук башлана. Озын, озакка сузылган фаҗигале тарихның барлык очракларына да тукталып тормыйм, максат ул түгел. Шулай да кайберләрен искә төшерү кирәктер. Авыр салымнардан, көчләп чукындырудан, таланудан гаҗиз авыл крестьяны һәрвакыт атлы булу турында хыялланган. Максатына ирешү, атлык акча эшләү нияте белән шахталарга, төрле приискаларга хезмәткә киткән (Ш.Камал «Бәхет эзләгәндә», «Акчарлаклар», Ф.Хөсни «Йөзек кашы»). Күп бәхетләр, рәхәт тормыш вәгъдә иткән Октябрь түнтәрелеше дә халыкка җәбер-җәфадан тыш әлләни алып килми. Илдә күптөрле сәяси экспериментлар үткәрү нәтиҗәсендә туган олы фаҗигаләр турында А.Гыйлаҗевнын «Өч аршын җир» повестенда сурәтләнә.

Унган, таза тормышлы игенчеләрнең шәхес хуҗалыкларын туздырып, малларын алып, кулак ярлыгы тактылар, аларны сөргенгә озаттылар. Шул рәвештә меннәрчә игенчеләрнен язмышы фаҗигагә әйләнә. Күбесе әле үз теләге белән хуҗалыгын ташлап качарга мәҗбүр була. Гасырга якын вакыт үткәч, югалган шәхси хуҗалыкларны торгызырга омтылу бара. Ләкин ул тырыш крестьянның берничә буыны алышынган, халык хуҗалык итү маһирлыгын, шул эштәге мөстәкыйльлеген, җиргә булган элекке мөнәсәбәтен җуеп өлгергән шул. Шунлыктан бу эш бик әкрен бара.

Газзәбану әсәрендәге Нургали дә бит, әнә шул егерме беренче елгы ачлыкта ата-анасын, хатыны-баласын калдырып, Ташкент якларына чыгып китә. Өч-дүрт

айга гына дип киткән ир үзе эшләгән кибет хуҗасының кызына өйләнеп тә куя. Дөрес, аның хезмәткә чыгып китүе бәрабәренә гаилә ачтан үлмичә кала. Чөнки Нургали акчасын, азык-төлеген җибәреп тора. Әсәрдә иренең өйләнүе турындагы хәбәрне ишетү мизгелен автор Газзәбануның үзеннән сөйләтә: «Һа-ай, ул коточкыч хәбәрне ишетеп өнсез калганнарым, кара кайгыда керфек тә какмый йокысыз узган төннәрем исемә төшсә, йөрәккәем әле дә булса, нәкъ шул вакыттагыча, сызып-сызып сулкылдый башлый. ...Чыдаса да чыдый икән бу йөрәк дигәнең... Ул көннәрдән соң юкса алтмыш еллап вакыт узса да, йөрәгемдә калган шул җәрәхәттән әле дә булса кан сава. ...Ир бирмәк — җан бирмәк, дип әйтмәсләр иде шул аны».

Газзәбану иреңең үле хәбәрен ишетергә дә әзер, ләкин бу хыянәтне (ә ул аны хыянәт дип кабул итә) күтәрү ачысының ни дәрәҗәдә авыр икәнен үзе генә белә. «Үлгәннең үкенече зур булса да, хурлыгы юк бит аның», — дип бәргәләнә Газзәбану. Шундый авыр вакытта, җан гаҗизләнгәндә, кая, кемгә барабыз? Әлбәттә, әти-әни янына. Газзәбану да йокысыз үткән төненнән соң туган авылына, әти-әнисе янына ашыга. Хатынның, рөхсәт итсәләр, әти-әнисе йортына кире кайтырга да исәбе юк түгел. Әмма ана белән бала арасындагы сөйләшүгә әти кеше килеп кушыла. Аның фикере, хәтта таләбе башка: «Кискән икмәк кире ябышмый. Абый, энекәшләрең яшәгән бу йортта син инде киселгән икмәк. Синең үз йортың бар, ул — балаң туган йорт. Эш аты бит син ул йортта. ... Шул Нургали кияү аркасында гына яшәп ятабыз бит әле», — ди, ачтан шешенеп үлгән гаиләләрне саный-саный, һәм сүзен дәвам итә: «Син, кызым Газзәбану, сабырлыгыңны җуймале. Ачуыңнан Нургалигә үзеннән биздерерлек итеп хат яза күрмә тагы. Кода-кодагыйга да илтифатлырак булырга тырыш, чыраенны бозма. Тешләреңне кысып булса да түз. Болай да югалтканнардыр инде үзенне, тизрәк балаң янына кайт, каенатa-каенанаңа елыш». Әти кеше кызын озата барырга теләгән анага акыл бирә: «Үзем дә бармыйм, сине дә җибәрмим, ничек килгән, шулай кайтып та китәр, каенана-каенатасыннан узып йөрмәсен, чәенне эчерсән эчер дә, абыйсы белән җиңгәсе кайтып җиткәнче, озат үзен».

Шушы урында Гөлчәчәк ханым бүгенге ата-аналарга, яшь гаиләләргә сабак бирә түгелме? Бүген таркалган гаиләләрнең саны һаман арта-ишәя бара. Әлбәттә, моның сәбәпләрен күп санарга була. Мин арадан берсенә генә тукталасым килә. Гаиләдә савыт-саба шалтырамый тормый, бигрәк тә яшь гаиләләрдә, әле очлы почмаклар ышкылып шомарып, ягъни бер-берсенә яраклашып беткәнче, бу хәл еш кабатлана. Әлбәттә инде, яшь бикәч үпкәсен күрсәтү өчен, ата-анасы янына йөгерә. «Үз сөягебез үзебездән артмас, бала да ким-хур булмас. Кайт, кызым, үзебезгә, интегеп яшәмә», — дип кинәш бирә ана кеше. Әти кеше еш кына бу сөйләшүгә катнашмый, чөнки бүген безнең җәмгыятьтә ата культы дигән әйбер юкка чыга бара. Шулай итеп, әни кеше кызының язмышын хәл итә дә куя. Берничә тапкыр кайталы-китәле уйнагач, гаилә таркала, кыз һәм кияү — тол, бала ятим кала.

Инде ир, аның хатыннары мәсьәләсендә динебез, шәригать карашыннан фикерләп алыйк. «Бер ирнең никахлы хатыны ике (яки өч вә дүрт) булып та, кием-салым, торыш-йөреш, ашау вә эчү, кичәләү вә бүләк бирү кебек эшләрдә тигезлек кылмаса, кыямәт көнендә ярты ягы корыган хәлдә халык хозурына килер», — ди Пәйгамбәребезнең бер хәдисе. Бу хәдискә аңлатма биреп, Р.Фәхретдин болай ди: «Мөселманнар өчен дүрткә кадәр хатын алу дөрес булса да, бу дөреслек чикләүсез түгел, бәлки күп шартлар астында дөрестер. Чарасызлык вакытында бердән артык хатын алырга рөхсәт бирә торган шәригать, әдәп вә әхлак ноктасыннан карап, бу эшне кайвакыт күп кешеләргә тыю итәдер. Һәрхәлдә, хасталык вә баласызлык яки мәхәббәтсезлек вә әхлаксызлык кебек кимчелекләр аркасында, зарурилык булмаганда, яки әйтелгән кимчелекләр булып та хатыннарына тигезлек кыла алуына ышанмаганда, хатын өстенә хатын алуда сакланырга тиешле».

Нургалинең өйләнүе куелган шартларга туры киләме? Нургалинең икенче хатыны Маһирә чибәр, малы бар (атасы сәүдәгәр), яхшы нәселдән, укымышлы, ислам динендә. Ә тигезлек хакында Гөлчәчәк ханым Газзәбануның атасыннан әйттертә: «Шул Нургали кияү аркасында гына яшәп ятабыз бит әле. Шөкер, сине яраткач, безне дә ташламады. Ашаган җиренә сыер да кайта, кияү дә кайтыр. Алла боерса, менә күрерсен». Әйе, кайта Нургали. Ләкин яшь хатыны Маһирә белән.

Газзәбануның эчке халәте, хәле-әхвәле ничек? Иренең өйләнгән хәбәрен инде ул ишеткән, ягъни яшене яшьнәгән, күге ничек күкрәр? Кунакларны каршы алуга әзерлек бара. Газзәбануның каенанасы Зөлкамал килененә яшьләр йоклар өчен ак келәтне, юынырларына мунчаны җыештырырга куша. Карышмый Газзәбану, эшли каенанасы кушканны. Ләкин соңыннан иҙәннәрнең чиста-ак булуын аңлатып, өзлексез түккән күз яшьләре белән юганын, шулар ачысыннан агарганын әйтә. Әйе, йөрәгенең җәрәхәте юк — авырта, төтене юк — яна. Әле җитмәсә Газзәбану, үз ястыгына яна теккән матур тышлыкны киертеп, Нургалиләрне каршы алырга барасы атның тарантасына салырга тиеш икән.

Монысына Газзәбану түзми, җан ачысы белән болай ди: «И-и, әнкәй, малаең үзе генә кайтасы булса, ниләр генә эшләмәсием. Кушканны гына эшли торган кешемени мин? Ничек бер дә сизмисең соң син? Менә инде ничә көн йокым — йокы, ашым — аш, эшем эш түгел. Эчләрем тулы ут. Болай да бит, мунчаны ю диден, юдым, аларга йокларга ак келәтне ю диден, анысын да юдым. Инде аларны каршы алырга үземнең бирнә ястык-җәймәләремне әзерләп куярга кушасыңмы? Каенана булдым дигәч тә... Бу баланы рәнҗетмәгәем дип тә уйлый алмыйсың бит ичмаса...» Зөлкамал килененең үпкәсен аңлый, унайсызланып та кала, ләкин ана кеше буларак күтәрелеп бәрелми. Киленен тынычландыру юлын таба, назлап, Газзәбануның аркасыннан да сыйпап куя.

Шушы вакыйгалар бүгенге каенана белән килен өчен үрнәк түгелмени? Гаиләләр таркала, дибез. Күбесе бит килен-каенана мөнәсәбәтләре аркасында була. Димәк, бу ике хатын-кызның бер-берен аңлап, юл куеп, сабыр итеп, бер-берсенең, халык әйткәндәй, кирәкле кылларына басып яшәгәндә генә гаиләнe, аның тынычлыгын саклап була.

Сабырлык — түземле булу, авыр хәлләр килгәндә чыдам булып, үзенә хуҗа булу, ямьсез сүзләр һәм начар хәрәкәтләрдән үзенне тыя белү дигән сүз. «Бары тик сабыр итүчеләргә генә хисапсыз бүләкләр, саваплар булачак», дип әйтелә Зөмәрә сүрәсенең 10 нчы аятендә. Сабырсызлык дөнья һәм ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булыр. «Газзәбану» романы нигезенә дин кушканча яшәү төшенчәләре, милли гореф-гадәтләребез, йолаларыбыз (аш-су әзерләү, кунак дәшү, Сабантуй күренешләре, кендек әбисе булу һ.б.) салынган. Алар барысы да халкыбыз арасында булган тыйнаклык, олы җанлылык, сабырлык, бер-берең белән яхшы мөнәсәбәтне күрсәтү, әхлак тәрбияләү максатына юнәлгән. Геройларның һәр гамәлендә гаиләдә ата кешенең урыны, шәхес тәрбияләүдә аларның роле ярылып ята. Чыннан да, халкыбыз дини кануннарга буйсынып яшәгәндә, ата сүзе, ата киңәше беренче планда булган бит. Әти кеше, гаиләгә кайтып, өстәл артына утырмыйча, балалар кашык күтәрмәгән, аның гаиләдә үз урыны, үз бурычы булган. Газзәбануның каенатасы Зариф, үз атасы Ибраһим шул гамәлләрнең үрнәге булып тора. Автор үзе үк «әсәр күбрәк ирләр колагына диебрәк язылды», ди. Чыннан да, динебез бу хәяттә ирләргә дә күп бурычлар йөкли. «Сезнең һәрберегез көтүче. Һәрберегез үзенең көтүе өчен җаваплы. Идарәче көтүче, ул шулай ук үзенең көтүе өчен җавап бирә. Хатын-кыз үзенең ире йортында көтүче, хезмәтче үз хуҗасының милеге өчен көтүче һәм һәркайсы үз көтүе өчен җаваплы», — диелә хәдистә. Күп гаиләләрдә тавыш хатыннарның ирләренә буйсынмауларыннан килеп чыга. Аллаһы Тәгалә Коръәндә ирләрне хатыннар өстеннән тәрбияче кылып яратуын әйтә. «Аллаһ кешеләрнең берсен икенчесеннән өстенрәк иткәнгә күрә һәм малларын сарыф кылганга, ирләр хатыннар өстеннән карап, күзәтеп торучылар» *(«Ниса сүрәсе, 34 аять)*

Бүген җәмгыятьтә күпхатынлылык турында сүз байтак. Күп хатыннар моңа каршы. Берсенең дә диярлек үзләрен Сәгыйдә яки Газзәбану урынына куясы килми. Ләкин кайсыгыз, хөрмәтле хатыннар, ирем фәкать минем белән генә яши дип ышанып әйтә ала? Бүгенге статистика буенча ирләр һәм хатыннар санын чагыштырып караганда да бу проблема актуаль булып кала.

Әйе, татар укучысы «Газзәбану»ны ябырылып укыды. Төрле очрашулар, «түгәрәк өстәл»ләр, тәкъдир итү кичәләре үткәрелде. Әлбәттә, мактау сүзе генә булмады. Кемдер киңәш бирде, кемдер тәнкыйтьләде. «Безгә бүген Газзәбанулар түгел, Альбиналар кирәк», — диючеләр дә табылды. Гөлчәчәк ханым, тәнкыйть көчле булган саен, үз әсәре өчен сөенеп, горурланып яшәде.

Гөлчәчәк Галиеваның заман рухын тоеп иҗат итүче әдибә булуын «Өзелгән өмет» повесте да раслый. Әлеге әсәрне Г.Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» повестена нисбәтле бәяләп үтик. 1900 елда дөнья күргән әсәрендә Г.Исхакый хатын-кыз мәсьәләсен милли дәрәҗәгә күтәрә, укучыга әсәрне язуының максатын да ача. «Укучым! Минем бу хикәяне язудан максудым — Камәр кеби булуның ахыры ни булачагын күрсәтеп, милләтемнең туташларын шул кара бәхетләрдән коткарыр өчен, аларга Камәр булуда нинди авырлыклар барлыгын белдереп, үзләрен саклар өчен бар тәнбиһтер».

Ире үлеп, унбиш яшьлек кызы Камәр һәм унөч яшьлек улы Габделәхәт белән калган, кәләпүш тегеп тамак туйдыра башлаган Кәримә кияүгә чыгу фикеренә килә. Ир буласы кеше балаларны кабул итми, шунлыктан Габделәхәтне мәдрәсә интернатына тапшыра. Кәләпүшләрне сәүдәгәр Сәлимовлар кибетенә илтү кызы Камәргә йөкләнә. Кибеттә сатучы булып эшләгән иске карашлы Вафаның күзе Камәргә төшә. Әсәрдә Вафа «бөтен дөньядагы матур хатын-кызны гүя Вафага гына рәхәт өчен яратылган» дип яши һәм Вафа кызны үз максатында файдаланырга була. Әле моңа кадәр егетләр белән беркайчан да аралашмаган, инде ана назыннан, ана тәрбиясе һәм аның җылы сүзеннән дә мәхрүм калган Камәр, егетнең матур сүзләренә, вәгъдәләренә ышанып, сафлыгын югалта. Соныннан Вафа аннан котылу юлын карый. Егет аны кызлар белән кәсеп итүче Зөһрә карчыкка тапшыра. Карчык кызны акчага сатып, табыш чыганагына әверелдерә. Героиня куллан-кулга китә. Куркыныч чир йоктыра, шифаханәгә эләгә, аннан чыккач та элекке шөгылен дәвам итә. Корсаклы булып, янадан шифаханәгә керә. Үле баласын ярып алалар, шунда үзе дә үлә.

1900 елда дөнья күргән бу әсәрдә татар дөньясында борчу тудыра торган зур мәсьәлә күтәрелә. Автор татар кызларын Камәр фаҗигасеннән саклауны зыялыларыбыз бурычы итеп карый, һәм әсәр, басылып чыгу белән, укучыларның да, җәмәгатьчелекнең дә игътибарын җәлеп итә. Әсәрне укыгач, һәркем үзенә «кем гаепле?» соравын куярга хаклы. Әсәрнең «хәтимә»сендә автор Вафа белән Зөһрә карчыкны гаепләсә дә, гаепне Камәрнең үзеннән дә эзли. Моны без шул ук әсәрдәге Васфикамалның Камәргә каршы куеп сурәтләнүендә күрәбез. Намуслы булганы өчен Васфикамал яхшы кешегә кияүгә чыга һәм бәхетле була.

Әлбәттә, әсәрдә сурәтләнгән бәхетсезлекнең сәбәпләрен башлап дөрес тәрбия бирмәүдә, динсезлек, наданлык, әхлаксызлык кысаларында карау кирәк. Коръәндә болай диелә: «Зинага якын да бармагыз, аның сәбәпләреннән дә ерак булыгыз, чөнки ул пычрак эш, вә бик яман кабахәт юлдыр»; «...Зина кылу кебек фәхеш эшләрнең ачык эшләнә торганнарына да, яшереп эшләнә торганнарына да якын бармагыз» *(«Әнгам» сүрәсе, 151 аять).*

Үзебез яшәгән XXI гасырга кайтыйк. Бу чорда хатын-кыз әхлагы мәсьәләсе тагы да кискенрәк булып алдыбызга килеп басты. Матди һәм кешелек кыйммәтләренең үзгәрүе җәмгыятебездә хатын-кызның кадерсезләнә баруын, ана товар итеп карауны барлыкка китерде. Гаяз Исхакый традицияләренең уңышлы дәвамы буларак Гөлчәчәк Галиеваның «Өзелгән өмет» повесте дөнья күрде. «Әхлакка әхлаксызларны күреп өйрәндем», — дигән бер акыл иясе. Шушы гыйбарәнең мәгънәсен Гөлчәчәк ханымның әлеге әсәреннән аермачык күреп була. Повестьта нәкъ безнең көннәр сурәтләнә.

Әсәр герое Талия урта мәктәпне тәмамлап, зур бер эшкуарга сәркатип булып урнаша һәм аның сөяркәсенә әйләнә. Талиянең бу тормышыннан әнисе дә канәгать, чөнки Касыйм Кадырович аны сыерлы, мунчалы иткән. Табибларга да йөртеп тора, кирәк чакта акчасын бирә, күчтәнәчләреннән дә калдырмый. Талиянең дә хезмәт хакы әйбәт, барлык кирәк-ярак, йорт җиһазлары белән тәэмин ителгән заманча фатиры да бар. Хуҗасы аны үзе белән чит илләргә командировкаларга да алып чыга. Ләкин Талия тора-бара бу «рәхәттән» туя. Аның үз тормышын, үз гаиләсен булдырасы, ана буласы килә һәм Касыймга бу турыда әйтә. Сонрак Талия, Касыйм белән араларын өзеп, хатыны, баласы авариягә очрап үлгән Ахияр белән никахлаша... һәм Касыймнан бала таба.

Әсәрнең финалы да гаҗәеп гыйбрәтле, Ахияр баланың Касыймнан икәнен аңлый.

Талия баласы белән авылга анасы янына китә. Авылдан килгәндә, авариягә очрап, Касыйм үлә. Касыймның законлы хатыны Камәрия авызыннан автор Талиягә менә нәрсәләр әйттертә: «Никадәр гөнаһсыз җаннарны харап иттең. ... Иреңә коточкыч борчу, хурлык китереп, йөрәген җәрәхәтләдең. Сабыеңа «зинадан туган» дигән хурлыклы тамга салдың. Яратып кабул иткән атасыннан аны да мәхрүм иттең. Үзеңне кызганмыйм, әле ир дә табарсың, кемнеңдер сөяркәсе дә булырсың. Әмма дә балаң жәл... Әниеңне дә кызганмыйм, һәр ананың үзе тәрбияләп үстергән җимешен үзе татып карамый хәле юк». Әйе, автор әйткәнчә, Талия, беренчедән, тәрбия җимеше. Моның шулай икәнен сонарып Талия дә аңлый: «И-и, әни, кияүгә чыгып, Касыймны ташласаң, риза-бәхил түгел дип баштук кем әйтте — син! Нәчәлник хатыннарының күбесе сөяркә тоталар икән, дип тукып торучы да син түгелме соң? Онытмагансыңдыр әле, унтугыз яшемдә үк, Касыйм абый сиңа өй салып бирергә вәгъдә иткәч, ашка чакырганнарые дип, безне кич буена ялгыз калдырып чыгып киткән әни кеше син түгелме соң? Каян килгән ул сиңа шулкадәр акчага, байлыкка хирыслык? Инде ул чир миңа да йокты бугай... Ә менә үзең хәзер мине гаепләргә маташасың».

Әйе, Талия әнисен дөрес гаепли. Чөнки шәригатебез хатын-кызга кич буена түгел, бик аз вакытка да ир-ат янында ялгыз калуны тыя. Икенче зур сәбәп — халкыбызда булган рухи кыйммәтләрнең юкка чыгуы. Аларны бүген бер-беребездән уздырып дөньяга табыну, байлык җыю алыштырды. Муеннарына бармак юанлыгында алтып чылбырлар асып (Коръән ир-атларга алтын тагуны тыйса да), танк зурлыгындагы чит ил машиналарында сөяркәләре янына ашыгучы ирләрдә, бүген өстемдәге бүрек-туным иртәгә башка хатын-кызда булмаса ярар иде, дип кайгыручы хатыннарда, олы юл буена тезелеп, «кайчан мине алып китәрләр икән», дип чиратта торучы кызларда нинди рухи кыйммәт була ала икән? Ачның күзе — икмәктә, тукның күзе — хикмәттә, ди халкыбыз. Әйләнә-тирәбездә ризык, күзләреннән явын алырлык кием-салым, ә күңелебездә, җаныбызда бушлык.

Динсезлекнең иң югары ноктасына җиткән узган гасырның 60-70 нче елларында да фәхишәлек әле бүгенгедәй түгел иде. Гасыр азагындагы үзгәртеп корулар, эшсезлек, ягъни җәмгыятебезнең түбән тәгәрәве алып килде бугай бу әхлаксызлыкны. Әнә бит «Шәһри Казан» битләрендә (*29 август, 2013 ел*) бер фәхишә: «Мин татар милләтен түгел, татар телен дә ташкаулчим генә беләм. Ул дәүләт, ул милләт мин шушы эшкә керешмәсен өчен нәрсә эшләгән соң? Укуым өчен түләгәнме, өч баланы ялгыз үстергән әниемә булышканмы? Мин бик озак үксез, ташландык, ач яшәдем — ул тормышка бер аягым белән дә кире басасым килми», — ди. Шуна да үзе турында: «Мин фахишә түгел, мин — эшмәкәр, — ди. — Акылым да, белемем дә, тырышлыгым да житәрлек. Әмма безнең илдә акылың белән генә ерак китеп булмый, йә блатың, йә эшлекле әтиең, йә матурлыгың булу кирәк. Миндә аның соңгысы гына булды». Бу сүзләргә аңлатма соралмый. Нәтиҗәне акыллы укучы үзе ясар, дип кенә әйтә алам.

Шулай итеп, хатын-кыз язмышын, гаилә мәсьәләләрен төрле планда ачкан Г.Галиева әсәрләре серле, мавыктыргыч вакыйгалары, сурәтле теле, гыйбрәтле язмышлары белән китап укучылар күңеленә үтеп кереп, аларны тормышка, мәгънәле яшәешкә өнди, битарафлыктан чыгара. Әдибә безгә шуның белән якын һәм кадерле. Бу язмабыз күптән түгел генә мәңгелеккә күчкән Гөлчәчәк ханым рухына дога булып ирешсен иде. Амин!

**Флёра ХАННАНОВА,**
*«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллимәсе*

# ШУНЫҢ БЕЛӘН ШУЛ... ВОКЗАЛДАН ЯЗАМ[1]

МЕМУАРЛАР

*Шулай да, бер вакыт җитәр әле – чынбарлыкта булып узган хатирәләрдән дә кызыклырак нәрсә табылмас.*

Уолт Уитмен

*Сез шәхси, хәтта интим тормышыгыз турында күбрәк язган саен, ул язганнарыгыз халыкка кирәгрәк булып чыга. Монда фәкать хаклы иканлегегезне белү һәм ихлас, хәтта ялгышкан, хаталанган чакта да, ихлас булуыгыз гына сорала.*

Гётеның Эккерманга язган хатыннан

Тормышың кояшы акрын-акрын гына баешына якынлаша башлауга, ирексездән артка, үткәннәреңә борылып карыйсың икән: нәрсәгә ирештең... ә нәрсәгә ирешмәдең? Ни эшләдең, ни эшләргә өлгермәдең, үкенечләрең каламы, калса, нинди үкенечләр? Һәм тагын бер кат инанасың: никадәр аз юл үтелгән дә никадәр күп хата кылынган! Ә күпмедер төзәтмә кертү, нидер үзгәртү – кызганыч ки, кулыңнан килерлек гамәл түгел инде. Булган – беткән. Яшең барган саен хәтергә, дөресрәге, аның сайлый белү сәләтенә сокланасың. Берәр хатирәне яхшырак, төпченебрәк искә төшерергә тырышасың да, гомумән үзгә, кирәкмәс очраклы бер истәлеккә төртеләсең. Кайберләре тавыш булып кире кайта, кайберләре – төс булып, кайберләре – хис булып; кайберләре – музыка аша искә төшә, гүя син иң алгы рәткә утырдың да, ретро-кино карыйсың, ә экранда – синең гомерең тәгәри һәм сюжет чишелешкә якынлаша инде... Нәтиҗәләр ясарга вакыт. Мондый очракта адәм баласының кабат үткәннәргә кайтуы – табигый дә кебек, анда, үткәндә, аның ямьле балачагы, гүзәл үсмерчагы калган бит. Танылган грузин шагыйре Карло Каладзе да юкка гына: «Балачагым гына истә, калганы – минеке түгел», – димәгәндер.

Ләкин язучының хәтер сандыгында актарынуы башка, гадәти кешенекеннән аерылып тора – ул үткәннәргә сагыну яисә юксыну сәбәпле генә кайтмый, мәңгегә агып киткән елларыннан ул монарчы әйтергә өлгермәгән, онытып торган мөһим вакыйгалар, мөһим сүзләр эзли.

Юл азагына якынлашкан һәр кеше житәрлек дәрәҗәдә тәҗрибә туплап өлгергән була, инде каләм әһеле мисалын карасаң, монда хәлләр бераз үзгәрә: укучыга аның үз йөзе, үз гыйлем-зирәклеге генә түгел, ә шушы сыйфатларның башка бөек шәхесләр, ил, халык, дәвер язмышында чагылышы да кызыклы. Язучы белән язучы булмаганның тормыш юлы арасындагы төп аерма – шул. Әдип соңгы сулуында да киләсе буыннарга үзенең өр-яңа ачышларын, монарчы ни сәбәпледер җиде йозак астында тоткан серләрен әйтеп калырга тырыша, үзе генә күргән, үзе генә белгәнне ачып салырга тели. Тормыш йомгагы сүтелә барган саен бу кичерешләр язучының күңел төбен ныграк тырный: аңа әйтеп калырга, кычкырырга, пышылдарга, яңа буынны, бәлки, кисәтергә, юатырга кирәк! Ул кадерле укучысына соңгы мәртәбә: «Хуш!» – дияргә тиеш. Ләкин аның калын-калын роман, хәтта аңардан югарак

[1] Журнал варианты.

бәян язарлык та вакыты булмаска мөмкин инде, димәк, кыска, төгәл, башка берәр тыгыз шәкел табу зарур!

Менә шул вакытта монарчы кеше күзе күрмәгән көндәлек кисәкләре, вак-төяк хәбәрләр теркәлеп барган иске дәфтәрләр, яна әсәргә чимал булырга тиешле язмалар ярдәмгә килә. Язучы гомер буе туплап барган бөек шәхесләрнен фикерләренә, әйткән сүзләренә, мәкальләргә, әйтемнәргә мөрәҗәгать итә. Ошаган шагыйрьләренең ак кәгазьгә күчереп барган шигъри өзекләрен укый. Ә алардан томнар җыярлык! Әйтик, мин үзем шигырьгә һәрвакыт мөкиббән булдым, һичкайчан шигырь язарга утырмасам да, кайбер тезмә юлнын берничә калын-калын чәчмә әсәрдән тирәнрәк, көчлерәк булуына төшендем. Мисал өчен: «Син Гайсәгә эндәшерсең, җавап бирер Иуда».

Аллаһы Тәгалә бүләкләгән озын гомеремдә мин андый дәфтәрләрне күп тутырдым; алардан тыш мине борчыган, мина кызыклы байтак материалны үз эченә алган йөзләгән сап-сары газета-журнал битләре, дусларым — XX гасырның танылган шәхесләре мина адреслаган хатлар сабыр гына үз вакытын көтеп ята. Ул шәхесләрнен һәрберсенә «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннән берәр китап багышлап булыр иде, әмма бу китапларны мин, кызганыч ки, беркайчан да яза алмам инде. Шушы кечкенә язмачыклар, хәтернең төрле почмакларына сибелгән вак хатирәләр белән канәгатьләнергә кала.

Әлбәттә, күпме гомер тузан җыеп яткан бу «әсәрләрнен» укучы өчен барысы да кирәк тә, кызыклы да түгелдер, бәлки. Әмма үткәннәремне барлый башлагач, мин шуны тәгаен аңладым: әлеге кәгазь кисәкләрендә беркайчан да кире кайтмаячак дәвер, тарих, үзгә рух, үзгә дәүләт, җәмгыять, гомумән, башка хыяллар, максатлар теркәлгән икән ич! Ул ашык-пошык язылган искәрмәләрдә минем җаным өчен бик кадерле кешеләр турында хәтер яши. Хыялларын, өметләрен, бәхетләрен, һәм, ниһаять, гомерләрен дә вакыт чигенең теге ягында — XX гасырда калдырган шәхесләр турында ул хәтер...

Хәер, кайберләре, шулар исемлегенә мин дә керәм, очраклы рәвештә, фәкать Аллаһы Тәгалә теләге буенча, аякларын сөйрәп кенә, XXI йөзгә үтте, һәм берәзга, үзләре дә теләмәстән, ни аңлап, ни күнеп булмый торган яңа тормышның юлаучыларына әверелде.

Кешелек дөньясынын һичкайчан да алдагы буын белән монын кадәр санлашмаганы юк иде әле, минемчә. Бу кызганыч хәлне бүгенге Русиядә күзәтергә туры килә. Яңа Русиягә ни үзенен үткәне, алдагы буыннарның ни уңай ягы, ни, бигрәк тә, хаталары кирәк түгел. Минем дә аларны маяк, үрнәк үк итеп күрсәтәсем килми, аның тәҗрибәләренә, югалту-табуларына да игътибар юнәлтергә исәбем юк. Бүген безнен тәҗрибәнең кирәге бер тиен. Мин үз замандашларымнын әдәби сурәтен күрсәтеп калдырырга телим, алар төгәл бер чорга береккән, бу — тарихка иң рәхимсез һәм иң канкойгыч булып кереп калган XX гасыр... Кемнәр ул? Нинди алар? Нинди хыяллар белән янган? Ничек яшәгән? Ни теләгән? Нәрсәгә омтылган? Максатларына ирешкәнме? Юкмы? Юк икән, нигә юк? Язмыш рәхимсез булганмы, үзебез ачыгавызмы? Белмим. Ул турыда хәзер баш вату да кирәкмидер, бәлки. Безнен вакыт үткән инде. Ком сәгате тып-тып кына соңгы көннәрне саный...

## Малеевкада рулетка уены

Безнен бәхетле яшьлеккә Иҗат йорты дигән могҗизалы урыннарның шау чәчәктә утырган вакыты туры килде... Мөгаен, бүгенге укучыга аның ни-нәрсә икәнен аныклап китү зарурдыр, бу төшенчә минем мемуарларда еш телгә алыначак әле.

Иҗат йорты — тулаем һәм фәкать Советлар Союзы, дөресрәге, Сталин уйлап тапкан «күренеш». Язучыларга мондый игътибар беркайда да, беркайчан да булмаган, юк, һәм, кызганыч, бик кызганыч ки, мөгаен, булмаячактыр да инде. Нәрсә ул минем фикер — хәтта дөньяның иң зур, иң данлыклы язучылары безнен Иҗат йортларында кунак булганнан соң бу могҗиза турында көнләшеп тә, сокланып та бик еш язды. Моны искә төшерү белән тагын бер кат көрсенеп алырга туры килә: их, СССР дигән мәгърур ил белән бергә Иҗат йортлары да үзеннән-үзе гаип булды шул. Ә бит совет китабынын азаккы битен ачып карасаң, ун китапның тугызында язу вакыты белән

язу урыны күрсәтелгән булыр, ә бу, нигездә — Малеевка, Переделкино, Дубылты, Гагра, Ялта, Күктүбә, Пицунда, Дурмень, Аккош күле, Комарово һ.б.

Иҗат йортлары гаҗәеп матур җирдә, шәһәрдән, тавыштан ерактарак — табигать кочагында була торган иде. Кайберләре, бигрәк тә диңгез ярларындагылары, җәйге санала иде, болары үзенә күрә курорт сыман, аларга сезон чакта якын киләм димә. Язу өчен иң яхшысы һәм иң рәхәте, мөгаен, Малеевка булгандыр. Ул Глухово авылы янында, Мәскәүдән 110 чакрым ераклыкта урнашкан. Бирегә язучылар күпләп килә, бер-ике ай дәвамында (ә романчылар, тәрҗемәчеләр — өчәр ай да була) яшәп, иҗат итеп китә иде. Йорт урман куенына сыенган, тимер юлга кадәр — уналты чакрым, кыскасы, бирeдәге тормыш калган дөньядан тулаем мөстәкыйль һәм аннан гомумән бәйсез иде. Монда үзгә, кызыклырак тормыш гөрли...

Патша заманында ук нигез салынган бина сугыш тәмамлануга В.П. Огарев исемле бик талантлы архитектор кул астында яхшыртыла, төзекләндерелә — нәтиҗәдә язучыларның һәр тәкъдим-теләге исәпкә алынып янартылган бу йорт барлык Иҗат йортларыннан да унайлырак килеп чыга. Төп корпусның икенче катында мәһабәт, кызыл агачтан эшләнгән киштәләре түшәмгә терәлеп торган бай, меңләгән сирәк китапны, белешмәлекне кочагына алган китапханә бар иде, ул дистәләгән журнал (шул исәптән, чит илләрнекен дә), исәпсез-хисапсыз санда газеталар яздыра иде, бу Әбугалисина мәгарәсеннән әһле каләм өзелмәде, һәм һәрберсе, яңа китабы чыгуга, имзасын куеп, аны яраткан китапханәсенә бүләк итәргә ашыга иде. Шушы җәүһәрләрнең барысы да — бөтен китап, бөтен журнал — барысы-барысы да! — Ельцин заманында күз ачып йомган арада мәңгелеккә юкка чыкты.

Соңгы классицизм стилендә салынган колонналы төп корпуска ике канат-корпус кышкы бакча белән кушылган. Әйе, әйе, чып-чын кышкы бакча белән! Бакча тулы сирәк үсенте, чәчәкләр, куак-агачлар, фикуслар! Язучылар бу гүзәллек аша көненә өч тапкыр ашханәгә уза. Үсентеләр арасында имән эскәмия, урындыклар тезелгән. Гайре табигый зур тәрәзәләрдән төшкән кышкы йомшак яктылык китап сөючеләрне, бигрәк тә бер-ике көнгә кунакка керүчеләрне, шушы бакчага тартып тора иде.

Шимбә-якшәмбеләрдә электричка белән ике арада автобус йөри: кем килә — рәхим итегез, кем китә — хуш, киләсе очрашуларга кадәр сау булыгыз!..

Мин Малеевкага тәүге тапкыр 1975 елда килеп эләктем. Бусагадан атлап керүгә үк мондагы гүзәллек аяктан екты — бер күрүдә гашыйк булдым ана. Шуннан 1991 елгача, уналты ел дәвамында, елына икешәр тапкыр бирегә килгәләп эшли башладым. Бу «авылчык» никадәр генә чуар булып, монда никадәр күп халык алышынып торса да, асылда, барыбер бер үк кешеләр ешлый иде — мин илленче еллардан ук юллары өзелмәүчеләрне дә беләм.

Хәзерге шактый сирәк күрешүләрдә без, карт малеевкачылар, туган йортларын югалткан ятимнәр кебек, бер-беребезнең кочагына ташланабыз.

Хәер, әйдәгез, күңеллерәк вакыйгаларга кайтыйк әле...

1979 елның кышында язучы, халыкара журналист Ярослав Кириллович Голованов Парижда уздырылган чираттагы фәнни конгресста катнашып кайтты. Голованов кебек танылган, дәрәҗәле кешене дә мин бүген тәфсилләп таныштырырга мәҗбүр, чөнки буыннар бәйләнеше мәңгелеккә өзелде. Дәвам өчен хәтта Сергей Королевның исеме дә һичнәрсә белдермәскә мөмкин, иң яхшы очракта — җырчы Наташа Королеваның әтисе, дип уйлаячаклар.

Ул вакытта Гагарин, галәм, Терешкова дип санап киткәндә, ирексездән Голованов фамилиясен дә өстисе килә иде. Ярослав Кириллович Гагарин галәмгә очканчы ук беренче космонавтлар отрядына керүе белән танылды, аны командага ракета төзү, космонавтика фәннәренә якын галим буларак тәкъдим итәләр. Без бу шәхес белән озак еллар таныш идек, минем шәхси китапханәмдә әлегәчә үзе имзалап биргән берничә китап саклана. Ул безнең галимнәр, чит ил галимнәре турында бик кызыклы этюдлар язган кеше, аның эрудициясе, мәгълүматлылыгы таң калдыра, ул инглизчәне су кебек эчә, алманчаны (немецча) да ярыйсы гына белә иде. Ләкин эш анда гына да түгел — Ярослав Кириллович гаҗәп дәрәҗәдә аралашучан кеше булды, тәүге сүзе, тәүге елмаюыннан ук авызына карата белде, нәрсә дип кенә мөрәҗәгать итсә дә, аны кире кагу, сүзен аяк астына салып таптау — мөмкин хәл

түгел иде. Хатын-кызлар картайганчы артыннан калмады, хәер, алай дисән, карт чагын хәтерләмим дә мин аның. Ахыргы көннәренә кадәр КВН яшьләр конкурсында жюри әгъзасы булып торды. Мөгаен, хәзер менә исегезгә төшкәндер — елмаюын, киң күңеллелеген, көтелмәгәнчә кызыклы җор сүзләрен хәтерлисездер.

Галәмгә очарга туры килми ана, әзерләвен әзерлиләр дә бит, ләкин нишләтәсең — язмаган, димәк. Байтак еллар дәвамында ул бик күп космонавтлар — Гагарин, Титов, Терешкова, Николаев белән дуслашып бетә, аларның туйларында бәйрәм итә, галәми уңышларга ирешкән күп кенә галим-голәмә белән дә таныша. Уңышлы һәм уңышсыз очышларны күрә. Байконурга барып казакъ далаларында космонавтлар белән күрешә, аларны ерак та, куркыныч та сәфәргә — Күккә — озата. Ул вакытта галәмгә, космонавтларга карата игътибарны-ихтирамны сүз белән аңлатып буламы икән?! Менә, мөгаен, совет фәне һәм космонавтикасының шул триумфлы елларын күргән кешеләр генә аңлар — без берсүзсез беренче номерлы галәм мәмләкәте дигән дан-дәрәҗәгә ирешкән идек.

Ярослав Голованов үзенең журналистлык һәм язучылык гомерен фәнебезнең, тәүге космонавтларның шундый алгарышын пропагандалауга багышлады — чоры өчен бик кирәкле шәхес иде ул, аны укыйлар, хезмәт иярәре алдындагы, институт, телевидениедәге чыгышларын көтеп алалар иде.

Махсус хәбәрче булып эшләгән «Комсомольская Правда» газетасында күләм ягыннан аны беркайчан да чикләмәделәр, фәнебезнең уңышлары, ул уңышларга ирешер өчен тир түккән «тылсымчылар» турындагы зур-зур очерк, этюд, әңгәмә, мәкаләләре һәрдаим басылып килде. Хакимиятнең халыктан һичнинди сере юк иде, ә халык үз галимнәрен таный, кадерли, данлый белде. Иманым камил: иң яхшы югары техник белем бирү йортлары абитуриентларның 1963-1980 елларда ташкын сыман ябырылуы өчен илнең техника мәсьәләсендә алга китүенә генә түгел (бусын хәтта дошманнар да таный иде), Ярослав Головановның миллионлаган тиражлы газетада дөнья күргән мәкаләләренә дә бурычлы.

Ярослав Кирилловичның юмор хисе дә сау иде. Малеевкада аның үз башыннан кичкән вакыйганы сөйләгәне истә. Ләкин әүвәл аңлатып китү зарур: галәм мәсьәләләрен космонавтлар янында озак еллар эшләгән галим, фән докторы буларак өйрәнүе, чит телләрдә сөйләшә белүе, чыгышы вакытында бар тамашачыларны үзенә каратып тота алуы Ярослав Кирилловичка Җир шарының бик күп почмакларында, шәһәрләрендә уздырыла торган халыкара симпозиум, корылтай, очрашу, күргәзмәләргә барыр өчен барлык ишекләрне ачты. Үзе төзегән кызыклы маршрутлар буенча ул, һичшиксез, бар дөньяны урап чыккандыр, заманында мондый мөмкинлекләр белән сирәк дипломатлардан тыш бик аз кеше мактана ала иде, әмма Ярослав Кирилловичның һичкайчан борын чөйгәне булмады.

Инде, ниһаять, вәгъдә ителгән вакыйгага тәмам якынлаштык...

Берсендә, вакыт төнгә авышкач, Лондоннан шалтыратып, Ярослав Кирилловичны галәмне тынычлык максатында үзләштерү мәсьәләләренә багышланган конференциягә чакыралар. Күптән ниятләнгән бу чара турында газетада беләләр, билгеле, һәм, махсус хәбәрчеләренә анда барырга алдан ук рөхсәт биргән булалар — рәсми чакырылуны көтәргә генә кала. Вакыт кыса башлый, Голованов сәгать унга редакциягә килеп җитә, кадрлар бүлеге белән бухгалтериягә сугыла (башка җиргә керергә кирәк түгел, мультивиза, салкын сугыш баруга карамастан, кесәдә ята инде, ул теләсә кайчан теләсә кайда очарга хокуклы — ВЛКСМ Үзәк Комитетының төп басма органы шундый дәрәҗәгә ия чак!).

**Рауль МИР-ХӘЙДӘРОВ**

*Дәвамы киләсе саннарда*

# «КАЧКЫН»

«Минем беренче операм Пугачёв восстаниесенә багышланган иде», — дип яза композитор Нәҗип Җиһанов үз көндәлегендә. Әлеге сүзләр «Качкын» операсы турында. Музыка белгечләре фикеренчә, «Качкын» — татар тарихында сәхнә кануннарына җавап биргән беренче профессиональ опера. Казанда 1939 елда Татар дәүләт опера һәм балет театры ачылуы да нәкъ шушы әсәр белән бәйле. Быел әлеге зур вакыйгага 75 ел тулуны искә алып, «Качкын»ның язылу тарихына мөрәҗәгать итәргә булдык.

Нәҗип Җиһанов «Рождение оперы» мәкаләсендә *(«Советская музыка», 1986. — №6. — Б.67-68)* «Качкын» операсы туугa этәргән вакыйганы болай бәян итә: «1936 елның көз аенда Генрих Литинский (ул вакытта мин Мәскәү консерваториясенең IV курс студенты идем) мине очратып, Татар опера студиясенең җыелышына чакырды. Гаҗәпләнеп: «Мин консерватория студенты бит, опера студиясенеке түгел», — дип җаваплaдым. Ләкин Генрих Ильич минем, һичшиксез, анда булуымны үтенде».

Җыелышны Татариянең мәгариф наркомы үткәрә. Анда сүз башлыча республиканың студиядә укуга акча җәлләмәве, уку тәмамлануга ике ел гына калуы турында бара. Төп басым Казанда опера һәм балет театры ачылуына һәм әлеге вакыйганың татар сәнгате өчен яна баскыч булуына ясала. «Опера театрын ачардай опера кайда соң?» дигән сорау җыелышның кульминацион моменты булды. Әлеге сорау студиядә укучы композиторлар Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһит Хәбибуллин, Мәсгуть Латыйповка мөрәҗәгать ителгәне көн кебек ачык иде. Ләкин көтмәгәндә Литинский, торып: «Татар операсы булачак, аны Нәҗип Җиһанов язачак, ә либретто авторы — Әхмәт Фәйзи», — дип әйтеп салды һәм, миңа иелеп: «Язам дип әйт», — дип пышылдады. Мин көтелмәгән бу яналыктан дулкынланып, куркып кына: «Әйе, опера булачак», — дип җавап бирдем», — дип искә ала Җиһанов.

Әлеге җыелыш «Качкын» тууга оеткы сала да инде. «Советская музыка» журналында басылган бу мәкаләдә фактик хаталар китүе ачыкланды. Нәҗип Җиһановның оныгы Алексей Егоров билгеләвенчә, күпсанлы документларны тикшергәннән соң, югарыда бәян ителгән җыелыш 1935 елда узганы һәм Җиһановның ул вакытта консерваториянең III курсында укыганы билгеле булды.

Җыелыштан соң киеренке эш башлана. Генрих Литинский опера Пугачёв явында Идел буе халыкларының кыерсытылу вакыйгасына багышланырга тиешлеген әйтә. Беренче вариантта опера «Булат батыр» дип атала. Ләкин соңрак, архивларда крестьян явы турында бик күп материалларны өйрәнгәч, аны «Качкын» дип үзгәртәләр. Чөнки Пугачёв гаскәрендә качак крепостной крестьяннар күп була, аларның күпчелеген татарлар, шулай ук Урал һәм Идел буеның башка халык вәкилләре тәшкил итә. Операга нигез итеп алынган сюжет бик гади. Пугачёв явыннан туган иленә кайткан элекке крепостной ташчы Булат крепостнойларны көрәшкә өндәп оештыра. Аны эзәрлекли башлыйлар. Ләкин халык ярдәме белән ул бу тозактан котыла һәм, крестьяннарны үз артыннан ияртеп, алпавыт утарын тар-мар итеп, Пугачёв явына кушылырга китә. Шушы төп темага параллель рәвештә Булат һәм Рәйхананең мәхәббәте һәм алпавыт ярдәмчесе Аблайның арага керүе сурәтләнә.

1937 елның җәенә бер актлы «Качкын» операсы әзер була. Әхмәт Фәйзи белән Нәҗип Җиһанов аны музыкаль даирәгә һәм партия җитәкчелегенә тәкъдим итү максаты белән Казанга кайталар. Яңа әсәр зур бәхәсләр тудыра, хәтта «татарга опера кирәкме» дигән фикерләр дә яңгырый, ләкин, Нәҗип Җиһанов искә алуынча, андыйлар күп булмый. Күпчелек әсәрне югары бәяли һәм авторларга әлеге опера



*«Качкын» операсын тудырган яшь иҗат төркеме. 1 нче рәт. Утырганнар (сулдан уңга): Мәскәү консерваториясе профессоры, композитор һәм Н.Җиһановның укытучысы Г.И.Литинский, дирижёр Г.С.Бергольц, режиссёр Е.Ф.Манакова, театр директоры З.Бермилеев, композитор Н.Җиһанов; 2 рәт. Басканнар (сулдан уңга): солистлар З.Байрашева, М.Булатова, З.Бичурин, У.Әлмиев, М.Алиев. Мәскәү, 1940 ел*

нигезендә өч яисә дүрт актлы тулы опера язарга тәкъдим итеlә.

1937-1938 уку елларында либретто авторы һәм композитор нәкъ шул эш белән шөгыльләнә дә: кайбер образлар тирәнәйтелә, яна персонажлар барлыкка килә, яна ария, ансамбльләр иҗат ителә, музыкаль драматургия кинәя. Либретто Мәскәү студиясе дирекциясе киңәшмәләрендә һәм Казанда ТАССР Халык Комиссарлары Советы каршындагы сәнгать эшләре идарәсендә үткәрелгән киңәшмәләрдә кат-кат тикшерелә. Әхмәт Фәйзи әйтелгән киңәш, тәкъдимнәр тәэсирендә драматургик материалны берничә тапкыр редакцияли. Студиянең әдәби бүлек мөдире Муса Җәлилнең «Качкын» либреттосының соңгы вариантына унай бәяләмәсе сакланган («1937 ел, 8 июль» даталы, язу машинкасында басылган рецензия Мирасханәдә саклана): «Киңәшмәләрдә чыгарылган нәтиҗәләр һәм рецензияләрдә әйтелгән фикерләр белән миңа китерелгән либреттоны чагыштырып караганнан соң, (...) Әхмәт Фәйзи үзенең либреттосын намуслы рәвештә редакцияләп чыккан, дип әйтә алам. (...) Минемчә, либреттода 100% канәгатьләндерү читен эш. Либреттода образлар үзенчәлекле, ышандырырлык итеп бирелгән. Вакыйгаларның үсеше логик яктан аклана, дулкынландыра һәм нык тәэсир итә торган вакыйгалар да юк түгел (Булат белән Рәйхананең очрашуы; Рәйхананең әсир төшүе). Композиция ягыннан либретто уңышлы эшләнгән. Халыкчанлыктан аерылган, беркадәр корырак һәм ясалмарак чыккан аерым урыннарын исәпкә алмаганда, либреттоның теле әдәби. Гомумән, либреттоны мин яраклы дип табам һәм тәмамланган әсәр буларак кабул итәргә дигән тәкъдим кертәм».

Нәҗип Җиһановка музыка язуда укытучысы Литинский зур ярдәм күрсәтә. Композитор истәлекләрендә аерым сәхнәләрнең кат-кат язылуы турында бәян итә, мәсәлән, «Рәйханә үлеме сәхнәсенә Генрих Ильич аерым игътибар бирергә куша, чөнки, аның фикеренчә, героиняның үлеме әсәрнең музыкаль драматургиясен көчәйтергә сәләтле. Профессорның «менә хәзер бу тиешенчә булды», дигән сүзләрен ишеткәнче, Рәйханә үлеменең бик күп вариантын язарга туры килә. Литинский шулай ук операның пентатоникасын төрле яклап баетуны таләп итә, шул рәвешле «Качкын» заманча музыкаль яссылыкта иҗат ителә.

1938 елның яз айларында, консерватория студентларының дәүләт имтиханнарыннан соң, Бөтенсоюз радиосының музыкаль редакторы Е.Грошева тәкъдиме белән «Качкын», рус теленә тәҗемә ителеп, Коммунистик интернационал исемендәге Мәскәү радиостанциясендә яңгырый. Төп партияләрне радионың солистлары Наталья Рождественская һәм Левон Хачатуров башкара.

Нәҗип Җиһанов та, Әхмәт Фәйзи дә, Мәскәү консерваториясен тәмамлаганда, диплом эше итеп «Качкын» операсын тәкъдим итәләр. 1938 ел ахырында студиядә укучылар Казанга кайта. Бу чорның тәфсилле сурәте Нәҗип Җиһановның беренче хатыны Серафима Җиһановага язган хатларында саклана. (Казанда торак мәсьәләсе хәл ителгәнче Серафима кызы Светлана белән Мәскәүдә яши.) Аларда тормыш-көнкүреш вакыйгалары белән бергә опера куелышы буенча барган эш процессы да сурәтләнә. Шулай ук «Качкын»ның Башкорт дәүләт опера театрында куелуына бәйле сөйләшүләр алып барылганы турында да мәгълүматлар бар.

Муса Җәлил 1939 елның 4 июнендә «Кызыл Татарстан» газетасында басылып чыккан

«Татар театры ачылу алдыннан» мәкаләсендә Казанга кайту чорын болай тасвирлый: «Театр коллективының Казанга күчеп, Дәүләт опера театры булып оешканнан соңгы биш ае портфельдә булган опералары куярга хәзерләү, аларның художество оформлениесен (декорация, костюм, париклар һ.б.) житештерү, куярга хәзерләнгән әсәрне редакцияләүне тәмамлау белән үтте». «Портфельдәге опералар» дигәндә, сүз Ш.Гунонын «Фауст», Н.Жиһановның «Ирек», шулай ук П.Гертельнын «Тщетная предосторожность» балеты турында бара. Муса Жәлил әлеге язмасында «Качкын» белән «Фауст»ның бер үк режиссёр Фёдор Каверин тарафыннан куелачагын билгеләп үтә.

Усман Әлмиев «Татар опера театры сәхнәсендә» истәлекләрендә «Качкын»га карата мәгълүматларны тулыландырган кебек (*«Еллар һәм жырлар». — Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. — 21 б.*): «Опера театрын ачар өчен театрда бернәрсә дә булмаганлыктан, театрга кирәкле реквизит, декорацияләр, костюмнар һ.б. нәрсәләр әзерләргә тотындылар. Костюмнар тегәр өчен, театрга тукылган материаллар кирәк иде. «Качкын» операсы крестьяннар тормышыннан булганга күрә, геройларга тукылган, киндердән тегелгән киемнәр әзерләнде. Киез эшләпәләрне читтән, барып, эшләтеп алып кайттылар. Хор өчен киемнәр дә киндердән тегелде. Киемнәр, ыштаннар-күлмәкләр — барысы да шул чорны хәтерләтә иде».

Нәжип Жиһанов март аенда Серафима Жиһановага язган хатларында опера театрының ачылышына «Качкын»ны сыйфатлы итеп куярга житешмәячәкләре өчен борчылса, 8 май белән даталанган хатында театрның ачылу тантанасын күчерүләренә уфтана. «Рус театры бинаны 25 майдан соң гына бушата», — дип яза ул. 3 июнь хатында «премьера көннәрендә кемгә жырларга?» дигән темага бәхәс баруын хәбәр итә: «Көрәш Рәйханә белән Булатлар арасында бара. Кайберәүләр үзләренең стажлары һәм татар халкы алдында популярлыкка басым ясый. Рәйханә — Кайбицкая, Садыйкова; Бикә — Измайлова, Рахманкулова, Зәбирова; Булат — Маннапов, Артёмов; Аблай — Бичурин, Родионов, Минаев; Кирәмәт — Насретдинов, Сәйфетдинов. Һәрберсе премьерада чыгыш ясауга өмет итә. Ой, нинди скандал булырга тора, күз алдына да китермисен! Мин директорга да, сәнгать житәкчесенә дә «премьерада яхшы вокалистлар жырлаячак», дидем, ягъни: Кайбицкая, Артёмов, Насретдинов...»

Кыскасы, «Качкын» тирәсендә шау-шу премьерага кадәр дәвам итә. Ниһаять, 1939 елның 17 июнендә Татар дәүләт опера һәм балет театры рәсми рәвештә «Качкын» белән ачыла. Операны Ф.Каверин сәхнәләштерсә, кумәк халык биюләрен Гай Таһиров куя, сәхнәгә куючы рәссам — Мортаза Абдуллин, баш дирижёр — Савелий Бергольц. Архив материалларында, истәлекләрдә аларның һәрберсенең эше тәфсилләп язылган, бу мәкалә кысаларында аларга аерым тукталып тору артык булыр.

Татар дәүләт опера һәм балет театры ачылу тантанасыннан соң, ул чор матбугатында күпсанлы рецензияләр дөнья күрә. Хәлимә Булатова-Терегулова 1939 елда «Советская музыка» журналының 8 нче санында басылып чыккан мәкаләсе аерым игътибарга лаек. Бирелә «Качкын»га музыкаль яктан житди анализ ясала, төп партияләрне башкаручыларга объектив бәя бирелә. Шул ук вакытта операның әле тулысынча эшләнеп бетмәве, моның өчен коллективка күп көч салу кирәклеге ассызыклана. 1940 елда «Качкын» операсы Башкорт дәүләт опера һәм балет театрында куела, Казанда 1944, 1952, 1964 елларда төрле режиссёрлар тарафыннан сәхнәләштерелә.

Күптән түгел Татар дәүләт опера һәм балет театры ачылуга 75 ел тулу нисбәтеннән, башлангычта торган күренекле артистларның якыннары Нәжип Жиһанов музей-фатирына жыелды. Бу очрашуда балалар-оныклар истәлекләр белән бүлеште, «Качкын» операсын янарту кирәклеге турында да сүз булды. Жәлил театрында булмаса, Казан дәүләт консерваториясенең опера студиясе тарафыннан «Алтынчәч» операсы кебек үк ачык һавада куелсын иде дигән теләктә калды алар. «Качкын»ның бүген сәхнәдән ни дәрәҗәдә актуаль яңгыравын фаразлау авыр, ул безгә, беренче чиратта, мәдәни ядкәр буларак кызыклы. Чөнки, Жәлил сүзләре белән әйтсәк, «Качкын» — татар совет культурасы тарихында зур вакыйга. Бу — татар сәнгатенең яңа баскычка күтәрелүен һәм уңышлы рәвештә алга үсә баруын күрсәткән факт».

**Гүзәл СӘГЫЙТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# МӘГЪНӘ

## КОРЪӘНДӘГЕ МОГҖИЗАЛАР

*Калмады сурәт, бары тәбдил ителде Мәгънәгә,*
*Әүрелеп Мәгънәгә, дөнья сәҗдә кылды Мәүлага.*
Г.Тукай

### Әбием догалары

Атам-анам икесе дә укытучы иде. Алар мәктәптә эшләгән заманнарда дин сүгелә, мәчетләр җимерелә, Аллаһ йортларын — мәчетләрне иске-моск келәте итәләр яки клуб ясыйлар. Иманнары әйле-шәйле булганнар шундук алласызлар әтрәтенә язылды. Дин сүгеп, Алла юк, дип акырып йөрү бер модага әйләнеп китте. Атам да, анам да коммунистлыкка язылмады, шулай да алар ачыктан-ачык дин дә тотмый иде. Совет укытучысына Аллага ышанырга ярамый иде. Алар ашар алдыннан «бисмилланы» да: кеше күрмәсә-ишетмәсә ярар иде дип эчтән генә пышылдыйлар иде.

1933 елда әтием Мөхлисулла әнием Мөкәррәмәгә өйләнгән. Әби авылның соңгы указлы мулласы Әшрәфҗан хәзрәтне никах укырга чакырган.

— Ындыр артлатып кына кил, хәзрәт, камунистлар сине күрмәсен, ату «никах укытты» дип Мөхлисулламны укытучылыктан алырлар! — дип кисәтергә дә онытмаган.

Әшрәфҗан хәзрәтнең бакча аша безгә килгәнен күреп, әтием аның каршысына йөгереп чыккан да:

— Кире борыл, хәзрәт, карангыда килерсен! — дип, мулланы кире борган.

Әбекәем яшереп-посырып мина дога өйрәтә торган иде.

**Әгузү билләһи миннәш-шәйтанир-ражиим, бисмилләһир-рахмәәнир рахиим.**

*Алланың рәхмәтеннән ләгънәт илә куылган шайтаннан Илаһка сыенам, дөнья вә ахирәттә бөтен җан иясенә мәрхәмәт вә ярдәм кылучы Алланың исеме белән эшемне башлыймын.*

Минем яшертен өйрәнгән беренче догам шушы булды. Икенче догам:

**«Ләә иләәһә илләллаһү, Мүхәммәдүр Рәсүүлуллаһ»** иде.

Аллаһтан башка илаһ юк, Мөхәммәд аның илчесе.

Өченче догам исә:

**«Раббәнәәә әтинәә фиддүнйәә хәсәнәтәү үә фил әәхыйрати хәсәнәтәү үә кыйинәә газаабәннәәәр».**

*Йа Раббем, безгә дөньяда да, ахирәттә дә яхшылык вә гүзәллек бир. Безне җәһәннәм газабыннан сакла.*

Аннан сон «Әл-Ихлас», «Әлхәм» сүрәләре... Әбиемнен изге истәлеге булып, шушы догалар мине гомерем буе озата йөрде. Әбием Мәгъсүмә карчыкнын гүре нур булсын, урынын җәннәттән әйләсен! Әмин!

### Бакыйлыкта калсын Бакыйның исеме

Язучылыкка тотынгач, мин һаман уйлана идем, Пушкиннар лицейларында «Закон Божий»ны өйрәнгән, Тукайлар мәдрәсәләрендә Корьәнне яттан укыган. Бәлки, диннәрне яхшы белгәнгә аларнын таланты шулай ачылып киткәндер? «Инҗилне» өйрәнеп, Пушкин поп булып китмәгән, ләбаса, үзенә «буй житмәслек шигъри һәйкәл» салган. Мәдрәсә бетереп, Тукай да мулла булмаган. Нәни Апуш «зуп-зур Тукай» булган.

Динне себереп түгеп, коммунист-дәһриләр татар язучыларын фәкыйрьләттеләр! Шуңа күрә, күп язучыларыбызның әсәрләрендә тирән фәлсәфә кимегәннән кими бара. Ярлы Кәримнәр, Фәкыйрь Галиләр, Юксыл Вәлиләр, Мескен Сәлиләрдән калган язмалар әдәбият хасил итә алмый.

Соң өлгердек без. Безнең буын Коръәнсез, динсез үсте. Динсезлектән денсезлеккә бер адым, ди торган иде әбием Мәгъсүмә. Мин Коръәнне бары тик иллегә житкәндә генә өйрәнә башладым. Соң, бик соң. Иллегә чаклы үлеп киткән булсам, мин шулай шыр надан килеш китеп тә бара идем. Шөкер, Аллаһы Тәгалә миңа форсат бирде, мин кулыма Коръән алдым. Анысы да Бакый Урманче белән еш аралашуым аркасында булды. Атаклы рәссам, сынчы Бакый Урманче эшеннән бушаган вакытларда һәрвакыт кулына Коръән ала торган иде.

— Бакый агам! — дидем. — Син Мөхәммәдия мәдрәсәсендә яхшы билгеләргә генә укыгансың, Коръәнне ныклап өйрәнгәнсең, әле һаман укыйсың.

Бакый ага кеткелдәп көлде дә әйтте:

— Дустым, Коръәнне мин сиксән ел укыйм, һаман укып туймыйм, һаман ниндидер яңалык табам.

Менә мин дә Бакый остазым юл күрсәткәнчә егерме алты ел Коръәнне өйрәнәм. Аллага шөкер, өйрәнгән саен нинди дә булса аңламаган өлешен аңлыйм кебек.

Шундый кечкенә утырышларыбызда мин әйттем:

— Бакый ага, урта белемле кешегә дә аңлашылырлык телгә Коръәнне тәржемә итәргә алынмассызмы? — дидем. — Сез тәржемә итәрсез, мин турыдан-туры машинкамда яза барырмын!

Бакый аганың күзләре балкыды, бу тәкъдим аңа бик тә ошый иде.

— Менә, дустым, хастаханәгә ятарга кушалар табиблар, системалар алып, ныгып чыгарсың, диләр. Атна-ун көннән килерсең, без бу олы эшне башлап җибәрербез, иншаллаһ!

Ләкин бу олы эшне башларга насыйп булмаган икән: остаз хастаханәдә вафат булды. Урыны җәннәттә булсын!

Әмма мин бу эшне үзем башларга булдым. Төрекчә, үзбәкчә, урысча Коръән тәржемәләрен алдыма җәеп салдым да Изге китапны өйрәнә башладым һәм «Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре» исемле китабым дөньяга чыкты.

Язучы буларак, мин табышларым илә башкаларны да таныштырасым, шатлыгымны уртаклашасым килә. Чөнки Коръән күңел күзен ача. Ике күзе дә күрмәгән кеше сукыр түгел, ике күзе күреп тә, күңел күзе күрмәгән кеше сукыр. Күңел күзе ачылган адәм беркайчан да яманлык кылмас, мохтаҗларны ярдәмчесез калдырмас, ата-анасына, балаларына, кешелек дөньясына миһербанлы булыр.

Тәржемәләрне, тәфсирләрне кат-кат укып, үзем өчен үзем ачкан табышларымны, галимнәр аңлатканнарны, хөрмәтле укучым, сезгә җиткерергә җөрьәт итәм.

Коръән ул мәңгелек китап. Шулай укый торгач, «Коръән аятьләренең татарча мәгънәләре» исемле китап алты тапкыр басылып чыкты, һаман ихтыяҗ бар, жиденче басмасын сорыйлар. Китап чыга тора, миңа хатлар килә тора, телефоннан да шалтыраталар. Кемдер хуплый, кемдер хурлый. Әмма китап сатылып бетә бара. Аллага ышанмаганнар да, Аллага иман китергәннәр дә яза. Аларның Коръәндәге аңлашылмаган нәрсәләрне аңлыйсылары килә.

Мин мулла түгел, мин язучы, күп тапкырлар Коръәннең тәржемәләрен, тәфсирләрен укып чыккан кеше буларак, аятьләрне ничек аңлаган булсам, шулай аңлатырга тырышам. Мин дөньяны әнә шулай күзаллыйм.

Бакый ага миңа бик кыйммәтле мирас калдырды: ул мине Коръәнне аңларга өйрәтте. Гүре нур булсын, исеме бакыйлыкта калсын, остазым Бакый агам!

## Фән Коръәнне кире кагамы?

*(Дәһриләр белән бәхәс)*

Бу бүлеккә мин атаманы «Алласызлар белән бәхәс» дип куйган идем. Уйга калдым. Алласыз кеше була алмый, хәтта: «Алла юк, мин аңа ышанмыйм» дип тәкрарлаучы да Алласыз була алмый. Чөнки ул Аллаһ барлыкка китергән дөньяда

яши, үзе дә Аллаһ кодрәте илә дөньяга килгән бәндә. Бәс, мин «дәһри» сүзен кулланмакчы булдым, гәрчә бу сүз күп мәгънәләргә ия. Мин аның йөрештә еш кулланылган мәгънәсен алдым.

**Дәһри** — Ахирәткә ышанмаучы, Аллага ышанмаучы, динсез, материалист, атеист, коммунист дигән сүз.

Күп кенә бәхәсчеләр, аларның күбесе элеккеге коммунист, «Коръән серләре» исемле китапның авторы Гариф Гобәй кебек дәһриләр:

— Фән Алла юклыгын исбат итте! — дип тәкрарларга ярата.

Әстәгъфирулла! Бу — көфер сүз! Киресенчә түгелме, әфәнделәр?

Шөһрәте дөньяга таралган табиб, галим Тәүрат, Библия, Коръән китаплары белгече Морис Бюкай «Библия, Коран и наука» исемле китабында ике китапны да фән күзлеге аша карап, тикшереп чыга һәм фәнни табышларның, космоска очуларның, атом-төш физикасындагы ачышларның Коръәндәге мәгълүмат белән каршылыкка килмәве турында тәфсилләп яза. Киресенчә, Коръән ул ачышларның булачагына кинаяләр ясый икән.

Галим шундый нәтиҗәгә килә:

*Мөхәммәд пәйгамбәр яшәгән вакыттагы кешеләрнең белем дәрәҗәсен искә алсак, Коръәндәге күп кенә мәгълүматның фәндәге теге яки бу аспектларны гади кешенең хезмәте нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип булмый. Шулай итеп, Коръәнне Аллаһ сүзе дип карау белән бергә ул башка китаплар арасында аерым урын тота дип хаклык рәвештә әйтә алабыз. Коръән, һичшиксез, мона лаек, чөнки ул ихлас, хак һәм анда бүген фән тарафыннан ачылган нигезләмәләр бар һәм Коръән аятьләре бүген яна сыйфатта янгырый. Мондый хәл Коръәннең могҗиза-феномен икәнен исбат итә, кеше акылы боларны эшли алмас иде.*

Менә тагын Исламны кабул иткән Вячеслав Полосинның фәнни китабы: «Евангелие глазами мусульманина». Вячеслав, Морис Бюкай кебек үк, изге китапларны чагыштырып өйрәнә һәм Коръәннең төзек, мантыйклы рәвештә корылуын искәртә.

*«Бу бик кыйммәтле китап, туганыбыз Погосин рәсми кабул ителгән дүрт Инҗилне[1] һәм Коръәнне тикшереп, ике дин арасындагы каршылыкларга караганда уртаклыклары күбрәк икәнен ачыклый. Шунысы да кызык ки, Погосин Православная духовная семинариясен тәмамлап, 16 яшендә поп булып эшли башлый»*, — ди Идел буе Диния идарә рәисе Мөкатдәс хәзрәт Бибарсов.

«Русиядә Ислам мирасы вә варислар» исемле Бөтенрусия иҗтимагый хәрәкәтенең рәисе Хөсәен Җабраилов бу китап турында менә нәрсә ди:

*«Кызганыч ки, ике дин арасындагы аерма һәм охшашлыкларны кайчагында чит ил миссионерлары, бигрәк тә неопротестантлык хәрәкәте әһелләре мәкерле рәвештә диннәр аермалыгын тагын да купайтып, арттырып күрсәтергә тырышалар, шулай итеп, алар Библияне белмәгән, тәҗрибәсез мөселманнарны үз диннәренә кертергә маташалар».*

Язучы, физик, тел галиме Адлер Тимергалинның язуынча, өч йөзләп галимнән сораштырганнан соң, мондый нәтиҗәгә киләләр:

*«242 галим Аллага ышана башлаган, фәкать 20се нинди дә булса дини карашны якламаган. Галимнәрнең туксан проценты дин тота, Аллага ышана икән, калганнары да Аллага ышанучыларга ихтирамсызлык күрсәтмиләр».*

Бу дөньяның, Галәмнең, Әсманның[2], адәмнәрнең ничек барлыкка килүе турында кешелек иң борынгы заманнардан бирле уйлый, Күккә, йолдызларга карап соклана, табигать гарасатлары-кырылышлар вакытында куркуга кала. Һаман үз соравына җавап эзли, бу дөнья ничек яратылган, адәм каян, ничек барлыкка килгән?

*Ул егетнең*
*Кайгы белән үткән көннәре*
*Озын булган, мәңге газап белән*
*Йоклый алмый үткән төннәре*
*Ул күп, бик күп уйлап йөргән:*

---

[1] Инҗилнең аермалы дүрт нөсхәсен.

[2] Әсман — Галәм, Бөтенгаләм (Вселенная, Макрокосмос).

*«Адәм кайдан килгән? — тагын да*
*Кайда китәр?» Ләкин моңа җавап*
*Табалмаган үзенең аңында.*
*Шуннан соң ул яшерен урын сайлап,*
*Кабер казып җиргә күмелгән...*

Һади Такташ. Мәңгелек әкият. 1923.

Күрәсең, Такташның ул егете Коръән белән таныш булмаган, юкса ул үзенә үзе кул салмас иде.

Иннәә лилләһи вә иннәә иләйһи ражигуун! Авыр туфрагы җиңел булсын!

Изге китапларыбыз: Муса пәйгамбәргә иңдерелгән — Тәүрат (Тора), Даут пәйгамбәргә иңдерелгән — Зәбур, Гайса пәйгамбәргә иңдерелгән — Инҗил (Евангелие), Мөхәммәд пәйгамбәргә иңдерелгән Коръәнне белмәвебез аркасында без күп еллар наданлык караңгысында, шомлы мохиттә, әхлаксызлыкның канунга әверелгән чорында яшәдек һәм килеп җиттек шикелле! Такташ әкиятендәге бәхетсез егет кебек, үзебезгә кул салыргамы, әллә Аллаһы Тәгаләнең тугры юлына кайтыргамы? Әллә шушы буталчык мохиттә әхлаксызлар ягына күчеп, хәттин ашып типтерергә, «яшәп калырга» кирәкме? Өч юл. Катиле нәфес (үзеңне үтерү) дин тарафыннан тыела. Димәк, соңгы ике юл кала.

Изге китапларда гөнаһка баткан халыкларның, кешеләре хәттин ашкан калаларның юк ителүе турында хәбәрләр байтак. Ир белән ирләрнең күтләклеге, никахлы хатыннарның әхлаксызлыгы сәбәпле, Карун кебек байлыкка комсыз булганнарның кайсысын җир упкан, кайсысын яшен суккан, кайсысы суга баткан.

Христиан илләрендә, Русиядә, шул исәптән, Татарстанда да хәттин ашканлык соңгы сиксән ел эчендә аеруча киң җәелде.

«Хәттин ашу» — Аллаһы Тәгалә куйган чикләрне бозу, артыгын кылану, тугры юлдан тайпылу, азгынлыкны максат итү дигән сүз. Балаларны ятим итү, уйнаштан бала табуны хөкүмәт дәрәҗәсендәге батырлыкка санау, исерткеч эчеп, тузынып йөрүнең гадәти күренешкә әверелүе, сәбәпсезгә кеше үтерү, халык малын талау, хатын-кызларны, балаларны көчләү кебек гайре табигый хәлләр артканнан-арта бара. Бәлки, чыннан да Ахырзаман якынлаша торгандыр?!

Вакытлы матбугатта шундый бер мәкаләм басылып чыккач, берәү миңа шалтырата:

— Стажлы коммунист Роберт Садыйкович Зарипов! — диде ул. — Сез арттырасыз, иптәш Батулла! — Аның тавышы кырыс һәм янаулы иде: — Ә сез Советлар чорында фән һәм техниканың алга китүе, Галәмне өйрәнү буенча илнең алда баруы турында сүз әйтмисез. Сез гел кара якны гына күрәсез. Сез тар карашлы злопыхатель!

Мин, сабыр булырга тырышып, сүз башладым:

— Хөрмәтле Роберт Садыйкович, — дидем. — Фән һәм техниканың алга китүеннән халыкка җиңеллек килдеме соң? Атом-төш коралларыннан кешеләргә файдамы, әллә зыянмы күбрәк булды?

Хиросима, Нагасакидагы йөз меңләгән гаепсез кешеләрнең һәлак булуыннан, нурланыш авыруыннан гарип туачак буын нинди файда күрәчәк соң? Ике атом бомбасы шартлатканнан соң ТОЦкида юкка чыккан авыллар нинди файда алды соң? Чернобыль гарасатыннан соң бөтен Европа, Русия зарарланды, файдасы күбрәкме? Шул генераторларны коруга киткән миллиард сумнарны халык мәнфәгатьләренә аерсаң, яхшырак булмас идеме икән? Америкадагы диңгез асты нефтенең океанны агулавы кешеләргә файда бирдеме икән? Реактив очкычлар, Галәмгә оча торган ракеталарның Җирне Кояш радиациясеннән саклаучы озон юрганын тишкәләве Җиргә нинди файда китерде соң? Җен чүлмәктән чыккан инде! Галәветдин килеп ярдәм итсә генә.

Телефон чыбыгының теге башында түземсез тавыш яңгырады:

— Сез техник прогресска каршымыни? — диде стажлы коммунист. — Әгәр дә без атом коралы әзерләмәсәк, ракеталар төземәсәк, реакторлар кормасак, Америка безне басып кына алачак.

— Менә шул була инде ул хәттин ашу, хөрмәтле Роберт Садыйкович. Америка — Русия басып алыр дип курка, Русия Америка бәреп керер дип шүрли. Америка белән Русия куалашкан чакта Япония алга китә, Кытай мыштым гына дөньяны, шул исәптән Русияне дә кан коюсыз гына басып ала бара. Озакламый Русиядә икенче дәүләт теле Кытайныкы булачак.

Трүбкәдә мыскыллы көлү ишетелде:

— Һы-һы-һы... Сезгә фантастик әсәрләр генә язасы калган! — диде әңгәмәдәшем.

— Фантазия түгел, кисәтү!.. Әгәр акыл кешегә хезмәт итми икән, ул коточкыч гарасатка илтәчәк. Әгәр дә фән һәм технология зиһният белән контрольдә тотылмаса, фәнни ачышлар ордым-бәрдем юлы белән барса, үзеннән соң ком чүле генә калдырачак...

— Язарга тема табалмасагыз, минем янга килегез! — диде стажлы коммунист Роберт Зарипов.

Соңгы вакытта, бигрәк тә чит ил матбугатында, «ачышларга омтылучы фән әхлак кануннарыннан читкә тайпылды, «хәттин ашты», дип язалар. Чыннан да атом шартлатучы галимнәр, кешеләрне күпләп юк итү кораллары уйлап табучыларның вөҗданы газапланмый шикелле. Чыннан да, алар уйлап таба, мәкерле кешеләр шул уйлап табуны үз файдаларына куллана, галимнәр гаепле түгел, кешеләр үзләре гаепле. Хәзер «генная инженерия» шаулап алга чыкты. Шул корал мәкерлеләр кулында булса, кешелекне гарасат көтә. Кеше электромагнит дулкыннары белән идарә ителерлек роботка әвереләчәк, кая кусалар, шунда бара, үтерә, шартлата, көчли. Аллам сакласын!

— Мотлак зарарсыз фәнни ачышлар була алмый, — диде Зарипов. — Алдагы елларда файда китерәчәк булса, галимнәр нәрсәне дә булса корбан итәргә мәҗбүр. Гидроэлектростанцияләр төзегәндә күп болыннар, изге каберлекләр су астында калды, атом станцияләре төзү әйләнә-тирәдәге мохитне саклар өчен чыгымнар таләп итә... Барысы да кешелек өчен...

— Кешелек өчен... Иблис тә Адәм белән Хавага матур сүзләр сөйли, Адәм белән Хавага файда эшләгән булып кылана. Ул аларны үлемсез итмәкче була. Нәтиҗәсе билгеле.

— Фән алга киткән саен, галимнәр Алла юклыгын исбат итә, хорафатларга ышану кими, материализм куәтләнә бара дип беләбез...

— Сез, Роберт Садыйкович, гомерегез буе марксизм-ленинизм философиясен укыткансыз һәм гомерегез буе «Алла юк» дип башкаларны да ышандырырга тырышкансыз. Булмаган нәрсә белән гомер буе сугышу ул зиһенлелек галәмәтеме?

— Сез минем зиһенемә кагылмагыз! — диде трүбкәдәге кеше. — Материализм Алланы инкарь итә.

— Инкарь иткәнгә карамый, миллиардлаган кешеләр Аллага ышана! Киресенчә, фән алга киткән саен, кешелек Аллага якыная бара. Бөек океанолог Жак Ив Кусто туксан еллык гомерендә океанны өйрәнгән олуг галим. Заманча җиһазланган батискафлар, компьютерлар, скафандрлар, эхолотлар белән коралланып, озак еллар океанны өйрәнгәннән соң ул бөек ачыш ясый: океан эчендә шундый елгалар-агымнар бар икән, аларның берсе тозлы, икенчесе төче сулы һәм ул агымнар берсе икенчесенә кушылмыйча ага икән. Кустога әйтәләр: «бу турыда Коръәндә моннан бер мең дүрт йөз ел элек язып куелган инде», диләр. «Булуы мөмкин түгел!» — ди Кусто.

Ана Коръәннең французчага тәрҗемәсен китереп тоттыралар. Анда 55нче (Рахмән) сүрәнең 19, 20, 22 аятьләрендә:

**«Без берсе тозлы, икенчесе төче суны яраттык. Алар кушылмасын өчен араларына күзгә күренмәс пәрдә корып куйдык»,** диелгән.

Шуннан соң Жак Кусто Аллага ышана башлый диләр. Чүл гарәбе Мөхәммәд каян белгән дингез эчендәге ул агымнарны? Әлбәттә, ана Аллаһы Тәгалә вәхий индергән. Димәк, дөньялыкны Аллаһы Тәгалә бар иткән.

Трүбкәдә ризасыз тавыш яңгырады:

— Сез идеалист! — диде бәхәзче. — Сез — булмаганга ышанучы хыялый. Ә мин — материалист. Мина исбат кирәк. Алланын барлыгына дәлил кирәк. Кайда ул Алла? Кем күргән аны?

— Кул чәбәкләгән саен йөгереп чыгарга Алла ул артист түгел. Сулый торган һаваны сез күрәсезме? Күрмисез, әмма һава барлыгына сез ышанасыз, чөнки сез аны сулыйсыз. Сез электр агымын күрәсезме? Күрмисез, әмма яктылыгында җылынасыз. Алланын барлыгына Бөтенгаләм, Бөтенәсман дәлил. Алланын барлыгына, ниһаять, сез үзегез дәлил. Алла Адәмне, Хаваны бар иткән, димәк, сезне дә бар иткән.

— Материализм — фәлсәфә өлкәсендәге берләнбер фәнни-гыйльми юнәлеш. Дөнья үз асылы белән матди, ул объектив рәвештә яши, безнен аннан, зиһеннән тыш, акылга бәйсез рәвештә яши. Матдә-материя — беренчел, ан-зиһен — икенчел.

— Әмма матдә ничек итеп ташларны, дингезне, кешеләрне, хайваннарны, үсемлекләрне барлыкка китергән сон? Жансыз жанлыны тудырганмы?

— Жансыз матдә жанлыны тудырган. Матдә беркем тарафыннан да булдырылмаган, ул мәнге булган, мәнге булачак. Бернинди Алла да, мулла да, Христос та юк. Физиканын тайпылышсыз төп кануннарынын берсе: бардан юк булмый, юктан бар булмый. Агач янып, юкка чыкмый, төтенгә, көлгә әверелә. Кеше үлгәч, юкка чыкмый, сөякләре, тәне череп туфракка әйләнә, туфрак орлыкны үстерә, орлыктан пешкән ипине без ашыйбыз...

Стажлы коммунист алга таба мине тынлап тормады, трубкәсен куйды, сөйләшүне өзде. Кызганыч, мин ана түбәндәгеләрне сөйләмәкче идем:

1932 елда Италия чыгышлы Америка галиме Энрико Ферми жир астындагы тизләткечтә (атом реакторында) атом төшен яра да янадан жыя. Протон да, нейтрон да, электрон да — атомнын бөтен кисәкчекләре дә исән, ләкин күләме ким. Тәжрибә алдыннан үлчәнгән атомнын күләме житешми, «растрата» чыга. Тизләткечнен диварлары калын кургаштан ясалган, аннан кисәкчеләр качып китә алмый. Тәжрибә күп тапкырлар кабатланса да нәтижә шул ук — житмәүчелек чыга. Бардан юк була, дип уйлый галим Ферми һәм Аллага ышана башлый. Алла бит дөньяны юктан бар иткән. Бардан юк булгач, юктан бар итү дә хак гамәл. Нейтроннан да кечкенә кисәкчек нейтрино әнә шул кургаш диварларны үтеп чыга ала, ана берни дә мәнгъ (киртә) булып тора алмый, үтә дә китә һәм нейтринонын массасы юк, ә тизлеге бар. Юк әйбернен тизлеге бар. Анын тизлеге яктылык тизлеге белән бер: секундына 300 мен километр. Нейтринон берни дә тоткарлый алмый, тимерме ул, ташмы ул, Жир шарымы, кеше гәүдәсеме — нейтрино барысын да бер мизгелдә үтәли тишеп Галәмгә оча...

Дөньянын юктан бар булганлыгын атом-төш галимнәре күптән белә... Атаклы Джером Фридман чагыштырмалылык теориясе тигезләмәләрен тикшереп караганнан сон шундый нәтижәгә килә. Бөек Шартлауга (Биг Бәнгә) чаклы дөнья булмый, бары тик юк дәрәжәсендә бер нокта була, анын радиусы «0», әмма шул ноктанын масса тыгызлыгы чиксез күләмдә матдә белән дынгычлап тутырылган була. Тигезләмәләрдән күренгәнчә, шул юк дәрәжәсендәге кечкенә нокта, ни сәбәпледер, кинәт кабара-кинәя башлый, ягъни шартлый. Ул шартлый башлар алдыннан вакыт та, пространство да булмый. Шул нокта коточкыч тизлек белән зурая һәм матдә шар булып, төрле якка тарала. Шулай итеп, матди галәм барлыкка килә. Бу турыда физик-теоретик Владилен Сергеевич Барашенков «Вселенная в электроне» исемле китабында 149 биттә яза. Юктан бар булган матдәдән галактикалар, галәмнәр, йолдызлар, жисемнәр ясала... Фән, атом-төш физикасы кайчак үзе куйган сорауларга жавап табалмый йөдәп бетә, атом ядрәсенен төбенә төшкән саен, алар сергә тап була, юк дәрәжәсендәге мезон үзе тагын вак кисәкчекләргә бүленә, аннан сон ни булыр? Алар Аллага якыная бара...

Корьәндәге әкияткә охшаган риваятьләр атом-төш физикасындагы парадокслар белән чагыштырганда артык гади булып күренәчәк. Атом-төш физикасында протон үз тәненнән шактый саллы кисәкчек — п и - м е з о н н ы бүлеп чыгарса да протон булып кала, авырлыгы кимеми, ә пи-мезонны ул каян алган? Димәк, пи-мезон юктан бар булган. Элементар кисәкчек — пи-мезон үзе катлаулы кисәкчек. Мәктәптә без укыган физика кануннарын атом-төш физикасында кулланып булмый.

Вак кисәкчекләрне бүлгән саен энергия чыга, күзгә күренми торган элементар кисәкчектә Җир шарын юк итә алырлык кодрәт бар...

Бер әкияттә бер малайны аю тереләй йота. Аю корсагына килеп төшкәч, малай сыкранып ята: их, пычагымны алган булсам, аюның корсагын ярып, иреккә чыгар идем, ди. Туктале, өйгә кайтып онытылган пычагымны алып килим дә аюның корсагын ярыйм дип йөгереп өенә кайта да пычак алып килеп, аю корсагын ярып иреккә чыга... Элементар кисәкчекләр физикасында (вак кисәкчекләр дөньясында) бу гадәти күренеш, анда бер кисәкчек бер үк вакытта ике урында пәйда була ала. Ягъни элементар кисәкчекләр дөньясындагы кеше үз кесәсеннән үзен тартып чыгара ала. Фантастларың бер кырда торсын! Бихисап тәҗрибәләре белән моны физика галимнәре раслый... Әмма галимнәр шуны белеп торырга тиеш: фәннең алгы сызыгында акыл җитмәслек шундый чынбарлыкка һәм кеше ышанмаслык идеяләргә тап булырга мөмкин...

Әйтик, Америка математигы Норберт Винер әйтүенчә, безнең дөньяга тиң антидөнья — безнең дөньяның тач күчермәсе бар икән, без анда барсак, юкка чыгачакбыз, чөнки антикисәкчек белән реаль кисәкчек кушылсалар, икесе дә юкка чыга, (бетерешә). Әмма, Винер исбатлавынча, кешенең генетик кодын (схемасын), аның миендәге бөтен уйларын, холкын язып, радио дулкыннар белән антимирга (телеграф кебек) юлларга була. Шул код-схема буенча антимирдагылар ул кешене үз шартларына яраклаштырып, антикеше итеп яңадан ясый алалар. Шулай итеп, без антидөньяга барып та исән кала алабыз икән.

Нейтрон физикасы Аллага ышанмый торган адәмне Аллага инанырга мәҗбүр итә.

Микрокисәкчек ул — Галәм, Галәм ул — микрокисәкчек. Галәм микрокисәкчек икән, Әсман чиксез дигән сүз. Галәм нинди дә булса бер элементның атомы булса, ул элементның зурлыгын күзаллау мөмкин эш түгел. Ул — чиксезлек.

Без Галәмне, Әсманны никадәр өйрәнсәк, шулкадәр кечкенә микрокисәкчеккә барып терәләбез. Микрокисәкчекнең төбенә төшәргә маташуыбыз Макрогаләмгә алып чыгачак. Микрокисәкчек (Галәме әсгар) — ул Макрогаләмнең (Галәме әкбәрнең) схемасы, Макрогаләм (Галәме әкбәр) ул үзе микрокисәкчек.

Аңласаң — аңла, аңламасаң — аңлама!

Материалистлар аңлаган физика кануннары бүген ярамый, ул кануннар, патша заманында эшләнгән бакыр акчалар сыман, монда йөрми.

Кинаяләр, читләтеп әйтүләр аша фәнни ачышлар турында да Коръәндә язылган.

Коръәннең Аллаһ тарафыннан иңдерелгәнлеге һәр зиһенле кешегә аңлашыладыр шәт. Бер генә фәнни ачыш та: булсын ул астрономия, булсын ул медицина, булсын ул эмбриология, булсын ул география, булсын ул нейтрон физика — аларның берсе дә Коръәнгә каршы килми, киресенчә, Коръән аларны раслый. Дөресрәге, космостагы, атом-төш физикасындагы, медицинадагы бөтен ачышлар да Коръәндә кинаяләр илә алдан каралган.

Коръәндәге бер генә мәгълүмат та хакыйкатьтән читкә китми. Фәнни ачышлар кешене Аллаһка якынайта бара!

**БАТУЛЛА**

*Дәвамы киләсе саннарда*

# С

**САДРИ** (Садретдинов) Мөхәммәт Хәбибулла улы (20.5.1913, Казан — 27.3.1999, Казан), шагыйрь, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). 1921дән ятим калып, дәү әнисе тәрбиясендә үсә, 1927 дә балалар йортына билгеләнә. 1928 дә М.Вахитов исем. сабын кайнату з-ды каршында урнашкан ФЗӨ мәктәбенә керә, слесарь һөнәренә өйрәнә, заводның күптиражлы «Вахитовчы» г-тасында корреспондент булып эшли. Мәскәүдә театр сәнгате ин-тын тәмамлый (1935). 1941 гә кадәр ТАССР Халык комиссарлары советы каршындагы Сәнгать эшләре идарәсенең музыка фольклоры кабинетында фәнни хезмәткәр. Бөек Ватан сугышында катнаша: тупчы-артиллерист, сугыш кораллары бүлеге башлыгы, транспорт башлыгы хезмәтләрен башкара; яраланганнан соң, «Ватан намусы өчен» фронт г-тасында хәрби корреспондент була. Сугыштан соң ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркатип. 1948 дән «Социалистик Татарстан» г-тасында баш корреспондент, 1953-56 елларда әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире.

«Җыр башлана» исемле беренче шигырьләр җыентыгы 1932 дә басылып чыга. Сугыш елларында җиңүгә, батырлыкка рухландырган очерклар, патриотик шигырьләр яза. Солдат тормышына багышланган лирик шигырьләре «Без җырлыйбыз» (1947), «Йөрәк тибүе» (1956), «Мин Берлинны алдым» (1969) җыентыкларын тәшкил итә. «Бәхет турында җыр» (1948), «Гүзәл яшьлек» (1950), «Тантана» (1953), «Яз сулышы» (1962) җыентыкларына тупланган шигырь һәм поэмаларда, нигездә, җиңүче-солдатның туган илгә әйләнеп кайту, тыныч тормыш шатлыгы мотивлары өстенлек итә. Аның республика композиторлары белән берлектә иҗат иткән җырлары да байтак. Балалар өчен язылган «Абыйлар һәм апалар» (1959), «Без хезмәт яратабыз» (1962), «Кышкы бакча» (1962) җыентыклары авторы. Татар теленә П.П.Ершовның «Конёк-Горбунок» («Канатлы ат», 1953; 3 басма 1966) әкиятен, А.С.Пушкин, В.В.Маяковский, А.Т.Твардовский, А.А.Сурков, М.В.Исаковский шигырьләрен тәрҗемә итә. Кызыл Йолдыз, «Почёт Билгесе» орденнары, медальләр белән; ике тапкыр ТАССР ЮС Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Әсәр.: Сайра, сандугач! К., 1967; Гасыр җыры. К., 1983; Иртешкә сәяхәт. К., 1989; Планета на рассвете. М., 1979.

**САДРИЕВ** Фоат Минлеәхмәт улы (10.3.1941, Мөслим р-ны Олы Чакмак ав. туа), язучы, драматург, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). Казан ун-тын (1965), Мәскәүдә Театр сәнгате ин-ты каршындагы Югары театр курслары (1982) тәмамлый. 1963-70 елларда Сарман һәм Мөслим районы г-таларында әдәби хезмәткәр. 1970-72 дә Лаеш авыл хуҗалыгы техникумының Мөслимдәге укыту-консультация бүлегенә җитәкчелек итә. 1972-81 дә Мөслимдә чыга торган «Авыл утлары» г-тасы редакторы. 1992-96 да Мөслим үзәк китапханәсе директоры. Матбугатта «Оҗмах ишеге төбендә» (1970) исемле беренче пьесасы басылып чыккач, Әлмәт, Минзәлә, Оренбург татар драма т-рлары белән актив хезмәттәшлеге башлана. С.ның «Их, сез егетләр!» (1976 да куела), «Ач тәрәзән» (1978 дә куела), «Кондырлы кодачасы» (1981 дә куела), «Тозлы бал» (1988 дә куела), «Аяз көнне яшен» (1989 да куела), «Яшьләй сөйгән ярлар» (1991 дә куела), «Безнең гомер язлары» (2001 дә куела), «Тәрәзәгә егет килгән» (2008 дә куела) пьесалары сәхнәдә уйнала. С. «Шаһзаманов эше» (1989), «Аләм әүлиясе» (1997), «Көлми торган кеше» (2004) исемле повесть һәм хикәяләр җыентыклары авторы буларак та укучыларга билгеле. Әсәрләрендә С. чынбарлыктагы тискәре күренешләрдән көлеп яза, ялагай, комсызларның сатирик образларын тудыра, унай геройларның характерларын юмор белән сурәтли. «Таң җиле» (1993) романы сугыш һәм аннан соңгы авыр еллар кичергән өлкән буын хатын-кызларына багышлана. «Бәхетсезләр

*Дәвамы. 2005 елның 4нче саныннан басылып килә.*

бәхете» (1-3 томнар, 2001-07) роман-трилогиясе тоталитар режим шартларында шәхес фаҗигасен ачып бирә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты (2010).

**САДЫЙКЫЙ-ҖАЕКЫЙ** Габдулла Гыйззәт улы (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче чиреге), язучы. Тәхәллүсеннән чыгып караганда чыгышы б-н Җаек ш. яки аның якын тирәсеннән булса кирәк. Белемен Ливандагы америка колледжында алган. Уку чорында «Бөек бер сәрвәт, яхуд Бик зур бер байлык» (1898) романын һәм «Хыялдагы тереклек, яки Зарлану һәм моңлану» (1899) хикәясен яза. Хикәясенең кереш сүзендә «Тарих әл-әнбия» (бәлки Н.Рабгузинең «Кыйссасел-әнбия» әсәренең татарчага тәрҗемәсе) әсәрен язганын әйтеп үтә. Галим М.В.Гайнетдинов мәгълүматлары буенча 1920-30 елларда Г.Сөләймани тәхәллүсе б-н дәреслекләр һәм уку-укыту әсбапларын бастырып чыгара.

**САЛАХОВ** Ибраһим Низам улы (30.8.1911, Күкчәтау шәһ., хәзерге Казакъстан Респ. — 7.7.1998, Казакъстан Респ. Күкчәтау өлкәсе Кызыл яр ав.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан пед. техникумын тәмамлагач (1931), «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр» г-таларында, «Пионер» ж-лы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1935-37дә Казан пед. ин-тында укый. 1930 елларда яза башлый. Шул елларда иҗат иткән әсәрләре революцион романтик рухта: «Ярату» пьесасы (1936), «Дуэль» повесте (1937), «Постта» шигырь җыентыгы (1937) һ.б. 1937 дә «корткыч элемент» Г.Ибраһимов белән элемтәдә булганы өчен гаепләнә, атарга хөкем ителә. Соңрак хөкем карары 10 елга иреген нән һәм аннан соң 5 елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә дигән карарга үзгәртелә. Җәза срогын С. Колымада, Казанның Пләтән, Бөгелмә, Свердловск, Чиләбе, Төмән, Тобол төрмәләрендә үтә. 1948дә азат ителә, 1956 да аклана.

Тоткынлыктан азат ителгәннән соң иҗат иткән әсәрләре, нигездә, автобиографик характерда. «Дала дулкыннары» (1957) лирик шигырьләр җыентыгында туган җир, аның табигате, яшьлек, мәхәббәт темалары үзәктә. Тарих белән аеруча кызыксына. Көндәлек матбугатта аның татар әдәбияты тарихы, мөһим вакыйгалар, билгеле шәхесләр турындагы язмалары еш басылып килә. Чирәм җирләрне үзгәртеү турындагы «Күкчәтау далаларында» романында (1965), үз шәхси күзәлләуларына нигезләнеп, совет системасының гаделсезлеген ачып бирә. «Төн кызы» (1971) җыентыгына тупланган хикәяләрендә, «Мәхәббәт картаямы?» (1980) повестенда казакъ авылларының гүзәл табигатен, халкының гореф-гадәтләрен, хезмәтен, бәйрәмнәрен, традицияләрен матур итеп сурәтли. Балачак хатирәләренә нигезләп язылган «Аристократ» (1969), «Тәүфыйксыз бала» (1969), «Яңа мажаралар» (1971), «Яшел йортның тарихы» (1978) әсәрләре белән язучы балаларны казакъ далаларының табигате, хайваннар дөньясы, көндәлек тормышы белән якыннан таныштыра. «Иманнәр тамыр җәйгәндә» (1986) тарихи роман-эпопеясы Казакъстан җирлегендә Октябрь революциясе вакыйгаларына багышланган. Тәнкыйтьләнүләргә карамастан, роман татар әдәбияты тарихында Казакъстан татарларының совет власте өчен көрәшен тарихи яктан дөрес тасвирлаган беренче әсәр булып кала килә. Автор бигрәк тә татар әдәбиятында беренчеләрдән булып ГУЛАГ темасын яктырткан «Колыма хикәяләре» (икенче исеме «Тайгак кичү», русчага тәрҗемәсе «Черная Колыма», 1991) автобиографик романы белән таныла. Роман ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясенә (1990) лаек була, Казан татар яшь тамашачылар т-ры сәхнәсендә куела (1995). Гомеренең соңгы елларында С. кабат тарихка мөрәҗәгать итә. Аның «Күкчәтау татарлары» (1995) исемле публицистик мәкаләләр җыентыгы Казакъстан татарлары тарихы буенча мөһим чыганак булып тора. С.ның тәрҗемә өлкәсендә дә хезмәтләре бар. Ул М.Светлов, А.Прокофьев, С.Сейфуллин, И.Жансогыров әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Казакъстан Респ. ның «Парасат» ордены белән бүләкләнгән.

Әд.: Минһаҗева Л. Ибраһим Салахов иҗаты. К., 1999.

*Г.М.Габделхакова, Л.И.Минһаҗева.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

*Сәхифәне* **Рәйсә МУСАБӘКОВА** *алып бара.*

Хәерле көн, хөрмәтле каләм ияләре!

Иҗат эшегездә, журналны чыгаруда уңышлар телим сезгә. Баш мөхәррирләр алмашынгач, сагаебрак калган идек, нинди үзгәрешләр булыр икән диеп. Эшләрнең элеккечә баруына һәм яшьләрнең эш-гамәлләренә сөенәбез. Кулга каләм алырга журналда басылган Р.Харис хатлары (№3) мәҗбүр итте.

«Казан утлары» — татарның иң мәртәбәле журналы. Моны дәлилләп торасы юк. Анда басылган һәр әсәр, мәкалә зур кызыксыну уята. Ә бу мәкалә аптырау, гаҗизләнү тудырды. Алдагы санда гына (№2) Р.Харис «Татар татарны ярата» дигән шигырен бастырган иде. «Татар татарны ашый, дип әйтү чеп-чи яла ул!» дигән юллары мәкаләсенең нәкъ киресен раслый бит. Капма-каршы фикерләр тудыра торган юллар күп бу хатта. «Музыкаль театр тарафдары — Сәйдәш, опера, балет театры тарафдары — Җиһанов». «Ләкин татар музыкаль театры тернәкләнеп китә алмады — аны опера һәм балет сәнгате арткы планга этәреп куйды». «Җиһанов — илкүләм билгеле шәхес, ул — властьта, ул — депутат, лауреат» һ.б.

Үткән заманда күпләрне идеаллаштырдык бит, ә нәтиҗәсе күз алдында. Тормышта булганча тасвирлау укучылар өчен кызыклырак һәм файдалырак, минемчә. Гасырлар үткәч, тарихта казынып, чын дөресен язам дип йөрмәс өчен!

Р.Низами да, Р.Харис та әдәбиятта үз юллары булган шәхесләр. Икесен дә ихтирам иткән хәлдә, бу язманы кабул итеп булмый. Р.Харисның фикерләре дөрестер дә, әмма аларны журнал укучыларына шушы рәвештә, тупас итеп җиткерү — аңлашылып бетми. Аны үзара, йә булмаса тар даирәдә күзгә-күз сөйләнеп, аңлашып булмый иде микәнни? Язучылар бер-берсе белән аралашмыйлардамы әллә хәзер?! Шушындый дәрәҗәле, олы язучы үрнәк күрсәтә дип калганнар да шундый юлга басмасмы, бер-берсен «ашау»лар китмәсме? (37нче еллар исе килгәндәй булды хәтта).

Заман кешене үзгәртә. Кемдер Европалаша, кемдер милләте өчен җан атып чәбәләнә. Әмма болар бер-беренә таш ату өчен җирлек була алмый лабаса.

Р.Низами — милләт җанлы, Туган тел, аның язмышы өчен янып-көеп йөрүче шәхес. Татар дөньясындагы һәр үзгәреш, яңалыкка шигъри җавабы вакытлы матбугатта урын ала килде. Әсәрләрендә кемнедер, нәрсәнедер каралту, пычрату бөтенләй юк анда.

Без, укытучылар, яшь буынны тәрбияләүдә ике язучының да әсәрләрен бик теләп файдаландык. Ә бу өлкәдә, минемчә, Р.Низаминың өлеше күбрәктер дә. Чөнки «Яшьлеккә хат»ны, Ф.Яруллин турындагы истәлекләрне, тезмә һәм чәчмә әсәрләрне укучылар аның үз авызыннан ишеттеләр. Туган ягы булган Теләче һәм Саба районнарына, Биектау якларына укучылар белән очрашуларга еш кайтты. Эчкерсез, бик җанлы очрашулар булды алар. Хәзерге көндә татар телен әйдәп баручы яшьләрнең бу яклардан күп булуында Р.Низаминың да өлеше бар дип уйлыйм мин.

Телебез, милләтебез язмышы кыл өстендә торганда, бер-беребезне берләштерә торган, өмет уята торган язмалар бирсәгез иде, бер-беребезне сөендереп, куанып яшәсәк иде. Бүгенге көндә трибуна артына басып, Туган телебезне яклардай кеше (язучылар да) калмады диярлек бит. Инде журналыбыз маяк булсын иде.

**Р.ГАЛИУЛЛИНА,**
*лаеклы ялдагы укытучы.*
*Казан.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Мирсәй ӘМИР**

## Кем ни белән килә?

Язучылар съезды җыйналачагы мәгълүм булгач, һәрбер язучы, һәрбер тәнкыйтьче, шулай ук редакция яки нәшрият җитәкчеләре үз алларына съездга нинди уңыш белән килүне бурыч итеп куйганнар иде. Менә хәзер шул бурычларның үтәлүен белдереп китәбез.

Язучы, шагыйрь һәм тәнкыйтьче иптәшләрдән:

Гомәр Толымбай — «Куян солдат» белән; Фатих Кәрим — җыентыгы белән; Кави Нәҗми — хатыны белән; Әсгать Айдар — «Ташбай» һәм тишек ботинкасы белән; Фатих Сәйфи-Казанлы — бетмәс репликалар белән; Ибраһим Гази — үтмәс остроталар белән; «Совет әдәбияты» — гыйнвар номеры белән; Газиз Иделле — вәгъдә белән; Язучылар шәһәр комитеты — зар белән; Оештыру комитеты — җар белән; Нур Баян — эшләпәсе белән; Хәсән Туфан — аңлавы авыр булган уйлар белән; Афзал Таһиров — Шәриф Камал белән; Мәҗит Гафури — хәзерге заман белән; Газиз Мөхәммәтшин — настроение белән; Мансур Крыйм — плацкарт белән; Шәйхи Маннур — дәрмансыз дәрт белән; Мирсәй Әмир — ярты роман белән; Афзал Шамов — «Ана»сы белән; Риза Ишморат — «Чит кеше баласы» белән; Кәрим Тинчурин — шул ук шәл белән; Мәхмүд Максуд — көч-хәл белән; Сирин — соңгы тамчысы белән; Галимҗан Нигъмәти — юкә камчысы белән; Фәтхи Бурнаш — «Яшь (чагындагы) йөрәге» белән; С.Гыйлфан — Туктаусыз сөйләү теләге белән; Салих Баттал — Айраплан белән; Гомәр Гали — тулмаган план белән; Мөхәммәт Гали — денщигы белән; Шәриф Камал — «Шиге» белән; Әхмәт Исхак — үзе белән; Исмәгыйль Рәми — ике күзе белән; Рахман Ильяс — «Әндәр карт»ы белән; Хәсни Кәрим — арты белән; Каратай — сүгенмәү шарты белән съездга киләләр.

*«Чаян» 1934*

**Нур ӘХМӘДИЕВ**

## Болай да...

Әзерне ашап, әзерне эчеп яшәргә күнеккән Гамил Афзал көннәрдән бер көнне, җәмәгате Нәфисә ханым эштән кайтуга, дөге боткасы пешереп куя. Күр, җаный, без дә төшеп калганнардан түгел, янәсе.

Ире тарафыннан мондый илтифаттан күңеле нечкәргән Нәфисә ханым ботканы бер каба, ике каба — теш арасында нидер шытырдый. Эшнең нәрсәдә икәнен төшенә башлаган тәҗрибәле хатын:

— Син дөгене юган иденме сон? — дип сорый.
Гамил Афзал горур төстә җавап бирә:
Анын нәрсәсен юасын, дөге болай да ак бит ул!

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Яхшы

*Хәзер миңа кайда яхшы...*
*Авыздан теш төшкән,*
*Кулымнан эш төшкән.*
Туксан яшьлек карт авызыннан

*Хәзер миңа кайда да яхшы...*
*Язмыйча чарам юк,*
*Каләмдә карам юк.*
Р.Фәйзуллин

Хәзер мина кайда яхшы...
Журналда төп эшем,
Тап-таза бар төшем.

Йортым бүрәнәдән.
(Мактый күргән адәм.)
Төпчегем янымда,
Ризыгым табында.

Дәрәҗә? Житәрлек –
Исләрең китәрлек.
Хәзер миңа кайда да яхшы...
Язсам да килешә,
Язмасам да килешә...

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Зыялы бизнес

— Соңгы арада фәнни мәкаләләрең чыкканы күренми, галимлекне ташладың ахры?

— Фәннең житдирәк өлкәсенә күчтем. Шәҗәрәләр төзим республикабызның күренекле шәхесләренә. Әле менә Президентка тәкъдим ясадым. Нәсел очын Чыңгызханга ялгарга дип кергән идем дә, сөйләшә торгач, Кубрат ханга ук житеп тукталырга булдык.

— Архивларда уналтынчы гасырның аргы ягына чыккан бер документ та сакланмаган, татарның хәтерен юкка чыгарганнар бит. Ничекләр эзләп табасыңдыр инде нәсел тамырларын?

— Интуиция, туган. Тоем, сизгерлек. Хәтта, фидакарьлек дип әйтер идем. Телисеңме, синең шәҗәрәңне дә гөл итеп эшләп бирәм.

— Мин бит алай затлы нәселдән түгел...

— Анысы өчен кайгырма... Зәңгәр канлымы, яшел канлымы – нәсел очы барыбер шул кара буразнадан баш тартә. Телисең, Мөхәммәд пәйгамбәргә, телисең – Атиллага тоташтырабыз шәҗәрәңне. Акчаңа карап инде.

## Язучылар очрашканда

Әллә каян ук елмаеп, Разил Вәлиев килеп күрешә:

— Нихәлләрдә, Нур туган!

— Исән-сау гына авырып йөрим әле, — ди Нур Әхмәдиев. — Гадәттәгечә, салмак кына әйтеп шаярта белгән Нурның сүзеннән көлеп куйган Разил:

— Болай ару гына күренәсен, — ди.

— Дисенме... Дөресен әйтмәсә дә депутат кешегә килешә шул, — ди Нур Әхмәдиев. — Үзеннең сәламәтлекләр ничек соң?

— Ярыйсы. Авырып алган чаклар да була.

— Безнең яшьтә бер авыруы да булмаган кеше сәламәт түгел инде ул, — ди Нур Әхмәдиев.

***

— Тормышлар ничек, тәгәриме? — ди Фоат Садри.

— Алтмыш яшьтән соң йөрәк сизгерләнә, миналанган кырдан барган кебек, — ди Марсель Гали.

— Алай булгач... Житмешнең теге ягында мин — дары мичкәсе өстендә утырам икән, — ди Фоат Садри.

***

— Соңгы арада бик күренмисен, — ди Зиннур Хөснияр.

— Көн әйбәт бүген. Күптән кояш күргән юк иде, — ди Рашат Низами.

— Кырымдагы хәлләр...

— Кырынырга онытканмын шул.

— Минем «Казан утлары»ндагы яна әсәргә күз төшермәгәнсеңдер? — ди Зиннур Хөснияр.

— Казанда күз төшәрдәй чибәрләр күп тә, без генә... — ди Рашат Низами, монсуланып.

— Рәхмәт, менә бер кеше әсәремне укыган ичмасам, — дип Зиннур Хөснияр Рашат Низаминың кулын, сулышсыз калдырып, кыса.

И гәпләшәләр болар. Колак катыланган саен, сүз жилеме йомшара, ахрысы.

## Чын хан табылса

Мөсәгыйт Хәбибуллинның татар ханнары династиясе турындагы язмасы «Мирас» журналында басылып чыга. Һәр ханның яшәгән елы, туган-үлгән көне минутына чаклы шулкадәр төгәллек белән бирелгән ки, исен-акылың китәрлек.

Бу язманы укыганнан соң Ркаил Зәйдулла башын чайкап торган да: — Алла, төгәл дә язган бит Мөсәгыйт ага, архивлардан чын хан документлары табылса, арага кыстырырлык та урын калмаган, — дип куя.

## Гасырга тиң сабырлык

— Камил Кәримов, өендә син ташбака асрыйсың диләр! Нинди исем куштыгыз?

— Әле ашыкмыйбыз. Анын өч йөз ел яшисе бар.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнен сәхифә!



*Мин –* **Дания Нәгыймуллина***. Балык Бистәсе районы, Югары Тегермәнлек авылында туып-үстем. Дөньяга 1991нче елның 7 маенда аваз салганмын. Казан сәүдә-икътисад техникумын тәмамладым. Хәзерге вакытта Казан кооперация институтында читтән торып белем алам, бухгалтер булып эшлим. Шигырьләр иҗат итәм. Алар тормышымның аерылгысыз бер өлеше дип әйтсәм, бер дә арттыру булмас.*

## Эт тормышы

Аксаклап һәм башың игәләп,
Кая соң, и маэмай, юл тотыш?
Төш булса уяныр идең лә,
Әмма бу — тәкъдирең, бу — тормыш!
Бу — тормыш...

Кемнәрдер, йомшакта чәңгелдәп,
Ризасыз булуын аңлата.
Урамның тузаны – туганың.
Кояшсыз тагын бер таң ата.
Таң ата...

Язмышың кебек үк тигәнәк
Артыңнан калырга уйламый.
Күзеңнән тын гына яшь тама...
Әйтәсең: «Көчлеләр уламый!
Уламый...»

Бер кеше сиңа дип калдырган
Ризыкны таптады башкасы.
Изгелек буенча үлчәсәң,
Хәзерге замана – таш гасыр.
Таш гасыр...

Әкрен, сак чокырлы юллардан
Атлыйсың, мескен эт, каядыр.
Көлмәгез сез аннан: тормышта
Һәркемнең аягы таядыр.
Таядыр...

## Әни догасы

Имтихан бирергә керәсең —
Әниең гел сиңа догада!
Янына фәрештә күк оча,
Кояшка ияреп тора да.

Теш сызлый. Әниең синнән дә
Катырак сызлана. Күр әнә
Ниләрдер пышылдый. Тагын бер
Сиңа дип ул дога өйрәнә.

Эшләрең уң булды. Үзең дә
Ышана алмыйча торасың.
Әниең юллады сиңа дип
Эчкерсез шифалы догасын.

Әниең авырды. Хәлләрен
Син кайтып белешә алмадың.
Хәтта ул чакта да әниең
Укыган догадан калмадың!

Әниең гел сиңа догада!

## Бәхетле кыз

Кечкенә авылда кин елга ярында
Яши ди бик чибәр унган кыз.
Чәчәкләр белән ул сөйләшә һәр иртә:
«Ник боек: су житми, тунасыз?»

Тавыклар жырына кушыла жим биргәч,
Кояшны елмаеп сәламли.
Тормышны тирәнтен уйлаган вакытта:
«Зарланып үткән көн әрәм», — ди.

Тойота ачкычын йөртми ул кесәдә,
Таптамый ресторан идәнен.
Әнисен кочаклап, ихластан сөйлидер
Никадәр бәхетле икәнен!

Сыерын саугач, кыз сөт кертә күршегә,
Бабасы этенә эчерә.
Жирдәге бар булган кешегә, хайванга
Ярату хисләрен кичерә.

Ходайга рәхмәтен житкерә әбисе
Өйрәтеп калдырган догада.
Керне дә башкача әлә күк тоела,
Үз кулы белән ул юа да.

Мин таныш бу чибәр кыз белән якыннан,
Матурлык тирәннән — күнелдән.
Жиһанга сөюле караштa булганга,
Үзе дә сөюгә күмелгән!

## Мичле йөрәк

Хәтеремдә һаман саклыйм әле
Мичтә пешкән кайнар ипи исен.
Серле утка карап тора идем
Суык көздә жылы өйдә кичен.

Балачакның учаклары сүнми,
Әби догалары саклап йөри.
Әниемнең шәле сыман жылы
Ак хыяллар югарыга үрли.

Әни сандыгына салып куйган
Без кайчандыр чиккән яулыкларны.
Чөкердәшеп яши бирсен иде
Әти-әни, булып саулыклары!

Тәгәрәткән бәрәңгене сагынам,
Мичкә куяр идем хәзер кулны...
Йөрәктәге мичне сүтмәү кирәк
Дәвам итәр өчен изге юлны!

## Гөнаһлы җиһан

Мин гажәпкә калмам кебек, әгәр
Жир әйләнеп, беркөн туктаса.
Кылган гөнаһларны кичерә алмый,
Язмыш таяклары тукмаса.

Гажәпләнмәм, кояш чыкмый гына
Оятыннан торса кызарып.
Җиһан тулы нәфрәтләрдән өркеп,
Бәби туса әгәр соңарып.

Тәнен сатканнарга ачу итеп,
Күкләр миңгә әгәр ярылса,
Сәерсенмәм. Адым саен сүгенү
Тузан булып жанга сарыла.

Кара туфрак кардәш-туганнарның
Күп сеңдергән садә каннарын.
«Кичер безне», — диеп әби сала
Мәчетләргә сәдакаларын.



***Алсу Нургатина:***

*«Дуслар миңа еш кына: «Син җир кешесе түгел», – дип әйтәләр. Алар белән килешми булдыра алмыйм. Күңелемнең бер өлеше: уйлану борчылуларым, хис-кичерешләрем әсәрләремдә, шигырьләремдә яши. Күңелем белән һәрвакыт матурлык эзлим. Кешеләрдә һәрвакыт детальләргә игътибар итәм: кайвакыт күз сирпүе, иңнәренә таралган чәчне төзәтеп куйганын карыйм да үзеннән-үзе әсәр туа, каршыга очраган зәңгәр күзле кечкенә кызчык төп геройга әйләнеп куя...»*

# СЫНАУЛАР

ПОВЕСТЬ

**1 бүлек**

## Барсы да алда әле...

Дәрескә кыңгырау шалтырарга өлгермәгән. Сыйныфта барысы да үз эшендә. Айгөл парта өстенә менеп утырган Гүзәлгә нидер аңлата, Гөлчәчәк химия дәресеннән соң акшарга баткан тактаны сөртеп азаплана, Ранил самолётлар ясаган... Дәрескә кыңгырау шалтыраганчы гел шулай була. Ә инде аннан соң, армиядә сафка тезелеп баскан солдатлар төсле, барысы да үз урынына утырып, укытучыны көтә башлый. Бүген дә шулай булды. Математика укытучысы Роза апа кабинетка килеп кергәндә, чебен очкан тавыш та ишетелә иде.

— Исәнмесез, — диде ул сыйныфка күз салып. Кәефе юклыгы йөзенә чыккан. Һәрвакыт ягымлы булырга тырышкан Гүзәл:

— Исәнмесез, Роза Әсхәтовна! Хәлләрегез? – дип сүз башлаган иде:

— Хәлләр хәл түгел әле монда. Кичә эшләгән контроль эшләрегезне тикшердем, бер дә куанырлык хәл юк! Күпме аңлатам, күпме сөйлим. Дәрес буе тикмәгә генә тукылдап утырраммыни мин?!

Ул кулындагы дәфтәрләрне ача-ача, парта өстенә ташлый башлады. Сыйныфта барсының да башы иелгән иде.

— Сынауларны ничек тапшырырсыз сез, белмим мин!

...Дәрес барышында әллә ничә кат әйләнеп кайтты ул бу темага. Әле бит тугызда гына укыйбыз, тугызның традицион сынаулары берни дә түгел дип ышандырдылар укучылар. Һәм аннан соң... Уку елы да әле генә башланды бит. Күңелдә әле җәйге хатирәләр... Синең алгоритмнарың да, квадрат тигезсезлекләр дә түгел!.. Уку елы башланып, ике атна үтмәде, инде сынаулар дип сөйли башладылар. Әле барысы да алда, аңа хәтле вакыт буа буарлык.

Тышта һаман җәй... Юлларга сузылган нечкә пәрәвездә кояшның салават күпере төсле нурлары җемелди. Иләс-миләс исеп куйган җылы җил чәчләрне иркәли. Яфракларга да сарылык иңмәгән чак әле! Кайсы көзләр пыскак яңгырлы була. Көнозын яуган яңгырлары үзәккә үтә, соры көннәренә карап, күңелдә булган бар кәеф тә эреп юкка чыга. Ә быелгы көз матур, кояшлы килде. Мәктәптән өйгә атлаганда, түбәләргә төшеп күзне чагылдырган кояш нурына карап, күңел балаларча сөенеп куя. Быелгы көз – җылы. Әллә җәй тулы моңсулык булганга микән?

Җәйдә булган күңелсез хәлләрне исемә төшерсәм, үз-үземне кая куярга да белми башлыйм. Тәннәрем чымырдап, мине ниндидер шомлы дулкынга иярттә... Бәхетле идек бит без. Әти, әни һәм мин. Авылның бер читендә, кечкенә булса да таштан салынган йортта яшәдек. Әти-әниемә бер генә идем мин. Бөтен кирәк

әйберемне алып торсалар да, иркә булмадым. Тик бер вакыйга гаиләбезне мәңгегә җимереп ташлады...

Җәй урталары. Болыннарда җир җиләге өлгергән чак... Бар халык болынга агыла, чиләкләрен тутырып, татлы җимешне җыя. Кышкы салкын көнгә җәй җылысын алып керергә телиләр, күрәсең... Җәйнең төсен мин дә саклап калырга теләгән идем. Чиләкне тутырып өйгә кайтып, ишегалдына үткәч, әнинең ялварулы тавышын ишетеп, туктап калдым:

— Нигә генә бөтен авыл өстендә шулай безне мыскыл иттең соң син, Гариф. Нинди начарлыгым тиде соң сиңа? Кайтканыңа барсы да әзер, урын-җирең җыйган. Көн дә шушы авыл башындагы кибеткә чабам. Булсын дип йөрим бит мин дә. Ниләр генә ошамады соң сиңа...

Минем килеп керүне күргәч, икесе дә шым булдылар. Күз алдымда шундый картина пәйда булды. Бер читкә текәлеп горур гына әти басып тора, әни тезләнеп аңа караган, күзләре яшьле...

— Ни булды? — дидем мин, үз тавышымны үзем танымыйча. Әни, урыныннан торып, яшьләрен сөртте дә:

— Кызым, әтиең бездән китә. Ул бездән яхшыракларны тапкан, — диде.

Әтине корт чактымыни:

— Гомер буена баланы миңа каршы котыртып яшәдең. Карале нәрсә сөйләп тора бит. Кер, кызым. Утыр әле менә монда, — диде ул, мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып.

Әти кухня өстәле кырында торган урындыкка өндәде. Мин ашыкмадым. Ни булганын бераз чамаласам да, ахырына кадәр барсын да белеп бетерәсем килә иде.

— Әнкәй? Ни булды?

— Кызым, — диде ул, яшьләренә буылып, — кызым... Әтиең түбән очтагы Салисә апаң янында чуалган икән. Хәзер балалары булачак, көмәне җиде айлык, ди. Әтиең китә, кызым.

Әни кабат сулкылдап елап җибәрде. Эсселе-суыклы булып китте шулчак. Өстемә бер чиләк салкын су койдыларммыни! Ничек, әти, ничек? Ничек безне шулай алдап йөри алган икән? Әле кем белән диген бит, дүрт балалы ирсез хатын белән.

Әти кулындагы чемоданын бер алды, бер куйды. Аннан иңемә кулын салып, «кызым» дигән иде, мин аның кулын этеп җибәрдем.

— Оныт безне, әти! Син башка безгә беркем дә түгел, ишетәсеңме!!!

Әти кулын селтәп чыгып китте...

Шуннан соң без әни белән генә яши башладык. Әтине гел күрә идем, безнең авылда яшәде. Очраса – күрмәмешкә салышырга тырыштым. Йөрәккә кереп гел әрнетә иде аның хыянәте. Салисә апа колхоз ашханәсендә пешекче булып эшләде. Безнең мәктәп юлы әнә шул сукмаклар аша үтә. Ара-тирә күземә чалынса да, бер сүз дә әйтмәдем. Мине күрсә, ул да башын түбән ия, гаепле күзләрен миннән яшерергә тырыша иде.

***

— Аңларбыз микән без, юкмы бу математиканы, тәмам туйдырып бетерде бит. Сынауларга әзерли, имеш. Сынаулар дип ярты йөрәк бетте хәзер. Ул улына да шулкадәр таләпчән микән, мескен Самат ничек түзә диген, ә...

— Алай димә инде. Ул безгә бары тик яхшылык тели. Башкача укымыйбыз ич без. Өстәвенә безнең сыйныф әле маймылланырга да бик ярата. Ирек кенә бир, хәзер Тәбрис ишәк булып кычкыра башлый, кыланырга да күп сорамас. Ә Роза апаның дәресләре тәрбияви була, минемчә.

Гүзәл белән мәктәп ашханәсендә чәй йотып, гәп куертып утыра идек, дәрескә кыңгырау чыңлады. Дәррәү сыйныфка йөгердек. Юк, укытучының шелтәләвеннән куркып түгел, бары тик яраткан дәресебез булганга. Географиядән безне Галия апа укыта ич. Галия Миркасыймовнаны һәркем белә, ул дәресләрне үтә дә шаянлык, төрле кызык хәлләр белән үреп алып бара. Бүгенге дәрес тә шундый булырга охшап тора...

Авыл мәктәбе – авыл мәктәбе инде. Сталин заманыннан калган иске карталар таушалып беткән. Читләренә кәгазь кисәкләре ябыштырылган. Урта бер тирәдә

шулай ук «ямау» күренә. Берәү бик тырышып Таллин шәһәрен күрсәткән бугай, тишелеп үк чыккан. Анда да шакмаклы дәфтәр бите ябыштырып куйганнар. Тик Таллин урынына Каенлы дип язганнар. Картага күз салсак, безнең авыл Латвиянең күршесе булып чыга.

Галия апа бүген тактага һәрнәрсәдән кызык табарга яратучы Илһамны чыгарды.

— Җәйге каникулдагы ят, шат хисләрдән бераз арынып, картаны кабатлап алыйк әле. Мин дәүләтне әйтәм, син башкаласын тап һәм күрсәт.

Илһам тактага чыккач, иркенләп утырсаң да була. Чөнки ул аннан тиз генә кермәячәк, хәтта дәреснең бетү ихтималы да бар.

Бик озак азапланды ул карта янында. Бары тик Каенлыны, Мәскәүне һәм Пекинны күрсәтә алды. Ә Австралиянең башкаласы Австрия икәнен белеп, көлә-көлә дәрестән чыгып киттек. Дәрес ахырында апа:

— Сынаулар дип артык борчылмагыз. Тугызның сынаулары авыр түгел ул. Болай да бөтен яшьлегеңне укуга бирәсең. Нәтиҗәсе булса ярый да бит... Күпмеләр кызыл дипломнарын кочып өйдә утыра, кайберләре ике югары белем белән чәй әзерләп йөри. Бу сынаулар чүп кенә ул. Ә менә тормыш сынауларында сыгылмый калу — чын батырлык! – диде.

— Тагын җиде ай бар бит, барысы да алда әле, — диештек.

Галия апаның бу сүзләрен аңламаган идем. Мәгънәсен тора-бара язмыш үзе төшендерде...

## Алмаз

Яратам да инде туган авылым Каенлыны... Бигрәк газиз, бигрәк якын минем күңелемә. Ул зур мәйданлы, киң булып җәелгән. Табигате дә үзенчәлекле, кайбер урамнары тау башында, кайберләре бөтенләй түбәнлектә урнашкан. Мәктәбебез исә тау өстендә горур булып басып тора. Аннан ерак түгел, тау астында чишмә бар. Тау аны үзенең кочагына алган төсле. Әнә шушы таудан кыш көне чана шуа идек. Дәресләр тәмамланып, эңгер-меңгер төшсә дә, шуа-шуа букчалар таушалып, аның эчендәге китаплар чүбеккә әйләнеп бетсәләр дә — барыбер ул ләззәтне берни белән алыштырып булмый. Шушы китаплар өчен директор каршында күпме кызарырга туры килде, ләкин барыбер кыш җитеп, кар ятуга, дәресләрдән соң шул тауга юнәлә идек.

Ә безнең йорт авылның иң башында. Шуңа яз да, җәй дә безгә иртә килә. Март кояшы бераз җылыта башладымы – карлар эрергә тотына, өй тирәсендә яшел чирәм баш тертә. Ә түбән урамнарда әле катлам-катлам булып кар ята... Нәкъ шушы вакытта әнкәй кечкенә каз бәбкәләре ала. Кыш чыккан «кысыр» ана һәм ата казга иярә. Алар исә «балалары»на куана, көзен бәрәңге чүпләре яндырган төтен таралып, кар ята башлаганчы шулар белән мәш киләләр. Бездә юллар такырайганда, түбән урамнарда әле ерып чыга алмаслык пычрак була. Кичләрен көндәлек эшләрне тәмамлагач, йорт каршысына чыгам да, иркен итеп бер сулыш алып, азанны көтә башлыйм. Дүрт манара да уч төбендәгедәй күренеп тора. Төп мәчет бездән ике адымда гына...

Балачакта, берәр танылган шәхеснең телевизордан яисә радиодан туган җирләрен үтереп мактаганын, аны яратуын аңлатканын ишетә идем. Моны тыңлаганда, күңелгә корт кереп, бар уйларны кимереп бетерә. «Хе... Каенлы. Каенлы тек Каенлы инде, бер матурлыгы да, үтереп мактар урыннары да юк», — дип уйлыйм да эшләвемне дәвам итәм. Бар икән шул. Язга чыккач, төннәр буена бакалар хоры концерт куйган Бабиль күле, кышын — каток, җәен «эштән бушаган» акбашлар йөзгән идарә бинасы каршындагы күл дә күңелдә, йөрәк түрендә. Үткән җәйдә ике атнага лагерьга баргач, бигрәк тә авылымны сагынып, кайтыр көннәрне көтә-көтә тәмам зарыккан идем. Шунда авылымның «караңгы» урамнарын, көз, яз җиткәч үтеп чыга алмаслык сазлыкка әйләнә торган юлларын уйлап, сагынып кайттым.

***

— Әни, бүген дискотекага чыгып керсәм ярыймы, бик соңга калмыйча гына?

— Ярар, соң. Тик кара аны: озак йөрмә, кирәкмәгән урында кирәкмәгән белән чуалма. Дискотекадан соң туп-туры өйгә.

Әнинең туп-туры дигәнен ишеткәч, гел көләсе килә башлый. Туп-туры, беркая да борылмыйча кайтсам – әрәмәдән, су аша үтәсе була бит. Безнең йорт турысыннан клуб бинасының бер кырые күренеп тора. Безнең өй кыегыннан шунда аркан бәйләсәң ничек булыр икән?! Арканны биленә урап, ыргак электерәсең дә туп-туры клубка! Менә бу чыннан да туп-туры булыр иде.

Гүзәл белән бүген безне дискотека көтә. Кичен бизәнеп, Гүзәлләргә йөгердем. Ул миннән бер урам аркылы яши. Аның бик озак чыкмый торуы, әлбәттә, гадәти иде. Шуңа да ашыкмаска кирәк. Тик өйдә озаграк торсаң, әни «ярар, йөрмә инде бүген, кызым», дип әйтергә дә мөмкин. Иртәрәк төшеп көтеп торасы булды. Көзге сентябрь һавасы салкынча. Күктә чекерәеп кенә йолдызлар яна. Төннең кара тунында ерганаклар ясап очкан самолётларның тавышы ишетелә, юллары сызылып кала. Шуңа шактый әсәрләнеп торганда, Гүзәл дә чыгып җитте. Күзләрен мелт-мелт йомып, еш-еш сулап, иңбашка сугып алды.

— Киттекме?!

Клуб тирәсендә иң ошамаганы – тәмәке тартучы егетләр, зур тормышның түбән тәүге кат татыган, кәпрәйгән малай-шалайлар. Килеп җитүгә, клуб эченә үтәр өчен, шушы зәңгәр томанны кичәргә кирәк. Ул гына да түгел, исе өстеңә сеңә, күңелне болгата. Керә-керешкә Гүзәл ничәнче егет белән кочакланышырга өлгерде инде. Аптырамагыз, бездә шулай исәнләшәләр. Миңа исә бу бик ошап бетми. Яңа гына хәмер капкан егетнең кочагына керәсем килеп тормый. Үзе килсә – борып җибәрмисең инде анысы.

Сентябрь ахырлары булуга карамастан, клубның бию залында кеше байтак иде. Шул агымны ера-ера, бер читтә урын табып бии башладык. Җемелдәгән аллы-гөлле утлар шәүләсендә Гүзәлнең ап-ак каешы, ялтыравыклы футболкасы күренеп кала. Бер карасаң, авыл балаларының бөтен юанычы да шул клуб бит инде. Башка барыр урын да юк.

Бераздан тынчу һавадан, тәмәке төтененнән туеп, урамга чыктым. Каршыда – төзелеп бетмәгән балалар бакчасы. Кайчандыр бик тырышып эшли башлаган булганнар, стеналары да өч кат кирпеч белән өелгән. Тик, кызганыч, бисмиллалары җитмәгәнме, акчалары калмаганмы шунда, бина төзелгән килеш басып тора. Ни ишеге, ни тәрәзәсе юк. Шомлы ул урын. Мин анда булмаска тырышам. Әле кичә генә радиодан бер тапшыруда «әтисез балалар еш ялгыша, еш хаталана», – дип сөйләделәр. Мин шуларның искәрмәсе булыйм әле! ...Кемнәрнеңдер кычкырып көлүе уйларымнан айнытып җибәрде. Ерактан ук таныдым, унберенче сыйныфның ике «йолдызы». Аларны һәр ана балаларына гыйбрәт итеп куя. Укулары уку түгел, яман гадәтләре дә бихисап. Гүзәлнең шулар белән бергә чыгып килүе күңелгә шом җибәрде.

— Айсылу! – диде ул бер кызарып, бер агарынып. — Сине эзләп арып беттем. Ә син урамга йөгергәнсең.

— Анда сулап булмый башлады. Тәмам тынчу. Әйдә, кайтабызмы?

— Син нәрсә? Әле бит дискотека башланды гына. Әйдә инде бераз биик, аннары — өйгә.

Ул шулай диде дә мине клуб бинасына җилтерәтеп алып кереп тә китте. Безгә теге унбердәге ике кыз да иярде. Моны өнәп бетермәсәм дә, сүз әйтмәдем. Тик бераздан берсенең кулында хәмер шешәсе пәйда булды. Аз гына да оятка алмыйча эчә үк башлады. Мин Гүзәлне читкә өстерәдем. «Әйдә киттек моннан, безне дә шундый дип уйлаячаклар». Гүзәл кулын җәһәт кенә тартып алды да кабат алар янына китеп барды. Мин үпкәләп чыгып киттем. Дустымның шундый кыланмышыннан йөрәгем әрни, күзләр дымланган иде...

— О, Айсылу, сәлам. Мине күрмичә дә узып барасың.

Кем дип торам, Динар икән. Унберенче сыйныф егете. Аның яңа гына кереп барышы бугай. Мин елмаеп үтеп китәргә теләгән идем:

— Әллә елый инде. Син нәрсә, кем рәнҗетте?

— Юк, рәнҗетмәде, юк. Болай кәеф юк. Өйгә кайтып барам менә, — дидем мин, күзләремне яшерергә теләп.

Динар, кинаяле караш ташлап, мине җитәкләп алып чыгып китте. Бераз баргач, авыл кибетләре артындагы бүрәнәгә килеп утырдык.

— Сөйлә әйдә. Нигә кәефләрең юк синең?

— Гүзәл инде. Теге унбернең «йолдызлары» белән чуала. Бүген каршыма ук китереп бастырды. Оятымнан үләм дип торам.

— Хи, исең китмәсен. Гүзәл шундый инде ул. Шуңа борчылып утырма инде, Айсылу, – дип кочаклап алды. — Әйдә, керәбез?

Минем җавабымны бүлдереп, телефон шалтырады.

«Әйе, Алмаз. Юк, мин кибет артында. Юк, үзем генә түгел. Ярый...»

Динар эшлекле генә елмаеп куйды. Бик күңелле кеше ул. Шул ягы белән үзенчәлекле: ул авыр чакта хәленә керә, ә күңелле икән, тагын да күңеллерәк ясый. Бар хәлләрнең дә үзәгендә булырга ярата ул. Үзен дә шуңа күрә бик яраталар.

Янибызга машина килеп туктады. Ишекне ачып, бер егет төште. Чем-кара чәчле, кара күзләр, йөгерек кашлар. Өстендә, салкын булуга карамастан, күн куртка, кулына сәгать таккан. Караңгылыкта бераз иялэнгәч кенә бу егетнең Алмаз булуын аңладым. Бездә тарих фәненнән практика үтәргә кайткан егет ул. Берничә дәрес тә укытканы бар. Динар сул кулы белән мине кочаклаган килеш кулын егеткә сузды.

— Сәлам, егет. Ни хәлләрдә? — диде ул олыларча көр тавыш белән.

— Әйбәт. Син нәрсә, кызлар кочып, тышта басып торасың? Мин сезгә комачауламаганмындыр бит?

— Юк, Алмаз. Айсылу китә инде. Өенә кайтып барышы аның.

Алмаз мине баштанаяк «тентеп» чыкты да:

— Әйдә соң, кайтарып куям.

Мин елмайдым. Юл буена ялгыз гына атласам, күңелсез булыр төсле иде. Ә Алмаз — күңелле егет. Машина белән җилтерәтеп кайтарыр да куяр.

Алмаз миңа карап елмайды. Мин дә. Берара шулай карашып тордык. Динар бер миңа, бер Алмазга карады да:

— Ярый, Алмаз. Борчылма. Мин аны үзем озатып куярмын, яме.

— Син бит клубка керергә теләгән идең, — дидем мин.

Динар ни эшләргә белми, уңайсызланып елмаеп куйды. Бераздан без Алмазның машинасында караңгы тыкрыкларны иңли идек инде...

Клубтан миңа шактый кайтасы. Алмазга кая борылырга икәнен әйтә тордым, ул, күңелле вакыйгалар сөйләп, туйганчы көлдерде. Безнең өйгә җитәрәк машинаны туктатырга куштым. Әни машина тавышы ишетсә, әллә ни уйлавы бар.

Тышта тагын да салкынайтып җибәргән иде. Машинадан чыккач, өйгә кадәр бергә атладык.

— Менә кайтып та җиттем. Рәхмәт инде озатып куюыңа, — дидем мин, кулларымны аның кулларыннан алып. – Пока!

— Хуш, Айсылу. Очрашканга кадәр, – Алмаз мине билемнән кысып елмайды. Кинәт муенымда аның кайнар сулышын тойдым. Башымны читкә борып, көчле кулларыннан аерылдым да өйгә юнәлдем.

— Очрашканга кадәр, — дидем мин, соңгы иҗекне булдыралганча сузып.

Өйгә кермичә, келәт алдына барып утырдым. Кызык та егет инде бу Алмаз. Мөгаен, аны яратып йөрүче, аның өчен барсына да әзер булган кызлар бардыр. Ә бүген ул мине озатты. Димәк, мин кемнеңдер хыялы белән кайттым. Кызганыч та, кызык та. Уйларымда — бүгенге кич, күзләрем авылны күзли... Еректан яктырган, балачакны хәтерләткән утларга карадым да катып калдым. Кап-караңгы авыл. Бары тик өй тәрәзәләрендә берән-сәрән булып утлар яна. Ара-тирә прожектор утлары «әле монда без дә бар бит» дип яктыралар. Шәһәрдәге төсле яп-якты түгел, ләкин әнә шушы черем итеп янган утларга карап та күңел сөенә. Бала чактан күңелгә кереп калган бу утлар. Кичләрен, эңгер-меңгер төшкәндә, өйгә кайтышлый иң беренче тәрәзәбездәге утларны күзәтә идем. Утлар яна икән – димәк, өй учагы җылы. Утлар бар икән – димәк, өмет тә бар. Урам буйлап «кеше көлдереп» йөрүче исерекбашларның өендә төннәрен кабынган ут аларны сафландыра төсле иде. Бала чакның яланаяк йөгереп, юл тузаннарында буталып калган шушы мизгелләре бүген кабат хәтер шәмен кабызды...

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# МӘХМҮТ КАШГАРЫЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ХИКӘЯЛӘР КОНКУРСЫ

**Ауразия Язучылар берлеге төрки илләр язучылары арасында Мәхмүт Кашгарый исемендәге өченче халыкара хикәя конкурсы игълан итә.**

**Татарстанда конкурсны үткәрү шартлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:**

1. Конкурска тәкъдим ителгән хикәяләрнең темасы чикләнмәгән.
2. Конкурска татар телендә иҗат ителгән әсәрләр кабул ителә.
3. Конкурста катнашучыларның яше чикләнмәгән.
4. Хикәяләр беркайда да басылмаган һәм бернинди дә бәйгедә катнашмаган, бүләкләнмәгән булырга тиеш.
5. Һәр автор бары тик ике әсәр генә тәкъдим итә ала.
6. Хикәяләрнең күләме бер мең сүздән дә ким һәм ун мең сүздән дә артык булмаска тиеш.
7. Әсәрләр 12 кегельдә, Word форматында җыелырга тиеш, аерым дискта һәм 6 нөсхәдә тапшырыла.
8. Әсәрләр Татарстан Язучылар берлегенә, Казан, 420012, Мөштәри урамы, 14 адресы буенча, шәхсән автор тарафыннан тапшырылырга яисә почта аша җибәрелергә тиеш.
9. Хикәяләр ябык тәртиптә, авторы күрсәтелмичә, бары тик девиз куелып тәкъдим ителә. Автор турында тулы белешмә (исем-фамилиясе, паспорт мәгълүматлары, тәрҗемәи хәле һәм бер фоторәсеме) аерым конвертта тапшырыла. Конвертлар, жюри әсәрләргә бәя биреп, җиңүчеләр ачыклангannan соң гына, жюри әгъзалары алдында ачыла.
10. Әсәрләргә 5 кешедән торган жюри бәя бирә. Жюри әгъзалары, аларның якыннары һәм туганнары конкурста катнаштырылмый.
11. Конкурста катнашкан хикәяләр авторга кире кайтарылмый.
12. Җинеп чыккан хикәяләргә Ауразия Язучылар берлеге хуҗа була.
13. Конкурс 12 илдә үткәрелә. Һәр илдә I урынны алган хикәяләр, төрек теленә тәрҗемә ителеп, халыкара жюрига җибәрелә. Халыкара жюри җиңүчеләрне ачыклаганнан соң, 1, 2, 3, 4 урыннарга лаек булучыларга халыкара призлар тапшырыла.

**Хикәяләрне тапшыруның соңгы көне – 2014 елның 30 сентябре.**
**Урыннарны игълан итү көне – 2014 елның 1 ноябре.**
**Татарстанда җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы 2014 елның ноябрендә үткәрелә.**
**Халыкара бүләкләү тантанасы 2014 елның декабрендә Бакуда (Азәрбайҗан) үткәрелә.**

**Татарстанда җиңүчеләргә өч урын бирелә.**

**I** урын өчен – 15 000 сум.
**II** урын өчен – 11 500 сум.
**III** урын өчен – 7 500 сум.

**Халыкара конкурста дүрт урын билгеләнә. Дүртенче урын өчен кызыксындыру премиясе бирелә.**

**I** урын өчен – 154 000 сум.
**II** урын өчен – 115 000 сум.
**III** урын өчен – 75 000 сум.
**IV** урын өчен – 38 000 сум.

*Татарстан Язучылар берлеге идарәсе*

### БОЛГАР ЮНЕСКО ИСЕМЛЕГЕНДӘ

Болгар тарихи-археологик комплексы ЮНЕСКО карамагындагы объектлар исемлегенә кертелде. Бу хакта ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы комитетының Катарда узган 38нче сессиясендә билгеле булды. Чарада Президентның социаль мәсьәләләр буенча ярдәмчесе Татьяна Ларионова житәкчелегендәге Татарстан делегациясе дә катнашты. Болгар исемлеккә 1002нче объект булып кабул ителде.

### ПУШКИН ТУГАН КӨН

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов Казанда бөек рус шагыйре Александр Пушкин һәйкәленә чәчәкләр куйды.

Аннары шагыйрьнең тууына 215 ел тулуга һәм Рус теле көненә багышлап бәйрәм үткәрелде. Анда шигырьләр яңгырады, театрлаштырылган шигъри күренешләр күрсәтелде, балалар ансамбльләре жырлады.

Ул көнне Рөстәм Миннеханов Казан үзәкләштерелгән китапханәләр системасының 45нче филиалында булды. Үзәкләштерелгән китапханәләр системасы директоры Резеда Исмәгыйлева Пушкин туган көнгә багышланган экспозиция куелган абонемент залын, матбугат басмаларын, уку залларын, әдәби кафе, музей, интернет-залны күрсәтте. Республика житәкчесе китапханәгә жиһаз алу өчен сертификат тапшырды.

### УТЫРЫШ

Казанда ТӨРКСОЙ халыкара оешмасына кергән дәүләтләрнең театр житәкчеләре советының өченче утырышы булды. Анда Татарстан, Азәрбайжан, Казакъстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Төркия, Алтай, Башкортстан, Саха (Якутия), Хакасия театрлары житәкчеләре катнашты.

### ФОРУМНАР

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында III халыкара «Нәүрүз» театраль белем бирү фестивальфорумы уздырылды.

Атна дәвамында актерлык осталыгы, режиссура, сценография, курчак йөртү серләре, театраль менеджмент, театр тәнкыйте һ.б. багышланган семинарлар үтте.

***

Казанда «Милли тормыш һәм дин» дигән V Бөтенроссия дин әһелләре форумы булды. Аны Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты, ТР Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе бергәләп оештырды. Форум эшендә Россиянең төрле төбәкләреннән, Татарстан район һәм авылларыннан килгән 800дән артык делегат катнашты.

Башта форум делегатлары төрле секцияләрдә фикер алышты. «Татар гаиләсен саклауда дини йолаларның һәм милли гореф-гадәтләрнең тоткан урыны», «Исламда социаль хезмәт», «Дөньяви жәмгыятьтә имамның тоткан урыны» дигән темаларга багышланган утырышларда милләтебез өчен иң актуаль булган мәсьәләләр тикшерелде. Аннары Камал театрында форумның пленар утырышы булды. Аның эшендә ТР Президенты Рөстәм Миннеханов, Президент аппараты житәкчесе Әсгать Сәфәров, ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров, РФ Дәүләт Советы депутаты Илдар Гыйльметдинов, ТР Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм башка төбәк Диния нәзарәтләре рәисләре, район мөхтәсибләре, авыл имамнары катнашты.

***

Казанда төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чаралары форумы булып үтте. 5нче тапкыр үткәрелгән жыен быел этник журналистика мәсьәләләренә багышланды. Форум эшендә катнашу өчен башкалабызга Россиянең 30 төбәгеннән, республика районнарыннан мәгълүмат чаралары житәкчеләре, танылган журналистлар килгән иде.

Кунаклар форум көннәрендә республикабызның мәгълүмат чаралары эше белән танышты, «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе, «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы, «Татарстан», «Сөембикә» журналлары, «Акчарлак» газетасы редакцияләрендә, Татарстан Халыклар дуслыгы йортында булды.

Икенче көнне Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының конференцияләр залында форумның пленар утырышы булды. Анда Федераль матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы житәкчесе Михаил Сеславинский, Россия Журналистлар берлеге секретаре Василий Балдицын,

«Этникара журналистика гильдиясе» төбәкара иҗтимагый оешмасы президенты Маргарита Лянге, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова, Республика матбугат һәм гаммәви мәгълүмат чаралары агентлыгы җитәкчесе Ирек Миннәхмәтов, ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова катнашты һәм чыгыш ясады.

### ҖЫЕН

Быел Изге Болгар җыены 25нче тапкыр үткәрелде. Җыенга 30 мең кеше килде. Алар арасында V Бөтенроссия дин әһелләре форумында катнашучылар да бар иде. Урта Азия республикалары һәм чит ил мөфтиләре, гарәп илләре министрлары, дөньякүләм ислам югары уку йортлары ректорлары һәм галимнәре дә килде. Башта Мәхмүт хәзрәт Шәрәфетдинов Коръән аятьләре укыды. Җыен Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов чыгышы белән башланып китте. Тантанада Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Россия мөселманнарының Үзәк диния нәзарәте рәисе Шәйхел-Ислам Тәлгать Сафа Таҗетдин, Татарстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һ.б. чыгыш ясады.

### ХИСАП-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЫ

Татарстан Фәннәр академиясенең гомуми хисап-сайлау җыелышы узды. Хисапны Татарстан Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мәзһаров ясады. Җыелышта яңа президент сайланды. Алдагы биш елда Татарстан Фәннәр академиясе белән Мәгъзүм Сәлахов җитәкчелек итәчәк. Җыелышта Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары — мәгариф һәм фән министры Энгель Фәттахов, министрлык һәм ведомство башлыклары, югары уку йортлары ректорлары, фәнни-тикшеренү институтлары директорлары, галимнәр катнашты.

### БӘЙРӘМНӘР

Быел Лаеш районы Никольское авылында узган «Каравон» XXII Бөтенроссия рус фольклор бәйрәме гадәттәгедән күбрәк иҗат коллективларын җыйды. Татарстанның 37 районыннан, шулай ук Мәскәү, Киров, Марий Эл, Чуашстаннан барлыгы 148 фольклор коллективы, шул исәптән атаклы «Бураново әбиләре» катнашты.

Бәйрәмне 20 мең кеше карады. «Каравон»да Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннехановның котлавын ирештерде.

***

Томск шәһәрендә федераль Сабан туе үтте. Анда ТР Президенты Рөстәм Миннеханов, Томск өлкәсе губернаторы Сергей Жвачкин, ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Ринат Закиров һ.б. катнашты.

***

Волгоград өлкәсенең Малые Чапурники авылында V гомумроссия авыл Сабан туе үткәрелде. Бәйрәмдә Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов кунак булды. Республикабыздан исә анда Нурлат муниципаль районы катнашты.

Бәйрәмдә Татарстан Президенты исеменнән Сабан туеның баш батырына LADA Kalina автомобиле бирү турында игълан ителде.

### ТӨРКИЯДӘН ХӘБӘР

Үткән ел Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатих Кутлу тәрҗемәсендә мәктәп балалары өчен 14 татар язучысының 17 хикәясе урын алган «Филдиши чакы», («Сөяк саплы пәке») исемле китап Төркиядә дөнья күргән иде. Китапны чыгарган «Бәнгү» нәшриятының җитәкчесе Якуп Өмәроглу «Албаннар әлеге китапны ошатканнар һәм үз телләренә тәрҗемә итеп Албаниядә бастыру максатыннан «Бәнгү» нәшриятына мөрәҗәгать иттеләр», — дип хәбәр итте.

### ОЧРАШУЛАР

«Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, бүлек мөхәррирләре Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Айгөл Әхмәтгалиева Арчада, Минзәләдә һәм Чаллыда педагогия көллиятендә укучылар, укытучылар белән очраштылар. Редакция портфелендәге яңа әсәрләр, яшь иҗат көчләрен барлау, киләчәктә журнал битләрендә аларга мәйданны киңрәк бирү, «Казан утлары» игълан иткән конкурслар турында сөйләделәр, әсәрләрен укыдылар.

***

«Казан утлары» журналы баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, бүлек мөхәррире Гөлзадә Бәйрәмова һәм Татарстан Республикасының халык язучысы Рабит Батулла Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре белән очраштылар. Очрашуда сүз әдәбиятның бүгенге хәле, киләчәге, дини темаларның «Казан утлары»нда яктыртылуы, аларның фәлсәфи һәм рухи кыйммәте турында барды.

***

Татарстан Республикасы һәм Марий Эл арасындагы мәдәни бәйләнешләрне ныгытуга зур өлеш керткәне өчен Татарстанның халык шагыйре **Миңнуллин Роберт Мөгаллим улына** «Марий Элның атказанган мәдәният хезмәткәре» исеме бирелде.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татарстан җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде: 2014 елның 1 июнендә 77нче яшендә Татарстанның халык шагыйре, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Республиканың Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе, прозаик, драматург **Рөстәм Гали улы Мингалимов** (Рөстәм Мингалим) вафат булды.

Рөстәм Мингалимов 1937 елның 15 августында Самара өлкәсе, Камышлы районы (хәзерге Келәүле), Йолдыз авылында игенче гаиләсендә дөньяга килгән. Бөгелмә авыл хуҗалыгы училищесын тәмамлагач, 1955-1962 елларда Казакъстанның Күкчәтау өлкәсе, Ташкент, Бөгелмә предприятиеләрендә эшли. 1962-1967 елларда Р.Мингалимов В.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый. Аны тәмамлагач, татар балалар газете «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») редакциясендә әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип, 1975-1977 елларда һәм 1989 елдан 1997 елга кадәр Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант булып эшли. 1977 елдан 1980 елга кадәр Мәскәүдә укый, СССР Язучылар берлеге каршындагы Югары әдәби курсларны һәм Дәүләт театр сәнгате институтында (ГИТИС) театр курсын тәмамлый.

Рөстәм Мингалим - республикада мәгълүм татар шагыйре, прозаик, драматург. Үз әсәрләрендә ул, шәхси кичерешләрен замана коллизияләре, дәвер тудырган конкрет вакыйгаларга бәйләп, тормышның глобаль проблемалары турында фикер йөртә. Р.Мингалим иҗатындагы сурәтләү чаралары системасы шигъри нюанслары, тел байлыгы, метафоралылык, ритм иреге белән аерылып тора.

Р.Мингалимнең «Кайда сез, ирләр?», «Дүрт кешелек утыргыч», «Тау астында илле бүре», «Соңгы чиктә», «Ахырзаман башы» кебек пьесалары замана тамашачысына актуальлеге һәм фәлсәфи тирәнлеге белән кызыклы. 1990 елларда аның драматург Р.Хәмид белән бергә иҗат иткән тарихи драмасы — «Идегәй» сценарие һәм Х.Яһудин белән бергә язган «Ак метеор» киносценарие җәмәгатьчелектә зур яңгыраш ала. Р.Мингалим балалар әдәбияты өлкәсендә дә уңышлы эшли.

1987 елда Рөстәм Мингалимгә «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелә. Татар балалар әдәбияты үсешенә зур өлеш керткәне өчен 1997 елда ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исемендәге әдәби премиясе белән бүләкләнә. Ә 2005 елда «Дәрт чүлмәге» шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы өчен Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек була.

Р.Мингалим хезмәт сөючәнлеге, кешеләргә игелекле мөнәсәбәте, үз эшенә чиксез бирелгәнлеге белән аерылып тора иде. Аның күпкырлы иҗаты татар әдәбиятында лаеклы урынын алды.

Рөстәм Гали улы Мингалимовның якты истәлеге безнең күңелләрдә һәрвакыт сакланыр.

**Р.Миннеханов, М.Шәймиев, Ф.Мөхәммәтшин, И.Халиков, Ә.Сәфәров, А.Сибагатуллин, Р.Корбанов.**

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татарстан җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде: 2014 елның 2 июнендә 88нче яшендә язучы-прозаик, публицист, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе **Миргазиян Юныс** вафат булды.

Миргазиян Мөхәммәтзакир улы Юнысов 1927 елның 25 маенда Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында крестьян гаиләсендә туган. Аның балалык һәм яшьлек еллары авыр сугыш алды һәм сугыш елларында үтә.

1944 елда ул армиягә чакырыла, хәрби-авиация мәктәбендә белем ала. 1950 елда Харьков хәрби-авиация училищесын тәмамлагач, СССР Хәрби-һава көчләрендә хезмәт итә. 1955 елда М.Юнысов Мәскәүнең М.Ломоносов исемендәге дәүләт университетының филология факультетына укырга керә. 1955-1968 һәм 1977-1988 елларда ул Кара диңгез һәм Азов диңгезе пароходчылыгында төрле вазифалар башкара, 1968-1977 елларда диңгез транспорты фәнни-тикшеренү институтында, СССР Диңгез флоты министрлыгында, «Наука и религия» журналы редакциясендә эшли. 90нчы елларда М.Юнысов Әлмәт һәм Казан шәһәрләрендә, ә 2005 елдан Мәскәүдә яши һәм хезмәт куя.

М.Юныс — әдәбиятка бай тормыш тәҗрибәсен туплап килгән каләм осталарының берсе. Аның әсәрләре татар прозасын тормышның мәгънәсе турындагы фәлсәфи уйланулар белән баетты, дөнья халыкларының милли характерлар төрлелеге белән таныштырды. Әдипнең «Тозлы җил», «Теләп алган давыл», «Таңда Босфор аша» повестьлары, «Шәмдәлләрдә генә утлар яна» хикәясе, «Юлда уйланулар» трилогиясе татар әдәбиятын сөючеләр тарафыннан җылы кабул ителде. Соңгы елларда М.Юныс публицистика, эссеистика һәм әдәби тәнкыйть жанрларында эшләвен дәвам иттерде.

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткәнe өчен 1998 елда М.Юныска С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия бирелде. 2004 елда «Альбатрос язмышы» исемле публицистик мәкаләләр җыентыгы өчен ул Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Миргазиян Юнысның кабатланмас иҗаты татар әдәбияты тарихында, аның турында якты хатирә безнең йөрәкләрдә һәрвакыт сакланыр.

**Р.Миннеханов, М.Шәймиев, Ф.Мөхәммәтшин,И.Халиков, Ә.Сәфәров, А.Сибагатуллин, А.Хәбибуллин, Р.Корбанов.**

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: А.МУТАЛЛАПОВ. Роман «Испытание»; З.ХУСНИЯР. Роман «Ураган» (прод.); стихи Г.МУРАТА, Ф.МУСЛИМОВОЙ, Ч.МУСИНА.
«Конкурс на повесть малого формата»: Р.ЗАРИПОВ. «Румянец лица милиции».
«История»: И.ГИЛЯЗОВ. «Мусульманские пленные в Германии в Первой Мировой войне».
«Мнение»: Ф.ХАННАНОВА. «Общие проблемы разных эпох».
«Память»: Р.МИРХАЙДАРОВ. Мемуары «Вот и всё... Я пишу вам с вокзала».
«Искусство»: статья Г.САГИТОВОЙ, посвященная к 75-летию первой татарской оперы.
«Жизнь и религия»: БАТУЛЛА. «Суть».
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: повесть А.НУРГАТИНОЙ; стихи Д.НАГИМУЛЛИНОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Белая мечеть, расположенная в музее-заповеднике Булгар;
V Всероссийский форум национальных и региональных СМИ. 19-21 июнь, 2014 год.
*Фотографии Г.САГИЕВОЙ.*

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: A.MUTALLAPOV. Novel «Experience»; Z.HUSNIYAR. Novel «Hurricane» (cont.); poems by G.MURAT, F.MUSLIMOVA, CH.MUSIN.
«Competition for a small-format novel»: R. Zaripov. «Blush of police face».
«History» I.GILYAZOV. «Muslim captives in Germany in the First World War».
«Opinion»: F.HANNANOVA. «Common problems of different eras».
«Memory»: R.MIRHAYDAROV. «That's all ... I'm writing to you from the station».
«Art»: article by G.SAGITOVA devoted to the 75th anniversary of the first Tatar opera.
«Religion and life»: BATULLA. «Essence».
Pages from «Tatar Encyclopedia».
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
«White Sail» novel by A.NURGATINA; poems by D.NAGIMULLINA.
From photo archive of the magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: White Mosque located in the Historic Area of Bulgar;
5th All-Russian forum of national and regional media. June 19-21, 2014.
Photos by G.SAGIEVA.

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Болгар музей-тыюлыгында урнашкан Ак мәчет.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* V Бөтенроссия төбәк һәм милли гаммәви мәгълүмат чаралары форумында катнашучылар. 19-21 июнь, 2014 ел. *Г.Сагиева фотолары.*

# Яңа китаплар




**Разиль Валеев.**
**СУДЬБУ ЛИСТАЯ НЕ СПЕША...**
*– Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. – 512 б. Тиражы – 3000 данә.*

Разил Вәлиев — озаклап күздән кичерерлек язмышка ия зат. Исмәгыйль атлы, авылда колхозга кермичә гомер итә алган үтә тәвәккәл шәхеснең малае ул. Тәвәккәллек Разилнең үзенә дә хас. 1968 елны Татарстан язучылары съездында Камал театры балконыннан, яшьләр журналы чыгаруны таләп итеп, кыю листовкалар ыргытуны оештырган һәм үзе дә ыргыткан, инде 1979 елда ук авыл мәчетенә манара куйдыра алган кеше ул.
Бу китапка Р.Вәлиевнең шигырьләре, бәяннары, хатирәләре, публицистик әсәрләре, чыгышлары һәм әңгәмәләре кертелгән.




**Булат Хамидуллин, Лилия Мухаммадеева.**
**ГАЗИ ЗАГИТОВ, ГРИГОРИЙ БУЛАТОВ.**
*– Казан: Татар.кит.нәшр., 2013. — 88 б. Тиражы — 2000 данә.*

Китап Бөек Ватан сугышына бәйле кайбер вакыйгаларны, Җиңү көне якынлашкан мизгелләрдә милләттәшләребез кылган батырлыкларны тасвирлауга багышлана. Гази Заһитов белән Григорий Булатов — Берлин шәһәре үзәгендәге Рейхстаг бинасына беренчеләрдән булып Җиңү байрагын элгән батырлар. Бу китапта шул гамәлне кылырга әмер биргән командирларның һәм әлеге вакыйгаларда катнашкан сугышчыларның истәлекләре дә, беренче булып байрак кадаучы батырларны орденнар белән бүләкләү өчен дип тутырылган кайбер документларның күчермәләре дә китерелә. Китап Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 70 ел тулуга багышлап чыгарыла.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2014
МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)